КАЗАН УТЛАРЫ

www.kazanutlary.ru

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Публицистик шигырьләр. ....3
Солтан ШӘМСИ. Кендек каным тамган йорт... *Бәян*. ....8
Шаһинур МОСТАФИН. Үлемсезлек җыры өзелмәс. *Шигырьләр*. ....51
Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА. Ак читек. *Бәян*. ....55
Гөлзадә БӘЙРӘМОВА. Моң ул бездә тумыштан. *Шигырьләр*. ....93
Лилия ГАЗИЗОВА. Сөенүләрен телим. *Шигырьләр*. ....104

«ИҢ ШӘП ХИКӘЯ» КОНКУРСЫНА

Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА. Кирлемән. *Хикәя*. ....97

*100нче бит:* Марсель ГАЛИЕВ. Нинди язмышка дучар без? ....100

ФӘНИС ЯРУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Рәдиф ГАТАШ. Халыкның сөекле шагыйре. ....108
Фәнис ЯРУЛЛИН. Анам теле – телләр теле. *Шигырьләр*. ....109
Сәвия ХӘКИМОВА. Әдип иҗатына бер караш. ....113
Динара МИННЕКАЕВА. Фәнис Яруллин драматургиясендә әхлак тәрбиясе. ....121
Нурислам ХӘБИПОВ. Яшәүгә мәдхия тудырган шәхес. ....126

*Әдипнең тәүге китабыннан:* Рамил ХАННАНОВ. Алты тиенлек шатлык. ....129
Фәнис ЯРУЛЛИН. Ана чәчәкләр китерә. *Хикәя*. ....131

*Газизә Сәмитованың тууына 155 ел:* Ркаил ЗӘЙДУЛЛА. Милләт Газизәсе. ....136

*Гаяз Исхакыйның тууына 140 ел:* Илдус ФАЗЛЕТДИНОВ. Исхакыйның геройлар эволюциясе. ....140

*Фатих Хөснинең тууына 110 ел:* Илдус ДИНДАРОВ. Бер көрешү. ....144

ЮБИЛЕЙЛАР

Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА. Сүзе хакның – йөзе ак *(Хуҗиәхмәт Мәхмүтовка 85 яшь)*. ....147
Вахит ИМАМОВ. Рәхмәтле каләмдәшем *(Шаһинур Мостафинга 70 яшь)*. ....150
Рәниф ШӘРИПОВ. Шигырьләре – гомер мизгелләре. ....153

*Китап күзәтү:* Тәлгат ГАЛИУЛЛИН. Тапкырлыкта – матурлык. ....157

*Табигать һәм мин:* Айдар ГАРИПОВ. Атларның да тугры җаны бар. ....163

*Котлыйбыз:* Рабит БАТУЛЛА. Локман Закирга 90 яшь. ....166

*Истәлекләр:* Габдулла ГАЛИЕВ. Кырынды авылы тарихыннан сәхифәләр. ....167

*Безнең календарь* (Гөлчәчәк Галиева, Гакыйль Сәгыйрев). ....185

*Куен дәфтәреннән:* Рәшит МИНҺАҖ. Ышанычлы иләк. ....187

*Шаян сәхифә:* Уены-чыны бергә. Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде. ....188

«Казан утлары» архивыннан. ....134
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

Гамәлгә куючы –
«Татмедиа»
акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР –*

**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Зиннур Мансуров**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Данил Салихов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Илсур Һадиуллин**
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**

*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Люция Сөләйманова** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266).*
◑: **Факс** – (843) *222-09-83 (өст.1612).*

💻: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.


---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 31.01.2018, график буенча 31.01.2018.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ Е-218. Тираж 4200.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2018 ел



Равил
Фәйзуллин

# ПУБЛИЦИСТИК ШИГЫРЬЛӘР

## Без әйтмәсәк...

Җиңел түгел дөрес сүз әйтү.
Җиңел түгел яңа сүз әйтү –
күңел офыкларын киңәйтү.
Ә әйтергә кирәк!
Без әйтмәсәк аны, кем әйтер?

Яшь чакларда яздык: «Җан ваклыгын
сылтама син, диеп, заманга!»
Күпме еллар үтте. Ә сызлаулар
һич тә кимемәгән һаман да...

Яшиселәр килә һәркемнең дә.
Гомер бирелгән бит бер генә!
Һәммә кеше лаек үз бәхетенә
тамырланган Туган илендә.

Кимеп барган чакта милли үзаң,
азайганда чын милли җырлар,
«Без үсәбез! Алга барабыз!» – дип,
калкып чыга миллиардерлар!

Туып тора төрле фиркә-миркә,
ява вәгъдәләр яңгыры!
Ә кайда соң матур нәтиҗәләр?
Кайда гамәл?.. Анасын алгыры!

Ни мәгънә даның-дәрәҗәңнән,
туган нигезең, тамырың югалса?
Таш-асфальтта иген үсмәгәнне
яхшы беләбез бит ләбаса!

---

Равил ФӘЙЗУЛЛИН (1943) – *Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Алты томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

Ни мәгънә иркен мәктәбеңнән,
укытырга бала булмаса?
Ни мәгънә җыйган байлыгыңнан,
күңелеңдә иман булмаса?
Ни мәгънә шигырь язуыңнан,
әгәр аны кем дә укымаса?
Ипи кисәгенә ымсынып,
каләмеңнән рәнҗеш-моң тамса?
Ни мәгънә чит тел белүеңнән,
ата-баба телен югалтсаң?
Болай таркау булсак, берләшмәсәк,
инкыйраз ул беркөн булачак...

...Әй, сез, байлар! Угры хакимнәр!
Сез дә бит бу Җирнең баласы!
Сез яхшы беләсез. Дөньяда
нәрсәне бирәсе-аласын...
Мал, алтын дигәндә, ике дә уйламый,
Җир-Ана карынын тишәсез...
Байыйсыз ч-е-р-е-п, белеп тә
юклыгын кәфеннең кесәсе!..

Онытмыйча бакыйлык турында,
булганына шөкер итегез!
Фәкыйрьләргә өлеш чыгарыгыз!
Ятимнәрнең яшен сөртегез!
Ходай каршында аз булса да
ачык булыр йөзегез-битегез.

Эзсез калмый ачы сызланулар,
халык күңелендәге борчулар.
Ачу-нәфрәтне яшереп булмый.
Тулышкач ул, барыбер бер чыга!

Җиңел түгел дөрес сүз әйтү.
Ә әйтергә кирәк!
Без әйтмәсәк,
аны кем әйтер?

## Сискәнеп уяну

*Ник тыныч түгел бу күңел?*
*Ник тыныч түгел бу җан?..*
*Көч бир Син миңа, мадәт бир!*
*И, Аллам – Бөек хуҗам!*

Балаларым исән. Үзем дә сау.
Йорт-җирем бар. Кул астында
чәчәк утыртырлык биләмәм...

Бурыч-кредитым юк шикелле.
Керемнәргә салым түләнгән...
Тыныч кына, тәмле төшләр күреп
йокларга мин хаклы түгелме?

Юк шул!..

Еш кына шом баса күңелне:
югалтып барам бит телемне!
Югалтып барам бит илемне!..
Иң изге мирасны югалтсак,
кардәшем, булабыз кем инде?

Төннәрен сискәнеп уянам.
Сагышлы уйларга уралам...
Сизәмен үземне таңнарда
баласын урлаткан анадай...

***P.S.***
*Әй, укучым!*
*Ялгыш җәлли күрмә!*
*Бу әрнүләр, бәргәләнүләр*
*юкка түгел! Язмыш киләчәктә*
*әҗерен аның әле бер түләр!*
*Чигенәбездер... әмма уянабыз*
*күтәрелер өчен яңадан!*
*Әгәр тамырларны корытмасак,*
*өстәлмичә калмас яңа кан.*
*Мин ышанам: халкым тарихына*
*язылачак әле яңа дан!*

## Нишләп?

Закон посып чатта
тора ирен тешләп.

Хуҗа булып йөри
түш киереп Ришвәт.

Күпләр башын чайкый:
«Йөрсәк тә без эшләп,
булмый берни эшләп!..»

Нишләп?

## Мәхлуклар

Сөембикә манарасы
авышканмы?
Авышкан!
Нигә безгә авышмаска?
Югарыдан кушылганны
сайлыйк бертавыштан!

Тел ул нәрсә? Баш саклансын!
Кирәк икән –
сал ыштан...

Мандатларны өскә чөеп,
раслыйк бертавыштан!

...Мәхрүм калма табыштан!
«Халкым!» дигән бул тыштан!..

## Ни чара?

Тагын көннәр озыная!..
Язга таба барабыз.
Сукмаклар яктырган саен,
тоныклана арабыз...

Яктылык күбәйгән саен,
җанга караңгы иңә.
Әйтерсең, мин күчеп йөрим
ак өйдән кара өйгә.

Каеннарның кәүсәсенә
сут йөгерер чак килә!
Парны күрәсем килсә дә,
санаганым так килә...

Төннәр җылыга барса да,
суына безнең ара...
Көннәр озая барса да,
гомер кыскара бара...

Ни чара?

## Күчү алды

*Г.Р. гә*

Эшләмәс инде ул Вакыт
карт-коры файдасына...
Сыгылып, чигенә җиткәч,
корыч та шартлап сына.

Тормыш яме кими, дисең.
Табигый хәл, борчылма!
Ышанып яшик сабыйларча
әкият-өметләребезнең
тормышка ашасына.

Тик... һәр мизгел әзер булыйк
«Яшәү»нең яңасына.

## Карт залим

Ояты качкан...

Качар да шул, ничек түзсен
бу гөнаһлы бәндәне!
Ничек аны моңа кадәр
Җир йотмаган ди әле!..

Барсы качкан: намусы да,
хәтере дә, аңы да...
Сыек тәндә калган бары –
нәҗес белән кан гына,
чыга алмаган җан гына.

## Коллык

Башың иеп, Җиргә кара!
Җирдә анда алтын ята!
Күккә бакма! Ай-йолдызлар
алар акыл чуалта!..
Кулыңнан төшмәсен бер дә
көрәк, кувалда, балта...

Эшлә син! Башың күтәрмә!
Баш күтәрсәң, эш яман!
Баш күтәргән кавемнәрне
аса, кисәләр һаман...

Баш күтәрмә, таш күтәр!..

* * *

*Таң-Шәфәкъ – бер бөтен.*

Иртәгә нәрсә буласын
ярый белмибез әле!
Олы өметләр белән
яшәп йөрибез әле!..

Яхшымы бу? Гаделме бу?
Әйтә алмас беркем дә!
Таңда кичке шәфәкъ төсен
күрер пәйгамбәр генә.

* * *

*Башың эшли, акылың юк.*
Әнием сүзе.

Була акыл иясе.
Була гыйлем иясе.
Икесенә дә ия булса,
аны даһи диясе!

...Тик кызганыч, кем булсаң да,
буласы гүр иясе.

* * *


Үткән бөеклек турында
сөйлибез кызып-кызып!
Безне аңлыймы яңа буын?
Бармы тоташыр сызык?
Төгәл җавап таба алмыйча,
гомерләр бара узып...

...Күрәмсең, Адәм затына
иртәгесе ачык булган
бүгенге генә кызык.

* * *

Йөрәгемдә таулар тамырланган.
Манарадай баскан кыялар!..
Хакыйкатькә күңелең ачык булса,
горур җанга бар да сыя ала.

Ялагайдай иелә алмыйм мин.
Ярамый да!
Ишелерләр юкса тауларым.
Кыя-хыялларым ауса әгәр,
ни кызыгы калыр дөньяның?



Солтан
Шәмси

# КЕНДЕК КАНЫМ ТАМГАН ЙОРТ...

БӘЯН

Гафур урта мәктәпне тәмамлаганнан соң авылда калды, институтка керергә документларын биреп, имтиханга бармады. Укытучы әнисе Суфия ханым бу хакта улы белән сөйләшеп карады, тик, Гафур әле үзенең кайда укыйсы килүен, кем булырга теләвен ачык кына белмәвен, шуңа күрә теләсә кая кереп укырга теләмәвен әйткәч, башка бу хакта сүз кузгатмады. Әнисе аны аңлады. Гафур белән мәктәп тәмамлаучыларның берничәсе генә укырга керә алды. Күбесе кире авылга әйләнеп кайтты. Ә кайберләре, ничектер җаен табып, авылга кайтасылары килмичә, Казанда эшкә урнашты.

Гафур исә, армиягә киткәнче  колхозда комбайнчы ярдәмчесе булып эшләде. Аннан аны армиягә алдылар. Ерак Байкал күле буена, Бурятиянең башкаласы Улан-Удэ шәһәренә, каладан ерак тормаган бер частькә китереп урнаштырдылар.

Авылда эш белән чыныгып үскән Гафурга армия тәртипләренә күнегү кыен булмады. Ул физик яктан көчле, киң җилкәле, көдрә чәчле, уртачадан бераз калкурак буйлы чибәр генә егет иде. Дөрес, беренче айда аларны хәрби частькә чыгармыйча, ябык карантинда тоттылар. Казарма да, уку бүлмәләре дә шул бер катлы, түбәсе шифер белән ябылган аерым бинада иде. Илнең төрле ягыннан җыелган, төрле милләттән булган, бик тә чуар егетләрне, армия тәртипләренә өйрәттеләр, хәрби уставны ятлаттылар. Көннең беренче яртысы уку белән үтсә, төштән соң – табаннары тәмам кызганчы казарма янындагы плацта строй белән йөрү иде. Кыскасы, бер ай эчендә чын солдат булып өлгереп, төрле роталарга таратылырга, хезмәт итә башларга тиешләр иде.

Хезмәт итәсе җирләренә бер капитан озата барды. Шулай килеп чыкты ки, юлда Гафурның урыны шул капитан белән бергә туры килде. Поездда, бөтен илне кичеп дигәндәй, дүрт тәүлек буе күп нәрсәләр турында сөйләштеләр. Сәер хәл, әллә инде капитан Гафурны ошатып өлгергән һәм, килеп җиткәч, аның турында

---

Солтан ШӘМСИ (1946) – *прозаик, тәрҗемәче; «Еллар эзе», «Идел Болгарстаны», «Низаглы йортта», «Күк капусы ачылса» һ.б. китаплар авторы. Ф.Хөсни, А.Алиш исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

уңай фикер әйткән. Әмма карантиннан соң егетне хезмәт итәргә частьнең штабына билгеләделәр. Алай гынамы соң, штабның да секретный бүлегендә хезмәт итәчәк иде ул. Хезмәт итәчәк дип әйтүнең дә бер сере бар – башта махсус органнардан рөхсәт килергә тиеш икән, шуннан соң гына әлеге бүлеккә кертәчәкләр. Өч ай буе бөтен нәсел-нәсәбен энә күзеннән үткәреп, бернинди шикле нәрсә табылмаса гына... Гафур әлеге бүлектә хезмәтен башлап җибәрде.

Кызыклы урын иде бу секретный бүлек дигәннәре. Гафур өчен өр-яңа дөнья. Моңарчы анда ике егет хезмәт иткән. Берсе – сыек гәүдәле Мәскәү егете, икенчесе – Украинаның Харьков каласыннан. Ул өлкән сержант дәрәҗәсендә булып, бүлектә өлкән санала, инде берничә айдан өенә кайтып китәргә җыена икән. Бер сүз белән әйткәндә – дембель. Ул каяндыр гантельләр, ике потлы гер юнәтеп, гел бүлектә тота, буш вакытларында шөгыльләнеп, мускулларын ныгыта, армиядән көчле спортсмен булып кайтып китәргә җыена. Мәскәү егете гергә якын килми, сирәк-мирәк гантельләр белән берничә күнекмә ясый да кире урынына куя. Аның фортепианода уйнап үскән нечкә аристократ бармаклары бу шөгыльгә яраклашмаган, ул бары тик хохол егете алдында бераз абруен саклау өчен генә гантельләргә тотынгалый иде. Ә менә Гафурга килгәндә, ул беренче көннән үк ике потлы герне баш өстенә чөеп, хохол егетенең хөрмәтен яулады. Авылда даими печән чабулар, утын ярулар, гомумән, авыл тормышының санап бетергесез эше Гафурны ныгыткан, чыныктырган иде. Алар монда бик ярап куйды.

Гафур хезмәт иткән хәрби часть СССРның ЦУКОС (Центральное Управление Космических Средств) системасына карый. Алар эшләгән бүлектә шушы өлкәгә нисбәтле техник документлар, «сов. секретно» грифы сугылган китаплар, төрле таблицалар белән тулган кулланмалар, Хәрби округтан көн аралаш килеп торган яшерен приказлар, шуның ише башка документлар тупланган иде. Яңа килгән документларны секретчик егетләр махсус журналга теркәп бара, аларга керү номеры сугып, реестер дип аталган махсус кәгазьгә исемнәрен күчереп яза, аннан часть командирына тапшыра.

Монда кызыклы документлар күп. Хәтта космонавтларның шушы часть өстеннән очып үткәндә нинди сөйләшү алып барганнарына тиклем бар иде. Әлбәттә, ул документларның төп нөсхәсе Мәскәүгә озатыла, биредә исә аларның күчермәсе генә кала. Ә бу сөйләшүләрне Гафур хезмәт иткән частьтәге махсус станцияләр язып ала.

Менә шундый кызыклы урында хезмәт итәргә туры килде Гафурга. Биредә күп нәрсәгә күзе ачылды, күңел офыклары гаять киңәйде. Авылда үскән егет өчен бу бик файдалы һәм гыйбрәтле тормыш иде. Ул армиядә хезмәт итүенә бер дә үкенми, биредә гомер әрәм үтә дип борчылмый иде.

Билгеле инде, армиянең язылмаган кануны буенча, иң авыр, интектергеч эшләре беренче ел хезмәт итүче яшь солдатлар – «салагалар» өстенә төшә. Өченче ел хезмәт итүчеләр, (ә Гафур солдатка өч елга алынган иде), үзләрен «дембель» саныйлар һәм иң авыр вазифаларны яшь солдатлар өстенә салыналар. Монда карышып маташудан файда юк, моны бернинди боерык белән дә үзгәртеп булмый. Шушы канун нигезендә яшь солдат Гафур Нигъмәтуллинга бүлектә төннәрен дә дежур торырга туры килә иде.

Частьта антенналары махсус ярымшар эченә яшерелгән күзәтү алып бару станцияләре көнен-төнен бертуктаусыз эшли. Станцияләрдә сменалап хезмәт итүче офицерлар эшкә барганда махсус әдәбият, таблицалар белән тулган китаплар алу өчен штабка киләләр, кул куеп кирәкле әсбапларны алалар, кечкенә

чемоданнарына салып, эшкә китәләр. Көндезләрен, секретчик егетләрнең барысы да үз урынында булганда, бу бернинди кыенлык тудырмый, гадәти эш санала. Ләкин станцияләр бит эшне төнлә дә дәвам итә. Төннең теләсә нинди сәгатендә эшкә барырга чыккан офицер штабка сугыла, үз чемоданын алу өчен шушы бүлеккә керә. Төннең теләсә нинди сәгатендә секретчик аңа хезмәт күрсәтергә тиеш. Бу шулай куелган, офицер эшкә соңга кала алмый.

Әмма шунысы бар: секретчик төнлә бүлектә берүзе калырга тиеш түгел. Бу – катгый таләп. Секретчик үз ротасында йокларга тиеш. Эшкә баручы офицер штабка килүгә ротага шалтыратып, секретчикны чакырып ала, чемоданын алгач, станциясенә юнәлә.

Беренче елны, яшь солдат буларак, төнге дежур тору вазифасы гел Гафурга йөкләнде. Бүлектәге егетләр төнне рәхәтләнеп йоклап үткәрәләр иде. Гафурның хәленә керергә теләмәделәр. Йоклап киттем дигәндә генә, берәрсе шалтырата да, Гафурга, күзләрен тырнап ачып дигәндәй, штабка йөгерергә туры килә. Бу хәл төнгә берничә тапкыр кабатлана. Ярый ла көндез бераз йоклап алырга ирек бирсәләр, анысы да гел тәтеми иде шул Гафурга.

Гафур, йокы күрмичә, беренче елны бик нык ябыкты, нервлары да нык какшады. Көннәрдән бер көнне, штаб начальнигы подполковник Горохов, аның арган, суырылган йөзенә игътибар итеп: «Нигматуллин, син авырыйсыңмы әллә? Чыраең бик начарайган», – дип кызыксынды.

Әмма Гафур серне ачып салмады: «Юк, авырмыйм, иптәш подполковник», – дип җавап бирде дә йөзенә елмаю галәмәте чыгарган булды.

Тик һаман болай дәвам итә алмый иде. Гафур, үз хәлен җиңеләйтү өчен, нинди дә булса чара күрергә, көтелмәгән адым ясарга тиеш иде. Әмма нинди? Мәсьәлә менә шуңа килеп төртелде. Бу хакта Гафур күп уйланды һәм ике генә юлны күрде ул. Беренчесе – тавыш күтәрү, үз хәлен аңлатып, бүлек мөдире өлкән лейтенант бурят Цыденжапов белән ачыктан-ачык сөйләшү. Ул да мәсьәләне хәл итмәсә, штаб начальнигы подполковник Гороховка мөрәҗәгать итү, барысын да аңлатып бирү иде. Әмма, тавыш чыгарып, мәсьәләне уңай хәл иткән очракта да, аңа штабта калырга, шул ук егетләр белән эшне дәвам итәргә туры киләчәк. Мөнәсәбәтләр тәмам бозылачак. Секретный бүлек кебек җаваплы җирдә хезмәтне бер-береңә тулысынча ышанып алып бару кирәк. Мондый җирдә дошманлык бик хәтәр нәрсә. «Очраклы» рәвештә генә берәр документ югалып куйса, Алла сакласын, хезмәтеңне тәмамлап өлгергәнче төрмәгә дә кереп утыруың бар. Димәк, ниндидер икенче – йомшаграк юлны эзләргә кирәк һәм ул юл аның штабта калуына чик куярга тиеш.

Күп уйлана торгач, Гафур, шактый хәтәр булса да, әмәлен тапты шикелле. Ул бит көн саен иртә белән, яңа килгән документларны часть командирына тапшыра, аңардан реестрга кул куйдырып ала. Бу эш өлкәннәр тарафыннан Гафурга йөкләнгән иде. Әгәр дә ул – секретчик Гафур Нигъмәтуллин, беркөнне часть командиры танышкан документларны алырга кергәч, реестр буенча кабул итеп, «ялгыш» кына берсен командир өстәлендә онытып калдырса? Әлбәттә, бик хәтәр эш. Командирның онытып калдырылган ул документка игътибар итмәве дә бар. Аннан соң документның, өстәлдә яткан башка кәгазьләргә ияреп, бүтән папка эченә кереп яшеренүе дә бик ихтимал. Әйе, бик хәтәр эш. Ләкин Гафур тәвәккәлләргә булды. Часть командиры җирән чәчле, зур итләч борынлы, олы башлы, кызыл йөзле немец – бик игътибарлы, үтә пунктуаль, пөхтә адәм иде. Гафур ышана, ул «онытылып» калган документка тиз игътибар итәчәк һәм шул сәбәпле эшнең зурга китүе дә мөмкин әле...

Гафур, беркөнне, документларны алырга кергәндә, ни булса шул булыр дип, берсен «ялгыш кына» өстәлдә онытып калдырды. Аннан командирның реакциясен көтә башлады. Бер көн үтте, ике көн үтте, бүлек мөдире Цыденжапов та, авызына су капкандай, бер сүз әйтми.

Өченче көнне аны часть командиры кабинетына чакырып алдылар. Анда зәп-зәңгәр күзле, киң маңгайлы, ак чырайлы штаб начальнигы Горохов та утыра иде. Күрәсең, ике көн буе алар арасында сүзләр булган һәм менә бүген Гафурны каршыга бастырып сөйләшү өчен чакыруларыдыр.

Сүзне часть командиры башлады:

– Нигматуллин, син секретный частьта күпме эшлисең?

– Ун ай, иптәш полковник!

– Димәк, син анда эшләү тәртипләрен яхшы беләсең?

– Әйе, иптәш полковник!

– Секретный документны югалткан өчен сине нәрсә көткәнен беләсең, димәк.

– Иптәш полковник, мин бернинди дә документ югалтмадым...

– Югалттың шул, Нигматуллин. Югалттың!

– Ничек? Бу мөмкин түгел...

– Мөмкин икән шул, Нигматуллин.

– Мин аңламыйм, иптәш полковник... Кайчан югалттым, нинди документны? – дигән булды егет.

– Минем өстәлдә онытып калдыру югалту түгелмени? Син бит аны реестр буенча кабул иттең... – Часть командиры Хәрби округтан килгән документны күтәреп күрсәтте. – Син аңлыйсыңмы, бу бит җинаять эше. Әгәр дә мин аны күреп алмасам, ул башка кәгазьләр арасына кереп китсә, сине бит судка бирәләр иде.

Кабинетта тынлык урнашты. Часть командирының сүзләренә каршы Гафур бер сүз дә кайтарып әйтә алмады. Бары тик башында: «Югалмаган, Аллага шөкер!» – дигән фикер генә елтырап узды.

Тынлыкны подполковник Горохов бозды:

– Нигматуллин, аңлатып бир әле безгә, ничек шулай килеп чыкты? Син ничек, секретчик буларак, шундый документны онытып калдыруга кадәр барып җиттең?

Часть командиры дәшми генә Гафурга төбәлеп утыра, ул да аннан җавап көтә иде.

– Иптәш подполковник, соңгы вакытта минем нигәдер зиһенем таркаулана башлады. Әйберне кая куйганымны онытам.

– Бу күптән шулаймы?

– Өч айлап бар инде...

– Моннан соң секретный бүлектә эшли алырсыңмы?

– Әйтә алмыйм, иптәш подполковник. Тагын берәр нәрсәне онытып калдырудан куркам.

Часть командиры белән штаб начальнигы бер-берсенә мәгънәле караш ташлап алдылар. Бу күп нәрсә турында сөйли иде. Аларның карашында Гафурга карата шик чагылып узды. Ә Гафурга нәкъ менә шушы нәрсә кирәк иде.

Часть командиры Гафурның күзләренә карап:

– Димәк, онытып калдырмам дип гарантия бирә алмыйсың?

Бу – сөйләшү барышындагы төп сорау иде һәм Гафур хәзер үзен корган

планы барып чыгарлык итеп тотарга тиеш иде. Ул икеләнмичә җавап бирергә үзендә көч тапты:

– Юк, иптәш полковник, гарантия бирә алмыйм. Нигәдер зиһенем таркауланды...

– Ярый, башка без сине тоткарламыйбыз.

Шушы сүзләрдән соң Гафур, кырт борылып, кабинеттан чыгып китте. Ул сөенеп куйды, төп сүзне курыкмыйча әйтә алды бит. Бу аның штаб коллыгыннан котылуы иде. Күп тә үтмәс, аны башка эшкә күчерерләр. Секретный документ югалта язган солдатны бүлектә озак тотмаячаклар. Кемнең үз өстенә андый җаваплылыкны аласы килсен. Ул бит кистереп әйтте: «Гарантия бирә алмыйм...» – диде.

Октябрь бәйрәме якынлашып килә иде. Кичен частьның зур клубында тантаналы җыелыш булды. Кичәнең рәсми өлешендә докладлар сөйләнде, аннан соң бәйрәм уңаеннан частьта хезмәт итүчеләргә төрле дәрәҗәләр (званиеләр) бирү мәрәсиме, соңыннан үзешчәннәр концерты булды. Шул исәптән, моңарчы рядовой булып йөргән Гафурга да ефрейтор дәрәҗәсе бирделәр. Моннан соң аның яшел погонында бер кызыл тасма булачак.

Бәйрәмнән соң Гафурны комендант взводына күчерделәр. Гафур моңа бик сөенде, чөнки комендант взводында хезмәт итүчеләр частька керә торган КППда (контрольно-пропускной пункт) график буенча дежур торалар. Аларның шуннан башка вазифалары юк. Иң кадерлесе: анда буш вакыт күп, сине төне буе йоклатмыйча штабка чакырып изаламаячаклар. Гафур өчен бөтенләй яңа тормыш башланды. Ә буш вакытны ул әрәм-шәрәм итмәячәк, аның әле тагын ике ел хезмәт итәсе бар. Шушы вакыт эчендә ул частьның бай китапханәсенә йөриячәк. Аның бик тә, китаплар дөньясына чумып, белемен арттырасы килә. Ул үзендә шундый ихтыяҗ тоя, рухы шуны таләп итә. Бу китапханәне мәктәп, авыл китапханәләре белән чагыштырырлык та түгел. Гафур хезмәт иткән җирдә, космос белән бәйле мәсьәләләр хәл ителгәнгә, монда хезмәт итүчеләр дә нигездә интеллигент хәрбиләрдән тора иде. Шул сәбәпле булса кирәк, китапханә дә гаҗәеп бай. Ерак Бурятиядәге бу частька ул кадәр китапны каян туплап бетергәннәрдер, шаккатмалы. Күрәсең, үзәктән, Мәскәүдән китерткәннәрдер, башкача булмас. Китапханәгә рус телендәге әдәби журналларның күбесе ай саен килеп тора. Почта бүлегендә хезмәт итүче бер таныш егетнең әйтүенчә, офицерларның күбесе журналларны өйләренә дә яздырып ала икән. Чыннан да, частьта зыялы, тәртипле, рухи ихтыяҗлары гаять зәвыклы офицерлар хезмәт итә. Бу нәрсә аларның солдатларга карата мөнәсәбәтләрендә дә бик ачык чагыла иде.

Шулай итеп, Гафур комендант взводында хезмәт итә башлады. Алар график буенча көнен-төнен дежур торалар, икенче пост станциянең капка төбендә урнашкан. Көндезләрен КПП аша халык күп йөри, часть тышындагы өч катлы берничә йортта офицерларның гаиләләре яши. Офицерларның хатыннары да төрле җирләрдә эшли. Ә менә төнлә дежур торулары бик тыныч. Берәр китап аласың да төне буе укып утырасың. Гафур мондый җиргә эләгүенә бик шат иде.

Взвод командиры озын торыклы, какча гәүдәле Рязань егете сержант Карпов, хезмәт вакытын тутырып, тиздән өенә кайтып китәргә җыена иде. Егетләр арасында аның урынына кемне куярлар икән дигән сүзләр йөри. Ике ай да үтмәде, кайтып китәр вакыты килеп җитте. Сержантны өенә зурлап озаттылар. Ул китәсе көнне комендант взводын штаб каршына тезделәр, командир үзе чыгып, кыска гына нотык сөйләде, күкрәгенә барлык значокларын таккан

Карповка яхшы хезмәт иткәне өчен рәхмәтен белдерде. Аны башкаларга үрнәк итеп куйды.

Карповны озатканның икенче көнендә Гафур өчен көтелмәгән вакыйга булып алды. Часть командиры приказы белән аны комендант взводы командиры итеп билгеләделәр, бер үк вакытта кече сержант дәрәҗәсе бирделәр. Ни өчен сайлаганнарын Гафур үзе дә аңламады. Бәлки штабта эшләүнең файдасы тигәндер, бәлки тырыш, тәртипле булуын исәпкә алганнардыр. Кыскасы, бу хәл Гафур өчен сер булып калды. Бер сүз белән әйткәндә, ул хәзер взвод белән идарә итә, үзенә буйсынган солдатларның тәртибе өчен җавап бирә. Әр төрле мәсьәләләрне штабтагы майор Косенко белән киңәшеп хәл итә.

Взвод командиры итеп куелу Гафурга яңа мөмкинлекләр ачты. Иң мөһиме – хәзер буш вакыты барлыкка килде. Ул бу хакта күптән хыяллана иде. Аның күптән рәхәтләнеп китапханәдә утырасы килә иде. Менә инде хәзер китапханә залында «Новый мир», «Знамя», «Юность», «Наука и жизнь», «Иностранная литература» журналларын караштырып, «Литературная газета»ны укып утырырга вакыты бар. Бу газета ил күләмендәге бик кискен мәсьәләләрне күтәреп чыга, аларны укыган Гафурның карашлары тирәнәя, киңәя бара иде. Газетаның чын мәгънәсендә интеллигенция ябырылып укый торган басмага әверелүен Гафур бик ачык күрде. Чит ил язучыларыннан Джек Лондон, Эрнест Хемингуэй, француз язучысы Экзюпери әсәрләрен ул бик яратып укыды. Китапханәдә рус һәм совет әдәбияты, чит ил әдәбияты классиклары томнары белән шүрлекләр тулган иде. Өстәвенә, китапханәче ханым, теләгән китапны сайлап алырга рөхсәт итә, андый солдатларга аеруча ягымлы була иде. Гомумән, китапханә шулкадәр бай, ул бер дә зур шәһәр китапханәләреннән ким түгел иде. Бурятиянең ачык даласында урнашкан бер хәрби частьта шулкадәр байлык туплансын әле, искитмәле хәл!

Берзаман Гафурның рус телендәге китапларны гына түгел, ана теле, татар телендәге китапларны да укыйсы килә башлады. Армиягә хәтле авылда яшәгәндә ул телне табигый нәрсә дип кабул итә, аның кадере һәм кыйммәте турындагы фикерләрдән ерак тора иде. Армиядә хезмәт итә башлап, даими рус мохитендә яшәү, аңарда туган телең турында төрле уйлар кузгатты. Дөресрәге, бу туган якны сагына башлау галәмәте иде. Әлеге җирсү Гафурда акрынлап уянды һәм торган саен көчәя барды. Аның берәр кеше белән татарча сөйләшеп утырасы, хыялланасы, ахыр чиктә берәр татар китабын укыйсы килә иде. Ул матур телле Фатих Хөсни, Әмирхан Еники кебек язучыларның әсәрләрен исенә төшерде. Казакъчадан татар теленә тәрҗемә ителгән «Абай» романының гүзәл теле дә үз вакытында нык тәэсир иткән иде (аны Кави Нәҗминең җәмәгате Сәрвәр Әдһәмова тәрҗемә иткән иде шикелле). Гафур шуны аңлады – чит җирдә, үзгә тел мохитендә яши башлагач үзеңнең бөтенләй башка халык вәкиле, татар кешесе булуың исеңә төшә, шул вакытта үз телеңне сагыну, күңелеңдә аның кадерен белү тойгысы уяна икән. Гафур күңелендә уяна башлаган бу тойгы туган җирне сагыну белән бәйле «җирсү» сүзенә бик якын тора иде, русларда ул «ностальгия» дип атала иде сыман. Бу сүзне Гафур әле мәктәптә укыганда бер шигырь җыентыгында очраткан иде. Шул чакта ук ул аның күңеленә кереп калды. Менә хәзер бу сүз тагын исенә төште һәм рәхәт булып китте. Нинди матур бит безнең ана теле!.. Ул авыл мәктәбендә рус теле белән рус әдәбияты укыткан әнисенә посылка белән берничә татар китабы җибәрүен сорап хат язарга булды.

Шулай да ул хезмәт иткән частьта бүтән татарча белүче берәр кеше юк

микәнни? Аның белән армиягә алынган егетләр арасында өч-дүрт татар егете бар иде. Тик алар татарча белмәүче кала егетләре булып чыктылар. Өченче ротада татарга охшаган бер солдатны күргәләгәне бар. Белешә торгач, Сиразиев фамилияле егет икәнен дә ачыклады. Өченче рота – элемтәчеләр ротасы иде. Аларның бер өлеше ЗАС (засекреченная аппаратура связи) урнашкан бинада хезмәт итә. Гафур, ниһаять, Сиразиев белән танышырга булды. Бәлки, дуслашып ук китәрләр. Бер көнне очраклы рәвештә ул аны часть клубы янында очратты, җайны ычкындырмас өчен, татарлыгы йөзенә чыккан бу егетне фамилиясен әйтеп туктатты. Үз фамилиясен ишеткәч, егет бераз аптыраган хәлдә аңа төбәлде. Гафур сөйләшүне русча башлап җибәрде:

– Ты, кажется, из третьей роты?

– Да, из третьей…

– Давно служишь?

– Два года.

Ниһаять, Гафур сүзне нигә башлавын ачып салырга булды:

– Моя фамилия – Нигматуллин, зовут Гафур, из комендантского взвода...

– Что дальше?.. – дип дорфа гына сорап куйды егет.

– Ты откуда призывался?

– Из Кемерово.

– Татарча беләсеңме? – дип татарчага күчеп карады Гафур.

– Что?.. Не понял... – дип җавап бирде егет. Аның инде ачуы килә башлаган иде.

Гафурга кабат русчага күчеп сорарга туры килде:

– Ты ведь татарин. Знаешь по-татарски?

Сорауны ишеткәч, Сиразиев як-ягына каранып алды. Берәрсе ишетмәдеме дип шикләнде, ахрысы.

– Нет, не знаю…

– Значит, родного языка не знаешь, – дип төрттерде Гафур.

– Он мне не родной… И вообще, отстань от меня…– Сиразиев, кырт борылып, кызулап китеп барды. Бераз киткәч, нигәдер ялт итеп артына борылып карады. Йөзе кызарган, ачулы иде.

Гафур моңа гаҗәпләнмәде, күмер чыгара торган татар төбәге Кемероводан солдатка алынган егетнең артыннан бераз карап торды да үз юлы белән китеп барды. Кайбер татарларның төрле сәбәпләр аркасында үз теленнән аерылуы Гафур өчен яңалык түгел иде. Шулай да бу сөйләшү аңарда күңелсез уйлар кузгатты. Татар исемен йөрткән кайбер кешеләрнең шундый хәлгә төшүен күрү гаять авыр иде.

Тырышкан табар, ташка кадак кагар, дигән борынгылар. Гафур егетләре дежур торган КПП аша, татарга охшаган, бер – кырык биш яшьләрдәге старшина үтеп йөри иде. Уртача буйлы, почык борынлы, яңак сөякләре бераз чыгып торган ак чырайлы бу старшинага Гафур күптән игътибар иткән иде инде. Аның татар икәнлегенә Гафурның шиге юк иде. Үз татарыңны бит әллә кайдан таныйсың. Татар кешесенең йөзендә нindидер сүз белән аңлатып булмый торган чалымнар бар. Монда интуиция ярдәм итә. Бәлки, җан тартуыдыр. Аңламассың.

Беркөнне шушы абзыйның КПП аша үтеп баруын күреп алгач, Гафур ирексездән ияреп китте, бераздан куып җитте дә русчалатып:

– Товарищ старшина, можно вас на минутку, – диде.

Старшина, туктап, Гафурга таба борылды.

– Вы меня извините, я давно за вами наблюдаю, – дип башлады сүзен Гафур, бераз уңайсызлана төшеп. – Мне кажется, вы по национальности татарин.

– Да, я татарин, – диде старшина, бераз гаҗәпләнә төшеп.

– Я тоже татарин, зовут Гафур, из комендантского взвода…

Старшина елмаеп ук җибәрде, шатлыгы сөякчел йөзенә таралды.

– Сез татарча беләсезме? – дип турыдан-туры сорады Гафур.

Старшина шундук саф татарчага күчеп:

– Белмәскә, мин бит татар авылыннан...

– Татарстаннан түгелме? – Гафур да татарчага күчте.

– Әйе, Саба районыннан. – Инде старшина үзе сорау бирде: – Ә үзең кайсы яклардан соң? Татарстан егетеме?

– Әйе, Арча районыннан...

– И-и, якташлар икәнбез бит... Казан артыннан. – Старшина тәмам үз итеп җавап бирде.

Шулай алар сөйләшеп киттеләр. Старшинаның исеме Закирҗан икән, фамилиясе Гобәев. Бу частьта күптәннән хезмәт итә, ике баласы – малае белән кызы бар. Алар сөйләшә-сөйләшә Закирҗан абыйның эшләгән җиренә – материаллар складына кадәр барып җиттеләр. Шушы кыска юлдагы сөйләшү аларны тәмам дуслар итте дә куйды. Аерылышканда Закирҗан абый Гафурга үз адресын әйтеп, кунакка чакырды:

– Хатынга әйткәч, и-и ничекләр куаныр инде. Ату монда үзеңчә сөйләшеп утырырга бер кеше юк, – дип зарланып алды ул. – Әбзәтелни кил, килми калма, яме. – Ул чакыруын тагын бер кат ныгытып куйды. – Бу ялда сәгать өчкә көтәбез.

– Ярар, килермен, – диде Гафур, шушы дөнья чигендәге Байкал артында якташын очратуга сөенеп. Аның күңелендә яңа хисләр уянып, әле урнашып бетә алмыйча тирбәләләр иде.

Ял көнне, чакырылган вакытка, Гафур старшина Закирҗан абый фатирының ишек төбендә иде инде. Ул звонок төймәсенә баскач, ишекне хуҗа кеше үзе ачты, Гафурны күреп алгач, йөзе шатлыктан балкып китте, елмаюы бөтен битенә таралды.

– Әйдүк, Гафур, без сине атна буе көтәбез инде. Бигрәк тә Кадрия апаң түземсезләнде. Килер микән, килсә генә ярар иде, ди. Әллә барып тагын бер исенә төшерәсеңме дип теңкәмә тиде...

– Әйткән сүз – аткан ук, дигән бабаларыбыз, – дип, Гафур күрешергә ике кулын сузды. – Исән-сау гына торасызмы?

Ул арада кухня ягыннан Закирҗан абыйның җәмәгате Кадрия апа да килеп чыкты. Күз ташлау белән Гафур аның авылда үскән чын татар хатыны икәнен күреп алды. Кунак каршылау хөрмәтенә булса кирәк, башында артка бәйләнгән маңгае чигүле ак яулык, колакларында түгәрәк алтын алкалар, чәчәкле күлмәк өстеннән алъяпкыч бәйләп куйган. Түгәрәк йөзле, матур гына борынлы, күпереп торган кара чәчле, коңгырт-яшькелт күзле бик мөлаем хатын иде ул.

– Әйдәгез, түрдән узыгыз, Гафур. Без монда татар кешесен күрергә, үзебезчә сөйләшергә горъян булып яшибез... – Ул да исәнләшергә кулын сузды.

Хатын-кыз белән кул биреп исәнләшмәсәләр дә, үз итеп кулларын сузгач, Гафур да җиңелчә генә аның йомшак кулларын кысты. Аннан хуҗабикә, ирләрне ялгыз калдырып, кухня ягына чыгып китте.

Бу гаилә ике бүлмәле фатирда яши икән. Зал ягындагы озынчарак өстәлгә

төрле ризыклар куелып, кунак килгәнче дип ул җиңел ак тукыма белән каплап куелган иде.

Ул арада, икенче бүлмәнең ишеге бераз ачылып китеп, анда башлангыч классларда укучы кыз белән малай күренде. Алар, кызыксынып, кунакка килгән солдат абыйны күзәтәләр иде. Гафур, елмаеп, күз кыскач ишек шундук ябылды, теге якта балаларның чыркылдап көлешүе ишетелде.

– Матур балалар үстерәсез икән, – диде Гафур, ишеккә ымлап.

– Аллага шөкер, – дип куйды Закирҗан абый.

Ул Гафурга өстәлнең бер ягыннан урын күрсәтте, кунак урнашкан арада өстәлгә япкан ак тукыманы күтәреп алды да җыеп куйды. Табын бик матур итеп бизәлгән иде. Монда нинди генә ризык юк. Уртада бер шешә акбаш та күренә.

– Балаларыгыз татарча беләме соң, Закирҗан абый?

– Өйдә гел үзебезчә сөйләшәбез. Шулай да урысча уку үзенекен итә. Татарча авыррак сөйләшәләр, кайвакыт урысча да җавап бирәләр. Мин инде тыеп та карыйм, өйдә үзебезчә сөйләшегез дип... Нишләмәк кирәк, иптәшләре бит урысча сөйләшә...

Алар сөйләшеп утырган арада Кадрия ханым балаларны кухняга чакырып алды да ашарга утыртты. Балаларны олылар белән утыртмаулары Гафурның игътибарын җәлеп итте. Юкса бит балаларны олылар табынына утыртсалар, сүз гел алар тирәсендә бара, андый чакта җитди сүзгә чират та җитми.

Кухня ягыннан алъяпкычын салгач тагын да чибәрләнеп калган Кадрия апа килеп чыкты. Кулына пары бөркелеп торган бәрәңге белән ит салынган табак тоткан. Ул аны өстәл уртасына урнаштырды да:

– Әйдәгез утырышыйк, кунакны сүз белән сыйламыйлар... – Ул табындагы сый савытларын төзәткәләде. – Син, Гафур, бик төгәл егет икәнсең. Бәрәңгем суынмаса ярар иде дип бераз борчылган идем. Бик вакытында килдең... – Аннан иренә борылып: – Закирҗан, әйдә башлыйк, – диде.

Ниһаять, табын янына утырыштылар. Ризыкларга тотынганчы Закирҗан абый кулына аракы шешәсен алды, Гафурның: «Кирәкмәс иде, мин эчмим бит», – диюенә карамастан, рюмкаларны тутырды:

– Күп эчмәбез, шулай да танышлык хөрмәтенә аз гына чиертеп куйыйк, – дип, ул Гафурга карап сөйли башлады: – Гафур энем, синең турыдан-туры «Сез татар кешесе бугай...» дип сүз башлавың миңа бик ошады. Димәк, син шушы җир читендәге Бурятиядә дә милләттәшеңне, татар кешесен эзлисең, үз телеңдә аралашасың килә. Халкыңа, туган телеңә битараф түгелсең... Моның өчен мин сине бик хөрмәт итәм... Безнең очрашу ике татар кешесенең танышып китүе генә түгел. Мин моңа зур мәгънә салам. Без синең белән Татарстаннан ерак шушы җирдә туган җиребезнең асыл вәкилләре булып яшәүче кешеләр. Еракта булсак та, хәл кадәре татарлыкны саклап яшик. Әйдә, шуның өчен... – Ул рюмкасын Гафурга сузды. Мондый сүзләрдән соң Гафур да эчмичә булдыра алмады, рюмканың яртысын йотып куйды. Авызын яндырган эчемлекне чөгендер салаты белән бастыргач:

– Бик акыллы, мәгънәле сүзләр әйттең, Закирҗан абый, шундый саф татар гаиләсе белән танышуыма бик шатмын, – диде Гафур.

Татарның токмачлы ашыннан соң ит белән бәрәңгегә керештеләр, чәй янына табынга гөбәдия, өчпочмак, суган турап йомырка белән пешерелгән сумса чыкты. Ризыклар барысы да тәмле иде. Инде ел ярым өй ашы күрмәгән Гафурга бу сыйлар җәннәт нигъмәтләре булып тоелды. Оста да соң безнең халык аш-суга дип, ул табынның муллыгына сокланып утырды. Ә Кадрия

апасы аны кыстады да кыстады, ул кыстаган саен Гафур ризыкларны мактый, рәхмәтләр әйтә иде. Табында Байкал күленең якынлыгын искә төшереп торган кызыл балыкка хәтле бар иде. Бер-берсе турында күбрәк беләселәре килеп, алар төрле сораулар биргәләп утырдылар. Кадрия ханым шулай ук Татарстан кызы икән, Минзәлә районыннан. Әти-әнисе белән илленче елларда Бурятиягә күчеп килгән. Закирҗан абый белән биредә, Улан-Удэда танышканнар. Шул вакыт Гафурның исенә килеп төште – ул малай чакта да авылларыннан Бурятиягә күчеп китүчеләр булган иде. Дөрес, ул вакыйгаларны Гафур бик томанлы хәтерли, беренче-икенче класста укыган чагы булгандыр. Ерак Бурятиягә китәргә үгетләп йөрүчеләр дә ничектер аның хәтеренә кереп калган. Олылар гел шул хакта сөйләшәләр иде. Гафур хәзерге ачык акылы белән уйлап куйды: бу хәрәкәт сугыштан соң болай да шактый кимегән татар халкының санын сыекландыру өчен махсус оештырылган акция булмады микән. Бик мөмкин. 1944 елда Кырым татарларын көчләп төрле якка таратканнар ич. Дөрестерме-юктырмы, Сталинның Казан татарларын күчерү планы да булган дип сөйлиләр. Аның бу планына атаклы хәрбиләр каршы төшкән, имеш. Алар татарларның фронтта бик яхшы сугышулары, Ватан өчен җаннарын бирергә әзер булулары турында сөйләгән. Әгәр дә бу эшкә барсак, батыр татар сугышчыларына ни дип әйтербез, ничек аңлатырбыз. Сугыш барганда, бу сәяси яктан дөрес булмас, дигәннәр, имеш. Бу хакта сугыштан исән кайткан, бәйрәм көннәрендә күкрәгенә орден-медальләрен тагып чыгучы бер авылдашының сөйләгәнен ишетеп калган иде Гафур.

Чәйдән соң сөйләшеп, күңел ачып утырдылар. Сүз җырчылар, артистлар, язучылар, аларның әсәрләре, татарча гәзит-журналларга күчте.

– Закирҗан абый, сез Казаннан берәр гәзит-журнал алдырасызмы? – дип кызыксынды Гафур.

– «Чаян» журналын гына алдырабыз. Анысы да кайбер айны килми кала. Әллә юлда югала, белмәссең... – диде ул.

– «Азат хатын», «Казан утлары» дигән журналлар да бар бит. Аларны алдырганыгыз булмадымы? «Казан утлары»нда, мәсәлән, татар язучыларының өр-яңа әсәрләре басылып тора.

– Беләсеңме, Гафур энем, туган җирдән еракта яшәгәч, үзең дә сизмичә татар культурасыннан ерагаясың икән ул. Тормыш баса...

– Әнә «Чаян»ны алдырасыз икән ич.

Закирҗан абый кеткелдәп көлеп куйды:

– Журнал килгәч, бер атна көлеп йөрим. Сурәтләрен бик яратам. Кайдан уйлап табып бетерә торганнардыр...

Бу сүзләрне ишеткәч, Гафур да елмаеп куйды. Мондый ерак җирдә, Байкал артында урыс хәрбиләре арасында яшәп тә татарлыгын саклап килгән Закирҗан абый аңа бик ошый иде. Аның «Чаян»ны алдыруы да күп нәрсә турында сөйли.

– Безнең Кадрия җырлар ярата бит, Гафур энем. Тавышы да ярыйсы гына... – дип, җәмәгатенә ымлады Закирҗан абый. – Яле, әнисе, берәр җыр сузып күрсәт әле безгә.

– Юк, юк... Нинди җыр, каян килсен миңа тавыш. – Кадрия ханым кулларын селкеп алды. – Әйдәгез, лутшы пластинка уйнатыйк. Чын җырчыларны тыңлыйк.

Ул, урыныннан кубып, почмактагы тумбочка өстендә торган уйнаткычка килде, капкачын ачты, чыбыгын утка тоташтырды. Аннан, сервантның аскы бүлегеннән, берничә пластинка алды да:

– Кайсын куйыйм соң? – дип сорады.

– Үзең беләсең инде, әнисе. Син бит ешрак тыңлыйсың, – диде Закирҗан абый.

Ниһаять, пластинка куелды, көй яңгырый башлады. Бу татар халык җыры «Рамай» иде.

Төнгә каршы берәү моңлы итеп, Рамай,
Аерылышу көен җырлады;

Салмак озын көйне яратып тын да алмыйча тыңлаганда кемнеңдер күз алдына үз язмышы, җанга якын туган-үскән яклары, балалык, үсмер еллары, үсеп җиткәч, туган яктан аерылу вакыйгалары килеп баскандыр. Күңелләр нечкәрде, кемдер язмышның адәм баласын дөнья буйлап бәхет эзләп йөртүен уйлый иде булса кирәк. Аннан соң пластинкадан борынгы җырлардан «Гөлҗамал», «Иске кара урман», Тукай сүзләренә язылган «Әллүки», «Зиләйлүк», «Тәфтиләү» кебек җырлар яңгырады. Гомумән, бу пластинкага борынгы сузынкы җырлар тупланган иде. Шушы җырлар тәэсирендә табын бераз сүрелеп киткәндәй, бүлмәне моңсулык баскандай булды.

Закирҗан абыйны бу хәл борчуга салды булса кирәк, ул:

– Карале, әнисе... Син бит Минзәлә кызы, әйдә безгә дәртле «Минзәлә»не җырлап күрсәт әле. Син аны ярата идең, – диде Закирҗан абый.

Минзәлә сүзен ишеткәч, Кадрия ханым баягы шикелле җырлаудан кырт кисеп баш тартмады, бары тик:

– Әй, тавышым да бетте инде. Кунак алдында җырларга тартынам да... – дип, аклангандай әйтеп куйды.

– Бер дә уңайсызланмагыз, Кадрия апа. Минем дә сезне тыңлыйсым килә. Монда гаеп итүче юк, – дип, Гафур да хуҗаның сүзен куәтләде.

Кадрия ханым урындыгына җайлабрак утырды, кулын күкрәгенә куеп, тамагын кыргалап алды да, бераз тын торгач, җырлый башлады:

Барасызмы Минзәләгә,
Мин барам Минзәләгә;
Минзәләне күрер өчен
Йөрәгем өзгәләнә.

Беренче куплеттан соң ул кабат тамак кырып алды:

– Күптән җырлаганым юк шул, тавышым ачылып җитми, – дип, гафу үтенгәндәй, әйтеп куйды, аннан дәвам итте:

Минем иркәм Минзәләдә
Туып үскән бер матур;
Минзәләгә бара алмасам,
Аны кемнәр юатыр?..

Җырның соңгы куплетын Кадрия ханым инде ачылган тавыш белән тәмамлады, күңеле күтәрелеп, йөзенә алсулык йөгергән хәлдә тыңлаучыларга:

– Әй, күптән җырлаганым юк шул, тавышым бөтенләй беткән икән, – дип, аклангандай әйтеп куйды.

– Бер дә бетмәгән, Кадрия апа, бик матур җырладыгыз. Рәхмәт сезгә. Сез чыннан да әйбәт җырчы икәнсез, – диде Гафур, аның күнелен күтәрергә теләп.

– Бик матур җырладың, әнисе, бер дә борчылма.

Шулвакыт Гафурның үсмер чагында, беренче гашыйклык сырхавы белән газапланып йөргән вакытта, бик яратып җырлаган бер җыр исенә килеп төште. Бу «Вәгъдә» дигән җыр иде. Ул өлкән классларда укыганда бу җыр бик популярлашып китте, аны еш кына радиодан да тапшыралар иде. Аһ, аның ул вакыттагы хисләре, кичерешләре! Гафур үзе белән бер класста укыган Әминә исемле кызга үлеп гашыйк иде ул чакта. Мәктәптә аны көн саен күрә, карашлары еш очраша, Гафур аркасына канатлар үсеп чыккан фәрештә сыман хис итә иде үзен. Әминәне уйлап, бөтен дөньясын онытып, әйләнә-тирәсендә бернәрсәне күрмичә, сәгатьләр буе бер ноктага төбәлеп утыруларын әле дә булса хәтерли Гафур. Нинди татлы, илаһи халәт ул беренче гашыйклык, аны бернәрсә белән дә алыштырып булмый. Ул йөрәгеңә мәңгегә кереп урнаша, пакълек мисалы, изге хис булып гомер буе күңелеңдә яши.

Вәгъдә биргәч, кирәк иде котәргә,
Нигә инде мине моңсу итәргә?
Яшьтән өзелеп сөйгән ярың
Үз вәгъдәсен үзе бозгач,
Газапланып тибә яшь йөрәк.

Әмма аның бит Әминәгә әле бер сүз дә әйткәне, аның белән вәгъдәләр бирешкәне юк иде. Бәлки, шул сәбәпледер, Әминә белән аралары суынды. Бәлки, ул Гафурдан сүз көтеп аргандыр, шуңа күрә алардан бер класс өстә укыган Дамир белән очраша башлагандыр...

Кадрия ханымның тавышы Гафурны тәмам әллә нишләтте, сихерләде, бүгенге халәтеннән аерып, әллә кайларга, хыялында гына яшәгән, анда гына җанланган, фәкать үзенә генә билгеле дөньяга алып кереп китте. Җырның соңгы сүзләре, Гафур нинди авыр хисләр генә кичермәсен, чынбарлыкны ничек бар шулай кабул итәргә, тынычланырга, тормышны дәвам итәргә өнди иде:

Ярсыма син, яшь йөрәгем,
Давылдан соң диңгез тына,
Сагышларым бетәр бер заман.

Әйе, сагышлар акрынлап басылды, ләкин беренче гыйшыкның илаһи хисе гомергә йөрәктә, хәтердә калды.

– Кадрия апа, сез бу татар җырларын кайдан юнәттегез?

– Ял вакытында Казанга кайткач, апамнан сорап алган идем. Бик кадерле нәрсәләр алар минем өчен.

– Аңлашыла. Мәскәүдәге «Мелодия» фирмасы татар пластинкаларын бик аз чыгара икән. Казанда сатуда алар бик сирәк була, ди.

– Әйе шул, үзебезнең Казаныбызда чыгару мөмкинлеге юк икән бит. – Кадрия ханым бу хакта апасыннан ишеткән иде.

– Барысы да Мәскәү кулында шул... – дип куйды Закирҗан абый, артык эчкә кермичә.

Гафурга инде китәргә вакыт җиткән иде. Болай да өч сәгатькә якын утырдылар. Ул урыныннан торды да:

– Рәхмәт сый-хөрмәтегез өчен. Матур гаиләгез белән танышу минем өчен бер бәйрәм булды... Кадрия апа, сезнең җырлавыгызны тыңлаганда үземне туган ягыма кайткандай хис иттем. Зур рәхмәт сезгә.

– Юк, юк... китмисең. Тагын утырыйк әле... Мин хәзер чәй яңартып алам, – дип каршы килде Кадрия ханым.

– Юк, китим инде... Эзләүләре бар. Бик матур утырдык, рәхмәт сезгә.

Гафур коридорга юнәлде, хуҗалар аны озата чыктылар.

– Очрашуыбызның соңгысы булмас. Киләчәктә дә утыргаларбыз әле шулай. Бик ошадың син безгә, Гафур энем. Чын татар җанлы егет икәнсең. Бик тансык без үзебезчә гәпләшеп утыруга, – диде Закирҗан абый.

Гафур пилоткасын башына киде дә, тагын бер рәхмәт әйтеп, чыгып китте. Аның күз алдында ерак Бурятиядә саф татарча яшәп яткан шушы матур гаилә, Кадрия ханымның илһамланып җырлавы, Казанга укырга китеп, аралары өзелгән Әминә тора иде. Әминә кабат исенә төшкәч, йөрәге сыкранып куйды. Җырның соңгы юллары хәтерендә яңарды:

Ярсыма син яшь йөрәгем,
Давылдан соң диңгез тына,
Сагышларым бетәр берзаман.

Әйе, аның сагышлары инде күптән басылды, ул хәзер бөтенләй башка дөньяда яши. Ул уйлары белән чынбарлыкка, үзенең бүгенге солдат хезмәтенә әйләнеп кайтты. Күпмедер вакыттан соң бу хезмәт тә тәгәлләнер. Аның алдында әле башланмаган тормыш юллары сузылып ята. Ул кайсыннан китәр, әлегә үзе дә белми. Әмма Гафур шуны белә: кайда яшәсә, кайда эшләсә дә, ул һәрвакыт үз милләтенең бер вәкиле булып калачак. Бүгенге очрашу бу фикерне тагын да ныгытты.

Гафур моннан соң да Закирҗан абый гаиләсенә килгәләп йөрде. Бу күрешүләр ике як өчен дә бәйрәмгә әверелә иде. Алар шундый очрашулар вакытында татар дөньясында яшәп алалар иде.

Армиядән китәргә ярты еллап вакыт калганда, бер җомга көнне, аны Закирҗан абыйсы эзләп тапты. Ул бу вакытта политзанятие уздыру планын төзеп утыра иде. Закирҗан абыйсы аны тышкы якка чакырып алды да:

– Гафур, син иртәгә төштән соң бушмы?

– Буш кебек...

– Алайса, иртәгә безгә килеп чык әле. Кадрия апаң да сагынды үзеңне... Закирҗан абый серле итеп елмаеп куйды.

– Нәрсә, берәр бәйрәм түгелдер бит?.. – дип кызыксынды Гафур, чөнки Закирҗан абый нәрсәнедер әйтеп бетерми шикелле иде.

– Юк, юк, просто үзебезчә сөйләшеп, чәйләп утырасы килә. Син бит инде безнең туганыбыз шикелле. Килми калма, яме...

– Ярар, берәр ашыгыч эш чыкмаса, килермен.

Сөйләшү шуның белән тәгәлләнде. Гафур, нәрсәдер сизенеп, Закирҗан абыйсының артыннан карап калды. «Әллә берәрсенең туган көне микән? – дип уйлап куйды ул. – Бүләксез килү ярамас».

Иртәгесен, Закирҗан абыйларга барыр алдыннан, Гафур часть эчендәге кибеткә кереп чыкты. Бу азык-төлек кибете булып, акчалы солдатлар анда, ризык төрләндерү өчен, конфет, печенье, шоколад, прәннек кебек тәм-томнар сатып алып сыйланалар иде. Гафур да, кунакка буш кул белән бармас өчен, тартмалы конфет алып газетага төрде. КППдагы егетләр барысын да белеп тормасыннар әле.

Бу юлы ишекне Кадрия ханым ачты. Матур итеп киенгән, чәчләрен күпертеп

тараган, муенына энҗе-мәрҗән таккан, иреннәренә чамасын белеп кенә иннек тә сөрткән. Гафурны күрүгә аның йөзе балкып китте, коңгырт күзләре аеруча үз итеп, хәтта бераз серле ялтырыйлар иде.

Хуҗабикә, сөйләнә-сөйләнә, Гафурны залга алып керде. Егетне бер сюрприз көтә иде. Ул өстәл янында урта буйлы бер кызны күреп алды. Аның алдында кара чәчләре иңнәренә төшкән, ак йөзле, кечерәк кенә матур борынлы, коңгырт-яшькелт күзле, өлгергән чияне хәтерләткән сусыл иренле, битенә матурлык өстәп торган җыйнак кына иякле бер сылу басып тора иде. Беренче караш ташлау белән Гафурның йөрәге, нидер сизенеп, талпынып куйды. Бу аңлатып булмаслык бер тойгы – ниндидер бәхет вәгъдә итүче тойгы иде. Гафур әле аның нәрсә икәнен дә аңламый, тик бу сылуның бераз оялып каршында басып торуы, бөтен килеш-килбәте ниндидер рәхәтлек бирә иде.

Гафур бераз каушаган хәлдә, тик каушавын сиздермәскә тырышып, сораулы карашын Кадрия ханымга күчерде. Кадрия ханым исә:

– Таныш булыгыз, бу – Гафур, бирредә хезмәт итә. – Кадрия ханым үз итеп егетнең иңенә кагылып алды. – Ә бусы минем племянницам Дилбәр була, – дип кызга күрсәтте.

Гафур кызга таба атлады, кулын сузып:

– Гафур, – диде.

Кыз да кулын бирде:

– Дилбәр. – Кызның йомшак кулы кайнар иде.

– Исемегез бигрәк матур икән. Сирәк очрый торган исем. – Гафур баягы каушавыннан арынып, инициативаны үз кулына алырга булды. – Кадрия ханымның мондый чибәр племянницасы барын белми идем. Бу минем өчен зур сюрприз әле, – диде ул, кызның күзләренә туры карап.

Бу караштан Дилбәр бераз уңайсызланды, йөзе алсуланды, Гафурга ул тагын да чибәрләнә төшкәндәй тоелды.

Ул арада Закирҗан абый да кайтып керде. Кулындагы ашамлыклар тутырылган сумканы Кадрия ханымга тапшыргач, зал уртасында басып торган яшьләргә елмаеп:

– Әнисе, карале, бездә бүген нинди асыл кунаклар. Бәйрәм итик әле бер. – Аннан соң нишләргә белмичә кара-каршы басып торган Гафур белән Дилбәргә якын ук килеп: – Таныштыгызмы? Алайса, әйдәгез бергәләп табын корыйк.

Закирҗан абый белән Гафур икәүләшеп бүлмә уртасындагы өстәлне зурайттылар, өстенә эскәтер җәелгәннән соң, Дилбәр кухнядан апасы әзерләгән ризыкларны китерергә тотынды. Күп тә үтмәде, өстәл тәмледән-тәмле нигъмәтләр, салатлар белән бизәлеп бетте. Гафур белән Дилбәрне янәшә утырттылар. Кадрия ханым:

– Дилбәрнең җәйге каникул вакыты... Күптән чакыра идем, менә кунакка килеп чыгып бик яхшы эшләгән, – дип, Гафурга кызның нигә биредә икәнлеген аңлатып бирде.

Гафур, янәшәсендә утырган кызга борыла төшеп:

– Дилбәр, синерактанмы? – дип сорады.

– Челябинскиның үзеннән...

– О-о... Еракта икән, – дип куйды Гафур. – Алайса кунакка сирәк йөрисең инде син.

– Сирәк шул. Соңгы тапкыр унны бетергәч килгән иде, – диде Кадрия ханым.

– Челябинскида Дилбәрнең кемнәре бар соң?

Сорау Кадрия ханымга бирелсә дә, кыз аңа үзе җавап бирде:

– Әтием-әнием белән торам.

– Әллә син бердәнбер кызмы?

Сорауга Кадрия ханым җавап бирде:

– Бердәнбер шул... Шуңа ул безгә бик кадерле. Сагынып көтеп алабыз.

Әңгәмә шулай дәвам итте. Табигый, табында Дилбәр гел игътибар үзәгендә булды. Гафур да чибәрлеге, мөлаемлеге белән үзенә тартып торган кызга битараф кала алмады. Кыз аның күңелендәге ниндидер тирән катламнарны хәрәкәткә китерде. Ул әле үзе дә моның нәрсә икәнен аңлап җиткерми, тик аңа бу гүзәл зат белән аралашу рәхәт һәм җиңел иде. Сөйләшү вакытында Гафур аның турында күп нәрсә белде. Дилбәр мәктәпне тәмамлагач, Чиләбе педагогия институтына кергән, хәзер өченче курсны тәмамлаган. Әтисе Чиләбе трактор заводындагы бер цехта технолог булып эшли, әнисе педагог, мәктәптә география фәнен укыта. Ә Дилбәр үзе профессиясе итеп тарихны сайлаган. Киләчәктә тарих укытучысы булырга җыена икән. Бу Гафурны бераз гаҗәпләндерде. Тарих бик катлаулы, авыр фән бит. Мондый чибәр, сөйкемле кызга тел, әдәбиятны сайласа җиңелрәк булмас иде микән. Язучылар, шагыйрьләр иҗатын өйрәнү күңеленә илһам биреп торыр, әдәбият, шигърият дөньясында яшәү аңа килешәрәк төшкән булыр иде шикелле, дип уйлап куйды ул.

Гафур үзе матур әдәбиятны ярата. Өйләрендә шактый бай китапханә бар. Ул шул китапларны укып үсте. Әнисе аңа беренче чиратта нинди китапны укырга кирәклеген әйткәләп тора иде. Педагог буларак, ул аны үзенә генә билгеле система буенча тәрбияләде. Гафурга бигрәк тә психологик тирәнлек белән язылган романнар ошый иде. Роман тормышны масштаблы итеп күрсәтә, күзләрне ача, күп фикерләр уята, уйланырга мәҗбүр итә.

Мәҗлес тәмамланып, алар табын яныннан купкач, Гафур җаен туры китереп, кыздан:

– Дилбәр, син монда тагын күпме торырга уйлыйсың? – дип сорады.

Кыз аңа күтәрелеп карады, карашында сорау бар кебек тоелды:

– Берәр атна торырмын, ахрысы, – диде.

Гафур, аның кулын учына алып, күзләренә карады:

– Бу соңгы күрешүебез булмас бит...

Дилбәр шаяру белән җавап бирде:

– Килсәң, күрешербез...

Кызның сүзләре Гафурга кыюлык өстәде:

– Алайса, мин иртәгә килермен. Ярыймы?..

– Кил...

Бу кыска сүз Гафурны дәртләндереп җибәрде, ул үзенә канатлар үсеп чыккандай хис итте. Аларның сөйләшүен Кадрия ханым да ишетеп алды, үзалдына елмаеп куйды. Гафурның Дилбәрне ошатуына ул бик шат иде. Дилбәр белән аерылышасы килмәсә дә, Гафурга инде китәргә, частька кайтырга вакыт. Ул, хуҗаларга рәхмәтләр әйтеп, урамга чыкты. КППга таба атлаганда бүгенге очрашуның очраклы хәл булмавын, Кадрия ханымның аны махсус оештыруы турында уйлап алды. Димәк, бу гаиләдә Гафурны хөрмәт итәләр, аның Дилбәр белән күрешүе киләчәктә күңелле вакыйгаларга китерү ихтималын да уйлап эш иткәннәр булса кирәк.

Гафур үзалдына елмаеп куйды. Киләчәктә нәрсә буласын кем белгән. Ә шулай да кыз аңа бик ошады, тирән хисләр уятты. Әнә, һаман аның күз алдында басып тора...

* * *

Шушы танышудан соң алар көн дә очраша башладылар. Офицерлар шәһәрчегендә барып утырырга кафе кебек урын булмаганга, гел өйдә күрешәләр иде. Кайвакытта Дилбәр өйдә ялгызы гына кала, шуңа күрә алар арасында ихлас сөйләшүләр күп булды. Бу аларны тиз якынайтты. Гел өйдә утырмас өчен, кайбер көнне Гафур кызны частьның клубына кинога да алып баргалады. Күп тә үтмәде, егет белән кыз арасында тартыну дигән нәрсә бетте, алар инде күптәнге танышлар кебек аралашалар, төрле темаларга ачыктан-ачык сөйләшәләр иде.

Ә бер көнне Гафур үзенең комендант взводындагы көндәлек вазифаларын башкарып, иртәнге якта егетләр белән атнага бер үткәрелә торган политзанятиене уздырып, төштән соң Дилбәр янына килде. Бу юлы Кадрия ханым да өйдә булып чыкты. Хуҗабикә Гафурны һәрвакыттагыча якты йөз белән каршы алды, Дилбәрнең дә күңеле күтәренке кебек иде.

Гафур исәнләшеп, җәйге көннең бигрәк матур, гадәттәгечә эссе түгеллеге турында бер-ике сүз әйткәч, Кадрия ханымга мөрәҗәгать итте:

– Кадрия апа, сез каршы килмәсәгез, мин Дилбәрне бераз йөреп кайтырга алып чыкмакчы идем. Елга буйларын күрсәтеп кайтырга исәп, – диде.

Дилбәр, апасын бу хакта алдан кисәтеп куйганга, бу сүз Кадрия ханым өчен яңалык түгел, киресенчә, ул хуп күргән эш иде:

– Барыгыз, бар... Йөреп кайтыгыз, көн дә матур тора. Аның монда килгәннән бирле беркая чыкканы юк бит әле, – диде ул, канәгать калып.

– Монда кая барасың, бер якта дала, икенче якта тайга. Бердәнбер барырлык урын – елга буе.

– Мин инде аны Улан-Удэга алып барыйм микән, дип тора идем.

– Әле Дилбәрнең Улан-Удэны яхшылап күргәне юкмыни?

– Юк шул, вокзалдан туры монда кайтты. Теге юлы килгәндә дә алып бара алмадым, – диде Кадрия ханым.

– Анда тарих музее бармы? – дип кызыксынды Дилбәр.

– Әйе, Бурятия тарихы музее дип атала.

Кыз эндәшмәде, башын гына селкеп куйды. Ә Гафур дәвам итте:

– Бер барганда кинога кергәч, бурят кызы белән сөйләшеп киткән идем. Син кайсы милләттән, дип сорый. Татар, мәйтәм. «Татар?!» дип, кызый күзләрен шарландырып миңа төбәлде. Аннан шаркылдап көләргә тотынды. Нигә көләсең, мәйтәм. Син монгол икәнсең, ди. Юк, мин монгол түгел – татар, дим. Ә ул шундый мыскыллы итеп елмая. Татар шул монгол инде ул, ди. Мин аптырашта калдым. Беренче тапкыр: «Әллә башка халыклар татарны монгол дип саный микән?» – дип уйлап куйдым.

– Әлбәттә, саный, – дип сүзгә кушылды Дилбәр. – Дәреслекләрдә һәрвакыт «татаро-монгольское иго» дип язалар ич. Монголлар еракта, Монголиядә, ә татарлар синең күршеңдә яши. Шуңа күрә тарихи нәфрәт тә татар өстенә төшә.

Кызның мондый нәрсәләрдә ачык фикере булу Гафурны гаҗәпләндереп кенә калмады, аңа карата хөрмәтне дә бермә-бер арттырды. Ул, сөенеп:

– Син, Дилбәр, тарихчы профессиясен юкка гына сайламагансың икән, – дип куйды.

Кадрия ханым бу әңгәмәне кызыксынып тыңлап торса да, яшьләрнең кая барырга җыенуын исләренә төшерде:

– Ярар, балалар... Барыгыз, йөреп кайтыгыз. Бик озакка калмагыз.

Гафур белән Дилбәр өйдән чыктылар да часть торган калкулык өстеннән машина юлы белән аска, ике чакрымлап ераклыкта яшел юрган сыман җәелеп яткан киң үзәнгә таба төшеп киттеләр. Анда талларга төренгән боргаланып аккан елга күренә, ә аңа җитәрәк туры сызыкны хәтерләткән тимер юл тасмасы сузылып ята.

Гафур да, Дилбәр дә ирекә чыгуларына бик шат иделәр. Тирә-якта тынлык эчендә йокымсырап яткан табигать манзарасы, еракта-еракта, киң үзәннең каршы ягында, күгелҗемләнеп, ылыслы урман белән капланган сопкалар күтәрелә. Гафурның ишетүенчә, ул сопкаларда тәмле чикләвек бирүче эрбет агачлары да үсә икән. Тик аның елганың аргы ягына чыкканы юк, бары тик кискен континенталь климатлы Бурятиянең җәйге эссесендә сирәк-мирәк елгага коеныргa төшәргә генә кайвакыт җай чыга. Анысы да качып-посып кына. Менә хәзер Гафур кызны үзән уртасыннан аккан йөгерек сулы Уда елгасына алып төшеп бара.

Башта кыз белән егет, әллә инде шушы бушлыкта ялгыз калуларыннан тартынып, әллә үзләрен чолгап алган тынлыкка хозурланып, сөйләшми диярлек атладылар. Үзгә шартларда сүз нигәдер ялганып китмәде. Гафур ара-тирә янәшәсендә барган Дилбәргә күз салгалап ала, аның мәрмәрдәй ак йөзенә, күтәренке сөйкемле борынына, ягымлы күзләренә, сызылып киткән кара кашларына, маңгай өстендә күпереп торган чем-кара чәчләренә карап, кызның чибәрлегенә сокланып бара. Дилбәр дә, аның кичерешләрен сизеп булса кирәк, ара-тирә елмаеп куйгалый.

Гафур кыз турында күбрәк белергә тели иде. Шуңа күрә ул аңа сораулар бирә башлады:

– Дилбәр, син яшәгән Чиләбе нинди шәһәр ул? Шул турыда сөйлә әле, – диде.

Кыз аңа күз ташлап алды да:

– Синең Челябинскины татарча Чиләбе дип атавың бик ошый әле миңа... Чыннан да, Челябинскиның исеме «чәләби» дигән татар сүзеннән чыккан дигән гипотеза бар. «Чәләби» – укымышлы, интеллигентный дигәнне аңлата икән. Чиләбе – иңкү җирдә урнашкан кала. Кайберәүләр шәһәрне Чәләби исемле татар авылы урынында барлыкка килгән, дип исәпли. Чәләби татар исеме булырга тиеш. Хәтерләсәң, тарихта билгеле Куликово сугышы алдыннан әүвәл бер-берсенә каршы торган ике гаскәрдән берәр батыр алга чыгып сугыша. Руслар ягыннан сугыш алымнарын яхшы белгән монах Пересвет булса, татарлар ягыннан Чәләби исемле батыр сугыша. Нәтиҗәдә, икесе дә һәлак була.

Гафур бу кадәресен белми иде. Ләкин белмәвен белдермәскә булды. Ул тарихчы түгел лә...

– Каланың исеме күңелгә ятышлы яңгырый, ул, чыннан да, татар сүзеннән чыккан булса кирәк, – диде.

– Кайбер тарихчылар Чиләбе шәһәре урынындагы җирләр борынгырак заманда нииндидер төрки батыр Сәләби-Чәләбинеке булган, дигән фикер дә әйтәләр.

– Бу җирләрдә элек төркиләр яшәгән, монда бернинди дә шик була алмый, – диде Гафур.

– Дөрес, руслар бу җирләргә XVII гасыр азагында – XVIII гасыр башында гына килеп урнаша башлаганнар. Чиләбе крепостена 1736 елда руслар хезмәтендә йөргән полковник Тевкелев дигән татар мирзасы нигез салган.

– Син Чиләбе тарихын яхшы беләсең икән, Дилбәр.

– Мин сиңа аның турында тагын бер сәгать сөйли алган булыр идем.

– Махсус кызыксындыңмы, каян барысын да белеп бетердең?

– Шәһәр тарихы турында курс эше язган идем. Күп казынырга туры килде, – дип аңлатты кыз.

Алар инде елгага кадәр ярты юлны уздылар. Сөйләшә торгач, юлның кыскара баруын сизми дә калдылар. Менә аста, үзән кырыйлап, товар төягән поезд үтеп китте. Тәгәрмәчләрнең тык-тык бәреп барган тавышы зәгыйфь кенә аларга да ишетелә иде. Гафур кызның кулын үз кулына алды. Дилбәр карышмады. Бер-береңә орыну аларны тагын да якынайта төште. Кызның бу хәрәкәтне кабул итүе күп нәрсә турында сөйли иде. Димәк, Дилбәр дә Гафурны якын итә, аңа битараф түгел. Гафур күңелендә кузгалган хисләрен кызга әйтергә теләсә дә, бу хакта сүз башларга батырчылык итмәде. Аларга катнашы булмаган сораулар биреп, әңгәмәне дәвам итте:

– Дилбәр, хәзерге көндә Чиләбе нинди шәһәр? Шул турыда сөйлә әле.

– Дөресен генә әйткәндә, Чиләбене илнең эш аты дисәң бер дә ялгышу булмас. Аны заводлар басып киткән. Бөтен тормыш шуларны тәэмин итүгә көйләнгән. Бөек Ватан сугышы вакытында Чиләбе трактор заводы, берничә эвакуацияләнгән завод белән кушылып, фронт өчен танклар җитештерүгә күчә. Аны хәтта халыкта Танкоград дип атап йөртә башлыйлар. Фашистларның котын алган «Катюша»лар Чиләбедә эшләп чыгарыла. Кыскасы, сугыш вакытында андагы заводларда патроннар, миналар, бомбалар, фугаслар, реактив снарядлар кебек кораллар җитештерелә. Сугыш ахырында һәрбер өченче танк, самолёт Чиләбедә эретелгән корычтан эшләнә...

Кыз кинәт, сөйләүдән туктап, Гафурга карады:

– Гафу ит, бәлки, болар сиңа кызык та түгелдер?

– Сөйлә, сөйлә... Бик кызык. Мин бит моңарчы Чиләбе турында берни белми идем. Менә син нинди калада яшисең икән.

– Промышленность үзәген тәшкил иткән калада яшим, – дип, киная белән әйтеп куйды кыз. – Игътибар үзәгендә заводлар булгач, халыкның тормыш-көнкүрешен кайгырту читтә кала бирә. Шәһәр нигездә беренче бишьеллыкларда ашык-пошык төзелгән беркатлы йортлардан тора. Бары тик соңрак чорда гына шәһәр үзәгендә, заводлар тирәсендә күпкатлы йортлар төзелә. Шул сәбәпле хәзерге көндә Чиләбенең элекке панорамасы акрынлап үзгәрә башлады.

– Алайса, син инде йөзе яхшы якка үзгәрә башлаган калада яшисең, – дип, шаяртып алды Гафур.

Дилбәр моңа каршы бер сүз дә әйтмәде. Алар инде тимер юл тасмасына җитеп, аны аркылы чыгалар иде. Яшеллек дөньясына аяк бастылар. Үлән арасында салынган сукмактан су буена юнәлделәр. Тиздән елгага да килеп җиттеләр. Биредә яшел үлән белән капланган бик матур тигез урын бар иде. Гафур кызны шунда алып килде.

– Менә шушы инде ул безнең коена коена торган урын. – Ул куллары белән елгага, әйләнә-тирәдәге агачларга күрсәтте.

Бу матур, аулак урын иде. Алардан башка монда беркем юк. Дилбәр беравык тиз агымлы, чоңгыллар ясап аккан елгага, аның ярларында куе булып үскән агачларга сокланып карап торды. Әмма кызда ниндидер уңайсызлану да бар иде шикелле. Күптән түгел танышкан егет белән мондый аулак җиргә килеп чыгу кызны бераз каушаткан иде шикелле. Дәшми тормас өчен Дилбәр:

– Чыннан да, матур җир икән... Елганың агымы бик көчле, коеныргга курыкмыйсызмы? – дип сорады.

– Курыккач солдат буламыни ул, – дип, Гафур шаярып җавап бирде.

Алар чирәм өстенә утырдылар да бөтерелеп аккан суга карап тынып калдылар. Бераз дәшми утыргач, Дилбәр:

– Гафур, менә синең тиздән хезмәт срогың тула. Армиядән соң нишләргә уйлыйсың?

Гафур өчен бу әлегә төп сорау иде.

– Катлаулы сорау бирдең син, Дилбәр.

– Нигә Казанга укырга китмәдең? Син бит укытучылар семьясыннан.

Гафур сорауга ничек бар шулай, ихлас җавап бирергә булды.

– Беләсеңме, Дилбәр, мәктәпне тәмамлаганда мин үземнең киләчәктә кем булырга теләвемне ачык кына белми идем. Ә теләсә кайсы вузга керәсем килмәде. Профессияне дөрес сайламасаң, гомер буе газапланып яшәргә туры киләчәк. Шулай түгелмени?

– Шулай, Гафур. Тамак туйдыру өчен генә эшләп йөрү гомер буе рухсыз яшәүгә тиң.

– Менә шул-шул...

– Ә хәзер бу мәсьәләне ачыкладыңмы соң?

– Нәрсә дип әйтергә дә белмим... Мин мәктәптә укыган елларда да, армиягә алынгач та, бик күп матур әдәбият укыдым. Бигрәк тә романнар укырга яратам. Кыскасы, мине әдәбият бик кызыксындыра.

– Шулай булгач, армиядән соң тот та университетка кер.

– Филология хатын-кыз профессиясе бит ул. Әнә, әнием мәктәптә гомер буе рус теле белән әдәбият укытты. Ул аңа, хатын-кызга килешеп тора.

– Фәнни эш белән шөгыльләнерсең.

– Армиядән кайткач, башта эш табарга кирәк булыр. Әти-әни картаеп баралар, алар өстендә яшәп булмас. Минем энекәш тә бар бит әле.

– Ничә яшьтә?

– Бер елдан мәктәпне бетерә.

– Хәзер бит эшли-эшли уку мөмкинлеге дә бар. Шәһәрдә берәр эшкә урнашырсың, укырга да керерсең.

– Армиядән кайтыйм әле, анда күз күрер...

Бу көтелмәгән сөйләшү аларны тагын да якынайта төште. Дилбәрнең аны кайгыртып сөйләгән сүзләре аны гаҗәпкә салды. Бер уйлаганда, кем инде ул аңа, очраклы танышу, очраклы танышлык. Очраклымы соң? Гафур сизә, Дилбәр белән ике арада аларны бер-берсенә бәйләп торган ниндидер күзгә күренмәс җепләр барлыкка килде. Гафур кызга якынрак утырды, сак кына аны биленнән тотты. Кыз, кирәкми, дип читкә тайпылмады. Егетнең җылы кулы кызның нечкә билендә калды. Аларның иңнәре бер-берсенә тоташты. Бу якынлыктан Гафурның йөрәге ашкынып тибәргә тотынды, күңелендә Дилбәрне сөю, үз итәсе килү хисе уянды. Ул кызны сак кына үзенә тартты, башлары якынайды, Гафур яратуга сусаган иреннәрен аның яңагына тидерде. Шунда Дилбәр көтмәгәндә аңа таба борылды, кайнар иреннәр бергә кушылды. Бу татлы халәт күпме дәвам иткәндер, кыз белән егет аны уйлау хәлендә түгелләр иде. Әмма ул Гафурның:

– Дилбәр, мин сине сөям, – дигән пышылдавы белән төгәлләнде.

Кыз аңа җавап бирмәде, бите уттай яна, карашы аяк очына төбәлгән. Гафурның күзләренә борылып карарга аның кыюлыгы җитмәде. Гафур исә аның колагына йөрәгеннән чыккан сүзләрне пышылдавын дәвам итте:

– Дилбәр, син шундый гүзәл, күңелемә шундый якын, сине очратуыма мин бик шатмын.

Кыз, хисси халәттән чыгу өчен, юри шаяруга күчеп:

– Кай арада мин сиңа якын булып киттем соң әле, Гафур? – диде.

Кызның «Гафур» диюе мин дә сине сөям, дигәндәй яңгырады.

– Дилбәр, син мине әллә нишләттең... Онытa алмаслык иттең...

– Өйгә кайтып китсәм, шундук онытырсың әле...

– Юк, Дилбәр, мин сине инде оныта алмам...

Дилбәр кинәт аягына торып басты. Җыерылган итәген төзәткәләде. Гафур да урыныннан торды.

– Безгә кайтырга вакыт, апам озак йөрмәгез, дип калды, – диде кыз һәм килгән сукмактан кире китте. Гафур аңа иярде. Аның йөрәге әле тынычланып җитә алмыйча тибә иде.

* * *

Дилбәр апаларында бер атна торам дип әйтсә дә, кунак булуы ун көнгә сузылды. Бәлки, аның Гафур белән аерылышасы килмәгәндер. Алар хәзер көн дә очрашалар иде. Гафур частьтагы эшләрен көйләп, көненә бер Дилбәр янына килми калмый. Дилбәр биредә башка барыр җир булмаганга, егетне гел өйдә көтеп утыра, ул килгәч, балалар кебек шатлана. Хуҗалар эштә чакта ялгыз да очрашалар иде. Бу хәл аларны бик якынайтты. Дилбәр инде Гафурны үз итеп каршылый, аның килүенә сөенүен яшерми, егетнең кочагына керүгә дә күнегеп китте. Бу көннәрдә алар бик күп нәрсәләр турында сөйләштеләр. Шушы сөйләшүләр аларның тормышка карашлары да бик якын икәнне күрсәтте. Берәр нәрсә турында сүз чыкса, алар тиз аңлашалар, бик тиз бер фикергә киләләр иде. Яшьләрнең шулай якынаеп китүенә Закирҗан абый белән Кадрия ханым бик сөенәләр иде. Гафур белән Дилбәрнең шулай якынаеп китүенә бигрәк тә Кадрия ханым өмет белән карый, ул аларны бер-берсенә тиң парлар дип саный. Дилбәр бик ачылып сөйләмәсә дә, Чиләбедәге Хафиз абыйсына бу хакта хат та язып җибәрергә уйлап куйды.

Санаулы көннәр бик тиз үтеп китте. Дилбәрнең кайтып китү көне дә килеп җитте. Яшьләр соңгы тапкыр күрешкәндә адресларын алыштылар, бер-берсенә хат язышып торырга сүз куештылар. Дилбәр Гафурның ярты елдан армиядән кайтасын белә, шуны истә тотып, ул:

– Гафур, армиядән кайтышлый бездә, Чиләбедә тукталсаң, тагын бер күрешер идек. Әтием-әнием белән дә танышыр идең, – дигән тәкъдим ясады.

Кыз ягыннан бу шактый тәвәккәл адым иде. Гафур беренче минутта хәтта ни дип җавап бирергә дә белмәде. Ул шуны аңлады – әтисе-әнисе белән таныштырырга әзер булгач, Дилбәр аны чыннан да үз итә, югалтасы килми икән.

– Белмим шул, Дилбәр. Алар мине бөтенләй белми, уңайсыз булмасмы?

– Нигә уңайсыз булсын инде... Ул турыда уйлама. Мин аларны әзерләп куярмын. Үз уллары кебек кабул итәрләр.

– Барыбер уңайсыз... Аннан соң самолёт Улан-Удэдан Чиләбегә оча микән? Анысы да билгеле түгел.

– Анысын ачыклау кыен түгел. Самолёт булмаса, минем шикелле, поезд белән кайтырсың. Солдатка билет бушлай ич!

– Ярар, аңа хәтле әле ярты ел бар. Уйлашырбыз, – диде Гафур, кызның йомшак кулын учына алып. – Ә чакыруың өчен рәхмәт. Кыю кыз син, сөеклем.

Сөйләшү шуның белән тәгәлләнде. Иртәгесен Закирҗан абый, каяндыр машина юнәтеп, Дилбәрне Улан-Удэдан Мәскәүгә китүче поездга алып

китте. Озатырга Гафур да килде. Кеше янында әллә ни сөйләшеп булмады. Дилбәрнең күңеле күтәренке түгел иде. Гафурга хәтта кызның күңеле тулгандай тоелды. Аның соңгы сүзе: «Хат язып тор!» – булды. Гафур үзе дә, аерылышу моңсулыгын яшерергә теләп, Дилбәрне елмаеп озатырга тырышты. Дилбәр китте, ул китү белән Гафур үзе өчен бик кадерле бер асыл заттан аерылганын, аның белән кичергән бәхеттән мәхрүм булып калуын сизде. Кыз аның күңеленә бик тирән кереп урнашырга өлгерде шул. Шушы санаулы көннәрдә Дилбәр аның бик кадерле кешесенә әверелде. Киләчәктә ул аңардан башка ничек яшәр? Язмышы нинди юллардан китәр? Ул әле боларның берсен дә күз алдына китерми иде.

Дилбәр китеп, ике атна үтүгә, Гафур өйдән җан өшеткеч телеграмма алды. Телеграмманы әтисе салган. Анда: «Улым, бездә зур кайгы. Әниең вафат булды. Сине көтәбез», – диелгән иде. Телеграмманы укыгач, Гафур егылып китә язды. Аның җаны бу хәбәрне кабул итмәде. Башында мизгел эчендә уннарча сорау туды. Аның моңа ышанасы килмәде. Телеграмманы кат-кат укыды. Күз алдына сары чәчләрен матур итеп тараган, ак якалы тыйнак укытучылар күлмәге кигән әнисе килеп басты... Ничек инде аның әнисе үлеп китә алсын... Йөрәге кысылып-кысылып, авыртып типте. Бу мөмкин түгел... Әмма кулындагы телеграмма хәлнең башка икәнен тәкърарлый иде. Гафур телеграмманың салынган көненә игътибар итте. Ул кичә салынган булып чыкты. Ара ерак, Гафур кулына килеп кергәнче бер тәүлек узган. Татарда мәетне тиз күмәләр. Бәлки, инде әнисе җир куенына кереп, гүр иясе дә булгандыр, дип ачынып уйлап куйды ул. Эссе җәй уртасы, аның кайтканын көтеп тормаслар...

Гафур штабка йөгерде. Андагы Строевой отдел дип аталган бүлеккә керде. Бәхеткә, капитан Беляев урынында булып чыкты. Гафур килеп керүгә, капитан, өстәлендәге кәгазьләрдән башын күтәреп, аңа текәлде. Гафур дулкынланган тавыш белән:

– Иптәш капитан, мин өйдән телеграмма алдым, – диде һәм аны капитан Беляевка сузды.

Такыр башлы капитан телеграмманы укып чыкты, Гафурга күтәрелеп карады да текстка тагын бер күз салды:

– Кайгыңны уртаклашам, Нигматуллин. Әнисез калгансың икән... Әниләр бер генә була шул...

Гафур эндәшмәде. Аның йөзе агарынган, йөрәге ярсып тибә иде. Капитан тагын аңа карады:

– Нишләмәкче буласың?

– Миңа срочно өйгә кайтырга кирәк, иптәш капитан.

– Аңлыйм, тик ара бик ерак бит, Нигматуллин. Күмәргә барыбер кайтып җитә алмассың.

– Анысы шулай. Барыбер кайтырга кирәк. Юл документларын әзерләп бирсәгезче.

– Син Татариядән бит әле.

– Әйе.

– Казанга туры рейс юк бит, Нигматуллин. Мәскәү аша кайтырга туры киләчәк.

– Барыбер кайтам.

– Үтенечеңне кире кага алмыйм. Очрагы шундый. Бер сәгатьтән керерсең, барысы да әзер булыр.

– Рәхмәт, иптәш капитан.

– Әниеңә ничә яшь иде?

– Быел җәен алтмыш тула иде.

– Иртә киткән. Тагын бер кат кайгыңны уртаклашам, штаб начальнигына әйтеп кит. Капитан Никифоровтан белеш, берәр машина Улан-Удэга бармый микән.

– Яхшы. Рәхмәт сезгә, иптәш капитан.

Гафур, чыгып киткәнче, штаб начальнигы подполковник Горохов кабинетына сугылды. Тик ул урынында юк иде. «Әй, капитан Беляев үзе әйтер әле», – дип, КППдагы егетләре янына ашыкты. Аларга хәлне кыска гына сөйләп бирде, графикны бозмыйча дежур торырга боерып, үзе урынына кече сержант Морозовны калдырды. Морозов әле яңа гына кече сержант дәрәҗәсен алган иде. Ул, ризалыгын белдереп, баш кагып куйды. Аннан Гафур ротага ашыкты, тик анда барып җитмәде, автохуҗалык белән идарә итүче капитан Никифоровны эзләп китте. Бәхеткә, аны гаражлар янында очратты. Аңа да үз хәлен сөйләп бирде.

– Улан-Удэга баручы берәр машина юкмы? – дип сорады.

Капитан Никифоров:

– Менә төштән соң ипи алырга машина җибәрәбез. Бүген чәршәмбе бит, – диде.

– Ах, башка, – дип, Гафур маңгаена сугып алды. – Бөтенләй хәтердән чыккан. Чәршәмбе шул, рәхмәт, иптәш капитан.

– Кайгыңны уртаклашам. Хәерле юл сиңа, – дип капитан аның артыннан карап калды.

Гафур, ротага кереп, тиз-тиз җыенды да штабка йөгерде. Анда документлар әзер булганны бераз көтәргә туры килде. Ниһаять, ул, тиешле документларны алып, КППга ашыкты. Ипи машинасы КПП капкасы аша уза, аны шунда тотарга иде исәбе. Төштән соң шул машинага утырып Улан-Удэга чыгып китте. Аның йөрәге ашкына, тизрәк калага барып җитеп, аэродромда билет алып, самолётка кереп утырасы, туган ягына очасы килә иде аның. Кызганычка, әнисен инде җирләгәннәр, Гафурны анда яңа кабер генә көтәдер. Тик Гафур әле моны күз алдына да китерә алмый, алтын чәчле әнисе тере килеш гел аңа карап елмаеп тора кебек иде.

Улан-Удэдан Мәскәүгә очкан самолёт, ярты юлны үткәч, Омскида туктап, өстәмә ягулык, яңа пассажирлар алды да юлын дәвам итте. Мәскәүгә ул, тугыз мең чакрым араны узып, кичен генә килеп җитте. Самолёт башкала аэропортына төшкәч, Гафур шуннан туры Казанга очмакчы иде, тик аннан Казанга очучы рейслар ачыкланды. Аңа икенче аэропортка барырга киңәш иттеләр. Күпме вакыт сарыф итеп, башкаланы аркылы кичеп дигәндәй, икенче аэропортка ул төн җиткәндә генә барып ирешге. Төнне аэропортның зур залында йокламыйча урындыкта бөгәрләнеп утырып чыкты. Иртәгесен Казанга очты. Казанда тимер юл вокзалында Арча поездына утырды. Арчадан алар ягына автобуслар йөрми иде. Юл читендә шул якка кайтучы берәр транспорт ауларга туры килде. Көтә торгач, ниһаять, бер машинага эләкте, анысы да алар авылына барып җитми иде. Гафурга кыздырган кояш астында бәйрәмнәрдә генә кия торган калын кительдән, күн итектән тагын җиде чакрым җәяү кайтырга туры килде. Шулай итеп, төн йокламыйча, арып-талып, шабыр тиргә батып, аңа икенче көнне төштән соң гына авылына кайтып җитәргә насыйп булды.

Авылга якынлашып килгәндә, Гафурга әнисе үлмәгән, аны өйдә көтеп торадыр сыман тоелды. Аның вафат булуына һаман ышанасы килми иде. Менә

Гафур капканы ачып керер дә ишегалдында бауга керләр элеп йөргән әнисен күреп алыр. Әнисе көтелмәгән очрашудан кычкырып куяр, йөгереп килеп аны кочагына алыр, шатлыктан зәңгәр күзләре яшьләнер...

Гафур үзенең авылга солдат киемендә кайтып килүен искәреп алды. Гади рядовой да түгел, сержант бит. Авылга керер алдыннан күперне чыккач, ул инеш ярына төште, салкын су белән битен, муенын юды. Кайтуының сәбәбе зур кайгы булса да, туган авылы урамына юлда өшәнгән килеш, арыган кыяфәт белән килеп керәсе килмәде. Клубка җитәрәк аңа колхозда егерме ел буе бухгалтер булып эшләгән, хәзер инде пенсиягә чыккан Госман абый очрады. Гафур белән беренче булып үзе исәнләште дә:

– Кайтып киләсеңме, улым... Өлгермәдең шул, әниеңне инде илтеп тапшырдык. Нишләмәк кирәк... – диде.

Ул кайтып кергәндә, әтисе белән Зөлхәбирә апасы (әтисенең сеңлесе) өйдә иделәр. Аны күргәч, нык сөенештеләр. Ничек кайтуын сораштыра башладылар. Гафур сорауларга теләр-теләмәс кенә җавап бирде, бу минутта мондый сораулар аңа урынсыз тоелды. Зөлхәбирә апасы чәй куеп җибәрде. Әтисе үз уйларына кереп чумган, бик боек күренә иде.

– Менә, улым, ятим калдык, – диде ул. Гафурга ул бөтенләй югалып калгандай тоелды.

– Ничек болай булды соң? Авырып та йөрми иде? – дип сорады Гафур, гаҗиз булып.

Әтисе җавап бирмәде, күзен челт-мелт йомгалап, бер ноктага төбәлде. Аның урынына Зөлхәбирә апасы сөйләп китте. Ул мәктәптә башлангыч классларны укыта. Ул көнне мәктәптә нәрсә булганны яхшы белә иде.

Асылда исә хәл болай була. Мәктәпкә районнан роно мөдире килеп төшкәч, директор укытучыларны ашыгыч рәвештә педсоветка җыя. Август башы булганга, укытучыларның күпчелеге авылда була. Директор роно мөдире Зөһрә Камиловнаның җитди мәсьәлә белән килүен искәртеп, беренче итеп сүзне аңа бирә. Роно мөдире укытучыларга шактый кырыс холыклы, үз сүзен бирми торган ханым буларак билгеле иде. Ул, аягына торып басып, җыелган укытучыларга күз йөртеп чыкканнан соң, мәсьәләне кабыргасы белән куя:

– Быелгы уку елыннан сезнең мәктәптә кайбер класслар русча укуга күчәргә тиешләр, – дип башлый ул сүзен. – Бу – безнең алга министрлык куйган таләп, без моны үтәми кала алмыйбыз. Укулар башланырга вакыт аз калды, шуңа күрә әзерлек чараларын күреп өлгерергә кирәк. – Ул, озын өстәл артына тезелешеп утырган укытучыларга күз йөртеп чыкканнан соң: – Бәлки, параллель рус һәм татар класслары булдыру турында да уйлап карарга кирәктер...

Сүзгә, әле өч ел гына директор вазифаларын башкаручы, яшь директор Рөстәм Хәмитович та кушыла:

– Кем чыгыш ясарга тели, иптәшләр? Бәлки, эшлекле тәкъдимнәр бардыр?

– Дәреслекләр вакытында кайтып җитәчәкме? – дип кызыксына физика укытучысы. – Юкса бит балаларга татарчадан русчага күчү, яңа төшенчәләрне, терминнарны үзләштерү авырга туры киләчәк.

– Дәреслекләр вакытында кайтып җитәр. Монысын мин үз өстемә алам, – дип җавап бирә роно мөдире.

Педсоветны алып баручы Рөстәм Хәмитович:

– Тагын кемдә нинди сораулар бар? – дип кызыксына, укытучыларга күз йөртеп чыга.

Шулвакыт Суфия ханым урыныннан күтәрелә:

– Миңа укыту барышындагы бу үзгәрешләр кыенлык тудырмаячак. Мин болай да балаларга рус теле белән әдәбиятын укытам. Әмма ләкин миңа бер нәрсә аңлашылып җитми... Гомер-гомергә саф татар мәктәбе булып килгән мәктәптә ни сәбәпле укытуны рус теленә күчерергә кирәк булды? Моңа нинди ихтыяҗ бар? Минем шуны аңлыйсым килә...

Маңгайга бәреп әйтелгән бу сораулар роно мөдиренә ошамый, тик ул тыныч калырга тырыша:

– Беренчедән, югары уку йортларына керүче балаларга рус телендә имтихан бирү җиңел булачак. Икенчедән, совет кешесе, нинди милләттән булуына карамастан, беренче чиратта, рус телен әйбәт белергә тиеш. Министрлык безнең алга шундый таләп куя. Бу – хәзер гомуми тенденция.

– Белүемчә, моңа хәтле милли мәктәп тәмамлаган укучыларга имтиханнарны үз телендә тапшыру рөхсәт ителә иде. Бу закон хәзер гамәлдән чыгарылмый торгандыр бит? – дип сорый Суфия ханым.

– Юк, әлегә ул гамәлдә. Әмма сынауларны рус телендә бирү уңайлырак, хәтта ул престижныйрак дип саныйм. Милли мәктәптә рус телен үзләштерүгә хәзер игътибар арта бара. Гомумән, хәзерге вакытта рус теле совет халкының төп теленә әверелә барганны үзегез дә сизәсездер. Бу – заман таләбе.

– Сезнең сүзләрегездән чыгып фикер йөртсәк, киләчәктә милли телләрнең акрынлап кысылуы, яшәү сферасыннан төшеп калып, юкка чыга баруы күздә тотыла икән. Шулай түгелме?

Сөйләшүнең хәтәр юнәлешкә кереп баруын сизеп алган роно мөдире аны тизрәк йомып куярга тырыша:

– Юк, мин алай димәдем, – дип баш тарта ул.

Мәктәп директоры роно мөдиренә ярдәмгә килергә ашыга:

– Суфия Әнвәровна, сез юкка борчыласыз. Мәсьәлә сезнең предметка бөтенләй кагылмый бит.

– Мин үз предметым турында сөйләмим. Сүз монда, Зөһрә Камиловна әйткәнчә, безнең күз алдында барган гомуми тенденция хакында бара. Әгәр дә шушы тенденция шулай дәвам итсә, ә ул дәвам итәчәк һәм көчәя барачак, безнең туган телебез ни хәлдә калачак соң? Классларны рус телендә укытуга күчерү балаларны туган телдән аермасмы? Русча укып чыккан бала төрле фәннәр турында үз телендә сөйли дә, яза да алмаячак. Бу киләчәктә татар техник интеллигенциясенең фәкать рус телендә генә фикер йөртүенә китерәчәк. Бик хәтәр тенденция дип әйтер идем мин моны. Кыскасы, мин мәктәптә рус класслары булдыруга каршы.

Суфия ханымның кискен сүзләре педсоветта бомба шартлагандай яңгырый. Роно мөдире белән директор, куркынышып, бер-берсенә карашып алалар. Барлыкка килгән киеренке вазгыятькә ашыгыч бәя бирергә кирәк була. Мәктәп директоры, педсоветны алып баручы буларак, үзе дә сизмәстән урыныннан күтәрелә дә:

– Суфия Әнвәровна, сезнең бу чыгышыгызны мин милләтче чыгышы дип саныйм. Сез бу чыгышыгыз белән бөек рус телендә укытуга каршы чыктыгыз. Милләтчелеккә бирелгән кеше буларак, үз йөзегезне тулысынча ачып салдыгыз. Утырыгыз. Алда әле сезнең белән сүз булачак,– дип, Суфия ханымга төртеп күрсәтә. Аннан хуплау өмет итеп, роно мөдиренә карый. Тегесе, дөрес эшләдең дигәндәй, баш кагып куя.

Әмма Суфия ханым куркып та, югалып та калмый. Ул элеккечә басып тора, тик йөзенә кызыл тимгелләр генә бәреп чыга.

– Мине беркем дә милләтчелектә гаепли алмый. Юкка тырышасыз, Рөстәм Хәмитович. Мин гомерем буе татар балаларына бөек рус теле белән бөек рус әдәбияты укыттым. Мин укыткан балалар рус теле, рус әдәбияты буенча үткәрелгән олимпиадаларда җиңеп чыгалар, дипломнар алалар. Гомумән, безнең илдә рус телен белми калу мөмкин түгел. Ул – СССР халыкларының үзара аралашу теле. Ул безнең мәктәптә дә дәрәҗәле урында. Без, татарлар, рус телен яхшы белгән хәлдә, үз телебезне дә сакларга, үстерергә тиешбез. СССР – күпмилләтле бөек дәүләт, һәм һәр милләт вәкиле шушы дус халыклар гаиләсендә яшәве белән горурлана. – Суфия ханым тирән итеп сулыш ала, тик сүзен тәмамларга җыенмый. Ул, директорның куркынган йөзенә туры карап:
– Менә сез, Рөстәм Хәмитович, миңа милләтче мөһере суктыгыз. Әйтегез әле, зинһар, сез саф татар мәктәбендә укытуны рус теленә күчерүне уңай күренеш, дип саныйсызмы? Болай без үз телебезне саклый алырбызмы?

Директор бөтенләй каушап кала, ярдәм сорап роно мөдиренә карый. Ә тегесе, кара коелып, дәшмичә утыруын белә. Ул педсовет, башка мәктәпләрдәге кебек, шома гына үтәр дип уйлаган иде. Тик алай булып чыкмады. Күп еллар шушы мәктәптә укыткан, мәктәпнең горурлыгы саналган, дистәләгән мактау грамоталары алган бу абруйлы укытучының авызын томалау алай җиңел эш түгел иде. Әйдә, сөйләсен, барысы да беркетмәгә язылып бара, соңыннан чарасын күрербез, дип уйлап утыра ул. Ә директор ык-мык итә, тик кайтарып Суфия Әнвәровнага дәлилле сүз әйтә алмый.

Суфия ханым исә үз соравына үзе җавап бирергә керешә:

– Беләсегез килсә, Рөстәм Хәмитович, үз халкыңны ярату, аны милләт буларак саклап калырга тырышу, үсешенә бөтен көчеңне биреп ярдәм итүне патриотизм дип атыйлар. Ә безнең халкыбыз – татар халкы. Димәк, без, үз халкыбызга хезмәт итүчеләр, барыбыз да патриотлар булып чыгабыз. Менә мин, рус теле, рус әдәбиятын укытучы педагог буларак, хәлемнән килгәнчә үз халкымны рус халкы белән якынайтырга тырыштым. Сезнеңчә ничек, милләтчеме мин, әллә патриотмы?

Шушы сүзләрдән соң Суфия ханым урынына утыра. Аның йөзе кызарган, маңгаена бөрчек-бөрчек тир бәреп чыккан.

Суфия ханым сүзен тәмамлауга, Зөһрә Камиловна вазгыятьне үз кулына алырга ашыга. Урыныннан торып, көчәнеп елмая да:

– Тагын сөйләүчеләр бармы? – дип сорый. Педсовет барган бүлмәдә тирән тынлык хөкем сөрә. Мондый ялкынлы чыгыштан соң ни әйтергә мөмкин. – Димәк, башка сүз алучы юк. Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә тиешмен: Суфия Әнвәровнаның чыгышы ул – бер педагогның гына фикере. Ә мәктәп коллективының фикере уңай булуда шигем юк. Шулай итеп, быелгы уку елыннан кайбер класслар русча укуга күчәчәк. Кабатлап әйтәм, бу – без уйлап чыгарган нәрсә түгел, ә министрлык таләбе. Без аны, һичшиксез, тормышка ашырырга тиеш. Кайсы классларны русча укытуга күчерү турында киңәшкәч, һәммәбезгә хәбәр итәрсез. Ә дәреслекләр тиздән кайтып җитәчәк.

Ул, директорга күз салып, урынына утыра. Директор дилбегәне үз кулына алырга ашыга:

– Тиздән август киңәшмәләре башлана, барлык педагогларның да актив катнашуын үтенәм. Шушының белән бүгенге педсовет утырышы тәмам, дип белдерәм. – Шулай педсовет утырышына нокта куела.

Халык тиз-тиз тарала башлагач, Рөстәм Хәмитович роно мөдирен үз кабинетына алып кереп китә. Мәктәптә бит барысын да белеп торалар.

Директорның анда Зөһрә Камиловна өчен әзерләп куйган сый өстәле булуы да сер булып калмый. Авыр педсоветтан соң ял итеп утырганда, Суфия Әнвәровнаның чыгышы турында да киңәшеп аласы бар. Бик уңайсыз ханым. Аннан тизрәк котылу җаен табарга кирәк. Яше күптән җиткән, пенсиягә озатмыйча булмас, дип эчтән генә үзенчә уйлап йөри иде инде директор. Бу мәсьәләне бары тик роно мөдире белән килештерәсе генә калган иде.

Педсоветтан соң әнисенең кан басымы күтәрелүен, төне буе йөрәгенә зарланып чыгуын һәм иртәнге якта кинәт өзелеп китүен Гафурга кыска гына итеп әтисе әйтте. Дөрес, ул хатыны белән кичен ике арада булып алган кискен бәхәс турында бер сүз дә әйтмәде. Суфиясы кайбер классларны русча укытуга күчерүгә каршы чыгуы турында сөйләгәч, Кәрим Фатыйхович аны сүгеп ташлаган иде. «Сиңа нигә кысылырга кирәк иде. Гомер буе тыныч яшәргә өйрәнә алмадың инде. Син чыгыш ясаганга карап, әллә берәр нәрсә үзгәрер, дип уйлыйсыңмы...» – дип, бик нык ачуы чыгып, хатынын гаепләде. Бәлки, бу сөйләшү аның хәлен тагын да авырайткандыр. Шуңа күрә Кәрим Фатыйхович бу хакта сүз кузгатмады. Ул кичтә алар аерым урыннарда яттылар. Гафур исә әнисен яхшы белсә дә, апасының педсоветта булган хәлне бәйнә-бәйнә сөйләп чыгуы аңа әнисен яңа яктан ачып җибәрде. Ул моңарчы да әнисенең батыр йөрәкле шәхес булуын белә иде. Ә бу очракта ул, гомумән, аның күз алдына чын көрәшче сыйфатында килеп басты. Кеше тик торганда педсовет утырышыннан соң дөньядан китми шул. Димәк, әнисе анда күп еллар уйлап йөргән сүзләрен әйткән, үзен аямыйча, барысын да әйтеп салган.

Бергәләп ашап-эчкәннән соң, Гафур:

– Мин зиратка барам, – диде.

Әтисе:

– Әйдә, улым, бергә барыйк, – дип караса да, Гафур: – Юк, үзем генә барыйм әле, – дигәч, берәү дә каршы төшмәде. Аның кичерешләрен аңладылар, үзе генә әнисе белән хушлашырга телидер, дип уйладылар.

Зиратта күптән түгел җирләнгәннәр рәтендә яңа кабер аерылып, күзгә бәрелеп тора иде. Әнисе кабере башына утыртылган шомартылган тактага шәмәхә карандаш белән үлгән көне дә язылган. Бу вакытлыча куелган такта иде.

Гафур кителенең өске төймәләрен чишеп җибәреп, янәшәдәге кабер янына куелган озын урындыкка килеп утырды. Башыннан фуражкасын салды. Кабердә аның иң якын кешесе – кадерле әнисе ята. Ул инде аны беркайчан да тере килеш күрә алмаячак. Әнисе аңа үзен белә башлаганнан бирле акыллы киңәшләре белән ярдәм итеп килде. Үскәндә аның алдына килеп баскан сорауларга гел әнисе җавап бирә иде. Гафур өчен ул юл күрсәтүче булды. Әнисенең иң еш кабатлаган сүзе: «Улым, менә бу китапны укымаган кеше үзен культуралы кеше дип саный алмый», – иде. Чыннан да, Гафур әнисен үзенең рухи остазы дип кабул итә иде. Менә хәзер кабер янында утырганда аның хәтерендә кайчандыр әнисеннән ишеткән кадерле сүзләр, вакыйгалар калкып чыга, җанлана, алар икенче мәгънә, төсмерләр ала башлады. Шул хатирәләр тәэсирендә аның күңеле тулды, күзләре яшьләнде. Каяндыр төптән, күңел түреннән югалту ачысы күтәрелде, Гафур, хисләренә ирек биреп, елап алды. Бу – әнисе белән мәңгегә хушлашу яшьләре иде. Кояшның ялан башны кыздыруын да сизмичә, ул кабер өеменә төбәлгән килеш утыра бирде. Ул үзен япа-ялгызы калгандай хис итте. Әнисе исән чакта дөнья тулы, аһәңле, мәгънәле, матур иде. Менә ул кинәт бушап калды. Моннан соң Гафур ничек яшәр, тормышын ничек корыр... Ул бу

хакта уйламый, уйлыйсы да килми иде. Бу халәтендә ул күңелендә бары тик бушлык – тирән бушлык кына сизде.

Аннан соң әтисе турында уйланып алды. Әтисе тормышта үз урынын таба алмады. Кайчандыр, әнисе кебек, педагогия институтын тәмамлаган, берничә ел мәктәптә тарих укытып караган, аннан колхозда парторг булып эшләгән, хәзер авыл советы рәисе вазифаларын башкара. Йомшак характерлы, фикерен тиз үзгәртүчән, кеше сүзеннән куркып яши торган бер адәм иде аның әтисе. Шуңа күрә халык арасында ныклы абруе да юк. Ул гомер буе нык характерлы, гаделсезлек күрсә, көрәшкә ташланучы хатыны күләгәсендә яшәде. Гомере үз өстенә җаваплылык алудан куркып узды дисәң дә ярыйдыр. Менә энекәше Илдар киләсе елда мәктәпне тәмамлый. Ул кайсы юлдан китәр, Гафур өчен анысы әле ачык түгел...

Гафур туган йортында өч көн торгач, Бурятиягә, хезмәт иткән частена әйләнеп кайтты. Көндәлек мәшәкатьләр аңа күңелендә хасил булган бушлыктан акрынлап арынырга ярдәм итте. Ләкин ул барыбер ялгыз иде. Уйлары белән Дилбәргә әйләнеп кайтты. Аның белән үткән гүзәл көннәрне исенә төшерде. Көтмәгәндә өстенә килеп төшкән кара кайгы турында кызга сөйләп бирәсе, эчен бушатасы килде. Үзе дә аңлап җиткермәстән, ул кыздан кайгысын уртаклашуны өмет итә иде. Дилбәр аның нинди хәлдә калуын, авыр кичерешләрен дөрес аңлар кебек тоелды. Ул аңа хат язып җибәрде. Бу алар арасында беренче хат иде.

Исәнме, кадерлем Дилбәр!

Бу хатны сиңа бик авыр рухи халәттә язам. Безнең семьяга зур фаҗига, кара кайгы килде. Син киткәннән соң, ике атна вакыт үтүгә, өйдән мине тәмам аяктан еккан телеграмма алдым. Анда газиз әниемнең вафат булуы хәбәр ителгән иде. Дилбәр, аңлыйсыңмы, мин әнисез калдым. Иң кадерле кешемне югалттым. Мин авылга кайтып җиткәнче әнием инде җирләнгән иде. Бары аның каберен генә күрергә туры килде.

Әнием минем өчен дөньядагы бар гүзәллекнең мисалы иде. Әти исән-сау булса да, мин хәзер рухи яктан ялгыз. Япа-ялгыз. Әнием мине тудырган, тәрбияләп үстергән ана гына булмыйча, тормышымда бердәнбер киңәшче, рухи остаз ролен үтәп килде. Аның үлеме минем өчен коточкыч зур югалту, аны язып кына аңлатып бетереп булмый.

Армиядән соң авылда калырга җыенмыйм. Әлегә кая китү, нинди эшкә тотыну турында анык кына фикерем юк. Әнинең вафаты йөрәгемдә тирән яра булып калды, гел аның турында уйлыйм. Син беләсең, ярты елдан солдат хезмәтем төгәлләнә. Шулвакыт эчендә нинди дә булса анык фикергә килергә кирәк дип уйлыйм. Без синең белән ул хакта бераз сөйләшкән идек. Укыйсым килә, әмма миңа инде эшләп укырга туры киләчәк. Үземдә барысына да өлгерермен дигән ышаныч сизәм.

Син, сөеклем Дилбәр, минем өчен бик кадерле кешегә әвереледең. Синең белән бергә үткәргән көннәрне гел искә төшерәм, сине сагынып яшим, сөйләшүләребезне оныта алмыйм. Әниемнең вафатыннан соң, син минем өчен иң якын, ышанычлы, бердәнбер кешегә әвереледең. Без бер-беребезне югалтырга тиеш түгел. Хуш, кадерлем, синнән түземсезлек белән хат көтеп калам...

Кыз озак көттермәде, ун көннән Гафурга җавап хаты килде.

Исәнме, Гафур!

Әниеңнең вафат булуы мине тетрәндерде, аны үз кайгым кебек кабул иттем.

Ихлас күңелдән кайгыңны уртаклашам. Хәлеңне, нинди хисләр кичерүеңне аңлыйм. Синең өчен борчылам. Гафур, шуны белеп тор – син ялгыз түгел, сине якын иткән мин барын онытма. Бу һәрвакыт шулай булачак. Өметеңне өзмә, тормыш әле башлана гына. Алда безне зур сынаулар көтә. Кызганыч, әмма якыннарыбыз безне ташлап китә. Югалтулар ничек кенә авыр булмасын, монда без берни эшли алмыйбыз. Тормышны дәвам итәргә кирәк. Әтиең белән рухи яктан чит кешеләр булуыгыз бик кызганыч. Шундый кайгы килгәндә якыннарың арасында таянып кешең булмау бик авыр хәл. Тагын бер кабатлыйм – син ялгыз түгелсең, мин барын онытма!

Мин хәзер өйдә ялгызым калдым. Әти белән әни Пятигорскига ял итәргә киттеләр. Көннәрем, игезәкләр кебек, бер-берсенә охшаганнар. Укулар башланды, лекцияләргә йөрим. Шулай да буш вакытта тарихчы С.М.Соловьёв хезмәтләрен өйрәнәм, кирәк булуы мөмкин урыннарын калын дәфтәремә теркәп барам. Бу тарихчының хезмәтләре миңа бик ошый. Ул үзе турында турыдан-туры: «Я родился историком», – дип яза. Аның хезмәтләрендә тарихи тәнкыйть бик көчле, ягъни ул бернәрсәне дә яшереп калдырмыйча, ничек бар шулай – дөресен язарга омтыла. Аның төп стихиясе – тарихилык. Ул тарихи процессны табигый һәм конкрет вакыйгалар аша күрсәтүне өстен куя. Аның күптомлы «История России с древнейших времён» дигән хезмәтен рус тарихы энциклопедиясе дип атап булыр иде. Әле кичә генә бер фикерен язып куйдым. Бер җирдә ул: «Государство есть необходимая форма для народа, который немыслим без государства», – дип яза. Ә без, татарлар, хокуклары бик тар булган автономияле республикада яшәргә мәҗбүрбез. Ә бит кайчандыр мөстәкыйль дәүләтебез булган... Бу хәл мине үзебезнең тарихны ныклап торып өйрәнергә мәҗбүр итә. Соңгы вакытта башым тарихи вакыйгалар, төрле сюжетлар белән тулды. Мәсәлән, күптән түгел кулыма Иван Грозный заманында яшәгән, 1552 елда Казанны яулап алуда катнашкан воевода Андрей Курбский язмалары килеп керде. Искиткеч кыйммәтле чыганак! Ул анда Казан ханлыгы башкаласының ничек яулап алынуы турында бик кыйммәтле мәгълүматлар бирә. Шушы вакыйганың шаһиты буларак яза. Бу язмаларны Андрей Курбский Иван Грозныйдан Литвага качып киткәннән соң язган, курыкмыйча барысын да сөйләп чыккан. Алар белән танышканнан соң минем күп нәрсәгә күзләрем ачылды. Мине иң гаҗәпкә калдырганы – Иван Грозный исеме белән тарихка кереп калган явыз патшаның Казанны алганда үзен куркакларча тотуы, башкалар кулында курчак булуы, Казанга русларның хәлиткеч һөҗүме вакытында патшаның, татарлар һөҗүменнән куркып, үзен саклар өчен чатыры янында егерме меңлек гаскәр тоту факты булды.

Башым тарих белән шыплап тулгач, бераз ял итү өчен киногa баргалыйм яки классик музыка тыңлыйм. Синең белән булган көннәрне еш искә төшерәм. Чыннан да, бәхетле көннәр иде... Гафур, синең хәзер нинди авыр кичерешләр белән яшәвеңне аңлыйм, бирешмә, үзеңдә рухи көч тап. Мин беләм, син көчле рухлы шәхес. Хатыңны көтеп калам... Дилбәр.

Дилбәрнең хаты Гафурга нык тәэсир итте. Хатны укыганнан соң кыз яңа яклары белән ачылды. Аның турында уйлаганда ул, Дилбәр белән горурланып, сокланып, хәтта аннан көнләшеп тә куйгалады. Дилбәр үз юлын тапкан, илһамланып шул юлдан бара. Ул тарихны белем туплар өчен генә өйрәнми, аның вакыйгаларга үз карашы формалашып килә. Бозып язылган, яшерелгән тарихта ул үз халкының эзен табарга тырыша. Кызда татар рухы уянып килә. Нинди гаҗәп кыз белән танышты бит ул! Бәлки, Дилбәр аның бәхетедер?..

Гафур да моннан соң тарихи хезмәтләргә мөрәҗәгать итәргә, аларны укырга кирәк, дигән карарга килде. Тарихны белмәү, бер яктан, фикер тарлыгына китерсә, икенче яктан, кыз алдында оят иде.

Әнисе аны матур әдәбият аша тәрбияләргә тырышты. Гафур, аның киңәшен тотып, үсмер елларында бик күп әдәби әсәрләр укып чыкты. Белгеч буларак, әнисе аңа рус әдәбиятының иң атаклы әсәрләрен тәкъдим итеп торды, шулай ук татар әдәбияты, чит илләр әдәбиятының иң мәшһүр әсәрләрен дә укыды. Гафур бу яктан гаять белемле, әдәби әсәрләрне күп уку нәтиҗәсендә күңел дөньясы баеган, карашлары киңәйгән, хисләре тәрбияләнгән, уйлау, тормыш күренешләренә анализ ясау сәләте үскән егет иде. Шуңа күрә Дилбәр белән аралашканда ул үзен бик иркен тота, белем ягыннан үзен аңардан бер дә түбән хис итми, хәтта дөнья мәдәниятенә кагылган мәсьәләләрдә кызга караганда киңрәк фикер йөртә иде. Ни әйтсәң дә, тарих ул, бик әһәмиятле фән булса да, таррак өлкә. Шуңа күрә Гафур өченче курсны тәмамлаган Дилбәр белән аралашканда үзендә бернинди кыенсыну сизми иде. Шул хакта уйлый башлагач, ул гомерендә беренче тапкыр мәрхүмә әнисенең аңа нинди зур рухи байлык бүләк итеп калдыруын искәреп алды. Әнисе үзенә генә билгеле план буенча эш иткән булса кирәк. Менә хәзер Гафур шуның нәтиҗәсен күрә, үзен иректле фикер йөртүче шәхес итеп тоя.

Гафур белән Дилбәр хат язышуларын дәвам иттеләр. Килгән бер хат аларның яңа сыйфатларын ача, егет белән кызны тагын да якынайта иде. Укулар башланып, мәшәкатьләре арта төшсә дә, Дилбәр хат язуын сирәгәйтмәде. Гафурның һәр хатына көттермичә җавап биреп торды. Егетнең хезмәт срогы төгәлләнеп килгәндә Дилбәр тагын бер кат Гафурны, кайтышлый Чиләбедә тукталып, үзләрендә кунак булып китәргә чакырды. Тик Гафурның туры үз авылына кайтасы килә иде. Ул Чиләбедә яшәсә, Дилбәр янына килеп-китеп йөрү табигый кабул ителер иде. Тик ул бит кызның ата-анасы өчен бөтенләй ят кеше, армиядән кайтышлый, хәрби киемнән аларга килеп керүне Гафур әдәп кагыйдәләренә сыеп бетми торган эш дип саный, шуңа күрә ул, Дилбәрнең күңелен төшерми генә, кызның тәкъдименнән баш тартты. Хатында: «Башта өйгә кайтыйм әле, андагы хәлләрне белим, соңыннан хәбәрләшербез. Мин сине бик яратам, һич тә югалтасым килми», – дип язды.

Гафурның хезмәт срогы төгәлләнүен белеп торган Закирҗан абыйсы өендә аны озату мәҗлесе оештырырга булды. Бу гаиләдә Гафур белән Дилбәрнең даими хат алышып торуын беләләр, егет белән кызның мөнәсәбәтләре шактый тирәнгә керүен дә чамалыйлар иде. Шуңа күрә Гафурны үз туганнары кебек якын күрәләр, киләчәктә ике яшь йөрәкнең кушылачагына чын күңелдән ышаналар, кайвакытта ярым шаяртып, Дилбәр анда нишләп ята, дип тә сорап куйгалыйлар. Андый сорауга Гафур, елмаеп: «Студент нишләсен, укып йөри...» – дип җавап бирү белән чикләнә иде.

Гадәттәгечә, Кадрия ханым бай табын әзерләгән. Озату мәҗлесе бик күңелле узды. Андый чакта саф татарча сөйләшеп утыру бигрәк тә Закирҗан абыйның күңеленә хуш килә иде. Сүз иярә сүз чыгып, Гафур төзек әдәби телдә Муса Җәлил һәм җәлилчеләрнең фаҗигале язмышы турында сөйләп чыккач:

– И батыр да соң безнең халык... Телебез дә нинди матур, – дип, Закирҗан абый күтәренке хис белән әйтеп куйды. – Тик телебез акрынлап кысыла бара шул. Киләчәктә телебезне ниләр көткәнен бер Ходай белә...

– Үз телеңә җитми инде, – дип өстәде Кадрия ханым.

– Татар бөтен илгә таралып яши шул... Гомер үз халкыбыздан аерылган

килеш уза, – дип, көрсенеп алды Закирҗан абый. – Өйдә балаларга күпме тукып торсак та, барыбер урысча сөйләшергә тырышалар. Хәер, алар әле татарча аңлыйлар, авыррак булса да, татарча сөйләшәләр. Киләчәккә күз салсак, оныкларыбыз кем булып үсәр? Алар бит инде өйдә дә русча сөйләшәчәкләр. Менә бит мәсьәлә ничек тора... Туган телен белмәгән кеше халкыннан аерылган кеше инде ул. Үз халкың белән яшәү зур бәхет икән ул. Аны картая башлагач кына аңлыйсың икән... – Аның соңгы сүзләрендә үз тәҗрибәсе аша ачылган хакыйкать ята иде.

– Сез хәзер өйдә өч ир-ат кына калдыгыз бит инде... Ничек яшәрсез икән? – дип сорады Закирҗан абый, Гафурның әнисез калуына ишарәләп.

– Анысын тормыш үзе күрсәтер... – диде Гафур, аның бу хакта сөйләшәсе килми иде. Закирҗан абый да бу сүзне кузгатуына үкенеп куйды.

Шулай шактый озак утырдылар. Балалар каядыр чыгып киткәннәр иде. Бераздан мәҗлеснең сүрелә башлаганын сизеп алган Кадрия ханым:

– Әйдәгез, бергәләп җырлап алыйк, – диде.

– Нинди җырны? – дип сорады Закирҗан абый.

– Син бит «Ай былбылым»ны яратасың, әйдә шуны җырлыйбыз.

Закирҗан абый белән Гафур да Кадрия ханымга кушылды. Җыр табындагыларны берләштереп яңгырый иде. Аннан соң Кадрия ханым ялгызы берничә җыр башкарды. Күңелләр күтәрелде, күзләр шатлык чаткылары белән тулды.

* * *

Гафур армиягә алынганда хезмәт срогы өч ел иде. Моннан бер ел элек Оборона министрының махсус приказы чыкты. Шул приказда кыска сроклы хезмәттәге хәрбиләрне ике ел хезмәт итүгә күчерү каралган иде. Армиядә өч елдан ике ел хезмәт итүгә күчү процессы башланды. Төрле сәбәпләр аркасында әлеге күчешне тиз генә гамәлгә кертү мөмкин булмаганга, күчеш чорында өч елга хезмәткә алынган солдатларны, вазгыятькә карап, өйләренә иртәрәк тә кайтарып җибәрә башладылар. Гафур да шушы күчеш чорына эләкте, кыш башында өенә кайтасы урында октябрь уртасында армиядән авылына кайтып төште.

...Менә Гафур матур капкалы, такта түбәле өйләренә якынлашып килә. Түбә кыегында элеккечә сыерчык оясы да күренә. Капкага килеп җитеп, Гафур дулкынланган хәлдә аны ачып җибәрде, ишегалдына керде. Монда барысы да элеккечә иде. Бары керләр элү өчен сузылган бауда яңа юылган керләр генә җилфердәми.

Өйдә аны энекәше Илдар каршылады. Өстенә шинель, башына бүрек кигән абыйсын күреп алуга ул, утырган урындыгын аудара язып, аңа ташланды, абыйсын кочып алды. Шулай алар кочаклашкан килеш шактый аерыла алмый тордылар. Гафур өстен салып кительдән генә калгач, абыйсының күкрәгендәге значокларга, сержант погоннарына сокланып карап торды.

– Абый, син бик нык үзгәргәнсең, прямо танырлык та түгел үзеңне, – дип куйды ул, соклануын яшермичә.

Гафур бер сүз дәшмәде, бары көлемсерәп кенә куйды. Ул, чемоданын ачып, аннан кечкенә капчык алды да Илдарга сузды:

– Монысы сиңа Бурятия күчтәнәче, – диде. Самолётка утырыр алдыннан Улан-Удэ аэропортында эрбет чикләвеге сатып алган иде.

Илдар капчыкны кулына алды да:

– Бу нәрсә? – дип абыйсына карады.

– Авызын чиш, күрерсең...

Энекәше, капчыкның бавын чишеп, кулын эчкә тыкты да аннан бер уч нарат кайрысы төсендәге вак чикләвекләр алды. Аның эрбет чикләвеген беренче күрүе иде.

– Бу нәрсә соң, ашый торган әйберме? – дип сорады Илдар.

– Кедр чикләвеге, бик тәмле, файдалы нәрсә, – диде Гафур, аннан энекәшенең учыннан бер чикләвек алып, теш арасына кыстырды. Ватып, эченнән ак төшен алды да Илдарга сузды:

– Мә, татып кара.

Илдар икеләнеп кенә чикләвек төшен авызына капты, чәйнәп карады да:

– Тәмле... май тәме килә, – диде.

Аннан алар өй хәлләре турында сөйләшә башладылар.

– Синең укулар ничек бара? Соңгы елың бит.

– Минеке нормально.

– Әти ничек, эшләп йөриме?

Бу сораудан энекәше ничектер уңайсызланып киткәндәй тоелды, күзләрен абыйсыннан яшерде. Нәрсәдер сизенеп, Гафур төпченә башлады:

– Нәрсә, әллә берәр хәл булдымы? Нигә дәшмисең, күзләремә туры кара әле. – Гафур аның башын үзенә борды.

Энесе башын абыйсы кулыннан ычкындырды да ачу белән:

– Әти Зәмзәмия янына йөри. Кайбер төнне шунда кунып та кала, – дип әйтеп салды.

– Нинди Зәмзәмия?

– Беләсең ич инде, әти белән авыл советында эшли. Секретарь.

Гафур аны шундук исенә төшерде. Зәмзәмия, авыл советында әтисе белән эшләүче, кияүгә чыкмыйча картаеп барган сазаган кыз иде. Ялгызы гына яши. Халык аның турында зәһәр нәрсә, дорфа холыклы кыз, дип сөйли иде. Авыл советы рәисе булып эшләгән әтисен дә үз кубызына биетә дигән сүзләрне дә ишеткәне бар иде Гафурның.

Бу хәбәр Гафурга башына күсәк белән тондыргандай тәэсир итте. Үзе дә сизмәстән:

– Әнине җирләгәнгә әле ярты ел да юк, – дип әйтеп салды. Әтисенең шундый эшкә баруы аны бик нык гарьләндерде. Әнисе истәлегенә хыянәт итүе аңарда нәфрәт уятты.

– Зөлхәбирә апа да әтигә ничә тапкыр әйтте: туктат бу эшеңне, кабып йота ул сине, харап буласың, ди.

– Ә әти?

– Хатын-кыз башың белән ирләр эшенә кысылма, дип кенә җибәрә.

– Өйгә алып кайтканы юкмы?

– Юк, коммунист бит, курка торгандыр.

– Алайса, кереп капкан икән әти... Күр дә тор, Зәмзәмия аны ЗАГСка барырга да мәҗбүр итәчәк.

– Шуңа ук барыр микәнни... Ул чакта без нишләрбез?

– Зәмзәмия безнең өйгә керә дә утыра. Үзенеке көчкә басып тора, тәмам беткән.

– Абый, безгә нишләргә соң?

– Әлегә белмим, әти белән сөйләшеп карармын.

Илдар кичәдән калган ашны керосинкага җылытырга куйды. Гафур аннан:

– Сез ничек яшисез соң? Ашны кем пешерә, керегезне кем юа? – дип сорады.

– Зөлхәбирә апа килеп көн аралаш аш пешереп китә. Кернең вак-төяген үзем юам. Өйрәндем инде, – дип мактанып алды Илдар. – Аш та пешереп караганым бар.

– Әни исән чакта өй гөрләп тора иде. Күңелсездер хәзер.

– Күңел-сез... – дип сузды Илдар.

– Син унны бетергәч нишләмәкче буласың соң? Берәр планың бармы?

– Казанга китәрмен дип торам.

– Кая керергә уйлыйсың?

– Химико-технологическийга яки авыл хуҗалыгы институтына.

– Яхшы. Керергә тырыш. Зәмзәмия килсә, монда сиңа көн булмаячак.

Шулвакыт ишек ачылды, өйгә әтиләре Кәрим Фатыйхович килеп керде. Ул башкалардан үзен олылап Кәрим Фатыйхович дип атауларын таләп итә иде.

– Исән-сау гына кайттыңмы, улым? – дип, ул Гафурны кочагына алды, аркасыннан сөйде. Бераз артка чигенеп, сержант кителен салып өлгермәгән улына тагын бер күз салды. – Үскәнсең, ныгыгансың, чын гвардеец булгансың.

Гафур ни дип әйтергә дә белмәде, бары тик:

– Кайттым менә... – дип кенә куйды.

Ашарга утырдылар. Кәрим Фатыйхович:

– Урамда түбән очның аю Галиәкбәре очрады да: «Нишләп йөрисең, улың армиядән кайтты ич!» – ди. Менә йөгереп дигәндәй кайттым. Ну, ничек соң, юллар бик авыр булмадымы?

– Тагын Мәскәү аша кайтырга туры килде. Бик әйләнеч...

– Бик еракта хезмәт иттең шул. Тугыз мең чакрым. Байкалда. Уйласаң, исең китәрлек...

– Үзеңдә ни хәлләр, әти?

– Бер килеш, улым. Эшләп йөрим.

Илдар, бу сөйләшү нәрсәгә китерер икән дип, тыңлап кына утырды. Ашап бетергәч, савыт-сабаны мич ягына чыгарып куйды да киенеп өйдән чыгып китте. Ул абыйсының әтисе белән сөйләшергә җыенуын онытмаган иде.

Илдар чыгып киткәч, бераз тын гына утырдылар. Сүз ничектер ялганып китми торды. Кәрим Фатыйхович сүзне үзе дәвам итте:

– Менә, улым, хезмәтеңне тутырып өйгә кайттың. Молодец. Армия сине теләсә нинди эшкә яраклы итеп тәрбияләгәндер. Инде ничек яшәргә уйлыйсың? Берәр планың бармы?

– Планнарым әлегә бөтенләй үк ачык түгел. Шуны гына әйтә алам – авылда калырга җыенмыйм.

– Кая китмәкче, нишләмәкче буласың?

– Шәһәргә китәм.

– Казангамы?

– Белмим әле. Бәлки, Казанга, бәлки, башка җиргә.

– Синең яшьтә конкретрак уйларга кирәк, улым.

Гафур әтисенә җавап бирмәде, бераз тын гына утырдылар. Гафур игътибар белән әтисенә күз салды. Менә аның алдында урта буйлы, таза гәүдәле, чәчсез маңгае ялтырап торган, костюмына килешле галстук таккан, алтмыш өч яше тулган ир-ат утыра. Аның әтисе саналган шушы кеше үзеннән егерме биш яшькә яшьрәк, ир-ат назы күрмичә картайган, язмышының барып чыкмавына үчләнеп, дөньяга зәһәрен чәчеп яшәүче карт кызга ияләшкән. Бәлки, аның белән язмышын да бәйләргә җыенадыр.

Тынлык озакка сузылды. Гафур этисе белән бу хакта сөйләшеп карарга булды.

– Әти, мин синең турында кызыклы хәбәр ишеттем, – диде ул, этисенә җитди караш ташлап.

Кәрим Фатыйхович, сүз нәрсә турында барачагын аңласа да, белмәмешкә сабышты:

– Нинди хәбәр, улым?

Гафур сүзен әйткәнче пауза ясады, аннан соң гына әйтеп салды:

– Син, әти, Зәмзәмия янына йөрисең икән. Дөресме шул?

Сорау шактый уңайсыз булса да, этисенә җавап бирергә туры килде.

– Ул ялгыз, мин ялгыз, күрешкәлибез... Син инде бала-чага түгел, барысын да аңлыйсың...

– Нәрсә аңлыйм, әти?

– Ир-ат хатын-кызсыз яши алмый. Табигый нәрсә.

– Иртә башладың түгелме, әти? Әнине җирләгәнгә ярты ел да үтмәде бит. Кешедән оят.

– Шулай килеп чыкты инде. Үлгән артыннан үлеп булмый.

Бу сүзләр Гафурга мәрхүмә әнисе истәлеген пычрату кебек яңгырады.

– Әнине бик иртә оныткансың, әти... Ул бит сиңа гомер буе терәк булып торды. Ул булмаса, бәлки, күптән аска тәгәрәп, бер алкашка әйләнгән булыр идең...

– Ярар, ярар... Атаң белән алай сөйләшмә.

– Сөйләшә торган көн җитте, әти. Ул Зәмзәмия сине бик тиз бөгәрләп кесәсенә салачак. Аның колы булып яшәячәксең. Яшь арагыз да бик зур. Ир-ат буларак мине аңлыйсыңдыр...

– Мин хәзер иректә кеше, үз язмышымны үзем хәл итәм...

– Синең язмышың – безнең язмыш, улларың язмышы белән дә бәйле шул. Анысын оныткансың, ахры.

Әтисе тыныч калырга тырышып җавап бирде:

– Син инде үсеп җиттең, мөстәкыйль кеше. Тем более авылда калмыйм, дисең. Илдар киләсе елда мәктәпне тәмамлый, укырга китәргә җыена. Укып чыкса, ул да авылга әйләнеп кайтмаячак. Мин монда ялгыз калачакмын... Син минем ялгыз калуымны телисеңме?

– Юк, әти, мин синең картаймыш көнеңдә ялгыз калуыңны теләмим. Тик сайлаганың бик зәһәр, холыксыз хатын бит. Аның белән сиңа тыныч тормыш булыр микән? Сайлаганда үзеңә тиңрәк кеше сайларга иде. Әнине дә бик тиз оныттың. Анда җаны рәнҗеп ятмый микән?

Улының шулай акыл өйрәтеп утыруы Кәрим Фатыйховичның горурлыгына тиде. Ул сүзне тизрәк төгәлләргә тырышты:

– Ярар, улым, солдаттан сержант булып кайттым, дигәч тә, миңа акыл өйрәтеп утырма. Башың яшь әле атаң белән болай сөйләшергә. Үз язмышыңны кайгыртсаң яхшырак булыр. Бу турыда башка сүз кузгатасы булма! Ишеттеңме? – Әтисе капылт урыныннан торды да, бер сүз әйтмичә, ишекне шапылдатып ябып чыгып китте.

Гафур аңлады: шушы минутта аны әтисе белән бәйләп торган соңгы җеп өзелде. Ул шунда бөтен ачысы белән әнисенең йөрәк җылысын тоеп үскән туган йортыннан аерылуын сизде. Хәзер аны монда берни бәйләп тормый иде. Ул үзенең, ирекле җан сыйфатында, башка җирдә, яңа дөньяга аяк атлап керергә, анда үзенә лаеклы урын табарга тиеш икәнлеген ап-ачык итеп күрде.

Әтисе белән соңгы сөйләшүдән соң, Гафурның туган-үскән йортта каласы килмәсә дә, ул аннан капылт кына кузгалып чыгып китә алмады. Кая да булса китеп бару өчен, башта өс-башны карарга кирәк иде. Ул армиядән буйга үсеп, җилкәләре киңәеп, таза-чибәр егет булып кайтты. Элекке киемнәре бөтенләй кечерәеп, тараеп калган иде.

Беркөнне, энекәше Илдар да өйдә вакытта, Гафур әтисе белән шундый сүз башлады:

– Әти, ялгышмасам, безнең әни кассага акча салып бара иде. Ул акчаны син алдыңмы? Алган булсаң, алар кайда хәзер?

Әтисе Гафурдан мондый сүзне көтмәгән иде. Шуңа күрә ул аңа гаҗәпләнеп карап куйды – акчаны үзенчә тотмакчы иде. Зәмзәмия янына да буш кул белән барып булмый. Пәлтәм искерде, дип зарлангач, туган көненә акча бирергә туры килде. Кыскасы, Кәрим Фатыйхович олы улының бу хакта сүз кузгатуын ошатмады, әмма тыныч җавап бирергә тырышты.

– Акчаны алдым, улым, алар миндә. Нигә ул акчалар белән кызыксынып киттең әле?

– Әти, мин армиядән кайттым. Инде хәрби киемнән йөри алмыйм. Мактанып йөргән шикелле килеп чыга. Кешедән оят. Ә элеккеләре кечерәеп беткән. Миңа өс-башымны карарга кирәк.

– Ярар, карарсың, улым...

– Алайса, син миңа шул акчаның бер өлешен бир дә, Казанга барып, үземә кием-салым алып кайтыйм.

– Кайчан барырга уйлыйсың?

– Иртәгә үк, – дип, кискенрәк итеп әйтеп куйды Гафур.

Улының бу сүзе дә ошамады Кәрим Фатыйховичка, ул, аны үртәгәндәй:

– Тагын нинди сорауларың бар, улым? – диде.

Гафур атасының яңакларында төерләр уйнап алуга әллә ни игътибар итмәде.

– Бер мәсьәлә бар, әти.

– Нинди мәсьәлә?

– Йорт мәсьәләсе... Закон буенча туган-үскән йортыбызда минем дә өлешем бар. Ләкин мин үз өлешемнән баш тартырга булдым.

– Нишләп андый фикергә килдең әле?

– Шулай дөресрәк булыр, дип уйлыйм.

– Улым, мин сине аңлап бетермим.

– Үз өлешемнән Илдар файдасына баш тартырга булдым, әти. Ул төпчек малай, йорт тулысынча аңа калырга тиеш.

– Мин дә исән бит әле, улым...

– Яшә, әти, озын гомерле бул. Тик синнән соң йорт тулысынча энемә калырга тиеш. Башка кешенең монда өлеше юк!

Бу сүзләр турыдан-туры әтиләренең гыйшык-мыйшык эшләренә кагыла иде. Моны барысы да аңлады.

– Син бит авылда калмыйм, дисең... Нигә болай армиядән кайтып керешкә үк йорт бүлешергә керештең әле? Мәсьәлә синнән башка да хәл ителер иде.

– Мин бернәрсә дә бүлмим, әти. Илдар үз хокукларын белеп торсын, дип махсус әйтүем.

– Алайса, махсус әйтүең инде... Бик акыллы булсаң, язу язып калдыр.

– Авылдан чыгып киткәндә язармын.

Җитди сүз шуның белән тәгәлләнде. Әтиләре, папкасын кыстырып, өйдән чыгып китте. Сөйләшүнең Илдар катнашында узуы әйбәт булды әле, дип уйлап

куйды Гафур. Әтисенә ышанып җитмәгәнгә, абый кеше буларак, энекәшенең мәнфәгатьләрен яклауны ул үзенең бурычы саный иде. Барысын да белеп торсын, алай-болай булса, төп башына утырып кала күрмәсен.

Иртәгесен әтисеннән акча алып, Гафур Казанга чыгып китәргә җыенды. Әтисе биргән акчаны санап карагач, ул аның уйлаган киемнәрне алырга җитмәячәген күрде, һәм, ни хикмәттер, Кәрим Фатыйхович аңа өстәп тагын акча бирде. Әтисе белән Гафур арасында, Зәмзәмия турында сүз чыкканнан бирле, киеренке ризасызлык урнашты. Гафурның бу йорттан тизрәк чыгып китәсе килсә, әтисе түземсезлек белән аның чыгып китүен көтә иде. Олы улы аңа теләгәнчә яшәргә комачаулый, шаһит сыман һәр адымын белеп, бәя биреп тора.

Казанда көне буе кибетләрдә, универмагта йөреп, Гафур көч-хәл белән үзенә кирәк әйберләрне сатып алуга ирешә. Әмма көн инде узган, кич җитеп, караңгы төшә башлаган иде. Бүген авылга кайту турында уйлыйсы да юк. Поезд белән Арчага кайтып өлгерә алса да, караңгы төшү сәбәпле, ул барыбер алар ягына кайтучы машина таба алмаячак. Кая барырга? Кемдә кунып чыгарга? Дөрес, барысын да алдан уйлап куя торган гадәте буенча, ул Кадрия ханымның Казандагы апасы адресын язып кесәсенә салган иде салуын. Тик төргәкләр күтәреп, кичен ят кешеләргә барып керүне яхшысынмады Гафур. Ят кешеләрне борчып йөрисе килмәде. Поезд белән соң гына Арча станциясенә килеп төште дә төнне кечкенә генә юлаучылар залында урындыкта үткәрде. Төн йокламыйча, арып-талып, төш вакытына гына авылга кайтып җитте.

Өйдәгеләр аны төрлечә кабул иттеләр. Әтисе, улының алып кайткан әйберләрен караштыргач, әллә ни шатлык белдермәде:

– Тәмам кияү егете булгансың, – дип әйтү белән чикләнде.

Ә энекәше Илдар, абыйсы өчен чын күңелдән куанып, Гафур алып кайткан яңа киемнәрне киеп күрсәткәч:

– Абый, сине танырлык та түгел хәзер... Кызлар артыңнан борылып караячак, – дип шаяртты.

Гафур үзе дә шат иде. Ул бер зур эш башкарды. Әнисе гүр иясе булып кабердә ятса да, гел ярдәм итеп тора. Ул, эченнән аңа рәхмәтләр әйтеп, рухының тыныч булуын теләде. Хәзер өйдән чыгып китү ягын кайгырта башларга да мөмкин иде.

Икенче көнне, өйдә ялгызы гына калгач, Дилбәргә хат язарга утырды. Кызның онытылмас образы шундук күз алдына килеп басты, аның белән үткән бәхетле көннәре исенә төшеп, йөрәге җилпенеп куйды. Чиләбе дигән ерак калада аның сөйгәне яши бит. Ул аны шундый сагынды, бер күрешер өчен әллә ниләр бирер иде. Ул киләчәк тормышын аннан башка күз алдына да китерә алмый. Дилбәр дә шулай уйлый микән?..

Дилбәрдән хат алганнан соң, Гафурның күңелендә өмет яңарды, киләчәгенең матур, бәхетле булачагына ышаныч артты. Менә Дилбәр аның күз алдында тора, Гафур тиздән аның белән күрешәчәге турында уйлый, гел кыз турында хыяллана. Әмма, өйдән чыгып киткәнче, кайбер эшләрне башкарасы бар.

Аның армиядән кайтуына инде бер айдан артык вакыт узды. Ноябрь азагы җитеп килә, җирне катыра да берничә көннән җылытып җибәрә, юеш кар ява, җир тагын җеби, юллар пычрак. Гафур, сатып алган яңа костюмын, кара пәлтәсен, кышкы бүреген, яңа ботинкаларын киеп, беркөнне район үзәгенә чыгып китте. Аңа хәрби учёттан төшәргә, мондагы тормыш белән арасын өзеп, ерак юлга чыгып китәргә, таныш булмаган җирдә яңа тормыш башлап

җибәрергә кирәк иде. Башланырга торган яңа тормыш, яңа кешеләр, яңа вазгыять аны куркытмый, ул үз көченә, акылына ышана, алдында калкып чыгачак барлык киртәләрне үтеп, алга барырга әзер икәнлеген бөтен күңеле белән тоя, барысы да яхшы булачагын сизенеп яши иде.

Военкоматта эш алай җиңел генә узмады. Өстәл артында утырган җирән чәчле, кызгылт йөзле капитан аңа сораулар яудыра башлады. Башта ул:

– Кая китәргә җыенасың? – дип сорады.

– Чиләбе шәһәренә, – дип җавап бирде Гафур.

– Анда нишләмәкче буласың?

– Берәр заводка эшкә урнашырга уйлыйм.

– Кая урнашасың ачык түгелмени?

– Юк, әлегә әйтә алмыйм. Баргач күз күрер...

– Күз күрер, дип булмый, егетем. Миңа синең кая урнашуыңны теркәп куярга кирәк. Бәлки, син анда баргач, бөтенләй хәрби учётка басмассың. Син – военнообязанный кеше, без сине югалта алмыйбыз.

– Минем анда танышларым бар. Эшкә урнашырга алар ярдәм итәрбез, диде.

– Танышларыңның адресын беләсеңдер бит.

Бу сорау Гафурны кыен хәлгә куйды. Үзләренә әйтмичә, Дилбәрләрнең адресын яздырасы килмәде аның.

– Мин аларда торырга уйламыйм. Гомумән, әле кайда торачагымны әйтә алмыйм.

– Алайса, мин сине учёттан төшерә алмыйм.

– Нигә төшерә алмыйсыз?

– Әйтеп торам бит, безгә синең кайда торуыңны теркәп куярга кирәк. Без синең эзеңне югалта алмыйбыз.

Гафур уйга калды. Военкоматта мондый хәл килеп чыгасын ул башына да китермәгән иде. Егетнең дәшми торуын күреп, капитан кабат телгә килде:

– Танышларыңның адресын әйтсәң, учёттан төшерергә мөмкин. Анда баргач, учётка бассаң, безгә хәбәр итәрләр.

Дилбәрнең адресын әйтүдән башка чара калмаган иде. Гафур, үзен көчләп булса да, кызның адресын яздырырга мәҗбүр булды. Баргач, барысын да аңлатып бирер.

Шулай итеп, ул хәрби учёттан да төште. Военкоматтан урамга чыккач, болар кешене үзләренең колы саный, ахры, дип уйлап алды. Мондый хәл белән аның беренче очрашуы иде. Шулвакыт энекәше Илдар исенә килеп төште. Гафурга бит йорттагы үз өлешеннән Илдар файдасына баш тартуы турында документ эшләтеп алырга кирәк. Андый документны нотариуслар эшләп бирә бугай. Гафур нотариусның кайда утыруын белми иде, кешедән сорашып тапты. Үз өлешен Илдарга калдыруы турында рәсми кәгазь алды. Илдар файдасына эшләнгән рәсми документны кулына алгач, әтисенең тагын ачуы чыгар инде дип уйлап куйды. Гафур барысыннан да бигрәк әтисенең, яшь хатын назларына алданып, Зәмзәмияне дә йортка яздырып куюыннан шикләнә иде. Бу документ энекәшенең хокукларын бермә-бер арттырачак.

Шушы эшләрне башкарып чыккач, Гафур үзендә зур җиңеллек тойды. Аны бәйләп торган җепләрдән арыну халәте иде бу. Ул хәзер, һавадагы кош кебек, тулысынча ирекле. Бүген бик мөһим эшләр башкарды, ул үз-үзеннән канәгать калды, хәтта күкрәк читлегендә аңлашылып бетмәгән шатлык хисе дә тоя иде. Авылга ул кич җитәрәк кенә кайтып керде.

Гафурның әле өйгә кайтканнан бирле классташ дуслары белән очрашып

сөйләшкәне юк иде. Бүген ул үзе якын иткән Хәйдәр янына кереп чыгарга булды. Энекәше Илдардан аның авылда икәнен ишеткән иде. «Аю табаны» булганга, Хәйдәрне армиягә алмадылар. Гафур хезмәт иткән чакта ул нишләп яткан икән, шуны да беләсе килә иде аның. Хәйдәрләр югары якта тора иде. Гафур, клуб яныннан борылып, шунда менеп китте.

Гафур аларның ишегалдына килеп кергәч, лапас ягыннан килгән тавыш ишетеп, туры шунда китте. Хәйдәр анда сыер асларын чистартып ята икән. Гафур аңа дәшкәч, ул борылып карады, шатланып, көрәген ташлады да, брезент бияләйләрен сала-сала, Гафурга якынлашты.

– О-о, солдат кайткан икән... Исән-саумы, бетереп кайттыңмы? – Кочаклашып күрештеләр.

– Башка барып тормаска исәп, – дип шаяртты Гафур.

Лапастан ишегалдына чыктылар. Хәйдәр өстенә соры фуфайка, башына бәйләнгән ак башлык, аякларына галошлар кигән иде.

– Кайтуыңны ишеткәнием. Сержант булып кайткан, дип сөйлиләр. Үзем дә сезгә кереп чыгарга йөри идем әле. Килеп яхшы иткәнсең, – диде Хәйдәр. – Әйдә, өйгә керәбез.

– Юк, кереп тормыйк. Монда гына сөйләшик, – диде Гафур. Сүз инде ишегалды уртасында бара иде. – Ну, синең хәлләр ничек?

– Күреп торасың... – Хәйдәр, көлемсерәп, лапас ягына ымлады. – Үзеңдә ни хәлләр бар?

– Кайттым менә...

– Служба ничек узды, бик авыр булмадымы?

– Төрле чак булды.

– Инде нишләргә уйлыйсың?

– Аптыраган... Әни үлгәч, өйнең бөтенләй яме киткән.

– Әйе, өйне хатын-кыз бизи шул, – диде ул, аннан шатлыгын белдермичә кала алмады: – Мин өйләнергә йөрим бит әле...

– Кит аннан... Кайчан? – Гафур шаярып аның янтыгына төртеп алды.

– Бер айдан туебыз була.

– Кемгә өйләнәсең?

– Кави Әлфиясенә.

– Чибәр кызны сайлагансың. Котлыйм!

– Рәхмәт. Әйдә, син дә өйләнеп җибәр. Өегезгә ямь керер. Синең дә күңелең булыр.

– Хатынны базардан сатып алып булмый шул.

Бу сүздән Хәйдәр көлеп җибәрде:

– Әйттең сүз, армиядән кайткан солдатка любой кыз чыгачак.

– Өйләнү алай капылт кына эшләнә торган эш түгел бит, үзең аңлыйсың.

– Анысы шулай... Без дә Әлфия белән ике елдан артык йөрдек. – Хәйдәр аңа хәйләкәр генә карап алды да: – Укыган чакта сезнең Әминә белән нәрсәдер барые шикелле.

– Ул читтән ошатып йөрү генә иде, – дигән булды Гафур, аннан сорап куйды: – Ул хәзер кайда соң?

– Казанда укый. Син армиягә киткәч, икенче елны педагогия институтына кергәние. Кияүгә чыккан дип ишеттек.

Бу сүзне Гафур тыныч кабул итте, шулай да сорады:

– Кемгә? Дамиргамы?

– Юк, Дамир белән алар озак йөрмәделәр. Казан егетенә чыккан.

Беравык тын гына тордылар.

– Хәйдәр, мин авылда калмаска булдым.

Хәйдәр, аннан тагын нәрсәдер көткәндәй, бераз уйланып торды да:

– Кая китмәкче буласың? Казангамы? – дип сорады.

– Юк, Чиләбегә.

– Бигрәк еракка җыенгансың.

– Ераграк шул...

– Нишләп Казанга түгел? Кайтып-килеп йөрергә дә уңайлы булыр иде.

– Бергә хезмәт иткән егет чакыра, – диде Гафур, Дилбәр турында әйтергә теләмичә. – Анда заводлар күп икән.

– Алайса, эшкә заводка керергә исәбең.

– Белмим әле... Баргач күз күрер. Үзең колхоздамы?

– Әйе, электрик. Мин бит шул эш буенча техникум бетереп ятам.

– Молодец! Бик яхшы эш, – диде Гафур.

– Кайчан китәргә җыенасың?

– Озакка сузмаска исәп.

– Алайса, безнең туйда булалмыйсың инде.

– Пожалуй, була алмам. Бәхетле булыгыз.

– Рәхмәт яхшы сүзеңә, – диде Хәйдәр. – Юкка өйгә кермәдең, бераз гәпләшеп утырыр идек. Армия турында да берни сөйләмәдең.

– Солдат – солдат инде... Аның нәрсәсен сөйлисең. Ярый, мин китим әле. Исән-сау тор, туйларыгыз матур узсын, – дип, Гафур китәргә җыенды, ике кулын хушлашырга Хәйдәргә сузды.

Дустының аны җибәрәсе килми иде:

– Бөтенләй киткәнче иркенләп кереп чык әле, сөйләшеп утырырбыз. – Хәйдәр аны капка төбенә кадәр озата чыкты, артыннан моңсуланып карап калды.

Иртәгесен Илдар мәктәпкә, әтисе үз эшләре белән өйдән чыгып киткәч, Гафур сервантның ябык бүлегендә саклана торган әнисе кәгазьләрен барлап чыгарга булды. Асылда бу бүлектә әнисенең кечкенә генә шәхси архивы тупланган иде. Әнисенең вафатыннан соң, бу документларга ят кеше кулы тимәгәнлеген Гафур андагы тәртипнең элеккечә саклануыннан күрде һәм моңа сөенеп куйды. Димәк, әтисе мондагы әйберләр белән кызыксынмаган, барысы да, әнисеннән ничек калса, шул килеш торган.

Гафур, өйдә ялгызы калудан файдаланып, серванттан папкаларны өстәл өстенә чыгарып тезәргә кереште. Менә төрле документлар тупланган папка. Анда әнисенә укыту эшендәге уңышлары өчен бирелгән дистәдән артык мактау грамотасы тапты ул. Гафур бер-икесен алып укып та карады, шунда күңеле нечкәреп, күзләре яшьләнде. Аннан соң биредә үзе укыткан класслар белән бергәләп төшкән һәм ниндидер тантаналы вакыйгалар вакытында мәктәп коллективы белән төшкән фотолар тупланган фотоальбом да бар иде. Ә иң астан зәңгәр тасма белән аркылы-торкылы бәйләп куелган тагын бер папка килеп чыкты. Аның эчендә нәрсә барын, ни өчен тасма белән бәйләп куелганын Гафур аңлый алмады. Тасманы чишеп җибәреп, папканы ачкач та, ул аның эченнән чыккан ике сан иске журналның ни өчен шулай кадерләп төреп куелганын аңлый алмый торды. Журналларның тышына «Совет әдәбияты» дип язылган иде. «Шундый журнал да булды микәнни? – дип уйлап куйды ул. – Хәзер андый исемдәге журнал юк шикелле». Гафур аларның берсен кулына алды. Эчендә берәр

кәгазь юк микән дип, җилфердәтеп ачкалады да беренче битенә, эчтәлегенә күз салды.

Әнисе бу ике санны нигә алай кадерләп төреп куйды икән? Бу минутта егетне фәкать шушы сорау кызыксындыра иде. Юкка гына ул аларны сакламагандыр, монда берәр хикмәт булырга тиеш. Эчтәлеккә күз йөртеп чыкканда, башка гадәти әсәрләр арасында, 39 биттә «Татар халык дастаны «Идегәй». Нәкый Исәнбәт җыйнамасы» дигән материал аның игътибарын җәлеп итте. Кем ул Идегәй? Берәр атаклы шәхесме? Гафур, журналны ачып, исеме чәчәкләр белән бизәлгән әсәргә күз салды. Әсәр шигырь белән язылган иде. Гафур текстны укырга кереште:

Борын үткән заманда,
Болгар белән Сарайда,
Җаек белән Иделдә,
Алтын Урда, Ак Урда
Данлы кыпчак җирендә...

Моның борынгы тарихи әсәр икәнен Гафур шундук аңлап алды. Монда сүз татар тарихы турында бара иде. Ул укуын дәвам итте. Ара-тирә аңлашылып җитмәгән сүзләр дә очрый иде. Текстны җыйнаучы-әзерләүче аларны саннар сугып битнең астындагы аңлатмаларда ачыклап барган. Алар булмаса, Гафур андагы «Алтын таш» кебек сүзләрнең Сарай шәһәрендәге хан бистәсе икәнен каян белер иде. Бу әсәрне туплаган Нәкый Исәнбәт исемле язучы, комментарийлар урнаштырып, текстны аңлауны шактый җиңеләйткән, бик файдалы эш башкарган икән.

Менә Гафур, татар мәктәбен тәмамлаган егет, татар, рус, шулай ук чит ил әдәбиятыннан күпме әсәрләр укыды, нигә ул бу борынгы әсәрне дә, текстта күзгә чалынган Идегәй, Туктамыш хан, Норадын кебек шәхесләрне бөтенләй белми, аларның исемен беренче кат укый? Моңа бик нык аптырады Гафур. Әнисенең дә ул хакта бер тапкыр да сүз кузгатканы булмады. Андый әсәрнең – татар халкының үз дастаны булуы турында сүз чыгармады.

Гафур әнисенең архивын үз урынына урнаштырганда фотоальбомнан берничә рәсем сайлап алды, журналның ике санын үзендә калдырды, аннан «Идегәй» тексты белән ныклап торып танышырга кереште. Дастан ике санда дәвам итә иде. Укыган саен аның күңелендә горурлык хисе үсә, күтәрелә барды. Әлбәттә, ул әле дастанны тоташ укымый, моның өчен күп көннәр кирәк. Ул әлегә аның төрле битләрен ачкалап укып карый, таныша, аның төзелешенә, стиленә, теленә игътибар итә. Менә кайда яшеренеп ята икән ул затлы татар теле! Бу борынгы текст ул бөтенләй белмәгән-ишетмәгән вакыйгалар турында сөйли иде. Гафур «дастан» сүзенең рус әдәбиятында кабул ителгән «эпос» сүзенә тәңгәл икәнен күптән аңлады. Димәк, татарның да үз тарихын сурәтләгән дастаны-эпосы бар икән. Нигә мәктәп дәреслекләрендә бу хакта бер сүз дә юк, татар баласы мәктәпне үз тарихын белмичә тәмамлап чыга? Бу нигә шулай?

Гафурның башында шундый сораулар туа башлады. Бәлки, бу татарның тыелган тарихыдыр, бәлки, аны махсус яшереп тоталардыр? Алай дисәң, ул бит татарча журналда басылып чыккан. Нигә соң бу хакта әдәбият дәреслекләрендә ләм-мим, бер сүз дә юк? Дастан басылып чыкканнан соң, берничә ел узгач, 1944 елда, «Идегәй» өстендә нинди сәяси яшеннәр яшьнәвен, әсәрнең нинди

авыр язмышка дучар булуын белми иде шул Гафур. Әнисе дә дастан турында шул сәбәпле сөйләмәгәндер, улын нахак бәлаләрдән саклагандыр. Улының җитлегүен көткәндер, мәктәптә укыганда, аңа бу хакта белеп сөйләмәгәндер. Шулай Гафурга әнисе яңа яктан ачылып китте, аның тагын бер сере ачылды. Өйдә «Идегәй» дастаны саклануын коммунист әтисе әле белми дә торгандыр. Кайчандыр парторг булып йөргән әтисе үз гаиләсендә тыелган «Идегәй» турында сүзләр куеруын ничек кабул иткән булыр иде? Әлбәттә, ул бу журналны юк итәргә тырышыр иде.

Гафур журналның ике саны белән дә танышып чыкты. Очраклы рәвештә генә карашы бер биткә тукталып, укырга тотынды:

Әй, ханиям, ханиям!
Җир китәр дә ни калыр?
Җиреннән тайган ил калыр.
Ил китәр дә ни калыр?
Ил киткәндә, йорт калыр,
Йорт китәр дә сөт калыр.
Ак күкрәктән сөт имгән
Сүзе татлы тел калыр, –

дигән юлларны укып чykканнан соң, Гафур, текстның тирән мәгънәсе, камиллегенә сокланып, ирексездән: «Гениально!» – дип башын чайкап куйды. «Ак күкрәктән сөт имгән сүзе татлы тел калыр», диелгән бит. Ул бу әсәрнең бәяләп бетермәслек хәзинә икәненә тагын бер кат инанды. Ул шунда Дилбәр турында уйлап алды. Аның өчен бу бик кыйммәтле чыганак булачак, алар бу әсәрне бергәләп укыячаклар, өйрәнәчәкләр. Әлбәттә, дастан-эпос чын тарих түгелдер, әмма андагы вакыйгаларны башка китаплардагы фактлар белән чагыштырып та бик күп нәрсә белергә мөмкин ич. Бит астына урнаштырылган күләмле аңлатмалар да нык ярдәм итәчәк. Дилбәр өчен бу бик зур бүләк булачак, Гафур аны кызга илтеп тапшырачак. Шушы хакта уйлап, Гафур кызның бу журналларга ничек куаначагын күз алдына китерде. Егетнең йөрәге шатлык белән тулды, ул аларны киләчәктә күпме сөенеч, бәхет, табышлар көткәнен уйлап елмайды.

Гафур, журналларны әтисе күрмәсен өчен, юлга аласы чемоданына бикләп куйды.

Туган йорттан чыгып киткәнче, Гафур, зиратка барып, әнисе белән бәхилләшеп кайтырга булды. Капкадан урамга чыкты. Көн аяз, салкынча, җирне катырган, юлда җыелган сулар каткан. Уйга чумып, зират урамына таба атлаганда, ул үзен туган авылы белән дә хушлашкан кебек хис итте. Иртәгә ул моннан чыгып китәчәк. Шуңа күрә Гафур, һәр урамны, тыкрыкны, йортларны исендә калдырырга тырышып, акрын гына атлап барды. Аның балачагы, үсмер еллары күңеленә мәңге кереп урнашкан шушы авылда узды. Мәктәпне дә шушында тәмамлады. Әгәр дә кеше гомерен өч өлешкә бүлеп карасаң, аның өчтән бере шушында үткән икән бит. Әнисе канаты астында узган бу еллар бик бәхетле еллар булган икән. Моңарчы ул моны аңламый яшәгән икән. Бәхетле кеше үзенең бәхетле икәнен сизми икән шул. Тормыш гел шулай дәвам итәр кебек тоела. Барысы да табигый кабул ителә. Әнисен югалткач кына, Гафурга мондый уйлар килә башлады. Мәрхүмә әнисенең үзе өчен нинди кадерле, алыштыргысыз зат булганлыгын үкенү һәм йөрәк сыкравы белән кичерә иде ул.

Гафур зәңгәргә буялган зират капкасын ачып эчкә үтте. Яңа каберләргә әле

сукмак салынып өлгермәгән, аяк астында суыктан катып калган, өсләренә бәс кунган үләннәр кыштырдый. Ул әнисе каберенә килеп туктады. Яңа кабернең әле чардуганы да, ташы да юк, бары тик кабер башына утыртылган сары такта гына монда кем җирләнгәнен белдереп тора.

Гафур янәшәдәге кабер читенә куелган озын урындыкка килеп утырды. Башыннан бүреген салды да тезләренә куйды. Кабердә аның иң кадерле кешесе – әнисе ята. Тик Гафур өчен әнисе вафат булмады. Ул аның үле гәүдәсен күрмәде. Аның хәтерендә әнисе алтын чәчле, матур, шат йөзле әни булып сакланып калды, гомер буе шулай сакланачак. Аның белән үткән бәхетле еллар, кылган изгелекләре, аның яратуы, кичерелгән бихисап мизгелләр гомер буе хәтерендә калкып, әнисен искә төшереп торачак. Кызык икән бу тормыш дигән нәрсә. Адәм баласы яши-яши дә, көннәрдән бер көнне караңгы кабергә керә дә ята. Аңардан кылган гамәлләре, тырышлык куеп башкарган эшләре, төрле истәлекләр, хәтер генә кала. Иң мөһиме – хәтердер. Адәм баласы бу дөньядан киткәч, кешеләр хәтерендә яшәвен дәвам итә. Аның әнисе дә Гафурның, тагын бик күп кешеләрнең хәтерендә матур истәлекләр рәвешендә яшәвен дәвам иттерәчәк. Үзе турында хәтер җуелса гына, адәм баласы үлеп югала. Кешеләр хәтерендә яшәгәндә, ул әле исән. Аның әнисе кешеләргә мәрхәмәтле, ярдәмчел зат иде. Ул әле онытылмаячак, яшәячәк. Бу фикер Гафурның йөрәк сызлануын бераз баса төште. Кабер янында утырганда ул үзен бер зур хакыйкатьне аңлаган сыман хис итте.

Кеше вафат булып, җеназа укыр алдыннан, сафка тезелгән, мәетне озатучы халыкка һәрвакыт бер сорау бирелә:

– Әйбәт кеше идеме?

– Әйбәт кеше иде, – дип җавап бирәләр сафтагылар.

– Бу дөньяда бурычлары калмадымы?

– Юк, калмады.

Бу йола исенә төшеп, Гафур аның асыл мәгънәсенә шушы минутта гына төшенде кебек. «Адәм баласын соңгы юлга озатканда бу йола кешеләр хәтерендә мәрхүм әйбәт кеше буларак сакланып калсын өчен үткәрелә торгандыр, мөгаен», дип уйлап куйды ул.

– Хуш, әнием! Рухың шат булсын, – дип пышылдады Гафур. – Син миңа чын ана булдың, мине тәрбияләү өчен көчеңне-вакытыңны кызганмадың. Ярдәмең бәяләп бетергесез зур булды. Сине беркайчан да онытмам. Кыен вакытларда синең якты образың күз алдыма килеп басар, син биргән акыл, киңәшләрең миңа ярдәм итеп торыр. Рәхмәт сиңа, газиз әнием. Теге дөньяда үзеңә лаеклы урын табарга язсын!

Гафур бүреген киде. Хушлашу минутында аның йөрәге кысылып сызларга тотынды, күңелен авыр хис биләп алды, күзләре яшь белән тулды. Ул кесәсеннән ак кульяулыгын чыгарды, күзләрен сөртте, аннан, кабергә иелеп, бер уч балчык алды да, кульяулыгына төреп, кире кесәсенә салды. Әнисе кабереннән алган бер уч балчыкны ул үзе белән алып китәчәк. Кайда гына яшәсә дә, ул балчык, гел әнисен искә төшереп, аның белән булачак.

Бераз кабер янында басып торганнан соң, Гафур, борылып, зират капкасына таба атлады. Аяклары карыша, бер дә атлыйсылары килми. Газиз әнисе белән аерылышу аңа бик кыен иде.

Төш вакытында әтисе кайтып керде. Энекәше Илдар әле мәктәптә иде. Әтисе белән сөйләшергә иң җайлы вакыт. Төшке ашка утырдылар.

– Әти, мин иртәгә китәм, – диде Гафур.

– Кая бармакчы буласың, улым?

– Чиләбе шәһәренә.

– Шулай ерак китәргә уйладыңмыни? – Әтисе Гафурның алай ерак китүенә эчтән сөенеп куйса да, тыштан сиздермәде, аның хәленә кергән кыяфәт чыгарып, сорап куйды: – Нигә Казанга гына бармыйсың?

– Чиләбедә таныш егет бар, бергә хезмәт иткән идек. Шул чакыра.

– Анда нишләмәкче буласың инде?..

– Эшкә урнашырга уйлыйм. Армиядән кайткан солдатка эш табылыр әле.

– Табыла күрсен.

– Миңа юлга акча кирәк. Әнинең акчасы калгандыр бит...

– Бирермен. Барып урнашкач хат яз.

– Язармын. Сез монда тыныч кына яшәгез.

Әтисе җавап бирмәде. Аштан соң тыныч кына чәй эчәргә тотындылар. Гафурның әле сүзе бетмәгән иде. Ул, башын күтәреп әтисенә карады да:

– Мин бүген зиратка әни янына барып килдем. Каберенә чардуган белән таш куярга кирәк.

Әтисе улына сөзеп карап алды, бу малай тагын акыл өйрәтә, дип уйлап куйды, тик тыныч җавап бирде:

– Җирләр катты. Быел булмас. Җәй җиткәч куйдырырмын, – диде.

– Ярар, яхшы булыр... Иртәгә район үзәгенә берәр машина бармый микән. Ишетмәдеңме? – дип сорады.

– Юк, ишетмәдем. Үзең барып сораш, бәлки, баралардыр. – Әтисе урындык аркасына сөялеп тураеп утырды да: – Алайса, туган йортны ташлап, бәхет эзләргә чыгып китәсең инде, улым. Кыен булмасмы соң?

Кәрим Фатыйхович бу сүзләрне, ата кеше буларак, улы алдында абруен саклап калу максаты белән әйтте. Гафур өчен борчыла, янәсе.

– Китәм, әти...

– Чит җирдә бәхетеңне таба алырсыңмы соң?

– Югалып калмам...

– Шулай була күрсен, – диде әтисе, өстәл артыннан торып, салып куйган пиджагын киярг͏ә тотынды. Киеп бетергәч, көзге каршына килеп галстугын төзәтте, папкасын алып, өйдән чыгып китте.

Берәр сәгатьтән укудан энекәше Илдар кайтып керде. Гафур аңа аш җылытып бирде, үзе аның ашаганын карап, сокланып каршында утырды. Ул армиядә чакта малай буйга үскән, борын астында кара төкләр дә күренә башлаган иде.

– Илдар, мин иртәгә китәм, – диде Гафур.

– Алайса, мин әти белән генә калам икән, – дип, моңсу гына әйтеп куйды Илдар.

– Әле өчәү булып куюыгыз да бар...

– Ничек?

– Әти Зәмзәмиягә өйләнсә, ул монда күчеп киләчәк.

– Өйләнер микәнни?..

– Бик мөмкин. Ул хатын килсә, сиңа кыенрак булачак инде. Үги әни үз әниең түгел.

– Ул миңа бернинди дә әни булмаячак... Җәйгә хәтле ничек тә түзәрмен. Аннан Казанга укырга китәрмен.

– Укырга китүең әйбәт. Тик миңа хатлар язгалап тор. Барып урнашкач, адресны салырмын.

– Абый, өй турында теге документны эшләп бирүең өчен рәхмәт.

– Син аны сакла, киләчәктә кирәк булып чыгуы бар.

– Аңлыйм...

– Тырышып укы. Институтка керерлек итеп. Мин менә армиядән әйләнеп кайттым, ә югары белемем юк. Соңарып булса да, укырга туры киләчәк.

– Юкка армиягә киттең. Сиңа да укырга кирәсе калган.

– Мин үкенмим. Дөнья күрдем. Тормыш яхшы кешеләр белән очраштырды. Күзләрем ачылды. Ә син монда калма, укырга керергә тырыш. Аннан соң нишләргә кирәген үзең күрерсең. Шуны онытма: без синең белән бер ана балалары.

Гафур урыныннан торды да энекәше янына килде, хискә бирелеп, аны кочагына алды...

Гафурның бүген туган йорттан чыгып китәсен кичә үк ишеткән Зөлхәбирә апасы алар иртәнге чәйне эчеп утырганда, өчпочмаклар төргән табагын күтәреп килеп тә керде, өчпочмакларны бушаткан арада:

– Нишләп болай мәшәкатьләнеп йөрисең, Зөлхәбирә апа, әллә солдат кеше ач калыр, дип курыктыңмы? – дип шаяртып әйтеп куйды Гафур.

– Өчпочмак юлда тамак ялгап алырга бик җайлы нәрсә ул, Гафур энем. Ватылмый да, бозылмый да. Кирәгенчә аласың да ашыйсың. Калганын төреп куясың.

– Рәхмәт инде кайгыртуыңа, – диде Гафур, күңеле булып. – Тик минем чемодан зур түгел бит, бу кадәр ризыкны сыйдырып булмас. Анда әле башка әйберләр дә бар.

– Сыйган кадәресен алырсың, – диде Зөлхәбирә апасы.

– Улым, бүген машина район үзәгенә ягулык алырга бара икән. Мин сөйләшеп куйдым. Соңга кала күрмә, – диде әтисе.

– Алайса, саубуллашыйк.

Гафурны капка төбенә хәтле озата чыктылар. Бу аның өчен иң авыр минутлар булды. Ноябрьнең салкын иртәсендә капка төбендә әтисе, энекәше Илдар, күзләрен яулык чите белән сөрткәләп, Зөлхәбирә апасы басып тора. Гафур тагын бер саубуллашып, бераз китте дә артына борылып карады. Аның якыннары иртәнге салкында боегышып басып торалар. Гафурның тамак төбенә ниндидер төер утырды, ул кулын болгады, туган йортына тагын бер күз салды да, юлын дәвам итте.

– Хуш, туган йорт! Туган авыл! – дип пышылдады ул. Шул мизгелдә, әлеге сүзләргә ияреп, «Идегәй»не укыганда, күңеленә кереп калган ике юл хәтерендә калыкты:

Кендегемне кискән йорт,
Кендек каным тамган йорт!

Бу минутта үзен дөньяга китергән, шушы йортта кадерләп үстергән әнисенең каберенә кайчан, нинди сыйфатта, кем булып әйләнеп кайтасын да күз алдына китерүдән бик ерак иде әле Гафур.



Шаһинур
Мостафин

# ҮЛЕМСЕЗЛЕК ҖЫРЫ ӨЗЕЛМӘС

«БАГЫШЛАУЛАР» ДӘФТӘРЕННӘН

## Сез – хөкемдар!..

*Моннан 74 ел элек – 1944 елның 12 февралендә Германиядәге Икенче империя судының Дрезденда үткәрелгән утырышында, «Рейхның хәрби көчен какшатып, дошманга булышлык иткәннәре өчен», «Идел-Урал» легионындагы яшерен антифашистик оешманың иң актив әгъзаларыннан 11 каһарман – Гайнан Кормаш, Фоат Сәйфелмөлеков, Абдулла Алиш, Фоат Булатов, Муса Җәлил, Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Абдулла Баттал, Зиннәт Хәсәнов, Әхәт Атнашев, Сәлим Бохаров үлем җәзасына хөкем ителә. Элемтәче легионер Рәхим Саттарны фашистлар, огнемёттан ут сиптереп, терелэй яндырып үтерәләр. Фәрит Солтанбәковны исә гомерлек каторгага озаталар...*
*Франциядәге партизаннарга (макизарларга) каршы көрәшү өчен җибәрелгән җәлилче легионерлардан Әмир Үтәшев, Нигъмәт Терегулов, Рушад Хисаметдинов, Гарәф Фәхретдинов һәм башкалар, фашистларның үзләрен җиңеп, туган илгә исән әйләнеп кайталар. Габбас Шәрипов, Әмир Үтәшев һәм Нигъмәт Терегулов, Муса Җәлилнең «Моабит дәфтәрләре»нең берсен киләчәк буыннар өчен саклап калып, чын егетлек үрнәге күрсәтәләр.*

Сынаулары белән сыный Тормыш –
Җиз иләктән кат-кат үткәрә...
Рухы-җаны көчле булганнарны
Йолдыз итеп күккә күтәрә!
Йолдыз итте Сезне дә ул, Җәлил,
Кормаш, Алиш, Гарәф, Рушад, Әмир!..

Йолдыз итте,
Тиңсез батырлыкка таң калып:
– Аяк-кулга зынҗыр салынса да,
Көрәшә, көлә белә бу халык!
Җырлый белә!..

Шаһинур МОСТАФИН (1948) *– эзтабар язучы һәм шагыйрь; «Васыять», «Ядрәләрне эреткән йөрәкләр», «Җирдә елмаюлар күбәйсен!» һ.б. китаплар авторы; Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Россиянең М.Ломоносов исемендәге премиясе лауреаты. Казанда яши.*

Кырык яктан үлем янаса да,
Алмаз кебек нык сез, бөгелмәс! –
Иманына тугры күңелләрдән
Үлемсезлек җыры өзелмәс!

Ургыла җыр!..
Зинданнарың, дошман,
Туктаталмый хисләр ташкынын...
Ургыла җыр юллар, еллар аша,
Кайта илгә, кайта ашкынып!..

«...Җырың белән дусны иркәли бел,
Җырың белән җиң син дошманны!» –
Сезгә көч һәм гайрәт бирде Җәлил,
Үтәр өчен халкым кушканны –
Көлеп җиңәр өчен дошманны!..

Без беләбез:
Төп хөкемдар тик фашизм түгел,
Гильотинада башлар чапса да,
Сезнең рухи ныклык, җырга күчеп,
Меңнәр күңеленә кайтканга,
СЕЗ – ХӨКЕМДАР!!!

Каныгыз белән язган һәр җырыгыз
Гаепләү акты булды фашистка,
Гаепләү акты булды хаиннарга –
Карарыгыз кискен һәм кыска!

Сатлыкҗаннар – яла-этдиновлар
Сезне гестапога чакса да,
Җыр тылсымы белән, Сез алардан
Алданрак басып чакмага,
Җиңү яуладыгыз шул «дуэль»дә! –
Хаклык сүзен кайтардыгыз Илгә!
(Сезне һәркем белә, башын ия –
Алдыгызга, зурлап, гөлләр сибә!..)

...Сынаулары белән сыный Тормыш,
Моабитлар аша үткәрә...
Рухы-җаны көчле булганнарны
Йолдыз итеп күккә күтәрә!

Йолдыз итте Сезне дә ул, Габбас,
Фоат, Нигъмәт, Сәлим, Әхәт, Баттал,
Гариф, Әхмәт, Зиннәт, Фәрит, Саттар!

Йолдыз итте,
Күңел күкләрендә кабызып!..
...Көрәшчеләр рухы көч-дәрт бирә –
Без яшибез Сезгә табынып!..

## Батырлыкта яши Матурлык

*Гомере буе ирен – офицер-юрист Шамил Ясәви улы Мәҗитовны (1924-1967) сагынып, аның якты рухын олылап – бер-бер артлы китаплар чыгарып, илаһи Тугрылык үрнәге күрсәтеп яшәүче милләтпәрвәр җанлы күркәм затка – икътисад фәннәре докторы, Россия гуманитар фәннәр академиясе академигы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, шәрәфле язучы Рауза Кадыйр кызы Мәҗитовага багышлыйм әлеге шигъри юлларымны.*

Одиссеен көткән Пенелопадай[1],
Күпме еллар сабыр итәсез!..
Тәрәз чиертеп, ишек шакысалар,
Сискәнепләр инде китәсез...

«Бәлкем, Ул кайткандыр?!.» –
Шундый уйдан
Тетрәнә һәрбер күзәнәк...
«Исән-имин булса әгәр ирем,
Яшәр идек гөрләп, бергәләп!

Икебез дә яз аенда туган,
Язларда без ихлас таныштык!
Бер-беребезне сынап, аңлашкачтын:
«Гомерлеккә!» – диеп кавыштык...

Кызларыбыз үсте – гөлләр кебек,
Гаилә бакчасына ямь өстәп!..
Бәхетебез ташып торган чакта,
Яшьләй иртә киттең... Әйт, нишләп?

Шул сорауны Сиңа еш бирсәм дә,
Җавабын да табам тиз ара:
Озак яшәп булмый яра белән
Сугышлардан торган дөньяда!

Яшь көенчә ут эченә кереп,
Саклап калдың газиз Ватанны!
Бик күбәүләр шәһит китте яуда –
Нурлы булсын өчен Ил таңы!
Җиңеп кайткач дошман өерләрен,
Масаюны белми һич кенә,
Көне-төне, ялсыз-нисез эшләп,
Мәңгелеккә бик тиз күчтең лә...

Гаделлекне яклап узды гомерең,
Гел Хак сүзле булдың – чын батыр!
...Барчабыз да Сине сагынып яши,
Мин дә әйтәм: «Шамил, уян, тор!»
Күрче, нинди Синең балаларың,
Кияүләрең, нинди оныклар!
«Мин яратам барчагызны!» – диеп,
Әйткәнеңне һич тә онытмам!..

[1] Ирле-хатынлы Одиссей белән Пенелопа – борынгы грек мифологиясе геройлары, бер-берләренә искиткеч тугрылык символлары. – *Ш.М.*

Рәсемеңнән карап торасың Син,
Еллар аша, мәңге яшь килеш...
Якты Рухың белән безнең янга
Син кайтырга тиеш, бик тиеш!..»

Рауза ханым монологы шундый –
Колагымда һаман чыңлый ул!
Хәтер Уты дөрли йөрәкләрдә –
Көне-төне яна, тынмый ул!..

«Сабыр иткән – морадына җиткән!» –
Бик тә белеп әйткән халкыбыз:
Рухы сау булгач, җылы сүздән терелеп,
Китап булып, Сезгә кайтты Ул!
(Одиссейдай, Сезгә кайтты Ул!)
Мәңгелеккә кайтты! Сезнең өйне
Нурлап тора Аның Китабы!
Кызлар, кияүләр дә, оныклар да
Кат-кат укый – юктыр хисабы!

«Изге Китап кебек кадерле ул,
Һәрбер сүзе якын йөрәккә!
Шундый ирең булу – нинди бәхет!
Авыр чакта – Ул нык терәк тә!»

Шатлыкта да кирәк асыл затлар –
Ясәви улы Шамил шикелле!
Портретыннан сөеп бага Сезгә:
Үзе – гади, үзе – сөйкемле!

Карашында – Олуг Рәхмәт хисе:
Изге әманәте үтәлде!
Сез, Рауза ханым, чын тормышка
Кайтардыгыз күптән көткәнне!
Язганнары – китап битләрендә,
Рәсемнәре калган уелып...
Рауза ханым, Сезгә, моның өчен,
Үзегезгә дә һәйкәл куярлык!
(Ак сүзләрдән һәйкәл коярлык!)

...Батырлыкның Туган көне бар! –
Үлгән көне генә юк аның...
Батырлыкта яши Матурлык –
Балкытасыз бергә Ил данын!..

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Айгөл
Әхмәтгалиева

# АК ЧИТЕК

БӘЯН

«Яшәргә яралгансың, яшә, оч!»

Хатынның уена ияргән карашы пәрдә тирәли бөтерелгән күбәләккә берегеп калды. Бичара, ут яктысы чакыргандыр инде үзен, ишегалдындагы иркенлекне ташлап, тоткынлыкка очып кермәс иде. Күрәчәге чакыргандыр...

– Пәрдәне тартсаң... – Хатын, каршыдагы диванда бик бирелеп гәзит укып утырган иренә иплəп кенә дәште дә янә өрфия канатын дерелдәтеп чәбәләнгән күбәләккә текәлде.

Ир күзлеген җәһәт кенә маңгаена күтәреп куйды, гәзитен ташлап, аяк очына күчеп утырды.

– Нәрсә дисең, әнисе?

– Үз дөньясына очсын. Канатлы килеш шуышмасын. – Хатын, керфекләрен тибрәтеп, чакырылмаган кунакка ымлады.

Аны күптән инде күз карашыннан аңларга өйрәнгән ир артык сүзне кирәксенмәде. Пәрдәне читкә шуыштырып, тәрәзәне киереп ачты.

– Бар, җанкаем, өченче – артык, ди әле монда апаң, бар, бар, безгә мишәйтләмә...

Пәрдәне япкач, янә гәзитенә үрелде.

– Берәр юньле хәбәр язсалар... – Ачусыз гына сукранып та куйды.

– Ни диләр?

– Иван Грозныйга һәйкәл куйганнар. Мәскәүдә. Әле кайбер ахмак башлар Казанда да куярга кирәк, дип дулый ди.

– Тапканнар... Явыз Иванга түгел, менә синең кебекләргә куярга кирәк ул һәйкәлне. – Хатынның тавышы сабыр, тигез иде. Түшәмгә төбәлгән күзләренә генә әйтеп бетергесез җылылык һәм моң таралды.

Ир, гаҗәеп бер ихласлык белән, гадәтенчә шаулап көлеп җибәрде, аның кул аркасын сыйпый-сыйпый, йөзенә иелде.

– Минем кебек авыл мужигына? Һәйкәл? И әнисе, әйтеп тә куясың инде син...

---

Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА – *язучы; «Синең өчен яшим», «Баланнарда бал тәме», «Таллыкүлдә былбыл бар» һ.б. китаплар авторы. М.Кашгарый исемендәге халыкара премия лауреаты. Чаллыда яши.*

– Көлмә. Кулымнан килсәме? Казан урамында бер якка – сиңа, икенче якка Нурсөя апага һәйкәл бастырып куяр идем әле.

– Нурсөягә? Фәррах бабай карчыгынамы? – Ир, аптыраган кыяфәт чыгарып, читкәрәк тайпылды. – Бар икән күрәселәрем...

– Шушыны... Шаяртырга булсын. – Шулай дисә дә, хатын үзе дә шаяртып кына иренең янтыгына төртеп алды. – Ниткән Фәррах бабай сөйлисең? Фәнис абыйның, Фәнис Яруллинның хатынын әйтәм. Баулыда һәйкәл ачылды, дип яздылар язуын, башкалада да булсын. Артык түгел.

– Әәә... Аңа ярый. Кирәк. Чын татар хатынын бөтен дөнья күрерие.

– Сине дә. – Хатынның күгелҗем күзләреннән агылган мәхәббәт нуры янәшәсендә утырган ирнең какча гәүдәсен, әле чал кунарга ашыкмаган куе чәчләрен, гомер буе эштән өзелмәгән сөялле кулларын, кояшта янып каралган йөзен сыйпап үтте. – Чын татар ирен күрерләрие.

– Һай, әнисе, әйттерерсең әллә ни... Кая, мендәреңне рәтлимме, арымадыңмы?

Җавап ишетелмәде. Хатын күзләрен йомган, буразна-буразна булып, иреннәренә тиклем кайнар яшьләр тәгәрәгән иде.

– Утыз җиде ел бит, Нургаян, утыз җиде ел!

– И Аллам, кайлардан телгә алдым бу Иван Грозныйны... – Нургаян, урыныннан кузгалып, караватянындагы өстәлдән ашъяулыкны күтәрде, чынаякка пыяла графиннан су агызды. – Зәйтүнәкәем, ничә әйтәм, синең кан басымың күтәрелми, син аны үзең күтәрәсең! Мәле, су йот.

Зәйтүнә, терсәкләренә таянып, мендәреннән күтәрелә төште. Яшь аралаш елмаеп, иренең кулыннан чынаякны алды.

– Борчылма, кан басымы әйбәт. Көн бозылса гына уйнаклый башлый.

– Бозылмый торсын берүк. Бәрәңгегә тотынгач кына... Иртәгә бетмәс микән, Алла боерса. Китереп кенә яумаса... – Ир юри сүзне баягы юнәлештән ераккарак борып куйды. – Көндез кызларга яңа чиләкләр алып кайттым, җиңеллеген күрсәң, әнисе! Чәнти бармак белән күтәрерлек, ант мәгәр! Кодагыйларга шуны тотып киттеләр.

– Бик төнгә калырлар микән, озакладылар әле.

– Исән йөрсеннәр, кайтырлар. Аның да бакчасы ару гына, кызларга да, балаларга да эш җитәрлек.

– Уттай эш өстендә җыелышын каян тапканнар, диген. Син дә барган булыр идең.

Нургаян белән Зәйтүнәнең кызлар дигәне – оныклары Гөлүсә һәм Илүсә, балалар дигәне – уллары Наил һәм килене Рәйлә иде. Кичен клубта авыл җыелышы буласы, килегез инде, дип, өй борынча әйтеп чыккач, Нургаян баш тартудан уңайсызланды, барырмын, дип калды.

– Теге бала үпкәләп китте микән... – Зәйтүнә көндез ишегалдында таптанып торган журналист кызны исенә төшерде дә, ирен беркадәр шелтәләгәндәй, сүзен дәвам итте: – Ике-өч авыз сүз алышсаң да күңеле булыр ие, болай, куып чыгарган шикелле...

– Үпкәләмәс. – Нургаян, укып утырган гәзитен йомарлап, әллә каян гына очып кергән чебенгә кизәнде. – Һе, минем турында язам, ди. Нәрсә сөйлим мин аңа? Амбразура капламаган, немец белән сугышмаган. Пенсиягә чыкканчы гомер буе трактор йөрттем, хәзер оныкларыма тырма ясыйм, диммени? Авылда ир-ат тагын ни кырсын?

– И Нургаян...

– Берәүдән дә артык җирем дә, ким җирем дә юк, Аллага шөкер. Гәзиткә язарлык батырлык эшләгәнем дә булмады.

– Ә мин?

– Нәрсә син? – Баш түбәсендәге күзлек инде борын очына төшеп утырды. Ирнең сораулы карашы шул күзлек өстенә эленде.

– Утыз җиде ел буе... мине кулыңда күтәреп йөртүең, дим. Батырлык булмый...

– Аллаһы Тәгалә тагын утыз җиде ел гомер бирә икән – тагын күтәрәм! Түлке гәзиткә язсыннар дип түгел, сине ятратканга, Зәйтүнәкәем! И-и, бигрәкләр дә каты яраттым шул үзеңне... – Нургаян, күз читендәге вак-вак җыерчыкларны җемелдәтеп, хатынына борылып елмайды.

– Гел шулай дигән булдың инде... – Зәйтүнә, күңеле тулганын сиздермәс өчен, күзен йомды.

– Алдашмаганымны беләсең, әнисе, үз гомеремдә бер дә ялганлаганым булмады.

– Булды. Бер тапкыр. – Хатын күкрәгенә салынып төшкән калын толымын сутәргә тотынды.

Ире, чиксез гаҗәпләнеп, түшәмгә текәлде. Әйтерсең, түшәм уртасындагы бәллүр люстрага «кайчан» дигән сорауның җавабы эленеп калган.

– Теге чакны... Эчеп кайткач...

Ир, андый чак та булды микәнни, дип шаккаткан төстә, күзләрен түгәрәкләндерде.

– Ә-ә... Бер эчтем шул. Ну бит, бүтән тамчы да эчмим, дип вәгъдә бирдем – авызга алмадым, алдамадым. Кая эчү, мәчеткә йөри башлагач, тәмәкене дә ташладым!

– Эчтең, димим. Алдадың. Вәсим сыйлады, дидең.

– Соң? – Ир, аптыраудан гаҗиз калып, бу юлы идәнгә төбәлде.

– Ул чакта... Нәзирә сыйлаган иде бит. Ә син, Вәсим, дидең, алдадың. – Хатын бу сүзләрне шулкадәр тыныч, салмак, әмма җан түреннән чыккан әчке бер сагыш белән әйтте. Озак еллар буе әйтергә теләп тә, менә бүген генә сүз кузгата алгангамы, гаять авыр йөктән, бурычтан котылгандай, җиңел сулап куйды, ирен читенә, үсмер кызныкыдай, иркә дә, бераз үпкәле дә елмаю таралды.

Нургаян аңа ялт кына күтәрелеп карады да, менә сиңа мә дигәндәй, бик озак ияк кагып торды, аннан, ике кулы белән башын тотып, рәхәтләнеп көлә башлады.

– Һай, әнисе, әнисе! Ничә еллар, диген! Бүген әйтә бит, ә! – Көлүеннән кисәк туктап, Зәйтүнәнең кулына үрелде. – Нәрсәләр генә уйлап ятмагансыңдыр! Вәт дивана хатын! Түлке шуны бел: мин аның бармак очына да кагылган кеше түгел! Әгәр андый нәрсә уйладым, дисәң, хәзер тал чыбыгы алып кайтып, тотып ярам үзеңне!

Нургаянмы? Чыбык беләнме?.. Зәйтүнә кинәнеп елмайды.

– Беләм. Кагылмаганыңны беләм.

– Шулай булгач?

– Алдадың бит. Вәсим сыйлады, дидең.

– Нәзирә белән кара-каршы утырып эчтем, дияргә идеме? Аның мине яңаклап кайтаруын да әйтергә идеме? – Ирнең тавышы кырыслана төште, күз алмасы зураеп, караңгыланып китте.

Өй эченә беразга тынлык урнашты.

– Ни өчен... яңаклады?

– Кагылмаганга. Аның кочагына егылмаганга. Ярар, җыен тозсыз нәрсәне искә төшереп утырмыйк әле. Зәйтүнәкәем, каршыма йөз хатын-кызны тезеп бастырсалар да, синнән башка берсе-бер кирәкмәгәнен беләсең!

– Беләм, Нургаян, беләм...

– Теге, гәзит кызын әйтәм әле... – Капка ачылган тавышны ишетеп, Нургаян тәрәзәдән үрелеп карады. Башлаган сүзен бүлеп: – Наилләр кайтты, – диде дә баягыча көләргә тотынды. – Авыл иренең, татар иренең чын үрнәген күрсәтәсе иде, ди, әллә нинди кызыл сүзләр сөйли. Әле дә борып кайтарганмын! Вәт сөйләп җиффәргәниең син аңа минем турында!

– Бер тапкыр алдашты, димәс идем инде анысы...

– Ярар, язарга темасы бетмәс, юкка кайгырма. Кеше белән ил тулган, табар...

– Кеше күп, Нургаян, синең кебекләр генә бик сирәк шул...

***

Авыл җыелышы гаугалы үтте. Чүплек базын бетерү, чүп җыю өчен районнан машина билгеләү, үзара салым акчасы җыю турында сүз чыккач, залда башта дулкын йөгереп узгандай булды. Аннан кара тавыш купты. Һәркем нидер әйтергә тели, тик берәү дә аны тыңламый, үзенекен сөйли бирә. Район вәкиле, аптырагач, өстәлгә шап итеп китереп сукты да, зал аңга килгәнче, дилбегәне үз кулына алды:

– Фикерегез бар икән, һәркем аерым-аерым, әдәпле итеп әйтсен, иптәшләр, монда сарык абзары ясамагыз! – диде ул, үзе артык әдәпле сүзләрне сайлап тормыйча.

– Иптәш Сафиуллин, син менә шуны әйт әле. Чүп җыярга машина билгеләнә, дисең. Ә мин менә абзардан чыккан тиресне ул машинага төйи аламмы? – диде кепкасын кулына йомарлап урыныннан күтәрелгән бер агай. – Сыер, сарык, бозау асрыйбыз – аларның астын бер генә көн чистартмый кара – тездән батасың... Мин аны кая куярга тиеш булам, сезнең машинага көрәкләп ташыйммы? Әллә бу эш төптән бик каты уйлап, авыл халкы мал асраудан тәмам туктасын өчен эшләнәме? Җайлы бит, читтән кергән «Буш боты» бетсә, тагын да очсызга куш бот кайтартырсыз...

Залдагылар башта көлешеп алсалар да, абзыйның хаклыгын аңлап, җитди җавап көттеләр.

– Тиреснең урыны бакча инде аның, абзый, ниткән машина сөйлисең? Бөтен кеше атна саен абзар б...гын чүп машинасына төйи башласа, ни була ул? – Сафиуллин сүзгә кеше кесәсенә керә торганнардан түгел, бүлтәеп чыккан корсагын кочаклап, бик үткер җавап биргәндәй, канәгать елмайды. – Яки шәһәргә аппарып сатасың, бер баруда айлык пенсияңне эшләп кайтасың...

– Син, иптәш Сафиуллин, күзгә төтен җибәрмә әле. – Агайның күршесе дә аягүрә басты. – Моннан соң чүп базына әйбер ташымыйсыз, дисең, анысын аңладык. Примерга, мин менә бакчада агач-куакларны кыркыгач, аларны кая аткарырга тиеш булам, шуны әйт әле син миңа...

– Ягасың, абзый, ничек инде кая аткарасың? Мунчада булса да мичең бардыр бит?

– Ва-пирвых, мунча мичен дә газга көйләп бетердек бит инде, апаем. Икенчедән, ул чи ботакны мин ни рәвешле яндырыйм ди? – Агайның үҗәтлеге җитәрлек иде, тиз генә чигенергә ашыкмады.

Сафиуллин да мондыйларны гына күрмәгәнме? Тамак кырып, корсагын тагын да киеребрәк басты.

– Иптәшләр, болар бит барысы да шулкадәр вак мәсьәлә! Моның ишегә вакыт әрәм иткәнче...

Аны өченче берәү бүлдерде:

– Бәрәч, вак дип сикертә башласаң... Иске-москы диван-креслоларны ташлап буламы соң ул машинагызга? Хет шуны әйтегез...

– Әлләй, минем дә хан заманындагы халадилникны чыгарып томырасым бар бит...

– Келәтнең түлен алыштырганыем, искесе бер өем...

Залда янә ата – улны, ана кызны белмәслек тавыш кубарга маташа иде.

Баядан бирле каршысындагы шифалы су шешәсе артында посып калырга теләгәндәй утырган хуҗалык җитәкчесе, торып, трибуна артына барып басты.

– Иптәшләр, иптәшләр! Иптәш Сафиуллин дөрес әйтә, вакытны гына сузабыз бит болай телләшеп, ә... Нигә соң сез һәр яңалыкны штыкка гына алырга торасыз? Әзрәк уңай ягын да күрергә тырышыгыз инде, иптәшләр. Баз түгел, авыл үзе чүплеккә әйләнеп бара бит, күрмисезмени? Үлгән сарык-казларыгызга тикле бакча артына, инеш буена чыгарап атасыз – шулмы эш? Беркөнне холерадан кырылып үләсегез киләмени? Штраф салгач, без дошманга әйләнәбез...

– Әй, сөйләгәндә матур сөйлисең, Рафаил абый, – диде яңгыравык тавышлы чая хатын, зал уртасыннан күтәрелеп. – Авылда кайчан юл була, менә шуны әйт син! Яренгә, ди-ди, шуны көтеп, инде ничә буын үлеп бетте... Балалар кайтса, бутый күтәреп каршыларына барабыз, адәм гыйбрәте...

– Какрас шуның турында сөйләшергә җыенабыз бит, салым акчасы нигә тотылачак дисең син? – Җитәкченең сабыры төкәнеп килә иде, ул өстәл янына барып, пластик стаканга шешәдән су агызды, ялт күтәреп эчте дә коточкыч ялгышлык эшләгән кыяфәттә район вәкиленә борылып карады. Хатасын төзәтергә теләдеме, икенче стаканга да ашыга-ашыга су агызды, аны тизрәк Сафиуллинга сузды һәм:

– Салкын түгел, әйбәт кенә, – диде, беркадәр гаепле йөз белән төче елмаеп.

Кеше башыннан елга ике йөз илле сум салым акчасы җыябыз, ул безгә дәүләттән күпкә артып әйләнеп кайта, дигәч, зал шартлады.

– Бер тиен дә бирмим!

– Сезнең кесәне калынайтырга исәрләр бар ди монда!

– Ул акчага юл төзеп буламыни?

– Артып кайткач бирермен...

– Үзебез көчкә очын-очка ялгап яшибез... Ике йөз илле сум, имеш...

– Балалар укытам...

– Башта зарплата бирегез!

– Машинага кредит түлим...

– Малайның ипотекасына булышам...

– Печән кибе аласым бар.

– Сөт тапшырган акчаны кисмәгез...

Нургаян арткы рәтләрнең берсендә, күршесе, укытучы Илсөяр белән янәшә утыра иде. Авылдашлары өчен шаккатыпмы, хәзерге дөньяны аңламаудан гаҗиз калыпмы, ул бөтенләй сүзгә кушыла алмады. Тегеләй дә уйлап утырды, болай да. Бер карыйсың – һәркем хаклы кебек: авылда эш урыны юк, кулга азмы-күпме акча алып эшләүчеләр мәктәп-почта-ферма тирәсендә генә калды. Авылның күзгә күренеп торган төп халкы – Нургаян кебек, пенсионерлар, аларга ай саен, акмаса да, җан асрарлык пенсия тамып тора. Икенче карыйсың

– акча юк дип зарланудан бушамаган һәр йортта затлы машина. Яхшы җиһаз. Кибеткә көн саен кайтып торган тартма-тартма кәнфит-прәннекне, ящик-ящик аракы-сыраны, колбасаны, суелган тавыкны, йомырканы, эремчек-каймакны, әфлисун-бананны сыдырып алып кына торалар. Атна азагында, берсеннән-берсе кәттә машиналарга төялеп, күпләрнең ишегалдына шәһәрдән балалар-оныклар кайтып җитә. Өсләрендә – энә-җептән чыккан кием, кыйбатлы тун. Дөрес, аларның яртысы кредит дигән шайтанга богауланган, әмма нәфес дигән нәрсә ул богаулардан күпкә өстен. Кышын-җәен кайсы Дубайда, кайсы Төркиядә, Кытайда, Грециядә ял итеп, кара чутырга әйләнеп тә кайтып төшәләр. Төшәләр дип, үзләре кайтып төшкәнче үк Интернетка куелган фотоларыннан Мәймүнә түтинең уллары Кырымга киткәнне дә, Кәримәнекеләрнең Сочида икәнлекләрен дә, Халик бабай оныкларының Италиягә үк барып җиткәннәрен дә бөтен авыл белеп тора. Берәү дә бернәрсәгә дә шаккатмый.

Ә менә ике йөз иллешәр сум җыябыз, дигәч, шаккаттылар, ду куптардылар. Югыйсә, ул акчаларны җыеп, вәгъдә бирүләренчә, урамнарга таш түшәсәләр, баганаларга ут элсәләр, чишмә-кое буйларын рәткә китерсәләр, бер дә начар булмас иде дә соң...

Уйга чумып утыра торгач, янындагы Илсөярнең торып басуын да искәрми калган икән.

Укытучы хатынның тавышы тигез, залны буйсындыра, тыңлата торган иде – гөжләү әкренләп тынды.

– Авылдашлар, мин дә үз фикеремне әйтим әле, – диде Илсөяр, тамак кырып. – Бу акчалар, чыннан да, үзебезнең авылны матурлау өчен тотыла икән, нигә дип ду киләбез соң без? Акча юк дип авызны капларга ашыкмагыз. Анлык кына бар, үзегез дә беләсез. Мәктәпкә балаларыгыз унбиш-егерме меңлек телефон күтәреп килә, аңа табыла бит... Мин сезне Нургаян абыйлардан үрнәк алырга чакырыр идем.

Үз исемен ишеткәч, Нургаянның битенә ут капты, берүк кирәкми, дип ялварып, Илсөяргә карады. Ләкин күрше хатыны аңа игътибар итмәде.

– Аларның тормышын барыбыз да беләбез. Берәр тапкыр зарланып авыз ачканнарын кем дә булса ишеткәне булдымы? Нургаян абый үзенең беренче пенсиясенә башта безнең урамдагы зиратка, икенче ай пенсиясенә аскы зиратка капка куйды. Мәчет ишегалдына да, зиратка да үз куллары белән будкалар төзеде. Авылыбыздан чыккан бер егетебез, эшләгән җиреннән, шәһәрдән узган атнада иске банерлар кайтарып сатты – Нургаян абый үз акчасына ике олы банер алып калды. Минәйтәм, печән өстен капларгадыр инде, дим. Юк, авылдашлар, үзенә алуы түгел. Хәлим бабайны җирләгәндә, коточкыч яңгыр иде бит, хәтерлисездер, шул көнне уена кертеп калдырган икән: явымлы көннәрдә кабер казырга туры килсә, туфрак чыланмас, өстенә капларбыз, дип алдым, зират будкасына илтеп куям, ди...

Нургаян, оялуыннан нишләргә белмичә, Илсөярнең җиңеннән тартты.

– Аның берәүгә дә, мин шулкадәр акча тоттым, дип хисап биргәне, кеше алдына килеп, акча теләнгәне юк. Авылыбызда иң күп гәзит-журналга язылучылар да шулар, «җан азыгы бит ул, акча жәлләп торырга», диләр. Нужәли шундый кеше безнең өчен үрнәк була алмый, авылдашлар? Бүген монда килгәндә сөйләшеп киләбез, Нургаян абый үзе өчен дә, Зәйтүнә өчен дә, улы-килене, оныклары өчен дә салым акчасы күтәреп килде. Көндез Зәйтүнә янында авызымнан ялгыш кына ычкынды: синнән кирәкмәс, сораучы булмас, Зәйтүнә, дигән идем, мине җир тишегенә керерлек итеп орышканын

ишетсәгез... Үзара салым дигәч, тавыш күтәрергә ашыкмыйк, төптәнрәк уйлап карыйк, авылдашлар. Кирәксә, ул акчаларның ничек тотылганын күзәтеп торырга үз арабыздан ышанычлы кеше дә билгели алабыз бит. Җай булса, иң беренче эш итеп Түбән оч зиратының коймаларын яңартыр идек, башка авыллар алдында оят, җәмәгать, коймасы череп авып бетте бит...

Чебен очканны ишетерлек тынлык урнашты. Ул тынлыкны кызмачарак тавышлы бер ирнең:

– Әй, тотасыз да шул зират дисез, авылда бүтән проблема юкмы әллә? Башта исәннәр турында кайгыртырга кирәк әле монда. Магазинда аракыны иртәнге уннан да иртә сатмаска дигәнне күтәреп чыгыгыз, атминәйте шул котсыз карарны, дим, жук, мин әйткән сүз берсенә дә җарамый. Нургаян абый әйткәне – җарый, – дигән сүзләре өзде.

– Әй, Нургаян абыйның ишегалдында мужыт акча базы бардыр аның... Хөкүмәт тә булышадыр әле. Техника арты техника ала, яңа өй күтәрделәр, – дип кушылды икенчесе, телен көчкә әйләндереп булса да.

Нургаян әкрен генә урыныннан торды, Илсөяргә ачусыз гына баш чайкап, ишеккә юнәлде. Инде ачам, дип тоткага кулын салгач, артына борылып:

– Мин һәр көнемә «Аллага шөкер» дип яшим, шөкер иткән саен малым да, тынычлыгым да арта, – диде дә, берәүгә дә күтәрелеп карамыйча, чыгып китте.

Һе, зират дигән сүзне яратмыйлар. Бүген булмаса иртәгә шунда барып ятармын дигән уй башларына да кереп карамый микәнни соң кайберәүләрнең? Үлгәннәргә кирәкми ул син коеп куйган капка, син тоткан койма, исәннәргә кирәк; мәрхүмнәргә аларга, рухларына дога кылып торучы булса, шул җитә. Савап дәфтәренә бер гамәл булып язылыр иде ичмаса. Ахирәт турында башыңа уй салыр иде: анда баргач ни көтә?.. Дөрес, анда, бәлки, үзара салым акчасы бирдеңме, юкмы, дип сорап та тормаслар, әлеге дә баягы гамәл дәфтәреңне каршыңа китереп салырлар да, яхшысын-яманын бизмәнгә куярлар. Шунысыннан курка Нургаян. Соңгы елларда, мәчеткә йөреп, китаплар укып, күзе ныграк ачыла барган саен, ул курку көчәя генә төште: гөнаһ кылмады, гомер буе хәләл көч белән табылган икмәген ашады, соңлап кына булса да, намазга да басты, кулыннан килгән кадәр бүтәннәргә ярдәм итәргә тырышты-тырышуын. Тәмәке тарткан өчен дә, элегрәк, тракторы ватылып җанга тигән мәлләрдә, ачы-ачы сүзләр белән сүгенгән вакытлары өчен дә ул кадәр уттан чыгып суга төшми Нургаян. Курыкканы – кайчан да булса, ялгышлык белән, үзе дә сизмичә, Зәйтүнәсен рәнҗетмәде микән? Тормыш иткәндә гел авыз ерып, уйнап-көлеп кенә тормыйсың бит: ачу килгән, үртәлгән, җан әрнегән чаклар да була. Әнә шундый мәлдә Зәйтүнәсенә кырын күз белән карамады микән? Авызыннан андый-мондый авыр сүз очмады микән? Менә шунысын тегеләй дә уйлап карый ир, болай да – үз сорауларына анык кына җавап таба алганы юк.

Бүтән чак булса, ул, күңелендәге уйларын җыр сүзләренә күчереп:

Үпкәләмәде микән,<br>
Ачуланмады микән?<br>
Уйнап әйткән сүзләремне,<br>
Зәйтүнәкәй, акчарлагым,<br>
Чынга алмады микән?

– дип, җырлый-җырлый атлар иде. Тик хәзер җырлыйсы түгел, елыйсы килә...

Кеше күңелендәге хөсетлекне, нәфесне ул беркайчан да аңламады, аңларга

да теләмәде. Нинди чир ул, каян йога, нигә йога – гел аптыраш инде менә. Кара, аның дөньясыннан көнләшүчеләр дә бар икән ләбаса! Авыл җыелышына бармаса, бөтенләй белми каласы булган бит. Шушында яшәп, үз авылдашлары арасында өр-яңа буын – ул белми, ул танымый торган буын үсеп җиткәнен дә абайламаган. Соңгы егерме-егерме биш ел эчендә авыл үзе дә танымаслык булып үзгәрде шул. Урамнары гына түгел, җаны коргаксып, бушап калды. Усалланды, бәгыре катты авылның. Катмас иде – бер колхоз булып яшәп яткан авылларны уңга-сулга чәчеп-таратып ташладылар, бер хуҗа кулыннан икенчесенә ыргыттылар, исем арты исем алыштырып, анысын банкрот, монысын банкрот дип игълан итеп, җирен-суын таладылар. Моңа тиклем Аллаһы Тәгалә нигъмәте саналып, яше-карты су коенган буа-күлләр дә, җиләк җыйган болыннар да аерым берәүләр кулына кереп йомарланды. Яшь гаиләләрне, бала-чагалары белән бергә, шәһәр үзенә суыра торды. Авыл йончып, картаеп калды. Яманнан да яманы – кешеләрнең күңелендә иртәгәсе көнгә ышаныч җуелып бара иде. Алар бүгенге көн белән яшәргә күнектеләр. Мал колына әверелеп, бүген типтереп яшәүне кулайрак күрделәр. Күп очракта өстәгеләргә каршы килергә җөрьәт итмәгәч, җөрьәт иткән очракта да файда урынына зыян гына күргәч, күңелгә утырган ул ачу якын-тирәгә, күрше-күләнгә, туган-тумачага таш булып атылды. Моңа тиклем гасырлар буе ике арада койма-киртә күрмәгән бәрәңге бакчасының ике карыш җире өчен күрше белән күрше ызгышты, ул ызгышны купайтып, гәзиткә язып, бер-берсен хурлыкка калдырып тәм таптылар. Атадан калган иске йорт өчен туган белән туган талашты, суд юлын таптап изаланды. Килене – каенанасын, каенана киленне яманлап, авылга телевидениегә кадәр чакыртып мәшәләнде. Мондый ыгы-зыгылар өчен, ни хикмәт, вакыт та, акча да табыла иде.

...Их, Илсөяр, Илсөяр! Зерәгә генә Нургаян турында сүз кузгаттың син. Яман нияттән әйтмәсәң дә, кирәкмәс иде... Бүген ишек төбенә килеп баскан гәзитче кызны да син чакырып китергән идең бит. «Җүнсез кешеләр турында язудан туктагыз, үрнәк булырдайларын языгыз», дип... Ә бит ир бер генә гамәлен дә кеше күзенә чалыну өчен эшләми. Күңел кушканына гына буйсына ул. Яраткан хатынын карап-тәрбияләп торуны да батырлыкка саный башласаң соң... И-и, тәнкәйләрең таза чагында, кемгә дә булса ярдәм итә аласың икән, йөгерә-йөгерә эшлисең. Әле бит дөньялары түгәрәк, шуңа канәгать була, шөкер итә белсәң, таң туган саен Аллага шөкер дип уянсаң, китек җире сизелми аның... Зират капкасы ясап кую белән мактанып йөрергә калса... Анысы бит аның күңелдә нәзер кебек йөргән ният иде...

***

– Әнисе, кара, уч тутырып акча алып кайттым! – Нургаян пенсиясен алырга дип почтага киткән иде, яшен тизлеге белән әйләнеп тә кайткан. – Юарга кирәк бит инде моны, әнисе, әллә чәй куеп җибәрәсеңме?

Зәйтүнә йөзтүбән яткан халәттә тартмадагы үрдәк бәбкәләренә агач калак белән җим болгатып маташа иде, эшеннән бүленде дә өстәлдә торган чәйнекне тотып карады, суынып киткәнен чамалап, плитәгә утыртты. Үзе, көлемсерәп кенә:

– Әйтәм җирле алтын күкәй салган тавык шикелле кытаклыйсың! Ярар, куанычын күрергә язсын! – диде, артык җәелеп төшми генә.

– Күрербез, Алла боерса!.. Күп чыкканмы, дип тә сорамыйсың, әй!

– Әйтәм бит, күпме булса да бәрәкәте булсын. – Иренең гадәтен белгән Зәйтүнә инде ул акчаның яртысы кибеттә калганын, Нургаянның бер кочак күчтәнәч күтәреп кайтканын чамалый иде.

– Алты мең! – Нургаянның әллә сөенүе, әллә шаккатуы иде – тавышыннан аерырлык булмады. – Трудавайга кермәгәнен исәпләмәсәң, егерме яшемдә колхозда эшли башладым, кырык ел трактордан төшмәдем, колхоз бетте, трактор бетмәде – алты мең! Ярар, син әйтмешли, бәрәкәте булсын. Мәле, алып куй әле, әнисе. Беразы тотылды, сиңа да, балаларга да тәмлүшкәләр алдым. Анда кибеткә керсәң, күз камаша, юк нәрсә юк! Ярты халык кырылып сөттер, эремчектер, катыктыр ала, вәт дөнья, ә! Авылда сыер асраучы син дә мин калган инде әллә... – Нургаян, сөйләнә-сөйләнә, күлмәк изүеннән бер йомарлам акча алып, хатынына сузды. – Йөзлекләр белән биргәч, хәтәр күп күренә икән үзе, – дип шаяртырга да җай тапты.

Зәйтүнә акчаны карават янындагы стенага беркетелгән киштәгә алып куйды. Гомер буе шуңа күнеккәннәр иде: Нургаян хезмәт хакын һәрчак хатынына кайтарып тоттырды. «Мин акча саный белмим, кесәмдә акча булса, этәч булып кычкыра», – дип котылды ир, башта ук бу хактагы сүзне уенга борып.

Бераздан, алып кайткан сыр, ширбәт, хәлвә ише ризыкларны өстәлгә тезеп, Зәйтүнәсе, зур бокалларга сөтле чәй ясап алдына куйгач, Нургаян урындыгында кыбырсынып алды.

– Ни бит, әнисе... Күңелдә йөрткән уй бар иде...

– Соң?

– Исән-сау булып, беренче пенсиямне алсам, безнең оч зиратына капка ясатырмын, дигән идем. Алайса, адәм ыстырамы бит...

– Бәй, ясат соң. Пенсияң җитмәсә, өйдә акча бетмәгән, кушарсың. – Зәйтүнә, тапкансың аптырар нәрсә дигәндәй, иңбашын сикертте.

– Беркөн хуҗалык җитәкчесен күргәч сүз каткан идем, авылыгыздан чыккан байлар бетмәгәндер, спонсор табыгыз, диде дә китте. Телендә «акча юк»тан башка сүз юк. Юкка тук булып яшәргә өйрәнеп беткәннәр, спонсор, имеш... – Нургаян, чәен пырдымсызрак болгатканын сизеп, кашыгын читкә куйды.

Зәйтүнә дә, терсәкләренә таянып чәй эчкән җиреннән, чынаягын өстәлгә утыртты.

– Китчәле, – диде ул, яраткан сүзен кабатлап, – шул бер капка өчен авыл бае эзләп йөрергә... Наил дә кушылыр, ниятең булгач, ясат та куй, кешегә ялынып йөрмә.

– Ярар, әнисе, син дә шулай дип торгач, иртәгә үк заказ биреп кайтам. Вәсимнең малаена әйтермен, тимердән әллә нәрсәләр коеп куя, кулы алтын. – Нургаян тыныч күңел белән чәен чөмерде. Тартмада пипелдәшкән бәбкәләргә ымлады: – Болар тагын миңадыр инде. Хәзер иркенләп сакларга була. Закунный пенсионер! Вакытыма үзем хуҗа!

– Әзрәк ныгысалар, капка төбенә апчыгарсың инде, Нургаян. Китапларыңны кыстырырсың да...

Зәйтүнәнең «китапларың» диюе – сүрәләр язылган китапчыклар, Коръән тәфсире иде. Нургаян узган ел, каз-үрдәк бәбкәләре саклаган арада, әллә никадәр сүрәне өйрәнеп, аятьләр ятлап, хатынын шаккатырды. Шуннан соң көзен мәчеткә дә сугылгалый башлады. Баштарак җомга вәгазенә генә барса, тора-бара шунда укырга йөреп, намазга да басып куйды. Аннан күреп, Зәйтүнә үзе дә догаларга тартылды, хәзер, әнә, киштәсе тулы дини китаплар. Күршеләре әле бер өем шигырь-хикәя китаплары да алып кергән, ахры, алары тәрәзә төбенә рәт-рәт тезелгән.

– Вәт син ул, әнисе, укып та куясың! Тәки шул чиреңне миңа да йоктырдың бит!

– Бәй, китапханәчелеккә укырга китәм, дип хыялланганымны беләсең бит!

– Алай да китмәгәнсең, Алабугада берәрсе каптырып калган булырые үзеңне, миңа эләкмәгән булырыең. – Нургаян, гөл чүлмәге янында яткан калын гына китапны алып, кулында әйләндергәләде. Тышындагы сурәтне ошатмыйча, эчтәлеген ачып карады. – Ярар, башта син укы да миңа сөйләрсең, калын күренә, укып тормам.

– Һи, шулай дигән буласың да, барыбер үзең дә укыйсың син аны. – Зәйтүнә, тәрәзә астындагы кранны ачып, табакка су агызды, кашык-чынаякларны чайкап, өстәлдәге сөлге өстенә тезде. – Сыйландык, Аллага шөкер. Хәлвәсе бик тәмле, и-и, әнкәй ярата торганые шуны. Ул чакларда авылда юк кына иде шул... Ниткән хәлвә, рәтле сабын-шампуньга тилмер дә...

Нургаян әллә уйнап, әллә чынлап йөзен чытты, кулын селтәде:

– Әйтмә шул шампунь дигәнне, йөрәгемә ярамый.

Иренең җай чыккан саен сүзне шаяруга борырга яратканын белсә дә, бу юлы Зәйтүнә аптырап китте:

– Нинди чебен тешләде?

– Шампунь күргән саен аэропорт исемә төшә хәзер.

Зәйтүнә, кулын селтәп, идәнгә иелде, каз канаты белән өстәл астын себергәләде.

– Чын әйтәм инде. – Ире диванга утырды, пульт алып, телевизорны кабызды, ошатмыйча, кире сүндерде. – Теге чакны, хәтерлисеңме, Кырымга санаторийга путёвка биргәч, районга, аэропортка киттек?

– Булгандыр инде, санаторийларга күп йөрттең, мең рәхмәт.

– Бүтәнен әйтмим әле, иллә мәгәр шул чакны онытмыйм. Казанга очасыек, беренче рейска билет юк, дигәч, ике-өч сәгать көтеп утырдык, исеңдә түгелмени?

– Ә-ә, күрше Илсөярнең дә сессиягә барган чагы иде, шуны сөйлисеңмени? Мине кулыңа күтәреп, койма буенда бик озак сөялеп утырганиең шул... Нинди шампунь бар иде соң анда? – Зәйтүнә, иренең сүз сөрешен аңламыйча, сәерсенеп китте.

– Юк шул менә, бер булса да шампунь юк... Билет сатучы хатын үзебезнең районныкы югыйсә, еландай телләремне салындырып аңлаттым, синең хәлеңне сөйләдем, озаклап көтәргә чамасы юк, арый, дидем. Илсөяр дә керде, үземнең билетымны бирәм, икенче рейста очсам да ярый, тагын берәр студентны икенчегә калдырыгыз, дип ялынды – юк инде, таш та таш, теге хатын да таш. Киресенә катты, тәки җибәрмәде безне...

– Шампуныңны әйтә белмәдең инде...

– Без соң, гел самолётта очып йөргәнмени, каян белик – ул хатынның көен көйләр өчен йә лимон, йә сыгып чыгармалы шампунь күтәреп керергә кирәк булган, әле беркөн генә, сүз иярә сүз чыгып, Илсөяр әйтте аны. Вәт, шул сиңа шампунь...

– И-и, мин тагы... – Зәйтүнә җиңел сулыш алып көлеп җибәрде. – Ниткән олы сүз сөйли, дисәм... – Аннан җитдиләнеп китте. – Түздең инде, Нургаян, авырлыгына да түздең, кимсетүләренә дә, борын төбендә шапылдатып ишек ябуларына да күп түздең, сабыр булдың. Утыз җиде ел түздең! Әҗер-саваплары берүк-берүк үзеңә була күрсен, гел шулай дип телим, бер Аллам кабул кылсын...

Сабырлык ул бүген дә кирәк, утыз җиде ел элек тә кирәк иде шул...

***

Түзәргә, тагын бераз гына түзәргә кирәк.

Кишәрлекнең куе таллар белән каймаланган урынын бер әйләнсә, бүгенгә җитәр, дип, иркен дә сулар, мөгаен. Алайса, иртәдән бирле күзенә ак-кара

күренми җир сөрә торгач, теле аңкавына ябышкандай булды, иреннәре чатнап ярылды. Һе, ярылыр да шул, гомер булмаганны, янында бер йотым су калмасын инде. Термостагы чәй әллә кайчан эчелеп бетте, көн саен трактор кабинасына менеп кунаклый торган өч литрлы банка исә, чишмә суы тутырылган килеш, болдырда онытылган иде. Үч иткәндәй, көне дә чамасыз кыздырып җелеккә төште: җәй азагы димәссең, менә, кич җиткәндә дә сүрелергә исәбе юк. Анысы, уракның кызган мәлендә яңгырсыз булуына сөенеп кенә тормалы инде үзе, бодай да ындыр табагына коп-коры килеш җырлап кына кереп китә, сөрүгә чыккан тракторлар да келтерәп кенә йөри. Узган ел күрше басуда бата-чума изаланганын искә төшереп, Нургаян үзалдына елмайды. Ул чагында кояш җылысын, коры көннәрне тансыклап тилмергәннәр иде, бүген исә күңел эсседән зарланырга маташа түгелме? Һай бу адәм баласы, бар чагында һич бернәрсәнең кадерен тоймый шул...

Ирнең күңеле тизрәк өйгә ашкына иде. Бүген клубка һинд киносы киләсе, кайтып юынганчы, капкалап алганчы да байтак вакыт үтәр, шуңа эшкә нокта куярга да юыртырга кирәк. Кыз белән егет булып йөргән чаклары әллә ни еракта калмаса да, Зәйтүнәсен култыклап клубка барулары, бер-берсенең тән җылысын тоеп, янәшә утырулары тансыкка әверелеп бара шул. Анысы, кино-концерт, дисәләр, кечкенә Наилне карап торырга әбисе бар, һич авырыксынмый, сөенә-сөенә бала белән әвәрә килә. Бу юлы да, кибет каршында эленеп торган белдерүне күреп кайткач, Саимә үзе сүз башлады:

– Индийски кино килә, дигәннәр, барырсыз. Баланы имезеп калдырсаң, «эһ» тә итми ул, башны башка терибез дә, ятабыз да йоклыйбыз. Барыгыз, бар, рәхәтләнеп парлап йөреп кайтыгыз.

Нургаян үзе кино дип артык егылып китми, ә менә Зәйтүнәсенең, һинд киносы, дисәң, күзләре яна башлый мәгәр. Карап утырганда елап-шешенеп бетә, кулъяулыгы сыгып алмалыга әйләнә. Янәшәсендә утырган Нургаянга исә хатынын иңбашыннан кочып, юаткандай, вакыт-вакыт җилкәсен сөеп кую, үрелеп, юеш бит очын сөртү, кай мәлдә, аның кулын учына алып, йомшак, җылы бармакларын иренен ә тигерү экранда барган күренешләрдән күпкә өстен тоела.

Бүген дә, кичен икәүләп клубка барырга дип сөйләшкәч, яшь хатынның сөрмәле күзләреннән сабыйларча сөенеч сирпелде:

– Алайса, син дә бик кичкә калма инде, Нургаян, – диде ул иренә, үзе каенанасы ягына рәхмәтле караш ташлады. – Мин дә амбардан иртәрәк кайтырга тырышырмын.

Зәйтүнә яслеДә ашарга пешерә, ә кызу урак өстендә берәүгә дә син сатучы, син пешекче дип аерып тормыйлар, ындыр табагына көндезен дә, төнен дә икмәк агыла тора, эшче куллар бер дә артык түгел. Ясле дәгеләрне дә, бу атнада ничек тә булышыгыз инде, дип, амбарга дәшкәннәр иде. Менә, бүген соңгы көнен эшләп кайтса, Зәйтүнәсенең кулы чишелер иде чишелүен. Алайса, бала имезергә дә кайта алмый, Наилне кул арбасына салып, көн уртасында каенанасы амбарга үзе менә.

Нургаян, тәгаенләп куйган кишәрлекне сөреп бетерүгә, басу читенә чыгып, тракторыннан сикереп төште. Бертын, кулын каш өстенә куеп, күз алдында камыр шикелле күпереп яткан җир өстенә карап торды. Чиксез дала кебек җәйрәгән кап-кара туфрак, әйтерсең, тере җан иясе: ир-егет аның тип-тигез итеп сулыш алганына тиклем ишеткәндәй булды. Җир, гүя, тулгак газабыннан котылган яшь ана, шулкадәр җиңел һәм рәхәт сулап, татлы йокыга әзерләнә. Җыеласы икмәк

мул булып җыеп алынган, яңгырга эләкмичә, ындыр табагына озатылган, шушы көннәрдә туңга сөрүне дә төгәлләсәләр, күңел тәмам тынычланыр иде. Күп калмады, тагын бераз гына түзсәләр... Шулай дисә дә, хезмәтеннән зарланырга җыенмый Нургаян. Кая ул зарлану, киресенчә, кыр эшләре тәмам төгәлләнеп, кар төшәргә итүгә, эче тынгысызланырга тотына. Тизрәк яз җитүен, тракторын йөгәнләп, басу-кырларга чыгар мизгелләр якынлашуын сабырсызланып көтә.

Теге чакта, армиядән кайткач, калага барып урнашырга да җай чыккан иде. Китмәде Нургаян. Әнисен япа-ялгыз калдыруны күз алдына да китерә алмады. Нургаяннан башка таяныч булырдай беркеме дә юк бит аның. Аннары, тракторыннан аерылу да башына сыймый иде. Ярар, таныклыгы булгач, шәһәрендә дә техникага утырды ди. Ә бит иркен басу-кырларны, язын баш очында сайраган тургайларны, ерак чишмә ягыннан җил алып килгән тау бөтнеге исен кесәгә салып та, үзең белән ташкалага апкитеп тә булмый, агайне...

Яшелчә бакчасында үзе ясаган душ астында коенып чыккач, Нургаян сәгатькә күз салды. Җиде тулып маташа түгелме? Зәйтүнәсенең кайтып килгәне күренми әле, җәһәтрәк атлармын, дигән иде дә. И бу хатын-кыз. Кайткан җирләреннән туктап, сукмак уртасында ләчтит саталардыр. Аларның шул бит. Ике хатын бергә килсә – базар, өч хатын булса – ярминкә, димәсләр иде аны. Көне буе сөйләшсәләр дә, сүзләре бетми. Алай дисәң, Зәйтүнәнең гайбәт сатарга, буш сүз сөйләргә яратмаганын белмиме инде Нургаян? Башына каян җүләр уй килә... Ярар, өлгерерләр. Киноны, сигездә башлана, дип язсалар да, авыл халкы барыбер мал-туарын урнаштырмыйча, сыер саумыйча, тота-кабалана клубка ашыкмый.

Өйалды баскычыннан кып-кызыл помидор тулы табак тотып менеп килгән Саимә, улының һаман керергә җыенмавын абайлап:

– Ашка әллә кайчан токмач салганием, куерып бетә бит инде, нигә ашый тормыйсың? – дип борылып эндәште дә, табагын куеп, ишек төбендәге кәлүшләрне рәтләргә тотынды. Тел әрәм итеп әйтүе генә инде, хатыны кайтып кермичә, берүзе кашыкка барып тотынамы Нургаян? Ярар, сулышларын бер-берсе дип алып кына яшәгән көннәре, кеше күзләре генә тия күрмәсен. Алайса, Саимә үзе утыз биш яшендә ирле килеш сыңар канат калып, улыкаен берүзе аякка бастырды, язмышына тигән һәр бирмеш көне яланкул кычыткан, тигәнәк йолкуга тиң. Улы белән килененә парлы тормыш язсын берүк, тату яшәсеннәр.

Нургаян әнисенә җавап итеп елмайды да, тирә-ягына каранып:

– Наил кая, чатыр чапканы күренми? – диде, коймага сөялгән өч тәгәрмәчле сәпидкә ымлап.

– Йоклады бит, алҗуы җиткән, көн буе уйнады. Уятырмын инде, кояш батканда йоклавы хәерлегә булмас, – диде Саимә, болдыр ишеген бер ачып, бер ябып. – Күр әле, минем кебек шыгырдый башлаган бит бу, улым, майлап куярсың әле.

Нургаян, үзалдына күңелле көй сызгыра-сызгыра, ишегалдында торган трактор арбасына сикереп менде. Солидол салынган банка шунда почмакта гына иде. Үрелергә ашыкмады, хатыны күренмиме дип, урамга күз салды. Ачуы да килә башлагандай булды. Иртәрәк кайтам дигән кешенең эзе дә юк, Ә Нургаян ашкынган-кабаланган булды. Ашкынмас иде, Зәйтүнәсен сагына. Кешегә әйтсәң, кеше кычкырып көләр, өч ел бергә яшәгән хатыныңнымы, дияр. Чын менә, көнозын басуда йөргәндә, ирнең колагында, матур бер җыр шикелле, хатынының ягымлы, йомшак тавышы яңгырап тора. Күз алдында – сөеп туймас зифа гәүдәсе, калын итеп үреп куйган ике толымы...

Ир, арбада таралып яткан эш коралларын бер читкә җыеп куйды да, башын күтәреп, янә урамга карады. Шулвакыт капкадан, җил-җил атлап, күрше хатыны Илсөярнең кереп килгәне күренде. Муеннан урап бәйләгән яулыгы артка шуып төшкән, маңгаеннан шабыр тир ага, борчылуы йөзенә чыккан. Аны күргәч, йөрәге жу итеп киткән Нургаян арбадан ни рәвешле җиргә сикерүен абайламый да калды. Илсөяр дә, Зәйтүнә дә амбарда ашлык чистартуда. Илсөяр монда, ә Зәйтүнә? Хәвеф барын сизенүдән ирнең йөрәге айкалып алды.

– Нургаян абый, – диде Илсөяр, өзгәләнеп-өзгәләнеп, – әйдә әле тизрәк, анда ни...

– Зәйтүнә кая? – Нургаянның тоник тавышы әллә каян, баз авызыннан ишетелгәндәй иде.

– Ни бит... Зәйтүнәнең өстенә... погрузчик ауды бит! И бер Аллам...

Нургаянның күзалды караңгыланып китте, Илсөярнең беләген келәшчә кебек кысып алуын да сизмәде.

– Нәрсә дисең? Нәрсә ауды?

– Соң... погрузчик, дим... Ашлык төйи торган... – Илсөяр такмаклап еларга тотынды, үзе, беләген ычкындырып, Нургаянны җитәкләп алды. – Әйдә инде, кадакланып торма, тизрәк барыйк.

Нургаян, эченә йөгергән калтырауны басарга тырышып, аңа иярде. Аяклары җирне тоймый, гәүдәсе үзенеке кебек түгел, баш миен бары тик бер генә сорау бораулый, тик ул сорауны кычкырып кабатларга курка. Күрше хатыны «юк», дияр дә, ир, кәүсәсенә пычкы тигән агачтай, гөрселдәп җиргә авар шикелле.

– Мин, дивана, әйтми торам, – диде Илсөяр, атлый-йөгерә барган шәйгә ул сорауны күңел күзе белән укып, – исән ул, исән. Сине генә көтәләр, бүлнискә илтергә кирәк.

Калтырау кими төште, шулай да маңгаена салкын тир бәреп чыкты. Нургаян тешләрен кысып, берара уртын чәйнәп йөгерде. Йөрәге һаман да чабышкы атныкыдай дулый, сикерә, башны тубал итеп, берсе өстенә икенче сорау өелә бара. Ничек, ни өчен, ни рәвешле... Тик тел тибрәтеп сөйләшергә җай юк, нәкъ баягыча, янә аңкауга ябышкан диярсең; күзне дә сәер бер томан каплаган шикелле.

Илсөяр үзе еш-еш сулап йөгерә, үзе, юатырга теләгәндәй, аның кулына кагылып-кагылып ала иде:

– Инде кайтабыз гына дигән идек... Соңгы машина, дип бодай китерделәр... Мин аңышмадым да: еракка куйдың бит, дигәч, Ренат машинасын арткарак чигендерә башлады. Зәйтүнә, җирдә аунап яткан кабельне таптый, дип, шуңа иелгән икән. Чигенгән шәйгә, Ренат погрузчикны аударган, Зәйтүнәнең аркасына гына килеп төшкән...

– Соңыннан, соңыннан... – Ирнең колагы берни ишетергә теләми икән. Иң мөһиме – Зәйтүнәсе исән, диде, исән! Әнә, амбар капкасы кул сузымында гына, тамак төбенә килеп кысылган менә бу төерне йотып, ыграк йөгерсә, ике атлап бер генә сикерәсе...

Ашлык, тузан, кызган салам исен күмеп, тирә-якка, яз көнендәге кебек, ашлама исе таралган иде, ындыр табагында бодай көшеле янында авыз-борыннарын яулык белән каплаган хатын-кызлар кайнаша. Алар, Илсөяр белән Нургаянны күргәч, сүз берләшкәндәй, читкә тайпылдылар.

Ир җиргә тезләнде. Зәйтүнәсен сузып салганнар, яшь хатынның сызлануы бөтен йөзенә таралган, күзләре йомык, тешләре кысылган. Кадерле кешесенең килеп җитүен сулышыннан сизде булса кирәк, ул кинәт күзләрен ачты, ирексездән аккан яшьләреннән кыенсынгандай, кызганыч елмайды:

– Аякларым... аякларым юк бит, Нургая-а-ан... – Өзелеп-өзелеп шулай дигәч, керфекләре янә йозакка бикләнде.

Нургаян, аның кайнар бит очын, кулларын, хәрәкәтсез аякларын бертуктамый сөя-сөя, хатынын тынычландырырга ашыкты:

– Бар, бар, Зәйтүнәкәем, аякларың үз урынында... авыртканга гына тоймыйсыңдыр... – Аннан, үзенең дә ихтыярсыз аккан яшьләрен кул аркасы белән сөртә-сөртә, тирә-яктагыларга күтәрелеп карады. Хатыннар, телсез калгандай, агач көрәкләргә таянып торалар, кепкасын кашларына кадәр төшергән Ренат, машина арбасына сөялеп, бертуктамый тәмәке көйрәтә, берсен ташлый, икенчесен кабыза.

– Рәхимә апага эндәшүче булмадымы? – Нургаян, хатыны янында авыл фельдшеры күренмәгәч, аптырап киткән иде, сорау тулы карашын янындагыларга төбәде.

– Рәхимә апа юк шул, кичкырын күрше авылга оныкк күрергә киткән, ди.

Өнсез калган хатын-кызлар да аңга килә башладылар ахры, арадан берсе:

– Районга илтегез инде, болай яткызып эш чыгамыни?! – диде, Нургаянга карап.

Ни уйларга, ни кылырга белми исәңгерәгән ир әле һаман хатынының кулын сыпыра, йөзен сыйпый иде, шулай дигәч, айнып киткәндәй булды. Ярдәм сорагандай, тагын башкаларга күтәрелеп карады.

Күршесе янына иелгән Илсөяр Ренатка ымлады:

– Син илтсәң инде. Кемне эзләп йөрисең хәзер.

– Ярар. – Ренат артык сүз әйтмәде. Тәмәкесен ташлап, кабинасына юнәлде.

Амбар коймасы яныннан иске ишек табып килделәр, Зәйтүнәне шуның өстенә күчереп салгач, машина әрҗәсенә менгерделәр. Нургаян аның янына утырды. Больницага барып җиткәнче, юлның һәр бормасында, һәр сикертмәсендә аның җаны өзелеп-өзелеп киткәндәй булды. Зәйтүнәсе әллә аңын җуйган, әллә сабырлыгы шул дәрәҗәдә – ник бер аһ итсен дә бер ыңгырашу авазы чыгарсын! Кай җирләре авыртадыр да, ничекләр түзәдер. Аякларым, ди, югыйсә, аяклары бәрелгән-сугылган кебек тә түгел, сынган-шешкәнгә дә охшамаган... Исән җаныкае, исән – шуннан артык ни кирәк? Сынган җире булса да төзәлер, барысы да җайланыр, үтәр. Исән бит аның күз алмасы, шатлыгы, җанкае, бәгырькәе, яшәвенең мәгънәсе. Шулкадәр яратып кавышканнарны Ходай болай гына сынамый калмас инде. Әнә бит, Таһир-Зөһрәләрне, Хәлил-Галиябануларны ничекләр сынаган, аерып сынаган, суларга агызып сынаган. Нургаян белән Зәйтүнә бергә бит әле, менә, хатынның бармак очларыннан агылган җылылык, тәндә яшәү суты барлыгын белдереп, ирнең дә тәненә өмет булып тарала. Нургаян үз учына алган йомшак бармакларны ныграк кысканын тоеп, хатынының кулын ычкындырды. Кул, яралы кош канаты сыман, читкә каерылып төште. Коты очкан Нургаян Зәйтүнәгә таба иелде:

– Әнисе, әнисе... Хәлең ничек, җанкаем? Түз инде, барып җитәбез хәзер.

Эндәшсен, җавап кына кайтарсын берүк. Авырта, көчкә түзәм, дисен, тик эндәшсен, эндәшсен генә...

– Наил... Әнкәй беләнме? – Зәйтүнәнең бер-берсенә укмашкан керфекләре дә, күгәреп каткан иреннәре дә ачылыр-ачылмас тибрәнде.

– Көн буе уйнаган, йоклый иде әле. Аның өчен кайгырма. – Нургаян хатынының юешләнеп маңгаена ябышкан чәчләрен рәтләде.

– Имәргә сорар инде... – Күгелҗем күзләр мөлдерәп яшь белән тулды.

– Ат хәтле малай, туктаса да ярар. – Ир, үзе дә йомшап төшмәс өчен, тавышын юри кырыслатты. – Авыз тутырып ботка ашар, нибуч, ике яше тулган.

– И-и, Нургаян...

Ата – беләк, ана – йөрәк, диләр шул. Зәйтүнәнең бәгыре, тән газабын онытырга мәҗбүр итеп, сабые турында уйлап сызыла иде.

Йөк машинасының әрҗәсендә, кулга-кул тотынып, яшь ир белән яшь хатын бара. Әле парлап яши генә башлаган, тәүге нарасыйларының чырык-чырык көлүенә сокланып туялмаган, бөтерчек малай янына тагын бер оя кызлар-малайлар алып кайту турында хыялланган яшь ата белән яшь ана. Хыяллары да, өметләре дә баш очында озата барган мамык болытлардай ак әле, хисләренә дә бер бөртек тузан кунмаган: һәр икесенең күңеле мәхәббәттән яктырып тора. Коточкыч авыртудан Зәйтүнә вакыт-вакыт аңын җуеп ала. Андый мәлләрдә күз алдыннан үзенең ап-ак чәчкәле тау итәгеннән оча-йөгерә төшеп килгәне сызылып үтә. Әй йөгерә, әй йөгерә, аяклары җиргә тигән дә, тимәгән дә кебек. Ул да булмый, әлеге ак чәчкәләрнең һич кенә дә тау итәгендә түгел, әнкәсе йортында, сәке буендагы тәрәз төбендә, авылда бер булып шаулап утырган «кәләш» гөле икәнен абайлап ала. Гөл янында иренең шәүләсе тирбәлә, ул бертуктаусыз «Зәйтүнә, Зәйтүнә», дип кабатлый-кабатлый, шул гөлгә су сибә, гөлнең ап-ак таҗларына кап-кайнар сулышын өрә. Үзе кулы белән бертуктамый Зәйтүнәнең калын толымнарын сыйпый.

***

– Теге кызның чәчен карале, чын микән ул?

Тузанлы басу юлының читендә гамьсез генә утырган ике егетнең дә муены, каерылып чыгардай булып, уңга борылды. Юлдан, шактый иске икәнлеге күренеп торган сәпидкә утырып, бер кыз килә иде. Өстендә – коңгырт күлмәк, аягында – кәлүш. Башына, арттан чөеп, акка кара борчак төшкән косынка бәйләгән. Икегә аерып үргән озын толымнары, сәпид тәгәрмәче әйләнгән шәйгә, ефәк бау шикелле, елкылдап-елкылдап китә. Озын баулы чүпрәк букчасын җилкәсенә аскан.

Нургаянның күзенә иң тәүдә озын толымнар ташланды. Булса да булыр икән! Тузгытып җибәрсә, биленнән дә хәйран узып китәдер! Егет ни өчендер башындагы кепкасын йомарлап кулына тотты.

Вәсим исә теш арасына кыстырган үлән сабагын, саташыпмы, нигәдер кесәсенә салып куйды.

Кыз аларга якынлашты. Юлга якын ук утырган егетләрдән куркуы булдымы, сәерсендеме, каушадымы, тизрәк үтеп китәргә теләп, сәпиден җитезрәк әйләндерергә тырышты. Үч иткәндәй, аяклары буталган кебек тоелды, оялудан бите алмадай кызарырга өлгергән кыз, ике егеткә керфек арасыннан ялт кына бер карап алды да, аларның юлбасар да, карак та түгеллегенә инанып, юлын дәвам итте.

– Безне дә утырт әле! – дип шаяртып кычкырган Вәсимгә җавап кайтаручы булмады.

Бүтән чакта җор телле, һәрнәрсәне шаяруга борырга яраткан Нургаян, кызның артыннан текәлеп, сихерләнгәндәй, телсез калган иде. Вәсим, аның янтыгына төртеп: «Һәй, ике күзең ияреп китте түгелме?» – дип көләргә тотынгач кына, айныгандай булды. Кепкасын янә кашына ук төшереп киеп куйды. Шуннан соң гына:

– Вәйт чибәр! Моны эләктерсәң дә ярар иде! – диде, мәзәк кенә тел шартлатып.

– Һи, бала-чага гына... – Вәсим сер бирергә теләмәде. Ул күрше авыл

больницасына шәфкать туташы булып кайткан Венера исемле кызга күз атып йөри иде. – Наратлыга мәктәпкә баруыдыр инде.

– Наратлыга баргач, бала-чага түгел инде, агай-эне, – дип каршы төште Нургаян. – Тугызда йә унда укыса, самай җиләк чагы... Каян килгән диген!

– Каян килсен... Безнең авылныкыдыр. Югары очтан төшеп килә бит.

– Әй, ул очларны каян белеп бетермәк кирәк, без – аерым, алар – үзләре аерым авыл шикелле, – диде Нургаян, башын янә кыз китеп барган якка борып.

Чыннан да, Нургаяннарның авылы кызык кына урнашкан: аны икегә бүлеп, уртадан тар гына инеш ага. Таулырак якка урнашкан өлешен «Югары оч», дип йөртәләр, иңкүлеккә урнашканын «Түбән оч», диләр. Сөйләшкәндә дә, кызык итеп, «Югары очка чыгып кайтам, менеп төшәм», дип сөйләшәләр. Кибет – Югары очта, шуңа күрә авыл халкы кибеткә «менә», ә клубка «төшә» – анысы Түбән очта. Һәр ике якның үзенең зираты бар, хак микән, Нургаяннарның урамын элек аерым авыл булган, дип тә сөйлиләр.

Вәсим белән Нургаянның, тракторга запчасть алырга дип, утыз чакрым ераклыктагы совхозга барулары иде. Бару дип, шушында күрешәбез дип сөйләшсәләр дә, ат җигеп килеп җитәргә тиешле «шофёр»лары һаман күренмәгәч, егетләр юл читенә чүмәштеләр дә гамьсез генә көтүләрен белделәр.

Ике дус, армиядән кайтуга, икесе дә тракторга утырдылар. Тик бергә озаклап җир җимертеп йөри алмаслар ахры. Шушы араларда колхоз рәисенә яңа машина кайтып, аның рулен Вәсимгә тоттырырга җыеналар, дигән сүз йөри. Утсыз төтен булмый: рәис – чыбык очы булса да, Вәсимнәргә туган тиешле кеше. Бу хакта егетнең үзеннән сорагач: «Тумаган тайның билен сындырмыйк әле, күз күрер», – дип кенә җаваплады ул, артык җәелеп төшмичә.

Көтә-көтә тәмам көтек булдык дигәндә генә, ниһаять, юлда колхозның җирән алашасы күренде.

Ат арбасыннан аякларын салындырып барган Нургаянның күңеле камыл арасында утырып калган иде. Егеткә кинәт кенә әллә нәрсә булды: баягы кызның мизгел эчендә генә чалынып калган йөзе, озын толымнары күз алдыннан китми йөдәтте. Югыйсә, рәтләп күргән шикелле дә булмады үзе. Алай дисәң... Сабыйлыгы да китеп бетмәгән чип-чиста йөздә күкчәчәк таҗына тартым бераз озынчарак күгелҗем күзләрне, аларның гаҗәеп яктылыгын аермачык күрде. Туп-туры булып сызылган кашларны да. Бераз турсаебрак, өскә кайтарылып торган сылу иреннәрне дә. Хәтта... үтә күренмәле шикелле алсуланып торган колак яфракларын да күргән икән.

И-и, әллә нәрсә югалып, җебеп калды бит шул чагында. Исемен булса да сорыйсы иде бит! Нәрсәсе бар инде аның? Сикереп торасы иде дә артыннан йөгерәсе иде. Вәсим тәгәри-тәгәри көләр иде көлүен. Көлсә, аннан гына укасы коелмас иде әле Нургаянның... Ярар, клубка чыгарга, шунда күзне ачыбрак карарга кирәк булыр. Кем бу чибәркәй, егете бармы – белми калмас...

Тик ярты төн җиткәндә эштән кайтып, юынып-киенеп ничә кич рәттән клуб сукмагын таптамасын, шау-гөр килеп күңел ачкан яшь-җилкенчәк арасында күгелҗем күз бер генә тапкыр да күренмәде.

Беркөнне Нургаянны күрше авыл басуына чөгендер ташырга куйдылар. Кичтән яңгыр явып киткән, аяк асты пычрак иде. Шулай булса да, авыл җирендә бүгенге эшне иртәгәгә калдыру гадәте юк: яңгыр ул атналар, айлар буе да явар. Күккә карап кояш көтеп ятсаң, бакчадагы бәрәңгеңне кар астыннан казып алыр көнгә дә калуың бар...

Басу гөрләп тора. Мәктәп укучылары чөгендерне җыеп, өемгә өеп,

яфракларын кисеп куйганнар. Итекләренә, авырлык өстенә авырлык өстәп, йодрык-йодрык юеш балчык ябышкан. Нургаян, тракторын чөгендер өемнәре янына күчергән уңайга, аларга кызыгып та, кызганып та карап ала. Кызыкмас иде – эш авыр дип тормыйлар, күмәк булуларыннан файдаланып, рәхәтләнеп гөрләшәләр, шаяралар; егетләр, әнә, юк сәбәпне бар итеп, кызлар тирәсендә кайнаша: кайсы ялгыш кына бәрелеп киткән була, икенчесе, үз рәтен ташлап, берәр кызга булыша, өченчесе, кулындагы чөгендерен оныткан да, аягүрә йоклап киткән шикелле, алдындагы ак яулыкка текәлеп каткан... Авыл балаларын кызганмаслык та түгел: уку елы башлануга, китап-дәфтәр урынына колхоз басуы көтә шул үзләрен. Бер басуда бәрәңге алалар, икенчесендә чөгендер йолкыйлар, ал да, ял да юк үзләренә. Нургаяннар укыганда да шулай булды, бер елны, сигезенчедә чагында, тоташ яңгыр астында бәрәңге җыйганнарын мәңге онытасы юк егетнең. Туңып, чиргә сабышып беттеләр, кемгә ютәл төште, кемгә – томау. Әмма чирлим дип өйдә аунап ята торган чак түгел иде, кичтән мәтрүшкәле чәй эчеп яттылар да иртән янә яңгыр астына, басуга ашыктылар... Ул бәрәңгене арбалап-арбалап, мең бәла белән колхоз базына илтеп бушаттылар. Язын әлеге базны ачу да мәктәп балалары җилкәсенә төште. Кулларында көрәк булганнар башта баз өстенә өелгән туфрак катламын ачты. Сәнәклеләр туфрактан соң салынган саламны кубарды. Катлам юкарган саен борынны ярып кергән яман ис көчәя генә барды. Бераздан, инде ачылды дигән баз авызында, алагаем күл булып, черек бәрәңге боткасы пәйда булды. Нургаян бүген дә бер нәрсәгә аптырый: ул ботканы күңел болгаткан сасы искә көчкә түзгән балалардан түктерү кемгә, нигә кирәк булды икән дә, кайсы җүләренең башына килде икән ул эш? Көрәккә чак эләккән сыеклыкны бер чокырдан ала торалар – янәшәгә түгә торалар. Моннан да ахмаграк, мәгънәсезрәк гамәл булмас иде, каядыр хисап бирү өчен башкарганнармы? Янәсе, фәлән тонна бәрәңге чыгардык, кызганыч, барысы да черегән... Кара сакалың кая барсаң да үз артыңнан калмый шул: балалар, балчыкка каткан чиләкләрен сөйрәп, көзен ай буе интеккәннәр иде, яз да аларга ярык кашык әзерләгән икән...

Тракторны күчерергә кушып кул изәүләре Нургаянны уйларыннан арындырды. Алда торган чөгендер өеме янына барып туктады да, аякларын язарга теләп, кабинасыннан сикереп төште. Төште дә, үз күзләренә үзе ышанмыйча, керфекләрен челт-мелт йомгалап, арбага чөгендер ыргыткан кызга төбәлде. Кара сырма, кара итәк кигән, башыннан урап зәңгәрсу юка шәл бәйләгән кызыкай – беркөн ай күрде, кояш алды дигәндәй юк булган күгелҗем күз иде. Калын толымнарын, калкулык итеп, баш артына, шәл астына яшергән. Кулындагы пирчәткәсе юешләнеп беткән. Җитезлегенә күз иярми: самавыр хәтле чөгендерләрне бармак очы белән генә дигәндәй эләктереп ала да, җилле-җилле генә итеп, арбага очырта. Кыз Нургаянга бөтенләй игътибар бирмәде, күзен дә күтәреп карамады, эшләвен белде. Шулчак янәшәдәге кызларның берсе:

– Зәйтүнә, әнә теге бәләкәй чөгендерне Нургаян абыйның башына ыргыт әле, айнып китмәсме? – дип эндәште дә челтерәп көлеп җибәрде.

Онытылып басып торган Нургаян теленә шайтан төкергән ул кызга эченнән генә мең рәхмәт укыды. Бик ансат кына озын толымның исемен дә белеп өлгерде бит.

Егет ике уйлап тормады, яктырып елмайды да:

– Юк, юк, чөгендер тимәгән килеш тә баш эшләми әле монда, – дип, Зәйтүнәгә борылды. – Зәйтүнә, чөгендереңне ыргытып бетеримме?

Кыз башын күтәрде, күзләрен тутырып Нургаянга бер карады да шунда ук, оялып, керфекләрен түбән төшерде.

– Ыргыт соң, – дигән сүзе дә ишетелер-ишетелмәс кенә яңгырады.

Егеткә шул сүз, шул караш җитә калды – өстендәге сырмасын салып, җәһәт кенә кабинага ташлады да дуамалланып эшкә ябышты. Зәйтүнә кишәрлегендәге башта бер, аннан икенче өем, әллә нинди тылсымлы кулга эләккәндәй, трактор арбасына күчеп өлгерде.

– Әлләй, анықын гына ташыйсыңмыни, Нургаян абый? Ә без? – диде бу юлы үпкәле тавыш белән баягы кыз, аңа башкалар да кушылды.

– Бигайбә, кызлар, – дип күзен кысып елмайды Нургаян, тулы арбаны бушатып кайтырга кузгалып. – Үзегез бит, башыма чөгендер ыргытырга куштыгыз да... Мин шуннан куркып кына... Хәзер әйләнеп киләм, сезнеке дә басуда утырып калмас...

Кузгалып китүгә, Нургаян кабинага гына түгел, бөтен җиһанга яңгырарлык итеп, күңеленә беренче килгән җырны сузды:

Су буена килмәс идем,
Су салкынын сизмәсәм.
Өзелеп җыр җырламас идем,
Син җаныемны сөймәсәм...

Егетнең тавышы матур, күкрәк түреннән агылган моң белән сугарылган иде. Үзалдына елмаеп, эченә әллә ни кереп утыргандай, җыр арты җыр көйләде ул. Бу араларда чыкмаска дигәндәй, болыт артына качкан кояш та аның җанына кереп урнашкан шикелле; сагыш төсе белән өртелгән каеннар да өр-яңадан яфрак ярырга җыенган кебек тоелды. Трактор тәгәрмәчен ярыйсы гына салуларга мәҗбүр иткән менә бу кара басу юлында кочак-кочак күкчәчәкләр тирбәлгәндәй күренде.

Әлеге минутларда Нургаян озын толымлы сылуның нинди утларда януын чамаламый иде әле. Кыз да аны тәүге тапкыр күргәндә, юл читендә чүмәшеп утырган мәлендә үк күз уңына алган, сихри җылылык бөркелгән ачык йөзле бу чибәр егетнең йөз сызыкларын күңелендә әллә ничә кат рәсем итеп ясаган иде. Ул яраткан һинд киноларындагы артистларга охшаган! Маңгаена төшеп торган кара чәч учмасына тиклем шуларныкы кебек! Коңгырт күзләренең тупТуры итеп, өздереп каравы!.. Бүген, чөгендер ташырга килгән тракторчының Ул икәнен күреп алуга, кыз уттан суга, судан утка төшеп аһ иткән иде. Басудагы әллә кемнәр, әллә кемнәр арасыннан тап аңа гына ярдәмгә ашыккан егет – унҗидесе тулмаган кызның хыялы, өмете, бер күрүдә бөреләнгән саф мәхәббәте иде.

Икенче көнне идарәдә иртәнге нәрәт вакытында Нургаянны үз авылларындагы басуга, бәрәңге ташырга билгеләделәр. Әй үртәлде егет, кәефе кырылды, чөгендергә куегыз, әле эш бетмәде бит, дип тә карады – нигәдер аның теләген исәпкә алучы булмады. Бүген дә Зәйтүнәне күрермен дип өметләнгән егет канатлары бәйләнгән очар кошка, тышаулап куелган чабышкыга тиң иде. Кичә сазга баткан басуда да келтерәп кенә йөргән тракторы бүген ярыйсы гына кипшенгән җирдә дә карышып маташты, гүя ул да хуҗасына теләктәшлек күрсәтә, бармыйм булгач бармыйм, дип үҗәтләнә... Нишлисең, нәрәт бирелгән: син колхозчы, син кол, эштән башканы дәгъваларга синең хакың юк.

Бүген бөтен җырларның сүзе дә, көе дә онытылган: егетнең юлдашы – моңарчы бер генә тапкыр да татымаган сагышлы бер сагыну иде.

Тау өстеннән җәелеп киткән басуның бер башы – Югары оч зиратына, икенче башы рәт-рәт утыртылган каеннарга тоташа. Басу инде буразна-буразна итеп казылган, бәрәңге, кайсы тавык йомыркасы, кайсы бала башы хәтле булып, таралып ята. Монда да бүген мәктәп балаларын менгергәннәр, әле җыелып бетмәгәннәрме, капчык көтәләрме – эшкә тотынмаганнар, каеннар тирәсендә чиләкләренә тезелеп утырганнар да чыркылдашалар.

Нургаян, тракторы белән килеп туктауга, кабинасыннан туп-туры арбасына сикерде, амбардан кочак-кочак итеп алып килгән капчыкларны җиргә ташлады. Үзе, шушы кычыткан чыпчыклары арасыннан өзелеп-өзелеп күрәсе килгән кешесен табарга теләгәндәй, өметсез генә бер караш белән кыз-кыркын ягына күз атты. Һәм... тапты да! Бәрәңгегә менгән кызлар арасында, башын аска иебрәк, кара сырма, кара итәк кигән, бүген инде алсу шәл бәйләгән Зәйтүнә дә бар иде!

И, болай булгач! Чөгендер басуына бар, дип, райком секретаре хет үзе ялынып килсен хәзер – Нургаян теше-тырнагы белән ябышып булса да шушында, тәгәрәп яткан бәрәңге арасында торып калачак...

Кыз исә аның тракторының зәңгәр түбәсен әллә кайчан абайлап алгандыр, йөрәгенең күгәрчен канат каккандай лепер-лепер итүе башкаларга ишетелмәсен дип, кулын күкрәгенә куеп, башын игәндер. Бит очларындагы кайнарлык ялкын булып кабына күрмәсен дип, шәлен йөзенә табарак тарткандыр...

Нургаянга җыр сүзләре әйләнеп кайтты. Теленнән төшеп кенә тамар иде дә басуны яңгыратыр иде:

Су читенә иелдем,
Төнбоекка үрелдем;
Бер елмаеп кара миңа,
Зәйтүнәкәй, акчарлагым,
Күтәрелсен күңелем...

Юк шул, анысына батырлык җитми... Кара инде, әллә берәр тылсым көче бармы соң бу кызда? Башны гел аның ягына борасы, күзне алмый карап кына торасы килә үзенә. Агыйдел камышы шикелле зифа сыны, сырма кигән килеш тә йөзек аша үтәрдәй нечкә биле, оялчан карашы, яп-якты нур бөркелгән түгәрәк йөзе үзенә тарта гына бит, әй. Югыйсә, як-ягыңа боргалансаң, төпченеп-төпченеп карасаң, башка кызлар арасында аннан да чибәррәкләре, шомырт кебек кара яки кыңгырау гөлдәй зәңгәр күзлеләре, мине үп, дип чакырып торган күперенке иренлеләре, толымнарының билгә түгел, үкчәгә җиткәннәре бардыр. Юк инде, күңел күзе дә, маңгай күзе дә шушы кызыкайдан башканы күрми түгелме? Күрми дә, күрергә теләми дә... Нәрсә булды соң әле бу? Кем әйтмешли, февраль микән, март микән – гыйшык микән, дәрт микән...

Бу – мәхәббәт иде. Моңарчы үзенә буйсындырмаган, йөрәкне чемер-чемер китермәгән тәүге, чиста, саф, эчкерсез мәхәббәт могҗизасы иде.

Кызлар-егетләр, җиргә ташланган капчыкларны күбрәк эләктерергә теләп, кош көтүедәй шул якка ябырылдылар. Үзләре көләләр, әйткәләшеп тә өлгерәләр, капчык бүлешәләр. Нургаяннар чорында да нәкъ шулай иде, чөнки укучылар, икешәрләп басып, туп-туры берничә рәт ала да, тизрәк шуның карап-карап күзне күгәртердәй икенче башына чыгып җитәргә ашыга. Хәлдән таеп булса да чыгып җиттеңме, чиләк өстенә утырып яки җиргә чүмәшеп, рәхәтләнеп ял итә аласың. Иртәрәк чыктыңмы, димәк, иң соңгы кеше сөйрәлә-

сөйрәлә эшен бетергәнче, иң күп ял тәтегән дә син булырсың... Дөрес, намус дигәнең бимазаласа, чиләгеңне күтәреп, күршегә ярдәмгә ашыгасың, әнә бит, бахырлар, җан-фәрман эшләгән кыяфәт чыгарсалар да, артта сөйрәләләр... Яртылаш балчыкка каткан бәрәңгене башта өемнәргә өяргә, аннан чиләк белән капчыкка тутырырга, тук капчыкның авызын бәйләп, бастырып куярга кирәк. Ул капчыкларны егетләр арбага чөеп аталар, өстә торганнар рәтләп тезеп баралар – эшлим дигән кешегә эш җитәрлек!

Нургаян, кабинада утырган килеш, әледән-әле Зәйтүнәнең ал шәле балкыган рәткә күз ташлый. Ике кыз, артык каударланмый гына эшләгәндәй күренсәләр дә, иң алдан баралар, чиләкләре уйнап кына тора. Чү, капчыклары бетеп китте түгелме соң? Их, белгән булса, Нургаян трактор кабинасына кочак-кочак салып куйган булыр иде дә, менә хәзер, шуларны күтәреп, кызның алдына ялт кына барып басар иде. Бүген бит сәлам бирешергә дә, сүз алышырга да җай булмады. Ярар, арбаны бушатып урап килгәндә, акыллырак булыр...

Буш арбасының тәгәрмәчләре җиргә әллә тиде, әллә юк, басуга менеп җитүгә, Нургаян арба өстеннән янә бер өем капчыкны алып ташлады, бер-берсенә бәрәңге атышып, шаярып утырган кызлар-егетләр янә шул тарафка ябырылдылар. Зәйтүнә арба янына килеп баскач, егет аның каршысына сикереп төште дә:

– Зәйтүнә, капчык биримме? – диде, «исәнме-саумы»лап тормыйча, турыдан ярып.

Кызның керфек арасыннан рәхмәтле дә, сөенечле дә бер нур түгелде, бу юлы да тавышы ипләп кенә чыкты:

– Бир соң...

Кабинага таслап төреп куелган капчыклар кызның култык астына күчте.

– Һай, абый! Кеше араламасаң...

– Кара, кара, Зәйтүнәгә асубыйны апкилгән түгелме?

– Әллә күзең төштеме, Нургаян абый?

Чаярак кызларның берсен-берсе бүлеп көлешүе бөтен басу өстенә таралды. Укытучы апалары, шәл астыннан бүселеп чыккан чал чәчләрен рәтли-рәтли:

– Эш калдырып телгә салынмагыз, әйдәгез, әйдә, – дип, аларны үз рәтләренә кумаса, комач кебек кызарган Зәйтүнә, җир ярылса, шунда кереп качар халәткә җиткән иде.

Кызлар көлешүдән туктамый гына эшкә тотындылар.

Кайчандыр Нургаянның үзен дә укыткан өлкән яшьтәге укытучы, егетнең дә югалып калуын сизеп, аңа үз итеп елмайды.

– Күзең төшсә дә гаеп түгел, үскәнем. Зәйтүнәгә җиткән юк авылда. Уңганлыгы дисеңме, ул сабырлыгы, тыйнаклыгы дисеңме... – Бүтәннәр колагына ишетелмәслек итеп, пышылдап кына әйтте дә, кайберәүләрнең тагын сабыйларча бәрәңге ыргытып уйный башлауларын күргәч, ах-вах килеп, шулар янына ашыкты. – Җиткән егетләр бит инде сез, кайчан акыл керер, ә... Башын ярасың бит, куй бәрәңгеңне...

– Апа, апа, Зиннурга табышмак әйткән идек, дивана кебек көлә. Әйтегез әле, туктасын... – Егетләрнең берсе, артка борылып башкаларга күз кысты да, теләктәшлек өмет итеп, бер гөнаһсыз йөз белән укытучының күзенә текәлде.

– Башта эшләгез, аннан уйнарсыз... Кая, ниткән табышмак? – Укытучы, чәченә чал төшсә дә, күңеле белән үзе дә бала иде шул.

Зиннур дигәннәре, иптәшенең йодрык күрсәтүен күрмәмешкә салышып:

– Ач булса – ята, тук булса – торып утыра, ди, нәрсә соң ул, апа? – диде, булышыгыз инде дигәндәй, ялварулы тавыш белән.

Апалары ялт кына аның култык астындагы буш капчыкны тартып алды да егетнең борын төбендә селкеде.

– Күп сөйләнеп торганчы, менә моны авызына кадәр тутырсаң, нәрсә икәнен бик тиз белер идең...

– Ну-у, апа, нигә әйттегез инде...

Ике йөрәкне бер иткән мәхәббәт яралсын өчен, челтерәп аккан чишмә буйлары, кыя тау итәкләрен юган диңгез дулкыннары, тургайлы тугайлар, шау чәчәккә күмелгән болыннар, шадраланып торган күл өсләре, шәһәрнең ясалма бакчалары, тукталышлары, пятачоклары булу һич мәҗбүри түгел. Мамык кебек сихри карлар яуган мизгел дә, ләйсән яңгыр астында гөрләвекләр челтерәгән чак та, алмагач-шомыртларның, туй күлмәге киеп, җил кочагында биегән мәлләре дә мәҗбүри түгел. Мәхәббәт һәр йөрәккә үз мизгелендә, үз төсендә, үз матурлыгында килә дә куна икән. Ул кыршылып беткән иске сәпидкә утырып килергә дә мөмкин икән, яңгырдан соң итеккә ябышып интектерә торган басу туфрагыннан да гөл булып күтәрелә икән, искерә төшкән кара сырма, зәңгәр түбәле трактор төсендә дә була ала икән... Бу – гаҗәеп бер хис икән: башыңны әйләндерә, йөрәгеңне иләсләнеп тибәргә мәҗбүр итә, кичә генә дөньяда барлыгын да белмәгән берәү кинәт кенә синең аерылгысыз өлешеңә әверелә. Шулчагында аптырап уйланасың: ә моңа тиклем? Моңа тиклем шул берәүсез ничекләр яшәлгән соң?..

Дөрес, әле Нургаян да, Зәйтүнә дә күңелләрендә купкан бу сәер давылга «мәхәббәт» дип исем кушарга өлгермәделәр. Аларның йөрәкләре, хуҗаларына буйсыныпмы, буйсынмыйчамы – бер-берсенә тыелгысыз булып тартыла, бары шул гына иде...

Ярый әле тау түбәсендәге басуга бәрәңгене гектарлап-гектарлап утырткannар. Ярый әле ул бәрәңгене җыярга, өяргә, төяргә тугызынчы-унынчы сыйныф балаларын чыгарганнар. Ярый әле амбардан капчыкларны, күзгә кырып кына салгандай, саранланып кына тоттыралар. Юкса, Нургаянга үткәндә дә, сүткәндә дә Зәйтүнәгә капчык бирергә туры килмәс иде, кыз да аңа, озын керфекләрен күбәләк канаты кебек лепердәтеп, рәхмәтле төбәлмәс иде, егет шул караштан исереп, кабинасында бертуктамый җыр көйләмәс иде.

«Мин сине капчык белән кулга ияләштердем», – дип шаярта иде Нургаян соңыннан, туйлар ясап кавышкач. И-и, аңынчы соң, дүрт ел йөрделәр, дүрт ел!..

Әлеге дә баягы бәрәңге басуында эшләгәндә, яңгыр ява башлагач, балаларга кайтып китәргә кушылды. Берәүләр, яшьлекләре белән, көзге яңгырга да кинәнә-кинәнә, чиләкләрен башка киеп, уйный-көлә җәяү кайтып китте, берничәсе арбадагы капчыклар янына сыенды, ә Зәйтүнә белән аның иптәш кызын кабинага утыртты Нургаян.

– Иң юкалары сез, икегез бер кешелек, – дип шаярткан булды егет, үз гамәленә аклану табып.

Әйтерсең, аның йөрәк ялкынын бүтәннәр күрмиләр дә, сизмиләр дә!

Юлын юри Түбән очтан башлады Нургаян. Балаларның берише шунда коелды. Югары очка кергәч, арбада капчыклар гына утырып калды. Тыкрык башында Зәйтүнәнең иптәш кызы да җиргә сикерде. «Җәяү атлыйм» дип аның артыннан талпынган Зәйтүнәгә Нургаян:

– Әйдә, капка төбеңдә төшәрсең, чыланып йөрмә, – диде, әлегәчә кызның кай тирәдә яшәгәнен, кем кызы икәнен белмәсә дә.

Бераздан кыз, тәрәз каршында балан куагы үсеп утырган дүртпочмаклы өйгә ымлап, шунда туктарга кушты.

– Бәй, Халисә апаның синең кебек кызы бармыни? – диде Нургаян, минутларны сузар өчен болай да әкрен генә барган тракторны бөтенләй ташбака адымына калдырып. Аннан башын чайкап: – Кара, без бер мәктәптә укыганбыз була түгелме соң? – дип өстәде.

– Шулайдыр инде. Түлке мин сине гел белмим, күргәнем дә булмады, Нургаян абый, – диде кыз, үзе, энҗе тешләрен җемелдәтеп, ихлас елмайды.

Нургаян, кепкасын баш артына шудыртып, башын кашыды.

– Вәйт кызык, мин дә сине хәтерләмим... Һи, хәтерләргә, мин сигезенчедә укыганда, син башлангычта гына чатыр чабып йөргәч соң...

Икесе дә тын калдылар. Трактор инде баланлы капка төбен узып бара иде.

– Мине калдырырга онытасың бит, Нургаян абый, – диде кыз, ишеккә тотынып.

Егетнең менә болай, тиз генә аннан аерыласы килми иде, ул:

– Бу бәрәңгене амбарга менгерик тә, кайтышлый төртеп булса да төшерермен, – дип шаяртты.

Тик кыз шунда ук җитдиләнеп китте.

– Юк, – дип, егетне кискен генә бүлдерергә ашыкты. – Төшәм. Болай да инде, әнкәй күреп калса...

– Алайса, кичке уенга чыгарсыңмы соң, Зәйтүнә?

Нургаян аңа туп-туры текәлде, утлы караштан ике бите мәк чәчәгедәй янарга тотынган кыз үзе дә сизмәстән баш какты, аннан кыюсызланып кына:

– Әнкәй рөхсәт итсә инде... Чыгып йөргәнем юк бит, – диде дә, ишекне ачып, җиргә сикерде.

Аның борылып каравын көтеп тилмергән егет аркада тибрәлгән ике калын толымга текәлеп торды, кузгалып китәргә ашыкмады. Өмете акланмагач, үзе дә, тракторы да авыр сулап кына амбар ягына юл тотты.

Аларны Зәйтүнәнең күз карашы койма ярыгыннан байтак кына озатып барды.

Инеш буенда тәмәке көйрәтеп, көлешеп торган егетләр, авызларына су капкандай, кинәт тын калдылар.

– Нәрсә дип күзегезне чекерәйттегез, кеше күргәнегез юкмы әллә? – Яулыгын галстук кебек муенына ураган чая тавышлы кыз тирә-якка шаян караш ташлады. Аның култыгына тотынган, озын толымнарының берсен аркасына, икенчесен күкрәгенә салындырган зифа буйлы Зәйтүнә исә, керфек күтәрергә дә оялып, егетләр яныннан йөзеп кенә үтте.

– Тәк, монысы ниткән асылкош булды бу? – Егетләрнең берсе, өлкәнрәк күренгәне, кепкасын баш артына этеп куйды да теш арасыннан гына җиргә чертләтеп төкерде. – Үзем кармак салам, ишетеп калыгыз...

– Сиңа каба торган балыкка охшамаган түлке... – Икенчесе шулай диюгә, ярны җимерердәй итеп шаулап көлештеләр.

– Ипи шүрлегеңне сакла, энекәш, менеп төшмәсеннәр... – Кепкалы егет, ачусыз гына җилкәсеннән какты да кызлар артыннан атлады, башкалар да, тәмәкеләрен ташлап, шул якка ашыктылар.

Көзге кич салкын булса да, яшь-җилкенчәк туңуны белми дә, уйламый да: уртада кыз-кыркын уен оештырып мәш килә, читтәрәк, Сабантуйдан калган эскәмиягә сеңеп беткән гармунчы егет, бер көйдән икенчесенә сикереп, бармакларын яздыра. Зәйтүнә, күрше кызыннан бер адымга да калмаска тырышып, ул кай почмакка барса, шунда иярде. Сабакташ кызларын күргәч кенә, эченә җылы йөгерде, алар Зәйтүнәне уратып та алдылар, үзләре янына уенга да дәштеләр.

– «Чума үрдәк, чума каз»ны уйныйбыз, үзеңә пар эзлә тизрәк.

– Эзләп интекмә, Зәйтүнә, үземне генә сайла, – дип, каршысында җир астыннан калыккандай Нургаян пәйда булып, үзен җитәкләп алуга, кызның йөзенә ут капты. Кайда булган да каян карап торган диген, күзгә дә чалынмаган иде...

Йөзендәге кайнарлык бармак очларына кадәр таралды бугай. Бая гына салкын тоелган кич тә кинәт җанны өтәрлек булып җылынды...

Уен башланганчы ук җитәкләшеп торуларыннан уңайсызланып, Зәйтүнә Нургаянның учыннан әкрен генә кулын алды, оялып, читкәрәк тайпылды.

– Нургаян абый, бүген дә җырламыйм, дисәң, Зәйтүнә белән бастырмыйбыз сине! – Кызларның берсе шаярып бармак янады. – Сүз бирсәң генә уйнатабыз!

– Зәйтүнә нәрсә ди бит... – Нургаян, беркемнән дә читенсенмичә, кызның күзләренә туп-туры текәлде. – Ул җырла дисә, рәхәтләнеп җырлыйм!

Гомерендә беренче тапкыр кичке уенга чыгып, игътибар үзәгендә калган Зәйтүнә нишләргә дә белмәде, аптырап, кара итәген учы белән сыпыра-сыпыра:

– И-и, Нургаян абый, нишләп миннән сорыйсың? – дип кенә дәшә алды.

– Әйт, Зәйтүнә, берүк җырла, диген! Әйт инде тизрәк! – Кызлар, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, аның янында гөрләштеләр. – Алайса, шулай ялындырырга ярата ул Нургаян абый!

– Бәй... җырласын соң...

«Чума үрдәк» тә уйналды. Кара-каршы басып, «Челтәр элдем читәнгә...» дип тә уйнадылар. «Капкалы» да калмады. Нинди генә уен булмасын, Нургаян Зәйтүнәдән бер адым да читкә китмәде. Моңарчы клубка чыкса – кызыл постаулы өстәл янында егетләр белән шашка, домино сугып утырган, кызлар оештырган уенга бөтенләй катнашмаган егетне алыштырып куйганнар диярсең. «Йөзек салышлы» уйнаганнан соң, үзенә эләккән җәза өлешен дә беркарусыз башкарды Нургаян, түгәрәк уртасына чыгып басты да ялындырмый гына җыр сузды:

Безнең авыл өсләрендә
Йолдыз яна яктырак ла,
Йолдыз яна яктырак.
Айга да йолдыз бик якын,
Син генә миннән ерак.

Егет моңның үзе белән сугарылган иде. Моңлы тавышы тәнне чемердәтә, җанны айкый, керфекләргә ирексездән яшь тамчысы элә.

Ул да булмады, Нургаян кисәк кенә дәртле җырга күчте:

Урам буе, юл буе ла,
Идел буе, су юлы.
Көттем, җаным, чыгарсың дип,
Йокламадым төн буе...

Яшьлек ваемсызлыгы, беркатлылыгы, самимилеге, җүләрлеге белән матур. Акыллы булса, ул инде чал сакаллы, чал чәчле булыр иде.

– Нургаян, син лутчы җырлама. – Кепка кигән баягы егет, Зәйтүнә ягына уфтанулы караш ташлап, Нургаянга борылды. – Бөтен кызны үзеңә каратасың да, безгә бер пачут та юк аннары.

– Әй, кем әйтә моны? – Кызларның берсе үртәп тә, бераз үртәлеп тә аның биленә төртте. – Бөтен кызны озатып чыктың бит инде!

– Озатса, мин бит яхшы нияттән генә. Караңгыда адашмасыннар, өйләренә туп-туры кайтсыннар, дип кенә, матурым...

Зәйтүнә Нургаянның моңлы җырыннан тәмам әсәренгән, йөрәген аңлашылмый торган сәер бер хис урап алган, кушылып җырлыйсы да, сулыгып-сулыгып елыйсы да килгән шикелле. Уен дәвам итеп, йөзекнең үз учында йомарланып калуын да абайламаган икән: йөзек кемдә, сикереп чык, дип, кат-кат әйткәч кенә уртага чыгып басты.

– Мин этәч булып кына кычкыра беләм, – диде ул, әллә нинди җәза биргәнче, җиңелрәген сайлап.

Тик кызлар аны тыңлап тормадылар, башын янтайтып утырган гармунчыга кул изәп:

– Инсаф, уйна, Зәйтүнәне биетәбез. Мәктәптә аннан да матур биюче юк, – диештеләр, күгәрченнәр кебек гөр-гөр килеп.

– Ниндәйне җиппәрим? Маричамы, урысчамы – әйтсен генә! – Инсаф дигәннәре гармунның сул як бакасын кинәт каты итеп кычкыртты.

– Диваналанып утырма! Татарча уйна. Ниемә сиңа урыс көе?

– Татарча тек татарча! – Инсаф, күзләрен йомып, бию көе сыздырып җибәрде.

Түгәрәк уртасында бераз тартынып басып торган Зәйтүнәнең аяклары, дәртле көйгә буйсынып, үзеннән-үзе биеп китте. Аккош булып та йөзде ул, күбәләк булып та бөтерелде, таң җиле булып назланып үтте, толымнарына урала-урала, каен кызы булып тибрәлде. Гүя көз төсенә кергән чирәм өстендә искерә төшкән кәлүш түгел, биек үкчәле чигүле читекләр тыпырдый; җилгә сибелгән толымнарның очында да гап-гади чүпрәк тасмалар түгел, көмеш чулпылар чыңлый...

Нургаян, көзге караңгылыкны яктырткан матурлыкны күреп, өнсез калды. Яшьлеге, сафлыгы, яктылыгы белән матур иде Зәйтүнә. Егетнең күңеленә әллә каян гына бер хис килеп кунды: нәзек билле, зифа гәүдәле бу кызыкайны дөньяның бар усаллыгыннан, явызлыгыннан, авырлыгыннан сакларга теләү иде ул. Баягы кебек, кайнар кулларын үз учына яшерер иде дә янынннан бер генә минутка да җибәрмәс иде, икесе бербөтен булып, гел янәшә атларлар иде. Гел, һәрчак, һәрвакыт...

Нургаянның, нишләптер, кисәк кенә күңеле тулды.

Зәйтүнәне озата кайтканда, ул берара эндәшми генә атлады. Кызның:

– Матур җырлыйсың икән, Нургаян абый, – диюеннән генә исенә килгәндәй булды. Үзенең кайда, кем белән икәнен аңлаудан авылның караңгы урамы яктырып китте, ул ипләп кенә кызны җитәкләп алды.

– Минем бит бүтән эшем юк, тракторда җырларга өйрәнеп кенә йөрим, – диде шаяртып. – Менә син ул, ай матур биисең, Зәйтүнә, күз генә тимәсен!

– И, күз тиярлек ди... – Зәйтүнә, күзгә күренмәгән нурда коена-коена, үзалдына елмайды. – Кәлүшләремә тисә генә... Вәт чын биючеләрне әйт син! Быел Сабантуйга башкортлар килгәние бит кансирт белән, андагы кызларны син дә күргәнсеңдер инде! Биек үкчәле ап-ак читек кигәннәр, әнекәем, ул читекләрнең матурлыгы! Үзләре тыпырдый, билләһи... Их, шундый читекләрем булса!

– Ак читек? – Нургаян, шул биючеләрне күрергә теләгәндәй, күзен күккә күтәрде. Йолдызлар куенында тибрәлгән ай, аңа күз кысып, читкәрәк шуышты. – Синеке дә булыр, Зәйтүнә, үзем алып бирермен, яме.

– Кызык кеше икән син, Нургаян абый. – Зәйтүнә атлаган уңайга, авызын

учы белән каплап, рәхәт итеп көлеп куйды. – Андый читекне кем сатсын... Сатса да, бик кыйбаттыр ул... Хыялланырга ярый инде.

– Юк инде, алып бирәм дигәч бирермен, әйткән сүз – аткан ук! Сүзендә тормаган кешене җенем сөйми... Менә туйлар ясап, миңа кияүгә чыккач, көннәрдән бер көнне шул ак читекне алып кайтырмын да тып итеп каршыңа куярмын әле, биисең килсә биерсең, аны киеп, керт-керт басып, чишмәгә йөрсәң дә бер сүзем юк...

Зәйтүнә, аның сүзләрен ишетеп, инде тыела алмый көләргә тотынды.

– Кияүгә? Китчәле, Нургаян абый, мин бит әле мәктәпне дә бетермәгән. Син бит мине рәтләп белмисең дә. Әйтәм бит, кызык кеше икән син.

Нургаян аңа кушылып көлмәде, киресенчә:

– Мәктәпне дә бетерерсең, мин бит сине иртәгә үк кияүгә алам, димим. Көтәрмен, – диде, тагын да җитдирәк итеп.

Алар тыкрык буеннан борылуга, сүзләре бүленде, кемнеңдер ишегалдында эт өргәне ишетелде. Аңа тагын берничәсе кушылды. Кайдадыр, саташып, әтәч тә кычкырды. Капка төпләрендә парлашып утырган яшьләр күзгә чалынды. Зәйтүнә кулын Нургаянның учыннан алырга теләде, тик егет аны ычкындырмады.

– Нургаян абый, мин оялам, – дип пышылдады Зәйтүнә, – берәрсе күреп әнкәйгә җиткерсә...

– Һи, алай курыксаң, бүтәннәр җиткергәнче, Халисә апага үзем барып әйтермен: Халисә апа, диярмен, кызыңны җитәкләп кайттым, кулларымда күтәреп кайтсам да ярыймы, диярмен...

– Китчәле, Нургаян абый... – Зәйтүнә, нидер уйлап, башын иеп атлады. – Белде инде ул...

– Нәрсәне?

– Кич чыгам, дигәч, кем белән, кая барасың, дип ныгытып төпчегенде дә әйттем инде. Нургаян абый чакырды, дидем...

– Шуннан? – Ни кыю Нургаянның да эченә ут йөгерде. – Нәрсә диде?

– Саимә малаемыни, диде. «Армиядән кайткан, олы җегет бит ул», – дип каршы килгәние дә башта. Торды-торды да, берүк әйбәт кенә йөрегез, дип чыгарып җибәрде. Бүтән кеше, дисәм, мәңге чыгармас иде, син дигәч, нишләптер бик тыныч күренде әле әнкәй. – Зәйтүнә беркатлы гына шулай диде дә кыңгырау кебек чыңлап көлеп җибәрде.

Нургаян җиңел сулап куйды. Тик бу юлы да җитдилеген җуймады:

– Зәйтүнә, «бүтән кеше» булмасын иде шул, минем сине берәүгә дә бирәсем килми. Бер күрдем – яраттым. Гомерлеккә дип.

Зәйтүнәнең аяк астында җир тибрәлгәндәй булды. Тез асларына тиклем калтырау йөгерде. Чәч төпләре тирләп чыкты. Тавышы качты. Мизгел эчендә бер янды, бер туңды.

– Абау... Син бигрәк... батырланасың, Нургаян абый.

– Бәй, кыюсыз төлке ачка үләр, ди. – Нургаян, үз калыбына кереп, шаяруга күчте. – Яратам дип әйтергә сузып йөриммени? Аңа айлар, еллар кирәкмидер инде. Үз сүземне әйттем. Син дә беркөн шулай диярсең әле, менә күр дә тор. Мин көтәрмен, күпме кирәк – шулкадәр көтәрмен. Түлке егерме бишеңне тутырсаң, өйләнмим, карт кызга өйләнергә, син мине...

Зәйтүнәне баягы кебек көлү өянәге биләп алды. Күпме генә тырышмасын, тыела алмады, керфек төпләренә яшь тибеп чыкканчы көлде дә көлде.

– Миңа унҗиде дә тулмаган бит әле, Нургаян абый, нинди егерме биш...

Карт кыз ди, абау!.. Унны бетерсәм, Алабугага – училищега, китапханәчелеккә укырга барыр идем, укытучылар да шулай ди... Анда да егерме биш булмый әле, Нургаян абый!

– Мин көтәрмен, Зәйтүнә, көтәрмен... Син, ни, абый димә инде, Нургаян гына диген, яме...

– Ярар, ярар, Нургаян абый!

Очрашып йөрүләренә дүрт ел булгач, Зәйтүнә Нургаяннар йортына килен булып төште – көзге муллыкта кулдан килгәнчә шаулатып туй ясадылар.

Яшь киленгә су юлы күрсәтергә барганда, иңбашына көянтә аскан ак күлмәкле Зәйтүнәгә дә, аны җитәкләгән Нургаянга да сокланмаган кеше калмагандыр: икесе дә күз явын алырлык чибәр, бер-берсенең күзенә генә карап торалар, бар булмышларыннан мәхәббәт нуры сирпелә.

– Зәйтүнәкәем, нәрсәгә дип дүрт елга сузганбыз инде, ә? Өйләнүнең бернәрсәсе дә юк икән бит, – дип пышылдады Нургаян, кәләшенең колагына иелә төшеп, гадәтенчә, шаярудан арына алмыйча.

– Китчәле, Нургаян, кеше ишетмәсен, болай да бөтенесе безгә генә карый, – диде Зәйтүнә, иренең беләгенә сыенып.

– Яратасың инде син «китчәле» дигән сүзне. Ну хәзер чыбыркы белән кусаң да китү юк, Зәйтүнәкәем. Син – минеке, мин – синеке! Законный төстә!

– Сиңа шаяртырга гына булсын.

– Сөйләвен чын сөйлим. Тик менә вәгъдәмне үти алмадым, Зәйтүнәкәем, шунысы күңелне кыра.

Зәйтүнә, сүзнең нәрсә турында икәнен аңламыйча, сәерсенеп китте, аптырап иренә карады.

– Нинди вәгъдә, дисең?

– Туй булды, ак читек булмады бит әле. Әллә кайлардан белешеп карадым, дөньясында бер пар читек сатучы табылмасын инде. Су юлына шулар белән кетердәтеп кенә атлап барырсың дип хыялланган идем дә...

Әллә кайчангы сөйләшүне көчкә исенә төшереп, Зәйтүнә, елмая-елмая, читкәрәк тайпылды, тагын «китчәле» дигән сыман, кул селтәде.

– Янымда син булгач, читек тә, итек тә кирәкми, Нургаян, уйнап әйткән сүз белән башыңны катырма.

– Ирмен дигән ир-егет сүзендә торырга тиеш, Зәйтүнә... Алайса, ничу ир исеме күтәреп йөрергә...

Бәхет өчен күп кирәкми икән.

Янында өзелеп яраткан кешең булып, һәр иртәне аның янәшәсендә уяну, калын толымнарның хуш исенә исереп, берара күзне ачмый гына үзалдыңа елмаю да бәхет икән. Өйгә кайтып кергәндә, мич алдында табагач уйнаганын күреп, коймак исенә хозурлану да бәхет. Яулыкларын бердәй арттан чөеп бәйләгән әнкәң белән хатыныңның кара-каршы чөкердәшеп чәй эчкәннәренә соклану да бәхет. Җырлый-җырлый эшкә дип чыгып китү дә, көн үткәнче, пар канатыңны өзелеп сагыну да, йөгерә-йөгерә өйгә кайту да бәхет. Тупырдап торган нарасыеңны учларыңда сикерә-сикертә, аның гөнаһсыз күзләрендә үз чагылышыңны, дәвамыңны күрү дә бәхет икән. Сау-сәламәт булып, гап-гади җан тынычлыгына кинәнү – бәхетнең үзе. Бу гадилек янында акча таулары да, алтын-көмеш тулы сандыклар да тузан бөртегенә тиң. Әгәр җир йөзендә һәр кеше шушыны аңлап, бәхетенең кадерен белеп яшәсә, дөнья елмаю белән тулыр иде. Сугышлар да, җир һәм мал бүлешүләр дә, җан кыюлар да булмас иде.

Нургаян бәхетле иде. Басу юлында Зәйтүнәне күреп калуы, йөрәгенең аны

сайлавы, яратып туймавы белән бәхетле иде. Инде уллары Наилнең туп кебек тәгәрәп үсеп килгән чагы, әтисе белән әнисе сөеп туялмыйлар үзен, ике яшен тутырса да, әле күкрәк сөтеннән дә аерылганы юк. Болар барысы да бәхет иде.

Утыз җиде ел элек бәхетләре түп-түгәрәк иде аларның. Көзгә кергәнче. Урып-җыю башланганчы. Йорт бусагасын бәхетсезлек атлап кергәнче...

Язгы чәчү төгәлләнгән көннәрнең берсендә Нургаян, Вәсимгә ияреп, Уфага барырга җыенды. Дустының сеңлесе Сабантуй алдыннан кияүгә китәргә әзерләнә, туйга кирәк-яраклар алырга дип, башкорт ягына чыгарга уйлаганнар икән. Ни дисәң дә, анда һинд чәенә дә, каплы-каплы ак майга да кытлык юк, машина юнәтә алсаң, бер барганда, чемоданы белән төяп кайтасың. Вәсим рәисне йөрткән «УАЗигы» белән шунда барырга ниятләгәч, Нургаянны да кыстады, җай булганда урап кайтыйк, диде.

– Тышына фил төшкән сары чәй булса, берүк алырсың инде, Нургаян, искәйләре үк такта чәйне бәреп ега бит, – диде Зәйтүнә,ниләр кирәген кат-кат исенә төшереп. – Үзеңә Сабантуйга кияргә кыска җиңле күлмәк булмасмы... Наилгә колготки белән носки кирәк ие. Ак майны онытмассың да онытмассың инде. Әнкәй яраткан хәлвә күренмәсме; аңа ярардай прастуй оек күзеңә чалынмасмы...

– Ярар, анысы булмаса да, әле искесе дә тузмаган. – Саимә, килененең сүзләренә күңеле булып, чәчәкле күлмәк кисәсендәге өч тәңкәне Нургаянның кулына сонды. – Митликаплы[1] прәннек күрмәссеңме, Зәйтүнә шуны ярата...

Нургаян, авызын ерып, туза төшкән сары тышлы чемоданны һавага чөйде.

– Сез мине ярминкәгә озаткандай кыланасыз, – диде ул, әнисенә дә, хатынына да елмаеп. – Уфа кибетендәге бөтен нәрсә монда сыеп бетәр микән соң?

– Чумаданыңа сыймаса, менә монавысын да ал әле, төшеп калмас, җәяү бармыйсың. – Саимә ишек буендагы кадакка эленгән чүпрәк сумканы алып, Нургаянга сузды. – Анда әйберне бүле[2] диләр бит. Безнең кибет киштәсендә генә ул... Кансирвыдан күп нәрсә юк. Эче агып, бер-берсенә ябышкан мендәр кәнфитне мәҗбүри бирәләр. Теш үтә торган булса ярар да иде...

– Шул мендәр кәнфитне әллә нишләп яратам инде мин, – диде Зәйтүнә, шүрлектә кәгазь капчыкта беткәннән-беткәнгә торган кәнфитне күздә тотып, каенанасы алдында оялыбрак.

Нургаян ипләп кенә аның аркасына, толымнарына кагылып үтте: янәсе, кыенсынма да, оялма да...

Киткән кыздан, мине дә алып китмәсә ярар иде дип, пумала да куркып тора, ди: Вәсимнең әнисе белән сеңлесе юл буе ниләр кирәген санап бардылар. Тәрәзә челтәре, пәрдә, өстәл-карават җәймәсе, чыбылдык... Кияү йортына алып китәргә дигән исемлекнең очы-кырые юк иде.

– Акча калса, бер-ике яшник кымыз да апкайтырбыз әле, – диде Вәсимнең әнисе, Уфа урамнарының уң ягына да, сул ягына да башын боргалап. – И-и, өйләрнең күплеге! Бу тиклем халыкны ничекләр туйдырып бетерәләрдер...

Нургаян да, ничарадан-бичара төстә, Вәсимнәргә ияреп, иң тәүдә туй бүләкләре эзләшергә мәҗбүр булды: кода-кодагыйга, туган-тумачага җиңле күлмәк, капрон яулык, ситсы-мазар ише әйбер дә кирәк икән... Бер кибеттән чыктылар, икенчесенә керделәр. Хатын-кызлар тукыма төргәкләрен сүтеп-җәеп мәшәләнгән арада Нургаян күрше бүлеккә сугыласы итте. Тәрәзәдән

[1] Митликаплы – диал., «мятные капли» дигәннән.
[2] Бүле – диал., «воля» дигәннән, ирек, ирекле, күп дигән мәгънәдә.

шунда эленеп торган мандолинаны шәйләп калган иде, кызык итеп кенә шул тарафка юнәлде. Рәт-рәт итеп тезелгән гармуннарны, баяннарны күреп, исе китте. Алдына да, артына да әйләнеп карады. Һәм... түрдә, укалы камзуллар, каймалы җиләннәр, камчат бүрекләр, көмеш тәңкәле хәситәләр, шөлдерле барабаннар янәшәсендә кукраеп утырган ап-ак читекләрне абайлап, өнсез калды. Шулар иде, Нургаянның хыялында байтактан йөргән читекләр иде алар! Зәйтүнәсе ымсынган, аңа бүләк итәргә иде дигән читекләр! Биючеләр өчен генә дип махсус тегелгәндер, үкчәләренә кадәр көмеш йөгерткәндәй күренә. Сабыр иткән – морадына җиткән, ди, хак шул, хак!

Шатлыктан күкрәккә сыймый талпынган йөрәк тибеше үзенә үк ишетелгән шикелле тоелды. Нургаян ике атлап бер сикерде дә өстәл артында торган кара кашлы, кара күзле кызыкай каршына барып басты.

– Апаем, миңа шушы читекләрне төреп бир, зинһар, – диде ул, ашыга-кабалана костюм кесәсенә тыгылып. Әйтерсең, акчасын шушы минутта эзләп алмаса, әле кул белән тотып карарга да өлгермәгән читекләр күз алдыннан эреп юкка чыгарга җыена.

– Абый, алар сатылмый бит! – Кызыкай, тип-тигез тешләрен балкытып, авызын ерды. – Болар бит күргәзмәгә куелган, сатуга түгел!

Аяк астындагы идән шуышып киткәндәй булды. Нургаян, нәүмизләнеп калган, ярдәм өмет иткән сабый шикелле, як-ягына каранды.

– Үскәнем, ни бәя дисәң дә алам, бик кирәк иде. Хатыныма вәгъдәм бар. Эзләп-эзләп таба алганым юк иде, менә бит, сездә бар икән!

– Абый, бу бит биючегә дип тегелгән. Урамда киеп йөри торган түгел! – Кыз, аны үртәгәндәй, елмаюын белде.

– Минем Зәйтүнәнең биегәнен күрсәң! Клубта бөтен бәйрәмне ул гына бизи, үскәнем! Бәясен әйт тә, алып китим...

Нургаян, моңарчы холкына хас булмаганча, ялынырга ук тотынды. Каршыңа үзләре йөгереп дигәндәй чыксын да, шушы читекләрне алмый кит, имеш! Зәйтүнәнең аякларына үлчәп тегелгәндәй генә күренәләр!

– Үскәнем, синең берәрсен яратканың бармы әле? – Нургаян, күзен читектән аермый гына, кара күзгә эндәште.

Кыз аптырап калды, елмайган иреннәре җыелды, кашлары дугаланып чөелде:

– Нигә, абый?

– Бик каты яратканың булса, мине аңлар идең... Зәйтүнә апаңны сөендерәсем килә. Кайчаннан хыялландык, ак читек алырбыз дип, юк кына бит... Ерактан килдем, монда атна саен йөри торган түгел. Сат инде, апаем!

– Сәер кеше булдыгыз... – Кыз икеләнеп калды, башын кыңгыр салып, бераз уйланып торды. – Хәзер, сорап карыйм әле...

Шулай диде дә, ширма кебек кенә күренгән ишектән башын тыгып, «Өлфәт агай!» дип, кемнедер чакырды. Өлфәт дигәне – кара чалбар, ак күлмәк кигән, сары мыеклы, илле яшьләрдәге таза гәүдәле ир икән. Әбәдләп утырган мәле идеме, салфетка белән авыз тирәләрен сөртә-сөртә пәйда булды да:

– Ну? – дип, кызга бер генә кәлимә ыргытты.

– Менә бу агай читекләрне сатыгыз, нык кирәк иде, ди... – Кыз, инде үзе дә Нургаянга кушылып ялваргандай, баягы самими елмаюы белән аның йөзенә текәлде.

– Бу бит аяк савыты сата торган кибет түгел, энем, анысы чаттагы кибеттә. – Өлфәт кире борылды.

– Анысын әйттеләр әйтүен. Өлфәт агай... – Нургаян, чарасызлыктан ни дияргә белми, сүзен өзде. Тагын түш кесәсенә тыгылды. – Ничә сум дисәгез дә алыр идем. Хатыныма, бүләккә кирәк, бик кирәк.

– Ал соң. Ике йөз сум. – Агай, керфеген дә какмый, шулай диде, үзе мыскыллы елмайды.

Ике йөз сум?! Чәйгә, майга, күлмәккә, оекка дигән акчаларның барысын бергә чыгарып салсаң да, алай ук җыелмас шул... Аена алтмыш тәңкә алып эшлә дә, ике йөз сум... Аны кем уйлаган... Алай да Нургаян кесәсеннән калын тышлы янчыкны тартып чыгарды, Өлфәт дигән ирнең әле дә булса йөзеннән югалмаган карашы астында, янчыктагы берлекләрне, бишлек-унлыкларны кат-кат санады. Йөз җитмеш биш тәңкә...

– Егерме биш сум җитми... – Нургаян шулай дип көрсенде дә, авыр сулап, янчыкны кесәсенә тыкты. Кулга керәм дип торган бәхет кошы учыннан очып киттемени – шулкадәр кызганулы караш белән түрдәге читеккә карады.

Өлфәткә нәрсәдер кызык тоелды, күрәсең, ул борылып кереп китәргә атлаган җиреннән Нургаянның янына ук килеп басты.

– Кара, энекәш, шушы читекне ике йөзгә алыр идеңме? – диде ул, аю биеткәнне тамаша кылгандай, күзен шарландырып.

– Алыр идем. Хатыныма вәгъдә иттем. – Ватык патефон шикелле, Нургаян һаман баягы сүзләрен кабатлады.

– Нәрсә, биимени, әллә сине биетәме?

– Өлфәт агай, хатыны матур бии ди... – Кара күзле кыз инде тәмам Нургаян ягына авышкан иде.

– Биюче... – Өлфәтнең ирен читенә янә мыскыллы елмаю кунаклады. – Ә абзаң үзе җырчыдыр инде...

Нургаянның сабыр савыты тулышты, бу агайның төртмәлегенә тәмам ачуы килде, шулай да кабынып китмәде:

– Безнең җыр капчыгының төбе тишелмәгән, агай. Юкка көләсең, – диде, тыныч булырга тырышып.

– Әллә «Карурман»ны, «Йәнбикә»не суза аласың?

Кара, мыскыллапмы-мыскылларга маташа түгелме соң бу сары мыек? Шуңа сер биреп торырга соң...

Базарларга барсаң, акбүз атның
Хаккынаен үзем түләрмен.
Әҗәлләрең житсә, әйт үземә, Йәнбикә,
Синең өчен үзем үләрмен...

Нургаян бернинди тартынусыз җыр сузды. Болын уртасында ирәеп басып тора диярсең – киң сулыш белән, күзләрен йома-йома, рәхәтләнеп моңланып алды да эченнән генә көлеп тә куйды: акбүз ат дип җырлый да җырлавын, ат түгел, бер пар читек алырга да рәте җитеп бетми шул әле...

Күзен ачканда, ни күрсен: сары мыек та, кара күз дә сихерләнгәндәй аңа карап катканнар, үз гомерләрендә «Йәнбикә»не ишеткәннәре юк диярсең.

– Ну моң икән үзеңдә, энекәш! Безнең кеше икәнсең бит! – Өлфәт агай ни өчендер бармак бите белән күз читен сөрткәләде. – Кая килеп, кая китмәгән – китер берәр... утыз тәңкә... Берәр ничек җайларбыз әле... Зинфира, бир читекне агаеңа!

– Әнекәем! Тәки үз сүзеңне онытмадың, әй! – Зәйтүнә аягына тап-таман

булып керәп утырган читекне, бик кыйммәтле нәрсә күреп, сак кына сыпырды, сыйпады. – Бигрәкләр матур, бигрәкләр ак!

– Синең кебек.

– Нәрсә минем кебек? – Иренең ни дип шаяртуын аңламагач, Зәйтүнәнең күкчәчәктәй күзләрендә сорау чагылды.

– Читекне әйтәм. Синең кебек матур. Синең кебек ак...

Хатыны тыелып кына көлеп куйды. Үзе дә шаярып, иренең борын очына бармагы белән кагылды да:

– Алайса, сыңары – мин, сыңары – син инде. Берсе – матур, икенчесе – батыр, үзсүзле, – диде көлә-көлә. – Боларны киеп биергә чыксам, көлеп егылмам микән, Нургаян? Уңын – син, сулын – үзем, дип күз алдына китереп?

– Көлә-көлә биерсең, Зәйтүнәкәем, болары тузса, яңасын алырбыз, рәхәтләнеп, аякларың талганчы биерсең...

– Сүз бирсәң, таш яуса да үтәрсең икән, Нургаян...

– Гомер буе яратырмын, дидем – анысын да үтәрмен, әнисе. Шушы ак читек кебек пар булып, гел янәшә яшәрбез, яме.

Аш бүлмәсендә чәй әзерләп йөргән Саимә, улы белән килененең сүзләренә елмаеп колак салган җиреннән, үз-үзенә: «Алла боерса... Алла боерса, диегез, балалар», – дип кат-кат пышылдады. Сүзен түр яктагылар ишетмәде. Саимә, юкарып һәм кыскарып калган толым очын бер үрә, бер сүтә, алар янына чыкты.

***

– Без рәтли торганга охшамаган. – Әйтерсең, сүз имгәнеп килгән яшь хатын турында түгел, тәгәрмәче тишелгән йә булмаса ишеге каерылган «Запорожец» машинасы турында бара – баш врач үз артыннан ияргән Нургаянга җилкә аша гына шундый кәлимәләр ыргытты. – Умырткалыкта җитди повреждениелар. Казанга күчерәбез, иртәгә вертолёт була.

Ике көн буе палатада ятып, Зәйтүнәсенә юньле-рәтле диагноз куелмагач, Нургаян тәмам пошаманга төшкән иде. Витамин дип, сәдәф биргән булдылар, авыртуны баса торган укол кададылар, система куеп маташтылар – селкенә алмый яткан хатынның хәле аз гына да яхшырмады.

Стена буяулары кубып, идән сайгаклары шыгырдап торган больница коридоры көндез дә әллә нинди шом белән өретелә, төнен исә, янәшәдә кизү өстәлендә пыскып янган лампа яктысында, бөтенләй котсыз булып күренә. Нургаян бүген дә төнен Зәйтүнә яткан палата төбендәге урындыкта үткәрә иде. Кичә дә йокы күрмәү үзенекен итте: керфекләрне кургаш авырлыгы басып, изрәп киткәч, ирнең башы бер якка янтаеп төште. Йокы ястык теләмәс, диләр шул, шушы уңайсыз халәттә бераз черем иткәч, кулларына кемдер кагылудан Нургаян иплән кенә башын күтәрде. Рәтләп айнымаган килеш, «Зәйтүнә!» дигән татлы уйдан ирен читенә елмаю йөгерде. Шул минутта ук, коты очып, күзен ачты.

– Җәлләп уяттым, бигрәк җайсыз утырасың. – Кизүдә утыручы шәфкать туташы икән. Шактый өлкән яшьтә күренә, пенсиядә килеш эшләп йөрүеме. Тәбәнәк кенә буйлы, ябык гәүдәле, күзлеген ак косынкасы өстенә күтәреп куйган хатын коридорның теге башына кулы белән изәп күрсәтте. – Бар, санитаркалар бүлмәсендә йоклап ал, улым. Кеше-кара йөри башлаганчы үзем эндәшермен.

– Ә-ә... – Нургаян кулы белән йөзен сыпырды, күзләрен угалады. – Рәхмәт. Мин шушында гына...

– Синең дә аяктан егыласың киләмени? Көчеңне сакла, әле бик кирәк булыр. – Күпне күргән хатын нидер белә идеме, сизенә идеме – авыр сулап куйды. Аның шул ымын тотып алган Нургаянның йокысы мизгел эчендә югалды.

– Зәйтүнә турында... Анык кына әйтүче юк... – Ирнең өмет тулы карашы үз өстәленә таба атлаган ак халатлы хатынның аркасына укталды. Шәфкать туташы тиз генә эндәшмәде. Урындыгын алып утырды, алдында яткан зур дәфтәрне ачып, кайсыдыр битенә каләм белән нидер төртеп куйды, өстәл тартмасын тартып, бүлем-бүлем тутырылган дару сәдәфләрен барлагандай итте. Шуннан соң гына, күзлеген киеп, Нургаянга борылды.

– Казанга озатуларына сөен, энем. Район бүлнисендә, ни дисәң дә, сукыр эчәктән ары китәлгәнебез юк. Монда җаваплылыкны үз өсләренә алырга тормаслар... Башкалада карарлар, белерләр, врачлар да, аппаратлар да җитәрлек.

– Озак яткырырлар микән?

Нургаян хатынын уйлап та, өйдә калган әнисе белән улы өчен борчылып та, сөрелеп бетмәгән басуны исенә төшереп тә беркатлы гына шулай дип сорады. Казан, ни дисәң дә, бакча артында гына түгел, Зәйтүнәсенә атналап-атналап ятарга туры килсә, көнендә генә урап килермен димә...

Хатын кызганулы карашын Нургаянга күрсәтмәде, шуны яшерер өчен, янә өстәленә иелеп, нидер эзләгәндәй кыланды.

– Кем белә инде, энем, кем белә... Тиз булмас инде ул. Байтак озак булыр. Тегенди-мондый җир генә түгел бит, умырткалыгына, биленә килеп төшкән. Алла сабырлык бирсен, хатыныңа да, сиңа да җиңел булмас, энем...

Зур уку йортларында укып врач булмаса да, саллы тормыш тәҗрибәсенә ия шәфкать туташы гомер юлында бу икәүне ни көткәнен ачык чамалый иде. Нургаян исә ул әйткән «озак»ның чыннан да озакка, бик озакка сузыласын кайлардан белсен...

***

– Ашыйсым килми. – Зәйтүнә күзләрен йомды.

Аш кашыгы белән аңа ботка ашатырга җыенган Нургаян берни дәшми сабыр гына көтеп торды. Хатыны күзен ачкач, үҗәтләнеп, кашыкны аның авызына китерде.

– Фигура саклау турында уйлар чак түгел. – Юри шаяртты ир, үзенең күз яшьләрен эчкә йотып шаяртты. Аз гына да кыймылдый алмый как ятакта яткан хатынын кызганып, аның сызлануларын үз йөрәге аша үткәреп, Нургаянның йөрәге елый иде. Шул хәләтен ничек тә яшерергә, сиздермәскә кирәк иде – ир, җай чыккан саен, сүзне шаяруга борырга теләде. – Син нәрсә, әнисе, авылга кайтканда, күбәләк авырлыгына калып, мине оятка калдырыр идеңме? Ашатмаган, кысмыр, диярләр, кеше көләр миннән... Яле, ач авызыңны. Син пешергән кебек булмаса да, Казан боткасы да хәтәр тәмле, мин әле аңа үзем май да өстәдем. Менә шулай. Яле, тагын бер кашык. Тагын, тагын...

– За маму, за папу... – Почмак караватта яткан Люба, бу палатага Зәйтүнәне урнаштырганчы, татарча бер кәлимә сүз белми-аңламый иде, тормыш өйрәтә икән, ярыйсы гына төшенә башлады үзе. Менә хәзер дә, Нургаянның, сабый баланы ашаткандай, хатынын кашыклап ашатуын карап ятты-ятты да, түзмичә, сүзгә кушылды. – Мине дә сеңлем шулай ашатты баштагы мәлләрдә. Ир курыкты, термос белән алып килгән ашын калдырды да чыгып тайды. У тебя, Зайтуна, муж не такой, как у меня. Он у тебя золотой. Ешь, если не за себя, то за мужа...

Любаның хәле яхшырак, үзе тотып ашый ала. Балконда кер элгәндә, дүртенче каттан егылып төшкән дә умырткалыгын сындырган. Тулы иренле, керфекләре курчакныкы шикелле өскә кайтарылып торган зур зәңгәр күзле, кырык яшьләрдәге бу хатынның матурлыгы да, вакыт-вакыт усаллыгы, төртмәлеге дә җитәрлек. Нургаянның, дүртенче пациент шикелле, көне-төне палатада булуын Люба башта мыгырданыбрак кабул итте. Янәсе, ничек инде, хатын-кызлар яткан палатада... Тик биредә һәркемнең үз хәле хәл иде, Нургаянның җенесе тиз онытылды. Өченчеләре, Рәзифә дигәне – авыл хатыны, сыерына печән төшергәндә, лапас түбәсеннән егылган, муенын имгәткән. Муенчак кигән килеш ул да караватка кадакланып ята, торырга рөхсәт итмиләр әле. Аны, ичмаса, төзәлер, оныкларыңның туенда тыпырдап биисең әле, дип юаталар. Палатадагы өч хатын тышкы дөнья яктысын алама пәрдәле тәрәзә аша читтән генә, почмаклардан гына күзәтеп яталар. Һәрберсе бүген булмаса иртәгә аякка басачагына өмет итә, шул өмет булмаса, алар өчен тормыш күптән туктар иде. Җан түренә караңгы уйлар үрмәләргә итсә, өмет уты ул уйларның юлына аркылы төшә. Өмет яшәтә, өмет иртәгә кояш чыгачак, иртәгә таң атачак, иртәгә якты булачак, дип искәртә. Бер-берсенә ялганган «иртәгә»ләр айга сузылырмы, елгамы? Тәкъдир китабына кемнәргә ни язылган, нинди сынаулар әзерләнгән – мәңгелек каршында тузан бөртегенә генә тиң адәм баласына боларны белү мөмкин түгел шул...

Авырулар янына туган-тумача килә тора. Күчтәнәчләрен калдыралар, хәл-әхвәл белешеп бераз утыралар да, үз дөньяларын искә төшереп, кайтырга ашыгалар. Ә Нургаян кала. Инде менә ничәнче көннәр, атналар, ул хатыны янында. Люба белән Рәзифә дә аңа инде тәмам ияләшеп бетте, сөйләшергә дә, шаяртырга да көч табалар. Нургаянның, тегеннән-моннан урындыклар ташып, көн саен Зәйтүнәсе янында кунуыннан да мәзәк ясарга күп сорамыйлар, үртиләр, елмаялар. Төннәрен исә, бер-берсенә сиздермәскә тырышып, больницаның сизрәп беткән юрганы белән йөзләрен каплыйлар да, әкрен генә елыйлар.

Зәйтүнә дүрт-биш кашык ботканы мәҗбүриләп йоткач, бүтән кирәкми дип, керфекләрен түбән төшерде. Больницаның тозсыз солы боткасы күңелен болгаткандай булды, шулай да, иренең күңелен төшермәс өчен:

– Тәмле шул. Җитте, тамагым туйды, Нургаян, – диде ул, күз карашы белән генә рәхмәт әйтеп.

– Туярга, әле чәй эчмәдең бит. Кара, кибеттән нәрсә табып кайттым? – Нургаян тумбочка читеннән нәзек борынлы кечкенә чәйнек күтәреп күрсәтте. – Суны шулай да банкада кипәтелник белән кайнаттым әле, моңа ышаныч юк, ярылып китсә... Хәз-зер, бушатабыз да...

Бераздан палата эченә болын исе, урман исе таралды. Тәрәзә буендагы караватта яткан Рәзифә дә түзмәде:

– Җен белән бер икәнсең, үскәнем. Мәтрүшкә кайнаткансың түгелме? – диде, Нургаянга таба борылып. – Кайлардан таптың аны?

– Казанда юк әйбер юк икән бит, Рәзифә апа, мәтрүшкә генә түгел, лимонга тиклем таптым әле мин монда. – Нургаян кояш кебек сап-сары лимонны кулында әйләндергәләде. – Шәһәрнең хлорлы суын тәмләтеп җибәрмәсме. Хәзер, барыгызны да сыйлыйм...

Аларны тыңлап яткан Люба:

– Не поняла, матрёшка – это душица чтоли, душицей же пахнет, – диде, аптыраулы тавыш белән.

Нургаян бераз башын кашып торды, аннан:

– Душитсамы, түгелме, анысын белмим, тётя Люба, матрушка – Казанда да матрушкадыр инде ул, – диде, аптыраган үрдәк арты белән күлгә чума дигәндәй, белгәненчә ярып салып.

Зәйтүнәнең әрнүдән генә торган күзләренә, каны качкан иреннәренә, очлаеп калган иягенә сизелер-сизелмәс кенә елмаю йөгерде. Ул, иренә теләктәшлек күрсәтеп, «әйе» дигәндәй, керфек какты.

Зәйтүнәгә яткан килеш чынаяктан су эчү дә җайсыз булгач, Нургаян менә шушындый нечкә борынлы чәйнек эзләп йөргән иде. Аннан эчү уңайлырак булыр шикелле иде, тик беренче коймак төерле була – кош баласын туендыргандай, чәй эчерәм дигәндә, мәтрүшкәле чәй Зәйтүнәнең битенә, муенына агып төште.

– Әбекәй гел теләп утыра иде, кеше кулларына калдырма, ди торган иде, мәрхүмә... – Зәйтүнә бу юлы кызганыч елмайды. – Интекмә, Нургаян. Эчәсем дә килми.

– Тәмле чагында эчми ди. Син ярата, дип, мәтрүшкә, лимон эзләп, Казан базарын аркылы-торкылы әйләндем. – Ире, кечкенә сөлге белән хатынының битен сөртеп, чәйнек борынын янә аның авызына китерде. – Яле, ипләбрәк салсам, түгелми дә, как наять[3] кенә була, әнисе...

***

Больницаның тынга каплана торган һавасы тәмам туйдырды инде, тар, каты караватта аунап яту турында әйтәсе дә юк. Тик врачлардан гына һаман бер дә өметле сүз ишетелми шул, тегеләй тикшерәләр, болай тикшерәләр, бирмәгән дарулары, кадамаган уколлары калмагандыр – билдән аста бернинди җан әсәре сизелми, аяклары да төптән киселгән диярсең, тәүбә, тәүбә... Район больницасында ике көн яткан арада да малаен уйлап үзәге өзелгән Зәйтүнәгә Казанга күчерүләре җәза өстенә җәза кебек булды. Операция өстәлендә үткән җиде сәгатьне чамаламаса да, наркоздан айнып, күзен ачкан мәлендә, хатынның күкрәге тулы татлы өмет иде: барысы да артта калгандыр, аякларына җан иңгәндер, табибларның алтын кулы төзәтәсен төзәткәндер... Бүген булмаса, иртәгә аякка басармын дип өметләнә торгач, ай артына айлар ялганды. Ярый әле Нургаяны янәшәдә, һич ялгыз калдырганы юк. Баштарак аннан уңайсызланып иза чикте Зәйтүнә, кыенсынудан янды, пеште, шабыр тиргә батты. Үз ирең булса да, бар булмышыңны аның кулына калдыру, ирнең юеш чүпрәкләр күтәреп палатадан чыгып китүләрен күреп тору һич кенә дә җиңел түгел иде.

– Берәрсен яллыйк, Нургаян, син авылга кайт, әнкәйгә берүзенә авырдыр, – дип тә карады Зәйтүнә.

Юк, ирнең үз киресе кире иде:

– Әйтмә дә, сөйләмә дә. Чит кешегә каратырга ни, син мине кем дип беләсең! – диде ул, башка бу хакта сөйләшмәслек итеп. – Врач та шулай дигән була, сиделка яллагыз, ди. Тапкан сүз...

Зәйтүнәне дәвалаучы Клара Денисовнаны Нургаян башта, авыл гадәте буенча, өнәмичәрәк кабул итте. Бераз тәкәббер дә, усал да, кирәгеннән артык кырыс та тоелды ул аңа. Табиб янына утырып, өеп-өеп сораулар бирәсе, барысын җентекләп сорашасы, Зәйтүнәсен тизрәк аякка бастыру өчен кайдан нәрсә табып булуы турында төпченәсе килә – юк инде, ул фикерләрне татарча

[3] как наять – диал., таман гына, нәкъ кирәгенчә генә дигән мәгънәдә.

уйлап, аны күңелдә русчага әйләндереп, вата-җимерә чыгарып салганыңны иркенләп тыңлап тора дисеңме?! Күзлек пыяласы аша кадалып бер карап ала да:

– Умыртка баганасына җитди зыян килгән, дидем, компрессионный перелом – миннән ни таләп итәсез? Аңлыйсыздыр, уен нәрсә түгел! – ди, сораган саен бер үк җавапны тәкрарлап.

Нургаянның да үҗәтлеге җитәрлек, китеп барырга ашыккан табибның юлына аркылы төшеп, үзенекен кабатлый:

– Аякка басармы? Йөрерме?

Әлегә тиклем анык кына җавап бирмичә, һәрчак «көтәбез, өметләнәбез», диюче табиб, ниһаять, дүртенче айга чыккач, җанга җылы бирерлек сүзе белән шатландырды.

– Әллә ничә тапкыр әйттем: хатыныгызның имгәнүе бик җитди, шулай да иртәме-соңмы таяк белән булса да йөрер дип уйлыйм, – диде ул, үз кабинетына килеп кергән Нургаянның чираттагы сорашуына җавап итеп. – Кстати, без аның арка миеннән пункция алырга җыенабыз, «риза» дип, документларга кул куюыгыз кирәк булачак.

Бу минутта, Зәйтүнәсе тиздән аякка басачак, дип торганда, Нургаян үз башын кисәргә дигән кәгазьгә дә кул куярга риза иде. Нәрсә ул пункция, нигә, ни рәвешле алалар – күңелендә бөреләнгән бу сорауларны әлегә җавапсыз калдырып, ир сөенә-сөенә башын селкеде.

Алар монда килеп эләккәндә, табигатьтә җәй ахыры хакимлек итә иде. Гомернең үтүен җырда гына аккан суга тиңләмиләр икән лә: больницада һәр көн, һәр сәгать тышаулап куелган ат шикелле тоелса да, монда да үтә гомер, алай да үтә, болай да... Кара инде, кыш җиткәнен күргәч, күңел ышанмый. Тышта шулкадәр аклык, матурлык, ә монда, шом белән өртелгән стеналар арасында, түшәменә кояш элеп куйсаң да яктырмас палаталар, коридорлар, кабинетлар. Шулай да «таяк белән булса да йөрер», дигән хәбәрдән бөтен больница эченә нур кереп тулгандай булды.

Нургаян күтәренке күңел белән палатага кергәндә, Зәйтүнәсе, башын стенага борып, мышык-мышык елап ята иде.

– Әнисе, сызланасыңмы әллә? – Нургаян, юа-юа уңып, сизрәп беткән простыняны читкә этте дә, хатынының аяк очына утырды, юеш битенә кагылып, күз яшьләрен сөртте. Тәне авыртмасын, чиләнмәсен өчен, Зәйтүнәне йөзтүбән борып яткыра Нургаян, хәзер хет анысын рөхсәт итәләр. Хатыны, арып китсә, керфек кенә кагып ала – ире, аны шунда ук аңлап, тагын уңайлап куя.

Зәйтүнә, соңгы айларда инде гадәтенә кергәнчә, яшь аралаш елмайды, башын бу якка борды. Тәүге тапкыр күргәндәй, бик озаклап иренең йөзенә карап торды. Нургаян бөтенләй тартылып, ябыгып китте, каракучкыл йөзендә ике күзе генә утырып калгандай. Шулай инде, такы-токы ашап, айлар буе дүрт урындык өстендә йоклап, тәненә ит кунуны көтәсеме... Ә менә күзләрендәге җылылык шул килеш, кыз белән егет булып йөргәндә ничек өзелеп-томырылып караса, әле дә шулай, аз гына да кимемәгән. Люба белән Рәзифә дә, торган саен аның сабырлыгына, кайгыртучанлыгына шаккатып:

– Дөньяның бер бәхетлесе икән син, Зәйтүнә. Кешенең ире түгел, туганы да түзми, болай итеп карамый авыруны, – диләр.

И, никадәр бәхетле икәнеңне аңлау өчен, шушындый сират күперләре кичү кирәк микәнни соң...

Наилен уйлап йөрәге телгәләнә яшь ананың. Инде менә дүртенче ай китте – сабыеның бит очларын чокырайтып, челтерәп көлгәнен ишеткәне, кулларына

алып дуылдатып сөйгәне, аяк бармакларына тиклем үбә-үбә иркәләгәне юк. Баштагы мәлдә күкрәкләренә сөт төшеп изаланган иде, нарасыен кочагына сыендырып имезә алмагач, сөт тә бетте, күкрәкләре корышып калгандай булды. Улын сагынудан, аны юксынудан кар өстеннән яланаяк чыгып чабар иде дә соң. Юк бит, юк, инде кайчаннан бирле аякларының барлыгын да тоя алганы юк. Авылда да кыш бит инде, Казанга гына ашыгып килүе түгелдер. Каенанасы берүзе тилмерәдер инде: балага күз-колак булырга кирәк, сыер әле ташланмаган, ди Нургаян – иртә-кич аны саварга, бозауны карарга, сәндерәдән печәнен төшерергә, тиресен чыгарырга, карын көрәргә кирәк. Тавык чүпләп бетермәс эшләр диген. Зәйтүнәнең әнкәсе дә булыша булышуын, ике кодагый, ике ялгыз хатын ничек тә дөнья көтәргә тырышалар. Ә менә Зәйтүнә әле дә булса кадаклангандай ята. Кайчан аякка басар – белсә, бер Алла беләдер. Нургаянны да авылга кайтырга күндерә торган түгел, ерак араны бер итеп, хәл белеп, ике-өч тапкыр урап килде дә, янә хатынының җан сакчысына әйләнде. Югыйсә, Зәйтүнәнең әнисе, Халисәттәй, беренче тапкыр хәл белергә килгәч, киявенә елардай булып ялынды:

– Кызым янында калыйм, син – ир-ат, хатын-кызның төрле чагы бар, миңа җайлырак бит, – диде. – Кайт, дөньяңны көт, колхозда да сүзе булыр, – дип тә карады.

– Янымда Зәйтүнә булмаганда, миңа колхозы да, дөньясы да кирәкми, әби, – диде Нургаян, кырт кисеп. – Хатынымны үзем карыйм!

Менә хәзер, янына килеп утыргач, Зәйтүнә газаплы йөз белән иренә озаграк төбәлеп торды бугай, Нургаян борчылып сорап куйды:

– Әнисе, дим, әллә врачка эндәшимме?

– Кирәкми. Наилемне сагындым. – Хатын простыня почмагын бөтәрләп яшен сөртте. – Үсеп беткәндер инде, теле дә ачылып беткәндер. И Ходаем, кайчаннар кайтып күрермен... – Ул янә мышык-мышык еларга тотынды.

Нургаян узган кайтуында әллә баланы да Казанга алып килергә микән дип талпынган иде. Белә ич ул, хатыны әйтмәсә дә, бик яхшы күреп тора: улын уйлап, җаны мең телемгә теленә бит җанкаеның. Янына алып килсәң, күңеле күтәрелеп китәр иде дә соң. Шулай да барысын да бизмәнгә салып, аек акыл белән уйлагач, фикереннән кире кайтты. Юлы юлмы, йөк машинасында кечкенә бала белән дүрт йөз чакрымны узу аңа манный боткасы ашату түгел. Машина дигәнең батып яки ватылып калса, баланы харап итүең бар... Болай, әбисе янында булгач, җаны тыныч ичмаса.

– Зәйтүнәкәем, Наилнең аның асты коры, тамагы тук, аның өчен борчыласы юк. Әле монда ни бит... Бая врач ни дип сөендерде: таякка таянып булса да йөрер, диде, ишетәсеңме, әнисе? Түз инде, җаныкаем, тагыннар түз инде бераз.

– Һай, Нургаян, андый көннәр дә булыр микән...

***

Любаның бу арада бер генә дә кәефе юк, башкаларга сүз катмый, иртән янына килгән апасы белән чыш-пыш, кирле-мырлы гына сүз алышты да, «арыдым, йоклыйм», дип, тизрәк чыгарып җибәрү ягын карады. Моңарчы атнага бер-ике күренеп киткән ире бу араларда бөтенләй күзгә-башка чалынмады, шуңа борчылуымы, әллә врачлар өметен җуярлык берәр сүз әйткәнме – Рәзифә сорашып-сорашып караса да, авызы йозакка бикләнгән диярсең – рәтле җавап алалмады.

Хатыннар палатада үзләре генә иделәр. Нургаян көн уртасында кибеткә дип

китте – иртәнчәк Зәйтүнәнең, нәрсәгәдер бәйләп, үзе яраткан мендәр кәнфит турында сүз кузгатуы булды, шуны эзләргә чыгып та чапты.

Адәм баласы барысына да күнегә икән. Беренче көннәрдә котсызның котсызы булып тоелган шушы палата да, аның акшары купкан биек түшәме дә, калшаеп беткән тумбочкалары, яртылаш караңгы зәңгәргә, яртылаш акка буялган стеналары да көннәрдән бер көнне сиздермичә генә үзеңнең бер өлешеңә әйләнә дә куя. Биредәге тормыш гел үзгәрештә һәм шул ук вакытта бер үзгәрешсез килеш үз түгәрәгендә әйләнә. Җанны әле таш авырлыгы баскандай була, ул авырлык күкрәк читлеген изә, сыта, сулышны буа; шулчак кайдадыр еракта, офык артында өмет чаткысы ялтырап китә дә әлеге ташны кубарып ата, җан иркенгә чыга, рәхәтләнеп тын ала. Больницаның фәкать үзенеке генә булган исе бар, берничә көн эчендә борын ул иска шулкадәр күнегә, тәрәзәне ачкач ургылып кергән һава кайчагында ят һәм кирәгеннән артык саф булып тоела башлый.

– А-аһ!

Любаның җан ачысы белән сулкылдап җибәрүе Зәйтүнәнең очы-очка ялганмаган уйларын бүлде, ул куркып күзен ачты.

Рәзифәнең йокымсырап яткан мәле иде ахры, ул да дертләп китте, куркынган тавыш белән:

– Сестра! – дип кычкырды.

– Кирәкми. – Любаның тавышы кирәгеннән артык тыныч иде. – Нигә чакырасың сестраны?

– Син бит... йөрәкне алдың. Ни булды? – Рәзифәнең хәле көннән-көн арулана бара, инде аягына басты, муенчагын, төшеп китмәсен дигән сыман, ике кулы белән тота да уклау йоткандай иплəп кенә йөри.

– Все мужики сволочи. – Люба, түшәмгә төбәлгән килеш, боз салкыны бөркелгән тавыш белән дәвам итте. – Все, без исключения!

Хатынның тавышындагы салкынлык Зәйтүнәнең эченә йөгергәндәй булды.

Рәзифә дә, аптырап, Любаның караваты янына килеп басты, нишләргә белмичә, янә үз урынына барып утырды.

– Минеке киткән. – Люба борынын мышкылдатты. – Белгән идем, озакка түзмәс, дигән идем. Әмма шулай тиз? Минем өйгә кайтканны да көтмичә? Сволочь!

Кем, кая, нигә киткән – әлеге сорауларга җавап башкаларның башына тиз генә барып җитмәде ахры, палатада үле тынлык урнашты. Бераздан Зәйтүнә, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән:

– Кая киткән? – диде, мәгънәсез сорау бирүен шул мизгелдә үк аңлап.

– Кая, кая... сәламәт сөяркәсе янына... Нигә кирәк аңа гомерлеккә инвалид коляскасына калган хатын.

– Ай Алла... Гомерлеккә дип... Нишләп алай дисең? – Рәзифә, тагын кузгалып, Любаның караватына күчеп утырды. – Иреңне әйтәм... Үзең генә гөманлап ятасыңмы? Юньле генә кешегә охшаган кебек иде бит.

Люба мышкылдаудан туктады, истерикага бирелеп, тәнне чемердәтерлек ямьсез көлү белән көләргә тотынды.

– Юньле? Ха-ха-ха... Мин монда эләккәнче дә сөяркә арты сөяркә алыштырды, шулмы юньле? Паразит! Балаларның чыраен да күрсәтмим мин аңа!.. Иртән апа әйтте. Әйберләрен төяп чыгып китте, диде. Трус! Үзе килеп, минем күзгә карап әйтергә курка, паразит! Ну ничего, ул да күрми калмас... Сәламәт, тупырдап торган хатын кочагында ятасы килгән берәүнең...

Зәйтүнә минут эчендә әле салкын, әле кайнар тиргә батты, хәтта берни

сизми, агач кебек яткан аякларын да көзән җыергандай тоелды. Их, авыл башындагы буага йөгереп төш идең дә салкын суында колач җәеп йөз идең. Тәнгә-җанга таралган менә бу ут бераз булса да сүрелмәс идеме... Инвалид коляскасы, ди Люба. Йа Ходаа, әгәр Зәйтүнәне дә шул язмыш көтсә? Юк, юк, ул беркөн килеп барыбер аякка басачак! Врачлар алдамас, таякка таянып булса да йөрерсең, диюләре юатыр сүз генә булмас! Таякка таянып бассамы? Үз аякларына? И-и, ул чагындамы, ул чагында...

– Зайтуна, ты тоже не очень надейся... Не будет так вечно продолжаться... Твой тоже уйдёт. Нургаян молодец, конечно, но ул тоже китәчәк. – Люба, хөкем карары укыган судья шикелле, бертөрле, тигез, хиссез, тимер чыңы ишетелгән тавыш белән аңа эндәште. – Иртәме-соңмы, китәчәк, мин әйтте диярсең. Ирләр алар тыштан гына көчле күренә. Алларында аз гына авырлык булса, йә урап узалар, йә сынып төшәләр.

– Юк, юк, Нургаян андый түгел!

Зәйтүнәнең тавышы үз яныннан ерак китмәгәндәй иде, шулай да Люба ишетеп алды. Баягы кебек ямьсез хихылдап куйды. Үз ярасы белән ялгыз каласы килмәү булдымы, Зәйтүнәнең дә ачык ярасына учлап-учлап тоз сибәргә тотынды.

– Ирләр барысы да бер чыбыктан сөрелгән! Нәрсә, синеке генә аерым камырдан әвәләнгән, дисеңме? Ладно, бүген ул синең чәчләреңне шампунь белән юа, астыңны алыштыра, пролеженьнәреңә мазь сөртә... И күпмегә кадәр шулай дәвам итәр, дисең? Бер ел, ике, өч? О-о, юк, душечка, сабырлыгы аңа да җитмәячәк. Ул әле япь-яшь, каны кайнап торган егет. Аңа үзе кебек янып торган хатын кирәк булачак. Синең дә, минем дә язмыш бер, коляска көтә безне. Ко-ляс-ка, инвалид арбасы! Кайсы ир үз янында шундый хатынны күрергә теләр? Эндәшмисеңме? Дөрес сүзгә җавап юк.

Рәзифә дә ошатмады Любаның явызларча тантана итеп көлүен, өстендәге чәчәкле халат итәген сыпыра-сыпыра:

– Кит әле, Люба, Зәйтүнәнең йөрәген бозып, теләсә нәрсә сөйләмә! Нургаянны күреп торасың, хатыннан хатынга сикерә торганга охшаганмы? – диде шелтәле тавыш белән.

– Бүген, да, сикерми. Чөнки ул хатыны аякка басар, терелер, дип өметләнә. Но, увы...

– Юк, юк! Нургаян андый түгел!

– Хатын-кыз җүләр бит ул, ирен яратам, ди, шул ирдән тәнен ерта-умыра бала таба, иренең температурасы утыз җидегә күтәрелсә, алдында бөтерелә. Чөнки ул – хатын-кыз! Ул түзә! Чөнки ул... хатын-кыз! – Люба җанны куыра торган салкын тавыш белән палатаны яңгыратты. – Ә ир-ат сына. Түзми. Ул җайлырак юл эзли.

– Юк, юк! Нургаян андый түгел!

Зәйтүнә үзалдына ничәнче кат шул сүзләрне пышылдады, ике күзеннән кайнар яшь тамчылары бәреп чыкты. Сикереп торасы иде дә сары чәчле бу марҗаны уңлы-суллы яңаклыйсы иде. Кара инде, Нургаян ничәмә-ничә айлар Зәйтүнәнең фәрештәсе кебек, аны саклап, яклап утыра. Ә Зәйтүнә иренә аткан ташны күкрәге белән дә каплый алмый, шакшы су кебек агылган сүзләрдән дә аралар җае юк, мәлҗерәп ята менә... Юк, Нургаян андый түгел! Ул башка, ул бөтенләй башка. Ул беркемгә дә охшамаган! Башкаларның сабырлыгы чамалыдыр, әйе, сынып төшүчеләр дә күптер, тик Нургаян андыйлардан түгел! Ул, Зәйтүнәсен беркайчан да язмыш кочагына ташлап калдырмас, яратып

туялмаган ире, тупырдап үсеп килгән улының әтисе, бердәнбере бит ул! Яшь бит әле алар, бик яшь! Яши генә башладылар бит. Барысы да үзгәрәчәк. Зәйтүнә аякка басачак, әле Нургаянына вәгъдә биргәнчә, аның кебек коңгырт күзле бер-ике кыз, үзенә охшап, күгелҗем күзле тагын берәр малай алып кайтасы бар... Хатынның күзләреннән чишмә кебек яшь түгелде, кайнар тамчылар битттән – муенга, муеннан ак җаймәгә тәгәрәп, тап-тап булып җәелде. Әгәр? Әгәр Любаның әйткәннәре рас килеп, беркөн Нургаянның да түземе бетсә? Беркөн ул да «җитте, туйдым», дисә? Зәйтүнәнең менә болай кеше күзенә карап, тилмереп ятулары тагын, тагын сузылса? Ул арада иренең юлында чәчрәп торган, Люба әйтмешли, янып торган хатын-кыз очраса? Аның ут-ялкыны Нургаянның йөрәген көйдерә калса?.. Куркыныч һәм коточарлык уйлардан хатынның битенә кисәк кенә сәер кайнарлык китереп бәрде, тәне дерелдәп калтырарга, башы кысылып-кысылып авыртырга тотынды. Кычкырып нидер әйтергә теләде – авызын ачса да, телен селкетә алмады. Рәзифәнең аңа карап торган мәле булдымы – нидер сизенеп, Зәйтүнә янына килеп басты, үрә каткан килеш кенә бераз чүгеп, хатынның йөзенә кагылды.

– Уеннан – уймак, ди. Кан басымың күтәрелгән түгелме, үскәнкәем? Тыңлама шуны, үз ачуына буылып кына әйтә ул...

Зәйтүнәнең эндәшерлек хәле юк иде. Рәзифә, муенчагын ике кулы белән тотып, ишеккә юнәлде. Бераздан, аның артыннан иренеп кенә атлап, шәфкать туташы килеп керде. Зәйтүнә янына утырып, пошмас кына бер кыяфәт белән, кан басымын үлчәде дә, тонометрга күз салуга, берни әйтми, ашыга-ашыга чыгып йөгерде. Күп тә үтмәде, Клара Денисовнаны ияртеп кире керде. Юантык гәүдәле, чәчен җыйнак кына итеп баш артына төйнәп куйган, борын очына кара кысалы күзлеген элгән табибә Зәйтүнәнең, кулын күтәреп, пульсын санап торды. Аннан карашын күзлек өстеннән генә йөртеп, палатаны айкап алды:

– Ире кайда?

– Кибеткә китте бугай. Кәнфит, дидеме... – Рәзифә борчулы йөз белән тәрәзәгә борылды. Кара инде, кирәк чакта анысы да кайтып керми бит...

– Тик торганнан ни булды? Кан басымын кисәк кенә болай күтәрергә... – Клара Денисовна Зәйтүнәнең йөзенә иелде. Аннан, шәфкать туташына борылып: – Әлегә валокордин бирегез, бераздан карарбыз. Бу патология түгел, артык борчылудан, стресстан, мөгаен. Үтәр дип ышанам.

Чыннан да, дару капкач, Зәйтүнә әкренләп тынычлана төште. Башын кысып торган кыршау да тора-бара юкка чыкты. Күзе белән генә ишек төбен айкады – ире күренми иде.

– Нургаян... кайтмадымы? – диде ул, күңел түренә янә үрмәләргә иткән курку хисен җиңеп.

– Кайта, әнә, йөгерә-йөгерә кайтып килә. – Рәзифә, шат елмаеп, тәрәзәдән урам якка кул болгады. – Һи, кул изәп маташам – күтәрелеп тә карамый җанашың.

Зәйтүнә рәхәт бер җиңеллек белән тирән сулыш алды. Клара Денисовна үзе аның кан басымын үлчәде дә:

– Менә бит, – диде, йөзе яктырып. – Мондый ирләргә һәйкәл куйсаң да ярар иде...

*(Ахыры киләсе санда)*



Гөлзадә
Бәйрәмова

# МОҢ УЛ БЕЗДӘ ТУМЫШТАН

## Исән килеш күмәләр

Падишаһлар фәрман бирә,
Яраннары – үтәүдә.
И туган тел! Язмышыңны
Салдылар бит үлчәүгә.

Бизмәннәрнең бер ягында
Чал тарихлы үткәнең.
Әткәм-әнкәм теле булып
Яшәвең – көн иткәнең.

Кемдер сине кирәксенми,
Кемгәдер син артык йөк.
Ә кемнәрдер өзгәләнә,
Өзгәләнә минем күк.

Өзгәләнә бүген милләт:
«Дәхи без дә бетәбез!»
Исхакыйлар фаразлаган
Инкыйразга җитәбез.

Инкыйразны фәрман биреп
Ашыктыра түрәләр.
Милләт – исән, телем – исән –
Исән килеш күмәләр!

Гөлзадә БӘЙРӘМОВА – *шагыйрә; «Әле кайчан гына...», «Син һаман шул сандугач», «Дөнья шигырь яздыра» исемле китаплар авторы. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

## Соңарган сын

Сынга табынулар, беләм, гөнаһ.
Зурлыйм, диеп, халкым улларын
Богауланган зынҗыр кидерә дә
Бәйләп куя аяк-кулларын.

Җәлил сыны гүя бер кисәтү
Үткәннәрдән – килер көннәргә.
Такташыма һәйкәл ачылганда,
Нинди көйне белмим көйләргә.

Онытылган көйме, яңасымы,
«Алсу»ынмы хәтер яңарта.
Татар бистәсендә Такташ сыны! –
Такташ белән яңа таң ата.

«Киләчәккә хатлар» бармадылар,
Үткәндәме алар югалды?
Тамбов урманнары каеннары
Шаулады да арып тын калды.

Теләгәнсең, Такташ, һәйкәлеңнең
Үрелүен кызыл гөлләрдән.
Теләгәнсең һәйкәл күкрәгенә:
«Яшьләй үтерелгән пәйгамбәр», дип,
Язылуын синең сүзләрдән.

Бер күңелдә ике «мин»ең белән,
Үзең белән үзең көрәшеп
Яшәүләре ничек җиңел булсын! –
Сының белән торам сөйләшеп.

«Мин киң хәят теләп илгә чыктым;
Албастылар кисте юлымны.
Мин «азатлык!» дидем.
Алар көчләп
Бәйләп куйды ике кулымны»,
Дип язгансың, шагыйрь, ни аяныч
Шагыйрьләрнең кулы богаулы.
Гасырларны гасырларга ялгар
Көннәр калып бара санаулы.

Аһ, сындырган кырыс заман җиле,
Өзеп атып сине як-якка.
Гасырларны минутларга бәйләп,
Син янәдән кайттың халыкка.

Тик... соңардың, Такташ,
Бүген инде
Үлеп бара милләт үзе дә.
Танымастыр сине яңа буын,
Бетеп бара аның теле дә...

Син теләгән азат яңа тормыш
Кемнең кулындадыр – кемнәрдә?
Һәйкәл эргәсендә сүзсез матәм:
Гыйсъянчы шагыйрь, бунтарь Такташ,
Яшьләй үтерелгән пәйгамбәр!

***

Бер җырладым – гел җырладым
Җырларымның моңлысын.
Кемдер кушылып җырлады,
Кемдер көлде соңынтын.

«Моңың юк», – дип әйтмәделәр,
Моң ул бездә тумыштан.
Язмышка язылып туган:
Җырласаң – җырламасаң.

Язмышка язылып туган
Хәсрәтләрнең ачысы.
Берәү татлы шәраб эчте,
Безгә калды тамчысы.

Кызганмады, кызгандырып
Йөрмәдекме үзебез?
Язмыш белән көрәшмибез,
Ни күрсәк тә түзем без!

## Әйтмә, яме...

Әйтмә, яме, «яратам...» дип,
«Сагынам...» дип тә әйтмә.
Сүзсез генә яратуга,
Сагынуга ни җитә!

Әйтмә, яме, чынга ашмас
Хыялны чыкма атлап.
Оныклар тора күзәтеп,
Үткәннәр тора саклап.

Әйтмә, яме, «язмыштыр...» дип,
Язмышлар бит – яралы.
Җөйләре тырный бәгырьне,
Булгангамы ямаулы.

Әйтмә, яме, «киләчәк... – дип, –
Бу, – дип, – безнең күрәчәк».
Күрәчәкне күрәм, диеп,
Кадерсезгә әйләнсәк?

Һәр сүзгә җавап тотасы,
Һәр гамәл тора сакта.
Алдавыч-буш хыялларга
Куярга өйрән нокта.

Әйтмә, яме...

## Гаепleme заман?

*Кешеләрдән җылы эзләр булсаң,*
*Кешеләрдән ерак кит икән.*
Л.Янсуар

Һәммә кеше мохтаҗ ул җылыга,
Һәммә кеше нидер көтә
Туар таңнан.
Дулкын ярдан киткән кебек,
Ерагая кеше бер-берсеннән.
Туган – туганнан,
Бала – анадан.
Гаепleme заман?
Дустан бизелгән,
Ара өзелгән.
Ник кителә
Аллаһ сүзеннән:

«Заманны сүкмәгез –
Заман үземнән».
Кайтырмы изге хисләр
Кире эздән?!
Кайчакларда кычкырасы килә,
Дөнья яңгыратып:
– Кешеләр! Ә бит мин сезне
яраттым!
Дус-танышым туганымдай булды,
Ә туганым
үземнән дә якын!
Мәхәббәттә күпме
җан аттым!

...Кешеләрдән җылы  таба алмый,
Кешеләрдән китеп барышым...

***

Чәлпәрәмә килде, чәлпәрәмә
Син яшәгән шәһәр сурәте
Төшерелгән савыт.
Калды бары –
Кыйпылчыклар-ватык.
Әйтте бугай кемдер:
Вакыт!
Вакыт онытырга –
Барсын-барсын.

Киләчәккә гамәлләрнең
Яхшылары гына барсын.
Кешеләрнең
күңелләре изгеләре генә
янәшәңдә калсын.
Әйтте бугай кемдер:
Вакыт!
Күп акландың.
Сөйлим, диеп, хакыйкатьне,
Күп вакландың!

## Бәхилләшү

Таралды хәбәр җиһанга,
Таң белән, иртә белән.
«Үлде» дияргә тел бармый,
Бары тик «китте», диям.

Талгансың татлы йокыга,
Арып бар дөньясыннан.
Бер гасырлык тормыш йөгең
Яшәеш арбасында.

Анда ачлык, анда сугыш,
Ил белән күтәрешкән...

Чәчләреңне сүтә-сүтә,
Тын гына бәхилләшәм...

Ак кәфенлек – ак биләүдә,
Әйтерсең, сабый бала!
Әниләр үлә димени!
Әниләр каршы ала.

...Кулларымда чәчүргечең,
Бер сүтәм дә бер җыям...
Чәчләреңә кырау төшеп
Өлгермәгән дә сыман...

***Редакциядән:***

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Фирүзә
Җамалетдинова

# КИРЛЕМӘН

ХИКӘЯ

Эшкә соңга калуның  яхшы ягы да бар икән: китәсе халык китеп беткән – трамвай шактый бушаган, этелеп-төртелеп бимазаланасы да юк. Басып баручылар да берән-сәрән генә күренә. Боларның күпчелеге, мөгаен, минем кебек хезмәт көнен өлгермирәк башлаучылардыр.

Әйе, кешеләр ике төрле була. Беренчеләре – таш яуса да эшкә вакытында килүчеләр. Икенчеләре – никадәр вакытында җитешергә тырышсалар да, ахырда барыбер соңга калучылар.

Моңа үзләренең һич исләре китмәсә дә, җитәкчелекне әлеге авыр мәсьәлә шактый ук борчый. Чөнки табигать тәртипсез балаларының күңеленә күпләргә аңлашылмастай ирек оеткысы салган. Ә табигать белән көрәшү комга су сибү белән бер: моңа каршы нидер эшләргә тырышу– һич әһәмиятсезгә көч сарыф итү генә ул... Дөресрәге, этне тукмап бүре итеп булмыйдыр инде...

Мин үзем һич тә соңга калучылардан түгелмен, тик гомергә бер тапкыр дисәм дә ярыйдыр, шулайрак килеп чыкты менә. Трамвай тукталышына җиткәнче, бимазаланып, җанымны талкып бетердем. Әллә ниләр күз алдымнан үтте. Ишек төбендә үк җитәкчебез каршы алыр. Сәгатенә карый-карый: «Бу хәл тагын бер  кабатланса...» дип кисәтү ясар... Ай-яй... Ярый ла кисәтү генә ясаса... Заманасы нинди бит. Ике сөйләшмиләр.

Авыр уйларымны өстерәп, мин трамвайның аргы башына ук барып тормаска ниятләдем, ягъни  кергән тирәдәрәк тукталдым. Ишек ачылуга төшеп сызарга җайлырак булыр, дип фикерләде аек акылым. Куркак йөрәгем аны куәтләде кебек.

Күзем тәрәзә кырыенда нәни терсәкләрен, зәңгәр бантиклы башын уйната-уйната җыр көйләгән нәни кызчыкка төште.

О Боже, какой мужчина,
Я хочу от тебя сына...

Аның күбәләктәй җиңел хәрәкәт җиленнән сары бөдрә чәчләре язылып-язылып киткәндәй тоела. Миләүшә чәчкәләредәй якты күзләрендә

---

Фирүзә ҖАМАЛЕТДИНОВА – *шагыйрә, прозаик; «Толымлы ай», «Җирбизәк», «Хикәяләр» һ.б. китаплар авторы. Һ.Такташ исемендәге әдәби премия лауреаты. Казанда яши.*

сокландыргыч назлы очкын уйный. Ирекле кыланышыннан сулыш юллары ачылып, тын алуы иркенәйгәндәй була.

Аптырауданмы, елмаеп куйдым. Салондагылар да, елмая-елмая, шул хакта сөйләшәләр икән.

– Бала җәмгыятьтән аерым яши алмый инде, хәзер тормыш юлында тормозлар бетте ич, – диде кайсыдыр.

– Телевизор, компьютер, эләктереп кенә алалар шул һәммәсен, – дип куәтләде икенчесе.

Ике-өч яшьләр тирәсе генә булганлыктан, ул үзенә кирәкле сүзләрне генә беләдер кебек тоела, шулай да җырның ике-өч юлын бик тырышып, дөрес итеп җырлый. Тын да алмый, авыз ера-ера, аны тыңлыйбыз.

Я хочу от тебя сына,
Я хочу от тебя дочку...

Яшь әни миңа күз йөгертеп алды да тизрәк хөрмәт күрсәтергә ашыкты: нәни кызчыгын җыры белән бергә итәгенә утыртып, урын тәкъдим итте. Тик кызчык әнисенең бу гамәлен ошатмады кебек. Миңа күзенең агы белән карап куйды. Аннан әнисенә борылып, авызын дәү ачып елап җибәрде.

– Олы кешегә без урын бирергә тиешбез, тәтием минем, – дип, аркасыннан сөеп алды яшь ана. – Сиңа итәгемдә урын җитмиме әллә, ә?

– Җитми, – дип үкседе кызчык, нәни йодрыклары белән күзләрен уа-уа. Күзләрен уганда да терсәкләре ирекле хәрәкәтләнде. Аңа бу мәлдә трамвай гына түгел, Җир шары да кысан булыр сыман тоелды.

– Йә инде, кызым, алай ярамый бит! – Әнисенең тавышы кырыслана төште.

– Ярый! Ярый! – дип тәпиләрен селеккәләде кызчык, тагын да киреләнеп. Сыңар зәңгәр сандалие, салон буйлап очып китеп, пеләш башлы бер агайның алдына барып кунды.

Агай, аны кулына алып:

– Ай-яй матур сандали, минем оныкка бик ярап куяр бу, таманга да охшап тора, – дип, кызчыкның күңеленә ут үрләтмәкче булды. Бала аны ишетмәде дә кебек, ул инде үкерә үк башлаган иде.

Мин урынымнан тордым, чөнки башка чара күренми кебек тоелды.

– Утырсын әйдә, үзе теләгәнчә, елатмыйк, зинһар, нарасыйны, – дидем. – Әйдә, җырла, матурым, «О Боже»ны!

Ул арада кызчыкның артында ук бер урын бушады, мин шунда күчтем.

– Без әниләрен гаепләгән булабыз, тагын да яманрак буын яралып ята ласа дөньяга, – дип ычкындырды янымдагы чал чәчле әбекәй, миңа табан иелеп. Яшь әни ишетте әлбәттә. Аклангандай итеп әйтеп куйды:

– Без болай тәрбияләр идекме? Әбиләре бар бит аларның, шулар боза. Һаман үсендереп торгач, менә мондыйга әвереләләр инде. Онык күргәннәр, имеш. Тыймыйлар, имеш, нишләсәләр дә ярый, имеш.

Кызчык исә беркемне дә ишетмәде, үзенекен тәкрарлады, әнисенең күкрәгенә суккалый-суккалый:

– Күчеп утыр, минем тәрәзәдән карап барасым килә, – дип сулкылдады.

– Күчмим, кызым, итәгемдә сиңа урын җитә, – диде яшь хатын. Ул арада чираттагы тукталыштан салонда яңа пассажирлар пәйда булды. Бер ир-ат кызчык янындагы буш урындыкка килеп утырды. Янә урын яулый алмау фаҗигасе кызчыкны чыгырыннан чыгарды.

Ул итәктән сикереп төште дә, баскан урынында тыпырдый-тыпырдый, әнисенә:

– Тор! – дип боерды. – Мин, үзем генә утырып барам, тор, әнием!

– Син минем йөземне кызартасың, балам, күрәсеңме, бөтен халык сиңа төбәлгән, ничекләр җайсыз хәлгә куйдың син мине. Оят миңа, оят! – Әни кеше бу сүзләрне чын йөрәктән әйтте.

Кызчыкка исә әлеге җөмләләр бөтенләй тәэсир итмәде. Ул әле чыелдавын, әле үксүен белде. Ана:

– Әйдә, алайса, яныма утыр, – дип, үзе күршесендәге ир ягына ук шуышып, кызына урын әзерләде һәм ике куллап күтәреп утыртып ук куймакчы булды. Кызны тимер кыршау китереп кыстымыни, ул тыпырчынды, әнкәсен терсәкләре белән этте. Үзе бертуктаусыз:

– Ирек җитми миңа, ирек кирәк миңа! – дип тәкрарлады.

– Трамвайда ирек бер кешегә дә җитми, һава да юк монда, ләкин берсе дә синең кебек шәрран ярып кычкырмый бит, кызым, – диде ана һәм, бар сабырлыгын җыеп, баланы шап иттереп янәшәсенә утыртып куйды.

– Тор, әнием! – дип боерды кыз, янә урындыктан шапылдап сикереп төшеп.

Шул мәлдә трамвайга кешеләр белән бергә буталып, бер эт килеп керде. Муенын затлы каеш кысып торса да, хуҗасы кем икәнлеген белеп булмады.

– Әнә нинди тәти эт керде, күрәсеңме?

– Күрмим.

Кызның күзләрен яшь элпәсе каплаган, ул чынлап та бернине дә күрергә теләми иде.

Кешеләр кайсы кая таралышып беткәч тә, эт әле юл өстенә нәзек тәпиләрен бөкли төшеп утырып, як-ягына каранып торды. Аннан, монда мин беркемне дә борчымамдыр, мөгаен, дигәндәй, олы гәүдәсен аулаккарак борып, арткы урындык янына чүмәште. Мин шуңа игътибар иттем: койрыгын кергәндә үк җыеп керде ул. Хуҗасы да, мөгаен, шунда булгандыр. Эт аны да борчымады. Матур гына икенче тукталышка кадәрле утырып барды да кешеләр төркеменә уралып төшеп тә калды.

– Мәскәү артистларына охшаган, интеллигент, – диде сүз озайтмыйча гына эшләпәле бер ханым, ирен чите белән генә елмая-елмая.

– Әллә безнеңчә яшәргә өйрәткәннәрме? Шауламаска, ирек дауламаска. Җир өстендә шыпырт кына йөрергә...

– Бәлки, гомергә бер бәйдән ычкындырганнардыр үзен. Нишләсен инде ул, шыпырт йөрмичә?

Монысы ир-ат тавышы иде.

Берәүләр көлешеп алды.

Җан ияләрен Аллаһ төрле итеп яраткан шул, дип уйлап куйдым мин.

– Тор! – Кызчыкның тавышында җиңүчеләр үҗәтлеге чагылып китте.

Әнисе кузгалмады. Әлбәттә, күңеле белән ул баласын кызгана, аңа үзе даулаган урынны бирәсе килә, тик бар гавамга кызчыгын шул дәрәҗәдә үк тыңлаусыз итеп тә күрсәтергә теләми иде. Вакыт-вакыт ул аның чәчләреннән сыйпап куя, тик әнисенең кагылуы кызчыкның ачуын отыры көчәйтә, ул дәү кулларны көчәнә-көчәнә читкә этә тора. Болай гына да түгел, әнисенең күнмәве аны тагын да ныграк ярсыта иде. Ул шул арада нәни бармаклары белән зәңгәр бантикларын йолкып алды да аларны һавага очырып җибәрде.

– Хулиган, – дип куйды бантикны җәһәтлек күрсәтеп һавадан ук эләктереп алган егет, елмая-көлә.

– Кара, нишли бу?

*100 нче бит: чор, милләт, вазгыять*

## НИНДИ ЯЗМЫШКА ДУЧАР БЕЗ?

Галимнәр әйтүенчә, дөньяда бүгенге көндә 6809 тере сөйләм теле бар, бу гасыр азагына шуның якынча алты меңе гамәлдән төшеп калуы ихтимал икән.

Киләчәге өметле телләр – кытай, инглиз, алман, гарәп, француз, испан, рус телләре санала.

Димәк ки, телне ышанычлы яшәтү өчен, халыкның саны да зур әһәмияткә ия. Күрәсез, киләчәкле телләр исемлегендә бер генә кардәшебез дә (бәйсез илле төрек, азәрбайҗан, төрекмән, кыргыз, казакъ, үзбәк) саналмаган. Бердәм көч белән упкын аша күпер салу урынына, бәхет ярына аерым-аерым сикерәм дип, фаҗигале тәвәккәллеккә бару – безнең дала беркатлылыгы канында типкән төрки галәменә хас сыйфат шул.

Ни үкенеч, күңеле – дала, рухы – бөркет булып дөньяны тоткан атҗанлы төрки халыклары замана сәхнәсендә каһарман түгел инде. Ислам илләре дә нефтьтән килгән алтын көшелен таркатып, кәеф-сафа корып кинәнгәндә, Европа илләренә яһүд галимнәре, атомны таркатып, дәһшәтле корал ясап бирделәр. Көчле илләр хәзер үз теле иминлеген атом-төш коралы белән саклыйлар. Һәм бернинди халыкара оешмалар да аларның, ялган сылтау табып, бүтән илләргә җимереп керүен туктата алмый. Боларның вөҗдан кысаларын инкарь иткән сәясәтенең гуманлыгына өметләнү – көчсезлегеңне аклау акылсызлыгы. Шулай... кешелек җәмгыяте, әхлак нормаларын, изге төшенчәләрне таптап, йөгәнсез фазага кереп бара.

Ә саннар рәхимсез... Күпмилләтле Россиядә бүгенге чорда 174 сөйләм теле исәпләнә (18 тел үлемгә дучар ителгән, 3се китап теле булып калган). Бу саннар киметелеп күрсәтеләдер дигән шик кала, әлбәттә...

2009 елда ЮНЕСКО Россиядә 136 телгә киләчәктә ихтыяҗ бетәчәген таныды. Димәк, тагын 136 халык-милләт исемен һәм җисемен җуячак.

Маңгаена өметсезлек мөһере сугылып, эшафотка менеп барганнарның берсе – минем халкыммы?!

Хәзерге заманда империя үз канаты астындагы халыкларның телен б е т е р ү алымын асу-кисү, кан-яшь түктерүгә бармыйча гына, тыныч-мәкерле юл белән дә хәл итә ала! Әйе, телне сугарып торучы саф чишмә – балаларда. Өлкән буынга табигый ялганырга тиешле шушы тере бәйләнешне өзәсең дә... Мәктәпләр капкасына «Татар теле кертелми!» дигән югарыдан төшкән «указлы бүкәйне» бастырып куясың да... Катнаш никахлы гаиләләре отыры күбәеп, милли рухы хәлсезләнә барган халык аңга килгәнче... Берничә елдан яшь буын, үзе дә сизмичә, Ана теленең кабер казучысына әверелеп, чардуган куячак.

Иртәгә телең бетә, дисәләр, мин бүген үләргә риза, дигән олуг Шагыйрь.

Нинди язмыш көтә безне?

Мәһабәт телебез тирәгенең яшь үсентеле ябалдашларын кырау сугып килгәндә, битараф кала алабызмы?!

«Җаны булганнарның җаны калыксын, каны булганнарның каны кайнасын, аңы булганнарның аңы уянсын!» – дип дәшә безгә йөрәгенә хәвеф төбәлгән газиз Ана теле.

**Марсель ГАЛИЕВ**

– Йә, тукта хәзер үк, алайса полициягә биреп җибәрәм үзеңне. – Монысын җитди кыяфәттәге ханым әйтте. Пиджагы астыннан ак кофта якасы күренеп тора, дөресрәге, ирек дигән төшенчә белән бик үк исәпләшмәүче укытучыга охшаган иде ул.

– Үрсәләнмә, сеңел, сындырачаклар барыбер, – дип елмайды бер ир-ат мыек астыннан гына. – Барыбызны да волейбол тубы кебек типкәлиләр, җиргә төшәргә һич ирек бирмиләр...

– Әлбәттә, сындырачаклар, җәмгыять әзерме соң мондый галәмәтне кабул итәргә? Йә, әйтегез әле сез миңа шуны! – Бу җөмләне яңгыраткан агай да дөнья күргән кешегә охшап тора иде. Ул эшләпәсен уңгарак авыштыра төште дә тагын бер җөмлә өстәде: – Тик, булган әтәч күкәй эчендә үк кычкырыр, ди халык!

Яшь әнинең битләре кызарып чыкты. Кызчыкка табан борылып:

– Ишетәсеңме, кешеләр үзеңә ни диләр? Йә, әйт, хулиганмы син?

Әни кешенең бу мәлдә баласыннан, һичшиксез, яхшы сүз ишетәсе килә иде.

– Әйе, – дип җөпләде кыз, үкси-үкси.

– Тәртипсез кызмы син?

– Әйе-е-е.

– Син акыллы да түгелме?

– Түге-е-л!

– Йә, нәрсә җитми соң сиңа, кызым?

– Ире-е-ек!

Минем колакларыма ерак Африка колларының көр тавышы ишетелеп куйгандай булды. Юк, юк, колның кайчан җиңгәне бар? Җиңә башласалар, кыйнап үтерәләр ич аларны. Шуңа авыз ачып сүз әйтмәскә өйрәнгәннәр. Дәшмәү – бәхет. Дау – давыл белән бер, диләр бит. Мөгаен, Франция каһарманы Жанна д’Арк бала чагында нәкъ менә шуның төсле булгандыр, мөгаен, аңа да ирек җитмәгәндер, югыйсә, баскынчы инглизләргә каршы көрәшмәс иде ул. Сихерче, дип, янган утка ташлаганнар үзен, унтугыз яшьлек гомере әрәм киткән бахырның. Ул фаҗигале 1453 елдан соң күпме сулар аккан, чорлар аккан...

Безгә шул чит илләрнең тарихын күбрәк өйрәттеләр кебек.

Хәер, үз туган җиремдә узган гасырның туксанынчы елларындагы тыгыз мәйданнар күзалдымнан үткәндәй булды. Фәүзияләр, Вафирәләр, Гөлзадәләр, Альмиралар... Һай аз икән лә батыр йөрәкле горур кызлары минем халкымның... Йомарланып өскә күтәрелгән йодрыклар, тигез адымнар, иркен сулап күзәткән киң урамнар... Кешеләр кыю, теләкләр изге иде. Тыгыз төркемдә җир өстендәге барча халыкларга ирек яулап бирерлек көч-кодрәт бар иде кебек. Минем газиз Ватаным, үзен яклап күкрәк куярдай затлары булгангамы, алтын баганадай нык күренде.

Бөеклеген бар дөнья таныйдыр кебек тоелды. Боларның тере шаһиты идем бит мин кайчандыр. Ирек! Азатлык! Аннан ул сүз янә үз мәгънәсен югалтты сыман. Хәтта аның халкымның сүз байлыгын сыйдырган сүзлекләрдә барлыгы да онытыла башлаган иде инде...

Дөньялар үзгәрде: кешеләр байларга һәм ярлыларга бүленде. Байлар – үзе турында, хәерчеләр гадәттәгечә җәмгыять турында күбрәк уйлый башлады.

...Кызчыкның тартынусыз иркен тавышы карлыгып беткән. Елый-елый эштән чыккан, тәмам арыган, күзләре кызарып кысылган иде. Тирә-юньдә кешеләр сөйләште:

– Җәмгыятькә каршы бунт күтәрмәкче диген, ә? Чәнти бармак кадәрле башы белән?

– Мин күпме гомер яшәп шуны аңладым: яраклаша белергә кирәк икән ул. Үзең дә үсәсең, карьераң да үсә.

Әңгәмәдәшенә әлеге фикер ошамады кебек.

– Дөрес әйтмисез Сез, – дип бүлдерде ир аны. – Бөтен кеше дә Намус яныннан күзне йомып үтсенме?

– Нигә? Дөрес сүзне кайчак әйтми калсаң яхшырак түгел микән? Менә синең янга бер бөкре кеше килеп басты ди. Аңа карап: «Абау, синең бөкрең чыккан», дисәң, бу кемгә ошый? Ә бит дөп-дөрес сүз. Бер ялган да юк.

– Белмим, – дип янә каршы төште тегесе. – Мин яшәргә өйрәнә алмадым инде. Ходай сәләт бирмәгән күрәсең...

Бала тавышы карлыкканны үзе дә сизде кебек.

– Мин башка еларга теләмим! – дип аяк тибеп кычкырды ул. – Төш, әнием! Ирек кирәк миңа!

Хатын, кинәт исенә төшерепме, сумкасыннан телефонын эзләп алды. Баласын үҗәт уйларыннан арындырырдай әйбер тапканга, йөзендә бер мизгелгә сөенеч очкыннары балкыган кебек булды.

– Менә кара әле бу телефонга, әйдә мультфильм куеп бирәм үзеңә, телисеңме? – диде ул, куанычыннан нишләргә белмичә. Үзе: – Хәзер килеп җитәбез, кызым, – дип, баланың тузгыган сары бөдрәләреннән сыйпады.

– Мультфильм кирәкми миңа!

– И кызым, үз кәефеңне үзең боздың менә, көне буена җитәрлек итеп, хәзер башың авыртыр инде... Әйдә, ишек төбенәрәк барыйк, матурым.

Яшь әни төшәр вакыт якынлашканга да куана иде булса кирәк, ул кызын күтәреп алырга уйлады. Тик кызчык тагын да катырак чыелдап елап җибәрде:

– Төшмим мин! Камил янына өйгә кайтыйк.

– Камил бакчада бит әле, кичкә керерсең аларга, йә безгә чакырырбыз да бергә уйнарсыз аннары.

– Юк, хәзер үк кайтыйк.

Үз киресенә катты тәмам, дип уйлап куйдым мин. Шунда ук эшкә соңга калуым исемә төште. Бездә берүзең өч кеше өчен эшләсәң эшлә, бу хакта берәүгә дә әйтмәскә генә кирәк. Беркөнне көлешеп сөйләшеп утырганда, рәисебез бүлмәгә килеп керде. Ник көләсез, имеш. Йөзеннән буран бара диярсең. Җитәкчеләр бай бит хәзер. Хәзерге байлар – нәфрәтле байлар. Чөнки алар үзләренең бай булырга лаек түгел икәнлекләрен беләләр. Шуңа аларда кешеләргә үч кайный, нәфрәт ташый... Тфү, тфү, тук яшәү хакына күпме михнәт чигәләр ич алар да. Ник көләсез, имеш...

– Сез без көлгәнгә сөенегез. Бу хезмәт хакына ничек көлә алалар икән болар, дип уйлагыз, – дидем. Ничек әйтә алдым мин бу сүзләрне? Искә төшсә, куркудан әле дә йөрәгем кысылып куя. Шуннан бирле дошман итә ул мине. Менә бераз телне кыскартырга сәбәбе дә күренеп тора хәзер... Их, Канар утрауларына китеп, кеше җанын кыймыйча гына яшәсеннәр иде дә соң!

Күңел түрендә, куркуны җиңәргә тырышып, тынычлык хисе баш калкытмакчы. Гомергә бер тапкыр инде... Әйдә, ни булса шул булыр, балта чапканчы түмәр ял итә, диләрме әле...

Ай Аллакаем, шулай да Жанна д’Арк чыкмас иде миннән. Ирек сөючеләрне бик орышалар да икән. Трамвайда балага усал сүз әйтмәгән ник бер кеше калсын! Ирекне һәркем сөя, аны яулап алырга тырышучылар берәүгә дә ошамый икән шул...

Трамвай тукталышка якынлашты. Ана кызчыкны, чыелдата-чыелдата, өстерәп диярлек, ишек янына алып килде һәм, төшәргә әзерләнеп, кулыннан тотмакчы булды. Тик кызчык әнисенең үзенә сузылган кулларын күрергә дә теләми, ул ишек төбендә дә ирекле тыпырдап тора бирде.

Трамвай туктады. Ишекләр киң итеп ачылып китте. Баланың кулыннан тотмый һич мөмкин түгел, чөнки, тәбәнәк булса да, баскычтан исән-имин җиргә басасы бар иде. Аннан ул баскычлар нәни тәпиләр өчен һич көйле түгел иде шул.

Ана янә нарасыена кулын сузды. Әмма кызчык әле һаман бар дөньяга чиксез ачулы... һәм шул ук вакытта чиксез ирекле иде.

Минем, эшкә соңга калуым исемә төшеп, янә йөрәгем жу итеп китте. Уч төбем кинәт тирләп чыкты. Рәисебезнең дәү корсагы киерелә төшүе, шома кызыл йөзенең тәкәбберлеге, кырыслыгы күз алдымнан шуып үтте. Миннән дә бәхетсезрәк шул ул. Кешеләр белән аралашу ләззәтен белми, колларны изүдән канәгатьлек ала... Ләкин бер нәрсәне аңламый: колларга бервакытта да таянып булмый. Алардан бүген хуҗагызны яклагыз, дип кул куйдырталар икән, һичсүзсез куячаклар. Иртәгә яңа хуҗа килә, хуплагыз, дисәләр, анысына да имза салачаклар. Җәмгыятьнең дә, җитәкче кешеләрнең дә төп хатасы менә шунда: кешеләрне кол итеп тотуда. Кәнәфине аларга Аллаһы Тәгалә мәңгелеккә бүләк иткәндәй кыланалар...

Гомергә бер соңга калып килүемне эштә кемнәргә нинчекләр аңлатасы булыр менә? Белә калсалар, бөтен коллективка эш булачак инде. Секретарь боерык язар, кадрлар бүлеге раслар, рәис кул куяр... Йа, Аллам, үзең саклачы мине...

Трамвайда кешеләр, гадәттә, бер-берсен танымый, исәпләми генә бара торганнар иде. Әллә кыз күңелләрен кузгатты, әллә башка берәр сәбәп булдымы, алар сөйләшеп калырга ашыктылар.

– Укыдыгыз микән, Яңа Зеландиядә өч яшьлек кызчык интернет-аукционда экскаватор сатып алган. Әти-әнисе йоклап киткәч, компьютерда төймәләргә баскалап уйнаган.

– Шуннан ни булган?

– Ни булсын? Иртән хат килеп төшкән: «Сезгә экскаватор сатып алуыгыз өчен рәхмәт. Ул сезгә ошар. Фәлән мең акча җибәрүегезне көтеп калабыз», – дигәннәр. Әнисе бала уйнаганга көчкә ышандырган ди тегеләрне.

– Булыр, булыр, менә күрәбез ич... Замана балалары башка...

Кешеләргә эшкә соңга калу куркынычы янамыйдыр, мөгаен...

Трамвай тукталышка якынлашты. Туктады...

Кызчык, ниһаять, ирекле җиргә ирекле булып төшеп басарга теләде. Тик нәни тәпиләре тигезлекне югалтып өлгердеме, әллә күз яшьләре аша җирне күрмәдеме, ул, чайкалып китеп, борыны белән асфальтка чәпәлде. Борыныннан шаулап кан китте. Ана, еларга җитешеп, сабыйны күтәреп җиргә бастырды, кесәсеннән кулъяулык чыгарды. Инде эш харап, тагын да катырак үкерә башлар, мөгаен, дип, тәрәзәләргә текәлгән халыкны хәйран калдырып, кызчык елавыннан шып туктады. Әнисе кулындагы кулъяулыкны тартып алып, борынын томалады. Ике куллап канлы битен сөртә-сөртә, әнисе янәшәсеннән терек-терек атлады. Ана безнең күз алдында соңгы мәртәбә кулын сузды. Кыз, сыңар кулын артка яшереп, кабат:

– Миңа ирек кирәк! – дип шәрран ярды. Ул инде еламый иде. Бу мәлдә нарасыйга кемнәрдер сөеп, кемнәрдер гаҗәпләнеп карады.

– Молодец!

– Молодец, пычагым, үзсүзле, диген... Киребеткән...

– Афәрин! Ачка үлмәс бу, иншалла!

Без кузгалып киттек. Аның: «Миңа ирек кирәк!» дигән якты авазы трамвай тәрәзәсенә килеп бәрелде, гүя ул сүзнең бәллүр кыйпылчыклары ватылып җиргә коелды... Юк, юк, бәллүр кыйпылчыклар юл буендагы гөлләрнең якты таҗларына эленде сыман, чөнки чәчкәләр кояш нурында ялык-йолык килә... һәм иртәгәсе көн барлыгын тоеп, аеруча бәхетле елмаялар иде.



Лилия
Газизова

# СӨЕНҮЛӘРЕН ТЕЛИМ

## Чәчәкләр булсын иде...

Нинди күңелле шөгыль –
Мөнәсәбәтләр уйлап чыгару.
Карашлар,
Кул хәрәкәтләре.
Бирелмәгән сорауларга
Көтелмәгән җаваплар табу.

Кайда да булса кафеда
Яки берәр һәйкәл янында
Очрашуны күзаллау.
Чәчәкләр белән...
Яки... мәҗбүри түгел.

Уйлап чыгару
Наз һәм дәртне.
Хәтта көнчелек һәм чыгырдан чыгуны...
Ә аннан – үкенүне...
...Нинди моңсу шөгыль –
Булмаган һәм булмаячак
Мөнәсәбәтләрне уйлап чыгару...

***

*Равил Бохараевка*

Шәмәхәләнер канәфер.
Ике мең дә унике.
Сирень төсенә керер:
Шатлыклар, төшләр, саташулар.
Миләүшә төс белән өртелер
Агачлар, этләр, китаплар.

---

Лилия ГАЗИЗОВА – *шагыйрә, тәрҗемәче; Россиядә һәм Европада төрле телләрдә дөнья күргән күпсанлы китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Россия һәм Халыкара әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

Язылмаган шигырьләрем,
Суыткычка ябышкан магнитлар.
Сирень төсендәге бүгенгемдә
Ак тап булып калырсың
Бары син...

## Дельфин

Яратасың
Ерак-еракка йөзәргә.
Яратасың
Ягышсыз күренергә бар кешегә.
Бары миңа гына
Чак-чак тотып алырлык
Һәлакәт сигналлары җибәрәсең.

Мин шунда
Дельфинга  әвереләм.
Һәм, бар дөньямны онытып,
Сиңа йөзәм...
Сине алып чыгам ярга.

Һәм син,
Исеңдә калдырырга теләгәндәй,
Карыйсың миңа озак-озак.
Йөзеп китәр өчен кабат ерак-ерак...

## Дус кызыма

Аңа тәшвишле төшләр керә.
Ул төштә – култыксасыз баскычлар.
Һәм көтмәгәндә алар өзелә.

Мин белмим төшләрнең төзелеш канунын.
Бу яман төшләрне ничек соң өзәргә?
Баскычка аралык ничек соң төзергә?

Тик беләм, ялгызы көчсез ул бу эштә.
Янәшә булырга тиеш бер иңсә –
Төзүче яисә фәрештә.

Шуңадыр, мөгаен, борчулы-тәшвишле
Йөзендә иртәнге елмаю.

## Синең куллар

Кулларың белән сөйләшмә!
Кая карарга да белмим –
Миннән ерак күзләреңәме,
Әллә
Моңа кадәр күрелмәгән бию башкаручы
Озын кулларыңа?

Мин, сихерләнеп,
Аларның мәңгелек хәрәкәтен күзәтәм...

Дирижёр була алмассың.
Кулларың хәтта
Музыка кануннарына буйсынмый.
Бары йоклаган чагыңда
Бармак очларың гына
Хәрәкәтен тизләтә барган
Галәм ритмына
Сискәнеп куялар...

## Исәрлек түгел

Күңелсезләнә күңел,
Елмаймаса сиңа
Сатучы яки чәчтараш...
Миңа, Кояшка сөенгәндәй,
Сөенүләрен телим.
Һәм, хәтта, бармактан кан алганда да,
Шәфкать туташы
Миңа елмайсын.
Бу хакта хыял исәрлек түгел.

Төп-төгәл беләм:
Бәхет өчен туган кеше мин.

## Сөембикәгә

Яратам кызымның сүзләрне бозуын:
«Продавщица» түгел,
«Продравальница»,
«Циркачка» түгел,
«Цирковщица», диюләрен.
Авазларны әйтеп бетермәвен.
Хаталарыннан арындырып,
Балачагыннан арындырам кебек.
Моңсуланам.

## Синең сурәт

Бармакларны каты бәреп,
Җидегә кадәр санаем.
Һәм синең сурәтеңне
Үземнән куалыйм.
Һәм кайтам үземнең
Яңгырларыма,
Күлдәвекләремә,
Кояшыма, –
Бу җирдә син булганга,
Дулкынландыргыч
Озын гомеремне яшәү өчен...

Йокысыз төннәремнең берендә,
Сальса биегән барга кереп,
Мин кабат латте сорармын...
Һәм кабат латте сорармын...
Һәм латте...

## Баш җуеп...

Нишләптер көлке күк
Кырык яшьтә
Баш җуеп ярату турында язуы.
Борчу-мәшәкатьләр,
Дөнья куу
Йота, йота гамьсезлекне.

Һәм каранасың, каранасың як-ягыңа.

Тик, шайтан алгыры!
Кырык яшьтә дә
Килә бит
Баш җуеп ярату турында язасы.
Һәм, хәтта,
Шул утта янасы!

***

Миләүшә һәм сары төстән торган
Кипкән букетта
Һәрвакыт ак бөрчекләр җитми.
Шуңа күрә кыланчык томан,
Лазутчик парашюты булып,
Шәһәремне каплый.

Һәм шәһәр йөзә шәрыкка таба,
Һәм төшләр йөзә шәрыкка таба.
Әкрен генә чеңләп, сикергәләп куя
Шкафтагы савыт-саба гына...

Кипкән букеттагы
Миләүшә һәм сары,
Сигез миллиардның берәрсен
Вәсвәсәләндерергә теләп,
Бер мизгелгә талпынып куя...

**Илсөяр ИКСАНОВА** *тәрҗемәсе.*

# ХАЛЫКНЫҢ СӨЕКЛЕ ШАГЫЙРЕ

Шагыйрь – барыннан да бигрәк үз халкының көтеп каршылаган сөекле, тансык улы, аның йөз аклыгы, иманы, вөҗданы!

Шулай булганда гына ул аның күрке, мактанычы да санала ала. Ышанып әйтә алабыз: бу саналганнар – халкыбызның күренекле шагыйре Фәнис Яруллинга да хас сыйфатлар; ул чын мәгънәсендә татар халык шагыйре, халык моңнары һәм өметләре бакчасында үскән, димәк ки, аның язмышыннан аерылгысыз шәхесләрдән иде.

Тукай, Җәлил, Кәрим, Туфаннар мәктәбеннән иде ул, нәкъ алар кебек үз вакытында мәйданга чыккан һәм пәйгамбәрләр язмышына тиң рухи ныклык, батырлык, Сүз үрнәге күрсәтеп, тагын бер тапкыр татар шагыйренең нинди булырга тиешлеген исбатлаган Олуг Язмыш иясе дә иде.

Күренекле башкорт шагыйре Хәсән Назар бер китабына язган кереш сүзендә: «Асылда мин гомер буе бер Китапны язам... Язмыш Китабын...» – ди. Бу сүзләрне остазы Нажар ага Нәҗми сөенеп кабул итә һәм: «Язмышың – Халкың язмышы була алсын», дип теләк белдерә.

Бу, минем уемча, барлык шагыйрьләргә дә, бигрәк тә татар халкы кебек күпне кичергән халыкның үз бәгыреннән чыккан талант ияләренә карый.

Әйе, үз язмышың китабы, шул ук вакытта халкың язмышын, аның газап-әрнүләрен сыйдырган китап! Аны сирәк талантлар гына тудыра ала!

Фәнисебезне дә без шундыйлар арасында күрәбез: нинди генә жанрларда язмасын (шигырь, поэма, җыр, хикәя-повестьлар, мәкаләләр һ.б.), асылда – Язмыш китабы ул! Фәнис – әнә шул Китапны тудыра алган, халыкның үз моңына әверелгән шагыйрь, әйе, халык баштан ук үзе дә сөеп, «маңлаеннан сыйпап үстергән» үз баласы, димәк, газаплар аша пәйгамбәрләр биеклегенә аша алган бәхетле иҗатчы!

Бүген инде Фәнисебез үзе бер легенда булып һәм туган җирендә тугры яры белән һәйкәлгә әверелгән рәвештә яши икән – бу да халкының аңа рәхмәте, мәхәббәте ич! Ышанабыз, Тукай әйткәнчә, «милләт яшәгәнчә яшәр» бу шагыйребез: аның гомере дә халык яшәвенә тоташ хәзер.


Сорау туа: сөйгән туган телендә язып, аның дәвамы булып, укучылар, мәктәп-авыллар, димәк, халкыбыз җанына шулай пәйгамбәрләр язмышы кебек береккән Сүз, кодрәт ияләре булырмы алда? Мең җәрәхәтле халкыбыз җаны яңа Фәнисләрне тудырырмы? Һәм туган телендә җырлап, сөя белгән милли Яр – Нурсөяләрне?

Әллә башка телләрдә язып, шәүлә генә булып яшәүче бәгъзеләр кебек халыкның «изге кан, изге сөт» тудырган иң мөкатдәс васыятеннән читләшербезме? Юк, мең кабат юк!

Фәнисебез кебек чын халык уллары, туган телебез сагында мәңгегә калачак шагыйрьләребез әнә шулай диячәк безгә!

Уйланыйк, дуслар!

**Рәдиф ГАТАШ,**
*Татарстанның халык шагыйре*



Фәнис Яруллин

# АНАМ ТЕЛЕ – ТЕЛЛӘР ТЕЛЕ

## Халыкка эндәшү

Халкым, сиңа нинди сыйфатлар хас,
Сабырлыкмы, әллә ярсумы?
Ярсу булсаң – ярсыр вакыт җитте,
Таләп итә һәрбер җан шуны.

Халкым, сиңа нинди сыйфатлар хас,
Түбәнлекме, әллә зурлыкмы?
Зур икәнсең – әйдә, тураеп бас,
Алып ташла иңнән хурлыкны.

Халкым, сиңа нинди сыйфатлар хас,
Турылыкмы, әллә ялганмы?
Туры булсаң – турылыгың белән
Турайтырга кирәк заманны.

Халкым, сиңа нинди сыйфатлар хас,
Мескенлекме, әллә хөрлекме?
Хөр икәнсең – дөнья белән сөйләш
Баштан салмый гына бүрекне.

## Язмышымны язам

Язмышымны язам ак кәгазьгә,
Язам аны гомрем буена.
Язмышымда заман гаме дә бар,
Язмышымда гавам уе да.

Язмышымны язам
Ак кәгазьгә,
Кара юллар ярылып калалар.
Кара юллар – кара эзләр безнең,
Кара юллар – канлы яралар.

Авыр еллар, ай-һай авыр еллар
Туры килде безнең буынга.
Кулыбызда богау булмаса да,
Муенчаклар булды муенда.

Ирегебез шушы муенчакның
Бавы кадәр иде нибары.
Ул бауның да очын вак түрәләр
Үзләренең кулына урады.

Әз-мәз генә читкә тайпылсак та,
Тынны буып баулар тартылды.
Коллар булмасак та, безнең башлар
Арзан бәяләргә сатылды.

Алучысы табылып тора анның –
Сат кына син бары, сат кына.
Әле дә күпләр кеше җаны сата
Үзенә бер ләззәт хакына.

Күңелләрдә һаман курку яши –
Кем сатар да безне, кем алыр?
Муендагы бавыбызның очы
Кемнең кулларына уралыр.

... Язмышымны язам, ә язмышым
Аерым түгел илдән, халыктан.
Гөнаһларны безнең яшерә-яшерә,
Җир арыган инде, ялыккан.

Язмышымны язам, язган саен
Ак кәгазьнең йөзе карала.
Кояшны да күптән таплар идек,
Буебыз гына җитми аңарга.

## Халык хәтере

Ни генә юк халык хәтерендә,
Хәтер чишмәсенә кагыл гына –
Әкият булып яки дастан булып
Вакыйгалар агылыр талгын гына.

Йә жыр булып ургып чыгар да ул
Күмеп китәр моңы, хисе белән.
Үткәннәрне ялгар бүгенгегә
Үзенең шундый сихри көче белән.

Бу хәтердә тагын ил тарихы,
Җир тарихы ята катлам-катлам:
Яхшыга да халык, яманга да
Үз хәтерендә һәрчак урын тапкан.

Саклаган ул кыз һәм улларының
Батырлыгын, бер дә киметмичә.
Әйләнгәннәр алар дастаннарга,
Телдән-телгә шулай күчә-күчә.

Яман эшләр хәтер төпкелендә
Ташка әверелгән, ята-ята.
Баласының кылган яманлыгын
Тирән яшерә бит ана-ата.

Халкыбызның хәтер мәйданы зур,
Урын җитә анда һәммәбезгә.
Яман эшләр, явыз эшләр белән
Пычратмаска кирәк аны безгә.

## Милләтем

Әй милләтем, милләтем –
Байлык тулы келәтем;
Шул келәткә ачкыч тап, дип,
Туган телне өйрәттең.

Келәтең бик хикмәтле,
Байлыкларың кыйммәтле,
Һәр байлыгың үзенә тартып
Җилкендерде йөрәкне.

Авыр узган юлларың,
Шуңар моңлы җырларың.
Тик җырларың өзелмәде,
Кысылса да тыннарың.

Гасырларның сыры бар
Синең йөздә, милләтем.
Матурларның нуры бар
Синең күздә, милләтем.

Үч тотмадың беркемгә –
Булдың олы йөрәкле.
Йөз чытмадың беркемгә –
Булдың изге ниятле.

Әй милләтем, милләтем,
Бар әле көч-куәтең.
Барасың иңеңә салып
Заманалар михнәтен,
Әй милләтем, милләтем.

## Анам теле

Татар теле – анам теле,
Иң борынгы бабам теле.
Буыннардан буыннарга
Күчеп килгән заман теле.

Ничә гасыр чарлангансың,
Матурайган, яңаргансың.
Халкыбызның күңеленнән
Җыр алгансың, моң алгансың.

Изелгәнсең, тапталгансың,
Пычратсалар – пакьләнгәнсең.
Милләтемнең үлмәс җанын
Син үзеңдә саклагансың.

Сиңа безнең язмыш сыйган,
Син – кайгы һәм шатлык теле.
Татарымны татар иткән
Беренче һәм актык теле.

Анам теле – телләр теле,
Милләтемнең бердәнбере.
Син булганга без дә исән,
Син булганга без дә тере.

## Горур булыйк

Мескенләнмик әле, горур булыйк,
Горур булуларга ни җитә!
Сокланабыз бит без бөркеткә дә,
Очса гына күктә, биектә.

Син бит, халкым, бөркет нәселеннән,
Һич килешми сиңа мескенлек.
Дошманнарың хөрмәт итсен, дисәң,
Горурлыгың итсен өстенлек.

Матур халык бит без, батыр халык,
Күпме изсәләр дә калыктык –
Милләт үлми гоурлыгы барда,
Горурлык ул – безнең таныклык.

Яшереп яткырмыйча йөрәкләрдә
Никадәрле гайрәт, көч барын –
Яшик җирдә бер дә кимсенмичә,
Башны биек тотып, татарым.

* * *

Шагыйрьлек тә пәйгамбәрлек кебек
Бирелә бары Алла тарафыннан.
Яза шагыйрь каурый-каләм алып
Фәрештәнең ап-ак канатыннан.

Шул каләмен күк нурына манып,
Ак кәгазьгә юллар тезә-тезә,
Халык күңеленә бара шагыйрь –
Мең-мең газапларга түзә-түзә.

* * *

Якын миңа, никтер, бик тә якын
Халкыбызның озын җырлары.
Шигырь язып яткан чакларда да
Сузып-сузып куям шуларны.

«Әллүки»не, «Зиләйлүк»не җырлап,
«Карурман»га барып керәмен.
Моңнар дөньясына кереп чумсам,
Әллә күктә, әллә җирдә мин.

Җырчылыгым шуның кадәр генә,
Җитеп җитми күпчак сулыш та.
Андый чакта күңел төпләреннән
Бәреп чыккан чишмә булыша.

Белмим, никтер, хәтер ярларына
«Уел»лары калган уелып.
Ялгыз чакта җанга терәк табам
Халкым җырларына сыенып.

Шигырьләргә ургып-ургып керә
Шул җырлардан килгән моң-тавыш.
Халкыбызның бер җырына сыйган
Шигырьләргә сыймас мең язмыш.

Шигырь язам, күңел төпкелендә
Дулкын-дулкын җырлар тирбәлә.
Шигырьләрем халык җырларыннан
Озак яшәү серен өйрәнә.

# ӘДИП ИҖАТЫНА БЕР КАРАШ

Татар әдәбияты – меңьеллык әдәби мирасы, бай язу культурасы, стиль үзенчәлекләре, жанрлар төрлелеге белән бөтен дөнья мәдәниятенә зур өлеш керткән әдәбият. Буыннар чылбырының ныклыгы, дәвамчылыкның көчлелеге нәтиҗәсендә ул безнең көннәргә кадәр килеп ирешә. Бай сүз сәнгатенең элек-электән тупланган тәҗрибәсе чагыштырмача яшьрәк әдипләрнең иҗатларына да йогынты ясады һәм әле дә ясап килә.

Менә шушы бай мираслы әдәбиятка санлы өлеш кертү юнәлешендә зур көч куйган әдипләр арасында Фәнис Яруллин да бар. Аның иҗатында Кол Галидән үк килә торган киң диапазонлы фикерләү куәсе, «Идегәй» эпосындагы масштаблылык, «Таһир-Зөһрә» кебек гыйшык дастаннарыннан күчкән кайнарлык, Г.Кандалыйдагы кебек үзенчәлекле шаянлык һәм шулар белән бергә халык авыз иҗатына хас тапкырлык, сагыну-сагышларны, милләтебезгә хас булган башка асыл сыйфатларын күрергә мөмкин.

Ф.Яруллинның беренче шигырьләре 1960 еллар башында матбугат битләрендә күренә башлый.

Аның шигърияте нигездә лирика тәшкил итә. Ф.Яруллин укучылар күңелен самими, шул ук вакытта фәлсәфи, тирән фикерле һәм эчкерсез әсәрләре белән яулап алды, шагыйрь буларак нәкъ менә шушы жанрда танылды. Бу турыда замандашы һәм каләмдәше Ф.Шәфигуллин хаклы рәвештә: «Фәнис Яруллин лирикасы гади лирика гына түгел. Аның лирикасында чиксез мәхәббәт җырлары да, тормыш матурлыгы өчен көрәш авазлары да, кешене, кеше акылының бөеклеген мәңгеләштерү мотивлары да бергә үрелеп бара», – дип билгеләп үтте.

Тормышының чәчәк аткан вакытында селкенә алмаслык хәлдә калу әдип күңелендә сәләтен эшкә җигә алмауга үкенү, төшенкелеккә бирелү мотивлары тудыра. Һәм бу аның шигырьләрендә дә чагылмый кала алмый. *«Мин дә шулай ярда калдым, тормыш өчен янган чагымда», «ә минем соң авыру газапларны, алып китәр нинди гөрелтек?»* кебек үз-үзенә биргән сораулары шагыйрьнең ул чордагы халәтен белдерә. Ләкин соңга табарак бу мотивлар сирәгәя. Аның шигырьләренең нигезендә шагыйрьне шагыйрь иткән – оптимистлык, рух көченә таянып биеклеккә күтәрелү омтылышы ята. Чөнки ул, үзенә Ф.Әмирхан, М.Җәлил, А.Алиш кебек олы шәхесләрне үрнәк итә («Төшә дә исемә» (1977), «Көч бирәсең миңа син, Муса» (1964)).

Ф.Яруллин иҗатының башлангыч чорыннан ук күңелендә кайнаган әрнү-сагышларын, хисләренең биеккә, матурлыкка омтылуын яшерми, чөнки белә: үз күңелеңне ачмый торып, башкаларныкына үтеп булмый. Ф.Яруллинның «Мин тормышка гашыйк» (1964) Һәм «Бакчалар бәскә төренә» (1967) җыентыкларына тупланган шигырьләренең күбесе авыл темасына багышланган. Аларда авыл табигатенә мәдхия җырлана: шагыйрь кошлар җырына соклана, икмәктә игенченең сулышын тоя, туган җирен «назга бай» анага тиңли, көзге җилләрнең «уйнап» йөргәнен күрә. Ләкин шул ук вакытта шагыйрь иҗатында барлыкка килгән сыйфат үзгәрешен дә күрми мөмкин түгел. «Кечкенәдән калган гадәт», «Сиртмәле кое монологы», «Йорт һәм оек», «Кеше туды» (1965) әсәрләре моның ачык мисалы булып тора. Шунысын да әйтергә кирәк: совет чорында аерым кешегә, әле аның кем буласын да белмәгән килеш, аңа мәдхия җырлау, гомумән, кыюлык иде. Шуңа күрә моннан кырык еллар элек язылган шигырь хәзер дә актуальлеген җуймый.

Ф.Яруллин иҗатында «туган як, туган авыл» темасы даими урын алып тора. Геройлар ераграк карый башлый һәм «авыл кешесе» образына яңа төсмерләр, буяулар өстәлә. Шагыйрьнең лирик герое туган якларын, аның табигатен сагынып яши, ул хакта сокланып, рухланып сөйли, үзенең кайгы-шатлыкларын, уңышларын туган ягы белән уртаклаша, яшәр өчен аңардан көч ала, аның үз җанына һәрвакыт кирәклеген тоя, тел ачкычы бирүе өчен рәхмәт укый, туган ягыннан иҗатына илһам, йөрәгенә җылылык, күңеленә яктылык җыя, туган ягы белән халкының аерылгысыз икәнен тасвирлый.

Ф.Яруллин лирикасында шактый урынны мәхәббәт темасы алып тора. Ул үзенең әүвәл иҗат ителгән шигырьләреннән алып соңгы шигыренә кадәр бу темага тугрылыклы калды. Нәкъ менә шушы факт, ягъни мәхәббәт шигырьләрен өзлексез язу аны яшьләр белән тоташтыручы күпер дә инде.

Яшьлеккә хас булганча, Ф.Яруллинның мәхәббәт темасына язылган беренче шигырьләрендә сөйгән ярын үзенә карату, аның мәхәббәтен яулап алу мотивлары өстенлек итә. Ул яраткан кешесе өчен теләсә нинди батырлыклар эшләргә сәләтле икәнен исбатлый: *«Йөрәгең кыя тау булса, / Ургырмын чишмә булып; / Агармын да агармын мин, / Тау төшкәнче убылып» («Әгәр йөрәгең таш булса...», 1962).*

Шагыйрь өчен ярату – яшәүнең бер мәгънәсе. Элеккерәк шигырьләрендә туган якка мәдхия җырлау күбрәк булса, тора-бара мәхәббәт темасы өстенлек ала. Шагыйрьнең күңел эволюциясе борма-борма юллар аша үтә. Бу, билгеле, табигый күренеш. Һәр шагыйрь – үзе яшәгән чорның баласы. Телиме-юкмы, тормышта булган кискен үзгәрешләр аның йөрәге аша уза.

Шагыйрьнең лирик герое заман сулышын йөрәге белән тоя, һәр үзгәрешне күңеленнән кичереп, борчылып яши. 1990 еллардан башланган үзгәрешләр Ф.Яруллин шигъриятенә дә үтеп керә. Фәлсәфи лирикасында ил язмышы торган саен күбрәк урын ала, чөнки аның язмышы, үзе язганча, «аерым түгел илдән, халыктан». Советлар Союзы таркалганнан соң, ил сәясәтенең нинди юнәлештә барачагын беркем дә әйтә алмады һәм хәзер дә әлеге мәсьәлә ачык булып кала бирә.

Авторның көн сулышын тоеп язган публицистик шигырьләре дә иҗатының шактый урынын алып тора. Россиянең кайбер төбәкләрендә сугышлар бара, бер сәбәпсезгә кешеләрнең гомерләре өзелә, урамнарда хәерчеләр көннән-көн арта. Бу проблемалар да шагыйрьне уйга сала һәм ул шушы күренешкә диагноз куярга тырыша, мәсьәләне чишү юлларын эзли.

Ф.Яруллинның гомеренең соңгы елларында язылган әсәрләре үткен реальлекләре белән аерылып тора. Ул үткәндәге тоталитар режимны яманлап, хәзерге системаны мактау юлына басмый, тормышта барган үзгәрешләргә объектив бәя бирергә тырыша. Сүз һәм вөҗдан иреге, дәүләтчелек һәм ил сәясәте турындагы шигырьләре татар халкының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге турында уйланулардан тора. Автор халкыбызны ирекле, дәүләтле, телле, азат һәм хөр итеп күрергә тели. Безнең яшьләребезнең башка милләт белән кушылулары (катнаш никах); бер-берсенә аяк чалу кебек аерым тискәре күренешләрнең күзәтелүе; үз моңыннан аерыла баруы; кайбер милләттәшләребезнең, илен, динен алмаштырып, татарлыктан ваз кичүләре; өстәгеләрдән куркып, аларның җырын җырларга тырышулар борчый аны.

Татар халкының киләчәге турында уйлану нәтиҗәсендә, Ф.Яруллин иҗатында ирек темасы да киң чагылыш таба. Суверенитет яулап алган вакытта язылган шигырьләрендә автор, Татарстан өчен шатланып: *«...Дөнья безнең шушы байрак аша / Омтылышны күрсен ireккә»*, – дип көр тавыш белән җырласа, 1993 елда язылган шигырьләрендә милләтнең өмете акланмавына ачына. Ф.Яруллин матур теләк-хыялларның гамәлгә ашмавының кайбер сәбәпләре итеп милләтнең вакытында берләшә алмавын, тиз арада тынычланып калуын күрсәтә.

Ничек кенә булмасын, Ф.Яруллин халкыбызның киләчәгенә ышаныч-өмет белән карый.

***

Соңгы елларда аеруча киң җәелгән башбаштаклык, әхлаксызлык күренешләре яшьләргә тискәре йогынты ясады: балаларның ата-анасына карата булган мөнәсәбәте дә төптән үзгәрде. Үзләрен кадерләп үстергән иң газиз кешеләр – әти-әниләр күп кенә балалар өчен кирәксезгә әверелде. Иҗатында гуманизмны калку яктырткан әдип буларак, поэзиясендә дә Ф.Яруллин бу проблеманы бөтен тулылыгы белән ача.

Ф.Яруллин дөньяда барган пычраклыкка, әхлаксызлыкка, намуссызлыкка карата көрәш коралы итеп көчле шигъри сүзне сайлый.

Ф.Яруллин иҗатында поэмалар да шактый күп урын алып тора. Лиро-эпик планда язылган «Нәсел агачы» (1989), «Ак үлем» (1990), «Коткарыгыз» (1990-1993) кебек әсәрләрдә чор проблемалары кискен рәвештә күтәрелә. Әйтик, Беренче Бөтендөнья сугышы, революция нәтиҗәсендә килеп туган гражданнар сугышы, аннары илебез халыкларын кара канга батырган Икенче Бөтендөнья сугышы, «Салкын сугыш», «Кайнар сугыш», Совет идеологиясен бар дөньяга җәелдерү максаты белән, астыртын рәвештә әле бер, әле икенче илгә басып керәләр. Шагыйрьнең поэмаларында сугышларның беркемгә дә җиңү китермәгәнлеге әйтелә. Мәсәлән, «Нәсел агачы» поэмасы дөньяда булган сугышларның берничәсен үз эченә ала. Лирик герой, зиратка барып, нәсел агачын эзли. Төп герой Зәйнәп әби образы аша автор җәмгыятьтә бервакытта да гади халыкка карата мәрхәмәт булмаганын, кемнеңдер ялгышлары аркасында тулы бер нәселнең юкка чыгуын тетрәндергеч итеп сурәтли. Зәйнәп әби Бөек Ватан сугышында җиде баласының алтысын югалта, бары тик Вәгыйз генә сугыштан исән кайта. Ләкин аны да туган авылында озак тотмыйлар, «тегендә» булган дип, каядыр алып китәләр. Вәгыйзнең улы Риф Зәйнәп әби тәрбиясендә кала. Риф өйләнә, аның Рамиз исемле улы туа. Армиядә ракета сынаганда, Риф тә авырый һәм гомере буе саулык җитмәүдән җәфалана. Рамиз исә сиксәненче еллар башында хакыйкый хәрби хезмәттә вафат була һәм аның җәсәде тимер табутта кайтарыла. Билгеле ки, табутны ачтырмыйлар. Ата-ана моны бик авыр кичерә. Алар улларын шәригать кануннары нигезендә соңгы юлга озатырга телиләр.

Рифнең үлүе белән Зәйнәп әбинең нәсел агачының соңгы ботагы да сына. Ул япа-ялгыз кала һәм күпмедер вакыттан соң, йөрәгендәге җәрәхәтләренә түзә алмыйча, вафат була.

Ф.Яруллинның әлеге поэмасы XX гасырның 90нчы елларында язылган булса да, анда күтәрелгән проблемалар бүгенге көндә актуаль. Әсәрдә бер нәселнең бетүен автор бөтен милләтебез язмышына кагылышлы рәвештә тасвирлый: сугышта иң асыл егетләр һәлак була, ә милләтне яшәтүче гаярь ир-егетләр бетсә, халкыбызның да киләчәге юк. Әсәр ахырында яңгыраган бала тавышы әлегә көчсез. Димәк, милләтнең әле бары тик еламсыраган тавышы гына ишетелә.

«Коткарыгыз» поэмасында да автор лирик герой язмышы аша сугыш чоры кешеләре кичергән газапларны тасвирлый. Җәмгыятькә кешеләрнең бары тик җиңү яулап алышырга гына кирәклеге, сугыштан соң аларның онытылуы, трагедиянең афәтләре, һаман баш очында кара болыт булып торуы сурәтләнә. Ватан өчен үз гомерләрен биргәннәрнең якыннары сугыштан соң да җәмгыять тарафыннан яклау тапмый, киресенчә, һәрдаим мохтаҗлыкка дучар ителә. Лирик герой атасына сугышта вафат булганнан соң бирелгән орденны сата, чөнки ул аларга бернинди юаныч китерми.

«Ак үлем» поэмасында Ф.Яруллин, беренчеләрдән булып, әдәбиятта, аерым алганда поэзиядә, наркомания темасын күтәрә. Поэма язылган вакытта (1990) әле бу афәт безнең илдә хәзерге кебек үк тамыр җәймәгән иде. Аның кешене нинди хәлгә төшерүен автор кыз бала язмышы аша тасвирлый. Әтисез, торыр урынсыз, мәхәббәттә алданган кыз юанычны наркотиклардан таба һәм упкынга тәгәрәвен үзе дә сизми кала. Алдагы поэмаларда күтәрелгән проблема бу поэмада да дәвам итә: гаделсезлек, җәмгыять тарафыннан яклау булмау, мәрхәмәтсезлек «Ак үлем»дә наркоманиягә илтүче юлларның берсе буларак күрсәтелә.

Гомумән, Ф.Яруллин поэмалары үткен фикер, җитлеккән акыл белән поэзиянең барлык мөмкинлекләрен кулланып язылган.

***

Ф.Яруллин иҗатының башлангыч чорында ук шигърият белән прозаны бергә алып бара. Гәрчә ул әүвәл шигырьләре белән танылса да, хикәяләр язуда да үзенчәлекле прозаик икәненраслый.

Эш шунда ки: ул беренче хикәяләреннән үк диярлек шул вакыттагы рәсми әдәби юнәлешкә бик үк туры килеп бетмәгән мәсьәләләр күтәрә башлый, һәм алга таба аның әлеге омтылышы көчәйгәннән-көчәя бара. Беренчедән, ул вакыйгалар агышын тормышның тышкы конфликтларына бәйләп түгел, ә геройлар күңелендә туган хис һәм кичерешләр белән төйнәп, җан киеренкелеге аша тормышның өске катламына чыгара. Икенчедән, иҗтимагый-социаль күренешләргә озак тукталмыйча, кешенең эчке дөньясы турында, гади язмышлы, шул ук вакытта рухи яктан бай персонажларны әсәренең геройлары итеп ала. Моның белән ул «кечкенә» кешеләрнең зур эшләргә, фәлсәфи фикер йөртергә, киң масштаблы тормыш төеннәрен чишәргә сәләтле икәнен күрсәтә.

Ф.Яруллин хикәяләрендә, аларның үзенчәлеген тәшкил итүче рәшә кебек, ерактан караганда – күренүче, якынрак килсәң, юкка чыгучы бер образ бар. Ул – Сагыш образы. Менә шушы вакыт-вакыт куерып, вакыт-вакыт сыегаеп алган сагыш әсәрнең үзәгенә әверелеп китә. Ул хикәянең буеннан-буена ниндидер музыкаль аһәң рәвешендә әкрен генә яңгырап тора.

Сагыш, шатлык, мәхәббәт кеше образында бирелмәсә дә, алар хикәяләрдәге геройларның үзара мөнәсәбәтен билгели, персонажларның психологиясен ачыша, композицион бөтенлек һәм хисләр гармониясен тудыра.

Ф.Яруллинның оптимистлыгы, яшь аралаш көлә белүе дә – талантының бер үзенчәлеге. Аерым әсәрләре тулаем юмористик планда чишелү, хикәянең үзәгенә көлкеле ситуация салыну һәм шушы вакыйганы ачучы геройларның характерлы үзенчәлекләрен бирүдә автор үзенең башлангыч иҗат чорында ук шактый уңышларга ирешә.

Әдәбиятта, сәнгатьтә йомшак итеп көлә белү – гаять кирәкле сыйфат. Көлү – кешенең җаны сәламәтлеген, яшәргә омтылышы барлыгын, башкаларның күңеленә яктылык орлыклары салырга теләвен һәм әйләнә-тирә мохиткә сәламәт рух бирүен белдерә.

Башка авторлардан аермалы буларак, Ф.Яруллин үз геройларының нәкъ менә эчке халәтенә, әсәрнең интонациясенә аеруча игътибар итә. Хикәядән хикәягә халәт аша тормыш чынбарлыгына якынаю, интонация аша тәэсир көчен арттыру мотивлары югарырак нотага күтәрелә.

Авторның күп кенә хикәяләрендә повестьлык материал ята. Тик Ф.Яруллин бу юлдан китми. Ул, вакыйгалар тыгызлыгын, вакыт аралыгын озынга сузмыйча, оста һәм урынлы кулланылган поэтик детальләр аша үз геройларын ача.

Бер үк вакытта әдипнең эстетик зәвыгы да үсә. Ул әдәбиятның чынбарлыкка мөнәсәбәтен һәм эчке төзелешен, аның формаларын, юнәлешләрен, метод-стильләрен торган саен тирәнрәк үзләштерә бара. Эстетик кичерешләрне, кешеләр арасында туган мөнәсәбәтләрне үтә нечкәлек белән бирергә тырыша.

Ф.Яруллин үзенең хикәяләренә тема сайлаганда, укучыны шаккатыру турында уйламый, киресенчә, гап-гади кешеләрнең гадәти эшләрен хисләр, кичерешләр, тетрәнүләр чылбырына тезеп, уйландырырлык, тәүбәгә килерлек әсәрләр иҗат итүне максат итеп куя.

Алда күренгәнчә, Ф.Яруллин – шигырьләр, хикәяләр, нәсерләр язу өлкәсендә танылган әдип. Әмма алар белән бергә автор укучыларның аңардан зуррак, тормышның тирәнрәк катламнарына үтеп керердәй, шигырь-хикәяләрендәге кебек образларга бай зур күләмле әсәр көткәнлеген дә яхшы аңлый. Һәм ул тиздән, үзенең күңелендә күптән йөрткән хыялын гамәлгә ашыру максатында, повесть яза башлый.

Әдип «Җилкәнне җилләр еккач» повестенда әлеге жанрның барлык мөмкинлекләреннән тулы файдалана. Сюжет гади генә башланып киткән кебек тоелса да, төп герой Фәниярны, ул үскән мохитне күпкырлы итеп күрсәтү өчен, вакыт

һәм чиксезлек дигән фәлсәфи категориягә таянып, әле үткәннәргә, әле бүгенгегә кайта, әле киләчәк чикләрен узып китә. Вакыт-вакыт әсәр хронологик тәртиптә бирелсә дә, шул рәвешле сурәтләү озакка сузылмый. Автор герой хәтерендәге берәр вакыйганы калкытып, үз персонажларын икенче яссылыкка күчереп куя. Бу – сюжетта стереотиплыктан һәм теманы ачуда бертөрлелектән котылу өчен эшләнә. Әсәр әледән-әле яңа компонентларга, төп геройларның характерлы сыйфатларын ачучы вакыйгаларга бай. Эчтәлеккә ныклап кереп киткәнче үк, үзәк геройның катлаулы язмыш кешесе икәне аңлашыла.

Әсәрнең рухы, интонациясе, вакыйгаларны төрле контрастлар аша сурәтләү күтәргән темасында, геройларның тышкы кыяфәте, портреты белән артык мавыкмыйча, аларны эчке дөньялары аша ачуда ачык чагылыш таба.

Ф.Яруллинның «Җилкәннәр...»ендә халыкның матур гореф-гадәтләре, кызыклы уеннары, каз өмәләре, егетләрне хәрби хезмәткә озатканда, пар ат җигеп, урам әйләнүләр кызыклы һәм тулы картинада сурәтләнә.

Халыкчанлык, фольклор элементлары татар этносының аерым сыйфатларын, аның менталитетын ачу юнәлешендә әсәр тукымасында оста һәм уңышлы чагылыш тапкан.

Әдип татар әдәбиятына яңа тип герой алып килде. Әлеге әсәрнең беренче тапкыр дөнья күрүенә утыз елдан артык вакыт үтсә дә, Фәнияр халык күңелендә яши. Бу әсәр мәктәп дәреслекләренә кертелде. Социаль-иҗтимагый формацияләрнең үзгәрүе, буыннар алмашыну да әлеге образны тоныкландыра алмады. Чөнки ул халкыбызның матур әхлакый сыйфатларын үзенә туплаган. Геройның һәм авторның күңелләре белән халыкка тоташуы – Фәниярны яшәүчән иткән сыйфат.

Ф.Яруллин 1985 елда «Кыйгак, кыйгак каз кычкыра» повестен яза. Бу әсәрен автор татар әдәбиятының традицион темасы булган хатын-кызлар язмышына багышлый һәм ул аны яңа яктан яктырта.

Әйтергә кирәк, сугыш елларында авылда яшәгән хатын-кызлар, аеруча күп балалы толлар хакында безнең татар әдәбиятында да, башка халыклар әдәбиятында да байтак язылды. Әгәр «Кыйгак, кыйгак каз кычкыра» шуларның бер төрдәше генә булса, аның кыйммәте әллә ни булмас иде. Автор повестенда авыр эш, газаплы тормыш нәтиҗәсендә хатын-кызның үзенә генә хас нәфислек, матурлык кебек сыйфатларын югалта бару нәтиҗәсендә бәхетсез кешегә әверелүен сурәтли. Бу ачы хакыйкать әсәрдә үзәк герой Сәхия образы аша ачыла.

Повестьта автор проблеманы социаль-иҗтимагый планга күчерсә дә, геройлар һәм җәмгыять арасындагы каршылыкны шактый тирән яшергән. Бу – шул чорда «эзоп теле» белән язарга мәҗбүр булу нәтиҗәсе.

Авторның алдан күрүчәнлеге әсәрдә аеруча киң чагыла. Повесть язылган чорда әле совет хатын-кызлары мәсьәләсе татар әдәбиятында бөтенләй мондый аспекттан чыгып каралмады. Алар, имеш, производствода тырыш, өлге алырлык эшче, өйдә бала-чагасын тәрбияләүдә үрнәк ана, иҗтимагый тормышта алдынгы карашлы гражданин. Ә бит хатын-кызларны ирләр белән «тигезләү» нәтиҗәсендә, аларның яшәештәге төп вазифалары, төп бурычлары нидән гыйбарәт булырга тиешлеге турында бөтенләй онытылды, уйлап та каралмады.

Ф.Яруллинның «Кайту» повестенда проблема ике яссылыкта, ягъни иҗтимагый-сәяси һәм вөҗдан яссылыгына куеп сурәтләнә. Повесть моңа кадәр татар әдәбиятында күтәрелмәгән теманы – җиңелү белмәс кебек күренгән хәрби кораллы көчләрнең эчтән таркалуын; шушы таркалу СССР империясенең җимерелүенә китерүен, җимерек хәрабәләр астында бик күп кешеләр язмышы калуын, кече милләтләрнең дә моңардан әллә ни отмавын тасвирлавы белән яңа һәм кызыклы. СССР хәрби көчләре илне тышкы дошманнардан саклау өчен төзелсә дә, чынлыкта аның вазифасы моның белән генә чикләнми. Ул – илне, халыкны йодрыкта тота торган көч. Һәм, әкренләп, менә шушы кысылган йодрык бушый башлый. Төп герой полковник Фәрит Шәйхиев – бар гомерен хәрби хезмәткә багышлаган һәм социализм идеяләренә бөтен барлыгы белән ышанган коммунист. Улын да үзе кебек тугрылыклы солдат итеп тәрбияләргә тырыша. Олегның ниндидер хәрби хезмәт үтәгәндә түгел, генералларга өй җиһазы ташыганда

һәлак булуы гына полковникны дөньяга эти кеше күзләре белән карарга мәҗбүр итә. Шушы фаҗига Ф.Шәйхиевнең йөрәгенә үткен хәнҗәр булып кадала. Менә шунда инде ул үзенең үткән гомере, кайсы армиягә хезмәт итүе, СССР державасының нинди сәясәт алып баруы турында уйлана.

Автор армиянең таркалуы югары чинлы хәрбиләрдән башлануын Олег фаҗигасе аша ача. Әсәрнең сюжеты беренче карашка гади булып күренсә дә, эчкәрәк керә барган саен, күтәрелгән проблемалар зурая, психологик киеренкелек көчәя. Автор оста хирург кебек эш итә: скальпеле, ягъни үзенең үткен каләме белән җәмгыятьнең «яман шешен кисеп ташларга» яки авыруга дөрес диагноз куярга тырыша.

Әсәрдәге вакыйгалар иҗтимагый-сәяси һәм әхлакый-этик яктан яктыртыла. Милләтләрне аерып карау, «өлкән туганнар»ның һәрвакыт «хаклы» булуы Олегның үлү сәбәпләрен ачарга тырышып йөргәндә ачык күренсә, милләтеннән, туган җиреннән ераклашу төп герой Ф.Шәйхиевнең үз-үзен югалтуга китерә. Дөрес, бу очракта бары тик бер аны гына гаепләп булмый. Чөнки ул совет чорындагы системага яраклашырга, анда ничектер яшәргә тиеш иде. Совет идеологиясе халыклар аңына интернационализм рухы сеңдерергә, бездә барлык халыклар тигез хокукка ия, дигән идеягә ышандырырга тырышты. Ф.Шәйхиев – шул системаның корбаны. Автор никадәр генә геройның гамәлләрен гаепләмәсен, ул аны әрнеп, хаталары өчен борчылып, шул ук вакытта яратып та тасвирлый. Әдип аның балачагын, ул үскән чорның авырлыкларын, әти-әнисенең кем икәнлеген ачу аша үз тамырыннан ераклашмаска чакыра. Авторның үз героена мондый теләктәшлеге, милләтебезнең асыл затлары кайчан да булса бер асылына кайтачагына ишарә буларак кабул ителә.

Әдип әсәрләре елны елга, чорны чорга бәйләп баручы чылбырны хәтерләтә. Чылбырның асылы – иҗтимагый-сәяси тормыштагы үзгәрешләрне хәтта яралгы хәлендә үк таба алуда һәм аларга тиешле бәясен биреп баруда. Бу аның шигырь-поэмаларында, драма-комедияләрендә, хикәя-повестьларында, публицистикасында һәм эсселарында ачык чагыла. Әдип үз геройлары аша әхлакый-этик проблемалар чишә, вакыт үзгәрү белән, әхлакый нормаларның какшый баруына борчыла.

Ф.Яруллинның һәр әсәрендә буйдан-буйга ак юл булып әхлаклылык ята. «Яралы язмышлар» повестенда бу аеруча калку чагыла. Балаларын чүплеккә ыргыткан аналар, ана назы күрми үскән балалар; шул ятимнәргә бераз булса да наз, җылылык бирергә тырышучы тәрбиячеләр; ятимнәрне уллыкка-кызлыкка алучы мәрхәмәтле кешеләр. Әсәрдә һәр герой, һәр персонаж шундый нечкәлек белән индивидуальләштерелгән – вакыйгадан вакыйгага күчкәнне сизмисең дә. Миңсылу апаның бабасы – олы мәгънәдә аксакал карт. Ул, оныгы сагышланып йөри башласа: «Әллә әниләреңә сөткә барып кайтасыңмы?» – дип, Миңсылуны әниләренә җибәрә. Монда картның киң күңеллелеге дә, оста тәрбияче дә, оныгын чиксез яратучы һәм аңа гел яхшылык эшләргә теләүче ныклы терәк тә икәнлеге ачык күренә. Картның капка төбендәге эскәмиядә көне буе оныгын көтеп утырулары, Миңсылу кайткач, өйгә керергә онытып, оныгы шатлыгына эчтән генә куанып утырулары, оныгының бәхеттән елмайган йөзе аеруча нечкәлек белән сурәтләнгән. Халык педагогикасы һәм әхлагы әсәрне буйдан-буйга сугарып бара.

Ф.Яруллинның «Яралы язмышлар»ы татар әдәбиятына яңа герой – Миңсылу апа образын алып килде. Күп кенә әдипләр үз геройларын производство алдынгылары арасыннан эзләгәндә, Ф.Яруллин иң зур батырлыкның әхлакый батырлык икәнен янә бер кат раслады. Бу «Җилкәннәр...»дә, «Кыйгак, кыйгак каз кычкыра» повестьларында шактый тирән чагылган иде инде. Әлеге әсәрендә автор, тагын да нечкәрәк психологик алымнар кулланып, проблеманың үзәгенәрәк керә алган. Җәмгыятьнең тотрыклы әхлакый кануннары булмавы, булганының да тормышта кулланыш тапмавы балаларны гына түгел, илнең үзен дә яклаучысыз һәм ятим итә. Әсәрнең үзәгендә шушы проблема ята.

Ф.Яруллин прозасында безнең җәмгыятебезнең барлык уңай һәм кимчелекле яклары яктыртыла. Интуитив тоемлау хисе көчле булганлыктан, ул шактый проблемаларны яралгы хәлендә үк тотып ала. Иҗтимагый процессларга үзенчә диагноз куя һәм шушы авырудан, күп кенә очракта, ничек котылу юлларын күрсәтә.

Гомумән алганда, Ф.Яруллин үзенең заманча идея-сәнгати эзләнүләре, оста каләме, туган телнең барлык байлыкларыннан урынлы файдалана белүе һәм һәр әсәрендә яңалыкка омтылышы белән татар прозасында барган ярыш хәрәкәтенә лаеклы өлеш кертте.

Безнең әдәбият тарихында балалар әдәбияты аерым карала. Дөрес, күп кенә шагыйрь һәм әдипләрнең иҗатында ул өлкәннәр өчен язылган әсәрләр белән тыгыз үрелеп бара һәм аларны аерып карау да җиңел түгел.

Ф.Яруллинның байтак әсәрләре шундый: аларны өлкәне, кечесе үзе өчен язылган дип укый. Мисалга «Җилкәннәр җилдә сынала», «Яралы язмышлар» повестьларын һәм бихисап шигырь һәм хикәяләрен әйтергә мөмкин. Ләкин әле бу әдип балалар өчен махсус атап әсәрләр язмаган дигән сүз түгел. Аның шигырьләр дәфтәрендә кечкенәләр һәм өлкәннәр өчен язылган шигырьләр гел аралашып бара. Күп шагыйрьләрнең иҗат башы балаларга багышланып, соңыннан зурлар өчен язуга күчкәне билгеле. Ф.Яруллинның әле сабыйларча, әле өлкәннәрчә фикер йөртүе нәрсәдән килә соң? Чөнки ул балаларның шаяру катнаш җитди фикерле алуына, аларның үзләренә хас фәлсәфәсе барлыгына, кыскасы, дөньяга уй аша, акыл аша карый алуына ышана.

Балачак кешене гомере буе озата бара. Шагыйрь һәм әдипләр кечкенә вакытта дөньяны ничек итеп күрүләрен: хыял-уйларын, шатлык-сагышларын, югалту табышларын үзләренең әсәрләрендә чагылдырмый калмый. Хәтер сукмакларына басып, балачакка кайту кеше күңелен нечкәртеп, сафландырып җибәрә. Кешенең балачагы нинди генә авырлыкларга туры килмәсен – ул барыбер күңелдә кайтарып булмаслык югалту буларак хәтерне яңартып тора. Ф.Яруллинның балалар өчен язылган шигырьләре, хикәя-повестьлары, әкиятләре укучыны балачагына кайтара, уйландыра; сагыш рәшәләренә алып кереп китә; күктәге салават күперләре буйлап йөгертә. Аның әкиятләре моңарчы таныш булмаган серле-тылсымлы дөньяга алып керә, шаян шигырьләре рәхәтләнеп көлдерә; тирән эчтәлекле хикәяләре дөньяның гыйбрәтле хәлләрен йөрәк аша уздырырга ярдәм итә. Балалар өчен язган әсәрләрендә дә ул җитди проблемалар күтәрә. Өлкәннәрдә була торган барлык сыйфатлар балаларда да бар. Автор тормышта килеп чыккан яки мөмкин булачак проблеманы, балалар җаны аша уздырып, үз әсәрләрендә чагылдыра.

Көлкеле шигырьләрендә дә ул, геройларының ниндидер ситуацияләрдән чыгу юлларын эзләгәндә, олыларга гына хас фикерләүләрен сурәтли, балалар гына куллана торган сүзләр таба.

Бала өчен ана – иң кадерле газиз зат. Шушы олы хисне, ата-анага булган мәхәббәтне бала күңеленә гомергә сеңдереп калдырырга теләгән әдип шигъриятендә тәрбияче ролен дә оста файдалана.

Гадәттә, балалар шаян телдә, кызыклы сюжетка корылган әсәрләрне ныграк ярата һәм аларны күңелләренә тизрәк сеңдерә. Ф.Яруллинның да шаян шигырьләре бар, ләкин алар тапталып беткән арзанлы мәзәккә корылмаган. Шаянлык, баланы көлдерү аның өчен үзмаксат түгел: әдип көлү аша берәр кимчелекне ача (ләкин физик кимчелекне түгел), начар гадәтнең аяныч хәлдә калдырырга мөмкин икәнен искәртә. Нәни герой һәр очракта диярлек ачышны үзе ясый. Авторның тел очында шаян сүз булса, әсәрнең нигезендә яшәү фәлсәфәсе ята.

Ф.Яруллин, сайлаган кыйбласына тугры калып, балаларга багышланган әсәрләрендә дә әхлак проблемаларын күтәрә. Аның «Солдат пәкесе» (1971), «Ак төнбоек» (1974), «Бүректәге бүре баласы» (1974), «Аксак Тимер» (1980), «Акбәкәл» (1984), «Кем син, абый?» (1994), «Акмаңгай» (1995) һәм башка хикәяләрендә әхлаксызлык, намуссызлык кебек категорияләр кискен тәнкыйтьләнә, үзенең вөҗданына тугры калган, хыянәт итмәгән яшүсмер бәхетле тормышка лаек була.

Автор геройларына исемне дә аларның характерына карап сайлый. Һәм геройларның исемнәре вакыйганың идеясен ачарга ярдәм итә. Мондый әсәрләрне зурлар да, кечкенәләр дә мавыгып укый.

Ф.Яруллинның балалар әдәбиятына караган «Язмышлар язылганда» (1972) һәм «Яшел утрау хуҗалары» (1974) дип исемләнгән ике повесте бар. Аларның икесендә

дә яшь геройларның тормышка мөстәкыйль булырга, үзләренең сорауларына үзләре җавап табарга, ягъни яшәү серләренә үз акыллары белән төшенәсе килүләре сурәтләнә.

«Яшел утрау хуҗалары» повестенда Үзле Яр авылында яшәүче малайлар язгы ташу вакытында барлыкка килгән утрау таба һәм аны җәй көне үзләре ял итәр өчен кулларыннан килгән кадәр тырыша. Балаларга өлкәннәр дә ярдәм итә. Тормыш куйган авырлыклар алдында куркып калмау, үз хезмәтләренең нәтиҗәсен күрү аларның характерларын үстерә, мөстәкыйльлеккә өйрәтә, күңелләрендә горурлык уята.

Бу әсәре белән әдип матурлыкны, яшәү, ял итү өчен уңайлыкларны үзең тудырганда гына җанга кадерле икәнен чын сәнгатькярләрчә балаларның психологиясен белеп, хыял-омтылышлары һәм кылган гамәлләре аша ачып бирә.

«Язмышлар язылганда» повестеның төп герое – Рәйхана. Ул безнең алда төрле яклап ачыла. Әсәрдә кыз тормышының бик катлаулы – формалашу һәм балалыктан үсмерлеккә күчү чоры тасвирлана. Рәйхана кечкенәдән классташларыннан тазарак булып үсә. Шуңа күрә ул, сигезенче сыйныфны тәмамлаганнан соң, мәктәпкә барудан баш тарта. Автор үзе дә яшь кешегә һөнәр сайлауда мөстәкыйльлек бирүне яклый һәм олыларның фикерләре белән килешмәвен кечкенә герое – Рәйхананың энесе – Фәйрүз образы аша әйттерә: «Өлкәннәр һәрвакыт үзләрен акыллыга санийлар. Безгә акыл өйрәтә. Безнең нинди булып үсәргә тиешлегебезне, хәтта нинди эш сайларга тиешлегебезне дә билгеләп куя».

Рәйхана повестьның ахырында үзенең күңеленә ятышлы эшне таба. Ул умартачылар курсы бетереп, колхозда умартачы булып эшли башлый. Әлбәттә, ул бу юлга эзләнүләр, ялгышулар аша килә. Нәкъ менә каршысына очраган авырлыкларны җиңеп чыга алуы, тормышта үз урынын дөрес табуы – аны шәхес буларак үстерә.

Г.Тукай традицияләрен дәвам итеп, балалар өчен матур-матур әкиятләр язучы татар әдипләре шактый. Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Р.Сверигин хаклы рәвештә: «Абдулла Алиш, Нәкый Исәнбәт, Әхмәт Фәйзиләр дә заманында бик матур әкиятләр иҗат иткәннәр иде. Һәм менә бүген шушы юнәлешнең бер тарафдары буларак – Фәнис Яруллин!» – дип яза. Аның «Зәңгәр күлдә Ай коена» (1990), «Өе балчык – иясе карчык», «Биюче бака» (1996) һәм «Серле дөнья» китапларында бик күп әкиятләр тупланган.

Ф.Яруллин әкиятләрендәге эчке рифмалар, вакыйгаларның үсә барып, герой рухы белән укучы җанының берләшүе әкиятләргә сихри күтәренкелек бирә. Ә инде әкият геройларының тышкы кыяфәтләрен сурәтләгәндә, образлылык өстенлек ала. Әдип үз әкиятләрендә тел белән ювелирларча эш итә. Бу сүзләрне раслау өчен, аның әкият китапларының теләсә кайсы битен ачып карау җитә. Аеруча әкиятләрнең башлам өлешенә зур игътибар бирә автор.

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: Фәнис Яруллинның үзенчәлеге тирәнтен фикер йөртә, гап-гади тоелган тормышыбызда бик күп матурлыклар, тирән фәлсәфәләр, катлаулы вакыйгалар яшеренеп ятуын чын рәссам каләме белән сурәтләп бирә белүдә. Ул гади кешеләрнең күңелләрендә йөреп тә, аларны тышка чыгара алмаган гыйбрәтле вакыйгаларны, тетрәндергеч язмышларны, беренче карашка сәер күренгән кешеләрне әсәрләренә герой итеп алып, аларның күңел төпләрендә яшеренеп яткан энҗеләрен күрсәтә һәм шулардан чын сәнгать әсәрләре тудырды. Аның иҗаты татар әдәбиятында үз урынын, үз укучысын тапты.

**Сәвия ХӘКИМОВА,**

*филология фәннәре кандидаты*

# ФӘНИС ЯРУЛЛИН ДРАМАТУРГИЯСЕНДӘ ӘХЛАК ТӘРБИЯСЕ

Ф.Яруллин драматургия жанрларында каләмен бераз соңлап сынап карады һәм бу өлкәдә дә шактый уңышлы иҗат итте. Ике дистәгә якын пьесасы аның талантлы драматург икәнен күрсәтте. Драматург үзе исән вакытта профессиональ театрлар тарафыннан унөч әсәре сәхнәгә куелды. Шунысы да игътибарга лаек: шагыйрь, язучы Фәнис Яруллин драма төренең барлык жанрларында да язды. Аның пьесалары арасында комедия, драма, трагедия жанрына караган әсәрләр дә бар.

Ф.Яруллинның драматургия өлкәсендәге иҗаты әлегә кадәр монографик аспектта фәнни эзләнүләр объекты буларак алынмады. Төрле елларда төрле газета-журналларда басылган аерым мәкаләләрдә авторның драма жанрларында басылган әсәрләренә кагылышлы фикерләр дөнья күрә, ләкин аларда, нигездә, драматургның сәхнәләштерелгән пьесаларындагы геройларны уйнаган артистларга, куючы режиссёрга, гомумән, бу әсәрләрне сәхнәгә менгергән теге яки бу театрның бүгенге халәтенә бәя бирелә.

Күзәтүләрдән күренгәнчә, Фәнис Яруллинның пьесалары бик аз өйрәнелгән. Шул сәбәпле, авторның драма жанрларында язылган әсәрләрен 1980-2000 еллар татар драматургиясе кысаларында анализлау, аларда әхлакый мәсьәләләр чагылышын ачыклау яңалык булып тора. Язучының пьесаларын бәяләү, иҗат эволюциясен күзәтү драматургның сүз сәнгатендә тоткан урынын билгеләргә мөмкинлек бирә.

Фәнис Яруллин беренче чиратта, комедияләр остасы буларак танылды. Сәхнә әдәбиятының төп таләпләренә буйсынып, автор әсәрләрендә замана өчен актуаль, тамашачыны кызыксындырырлык конфликт-каршылыкларны оста тотып ала, проблемаларны халкыбызның рухи-әхлакый кыйммәтләре яссылыгында хәл итә. Драматург Ф.Яруллин каләме тудырган геройлар арасында рухи-әхлакый кануннарны бозучы, аларны исәпкә алмаучы, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртучы, милләтебезнең һәммәбезгә мәгълүм язылмаган кануннарын санламыйча, матди байлыкка табынып яшәүче геройлар кискен тәнкыйть ителә. Автор идеалы буларак, күп пьесаларында тормыш тәҗрибәсе туплаган өлкән буын вәкилләре, катлаулы тормыш юлы узып та, гомумкешелек кыйммәтләрен җуймаган персонажлар бирелә. Драматургның балаларга багышланган әкият-драмаларында милләтебезнең киләчәген дөрес юнәлешләрдә, гомумкешелек, милли кыйммәтләр үрнәгендә тәрбияләү максаты куела. Ф.Яруллинның драма әсәрләренең теле дә, поэзиясе һәм прозасындагы кебек үк, юморга, сурәтләү чараларына бай, эмоциональ, йөгерек булуы белән игътибарны җәлеп итә.

Татар әдәбияты тарихының нигезендә торган гомумтөрки сүз сәнгатеннән башлап бүгенге көн әдәбиятына кадәр кеше бәхете мәсьәләсе үзәккә куела килә, әхлаклы, кешелекле мөнәсәбәтләр генә бәхетле тормышка нигез сала дигән фикер үткәрелә.

Әхлак – кешенең шәхес буларак ачылуына китергән аралашуның төп факторы. Җәмгыятьтә әхлак тәрбиясе бирү, билгеле бер чордагы әхлак идеалына туры китерелеп, кешеләрнең үз-үзләрен тотышын формалаштыруга юнәлдерелгән. Әхлак кешенең үз-үзен тотышын җәмгыять мәнфәгатьләре белән килештерүне, җәмгыятьнең тормыштагы идеал принциплары, таләпләре белән таныштыруны; әхлакый белемнәрнең инануларга әверелүен; тотрыклы уңай сыйфатлар, хисләр формалаштыруны күздә тота.

Сәнгать, шул исәптән әдәбият та, кешелек дөньясының рухи һәм әхлакый

кыйммәтләре чыганагы буларак кабул ителә. Сүз сәнгатендә әхлак мәсьәләсе чагылышы хакында фикер йөрткәндә, әлбәттә, әдәбиятның тәрбияви роле дигән мәсьәләгә кагылмыйча мөмкин түгел.

Рус галиме Д.С.Лихачёв кешенең рухи халәтенә һәм әхлагына әдәбиятның искиткеч йогынты ясавына аеруча туктала. Рус классик әдәбияты турында фикер йөрткәндә, галим аның халык, бигрәк тә зыялы катламы белән киң колачлы диалог булуына игътибар юнәлтеп, әдәби әсәр – «халыкның вөжданына мөрәҗәгать», дип ассызыклый. Бу турыда фикерен дәвам итеп, Д.Лихачёв кайбер заманнарда әдәбиятны «вөжданның бердәнбер тавышы, халыкның милли үзаңын билгели торган бердәнбер көч»[1], – дип тә өсти.

Ләкин, шуның белән бергә, әдәбиятның тәрбияви роле – шактый катлаулы мәсьәлә. Әлбәттә, сүз сәнгатенең укучыда әхлакый сыйфатлар тәрбияләве беркемдә дә бәхәс тудырмый. Ләкин, теге яки бу әсәрне өйрәнгәндә, әдәбиятның тәрбияви үзенчәлекләрен ни дәрәҗәдә ассызыклау мәсьәләсе бүгенге көндә дә актуаль булып тора. Әлеге мәсьәлә, беренче чиратта, әдәбиятны укыту методикасы өлкәсендә эшләүче галимнәр хезмәтләрендә чагылыш таба[2].

Татар әдәбияты үзенең эчке хасиятләре, максаты белән үк һәрвакыт әхлаклы булды. Борынгы һәм урта гасырлар әдәбиятындагыча, турыдан-туры дини әдәп-әхлак мәсьәләләренә багышланган яки милләтнең тәрәккыятен турыдан-туры гыйлем һәм тәрбия белән бәйләп сурәтләгән мәгърифәтчелек чоры әсәрләрендә генә түгел, гомумән, теләсә кайсы чорда иҗат ителгән һәм татар халкының яшәү рәвешен чагылдырган әсәрләрдә дә милли әдәп-әхлак мәсьәләләре алга куела яки вакыйгалар сөрешеннән, геройларның кылган эш-гамәлләренә мөнәсәбәттән аңлашыла. Тукайгача чор татар сүз сәнгатен, гомумән, әхлакый әдәбият дип атарга мөмкин булыр иде.

Ф.Яруллин драматургиягә килгән еллар – XX гасыр ахыры татар әдәбияты, шул исәптән драматургия дә каршылыклы әхлакый эзләнүләр чорына керә. XX йөзнең сиксәненче еллары азагында татар халкының милли үзаңы үсүгә бәйле үткән тарихы, олы шәхесләре белән кызыксыну, телне, гореф-гадәтләрне, традицияләрне саклау, гомумән, халыкның милләт буларак сакланышы мәсьәләсе алгы планга чыга. Шул нигездә сәхнә әдәбиятында да тема-проблемалар киңлеге, жанрлар төрлелеге күзәтелә. Тәҗрибәле әдипләр янәшәсендә драматургиягә килгән яңа буын авторлар иҗаты кыю эзләнүләргә, үзенчәлекле алымнарга, реалистик һәм романтик сурәтлелеккә, яңалыкка омтылыш белән характерлана. Театр сәнгате, гомумән, үзенең тамашачыга тәэсире белән аерылып тора. Замана әдәбияты үзәгендә дә гыйбрәтле язмышларны чагылдыру проблемасы тора, бу очракта да әсәрләр үзәгенә кеше образы куела.

Драма әсәрләре язу эшенә Фәнис Яруллин әдәбиятның поэзия һәм проза өлкәсендә тәҗрибә туплап, күпсанлы укучыларның, әдәби тәнкыйтьчеләрнең игътибарын яулап алганнан соң гына килә, дидек. Ул әдәбиятның әлеге төрендә дә гаять актив һәм нәтиҗәле иҗат итә. Драматург буларак язучыны таныткан «Әнә килә автомобиль» (1964) әсәреннән соң, 1980-2000 еллар арасында, Ф.Яруллинның бер-бер артлы «Бай эти» (1986), «Койрыксыз сандугач» (1987), «Сөембикә егет сайлый» (1989), «Бер күрешү – үзе бер гомер» (1996) пьесалары дөнья күрә. Әдип иҗатында драма төренең комедия жанры өстенлек ала. Көлү – сүз сәнгатендә тормыштагы җитешсез, кимчелекле якларга укучының игътибарын тарту, тәнкыйтьләү юлы аша җәмгыятьне төзәтү омтылышының үтемле бер формасы.

Ф.Яруллин драматургиясенең төп яңалыгы тормышчан конфликтка йөз тоту белән бәйле. Ул пьесаларында, каршылыкның бихисап төрләрен үзәккә алып тасвирлап, вакыйгаларның кызыклы, мавыктыргыч булуына, драматик хәрәкәтнең җанлы, тыгыз бирелүенә ирешә. Яшәешнең шактый якларына мөрәҗәгать итеп, тема һәм проблема киңлегенә омтыла.

«Әнә килә автомобиль», «Бай эти», «Койрыксыз сандугач» әсәрләрендә авторны яңа заман, сәяси үзгәрешләр нигезендә туган бүгенге җәмгыятьтә кешенең үз-үзен

[1] Лихачёв Д. Раздумья о России. – Санкт-Петербург, 1999. – С.377.

[2] Загидуллина Д. Нравственно-эстетическое воспитание на уроках татарской литературы при изучении лирических произведений (в V-VIII классах): Автореф. дис. на соискание уч. ст. канд. филол. наук. – Казань, 1993. – 22 с.

тоту мәсьәләсе борчый. Драматург буларак, автор тормыштагы әхлакый-психологик моментларны дөрес тоемлый һәм үтемле итеп тасвирлый. Әлеге проблемалар һәр драма әсәрендә теге яки бу ситуация, вакыйга эчендә күтәрелә һәм авторның дөньяга карашлары күзлегеннән хәл ителә.

Ф.Яруллин алда аталган пьесаларында аеруча рухи-әхлакый кануннарны онытып, матди байлык туплау турында гына уйлаучы, кешеләр исәбенә яшәргә күнеккән һәм физик яктан да, рухи яктан да башкаларны таптап үтә алырдай кешеләрне сурәтли, һәм шулар мисалында бу күренешнең җәмгыять, милләт киләчәге өчен никадәр куркыныч булуын ассызыклый, шул юнәлештә уйланырга этәрә. Шушы процессны чагылдыруда драматург кеше кичерешләрен тирән итеп сурәтли, психологик портрет остасы сыйфатында ачыла.

Драматург комедияләрендә төп темаларның берсе әхлакый кыйммәткә ия булган туганлык, дуслык төшенчәсе белән бәйле. Әсәрләрдәге яшь геройлар рухи яктан сынау алдына куелсалар, өлкән буын вәкилләре, нигездә, әхлакый кыйммәтләрне саклаучы, буыннар бәйләнешенә омтылучы шәхесләр буларак тәкъдим ителә.

Ф.Яруллин иҗатында туган җир өчен җаваплылык тойгысы көчле. «Сөембикә егет сайлый», «Кызлар күңеле – тирән сер», «Җимерелгән хыяллар», «Мәхәббәт яңгыры» пьесаларында авыл җирендә туып-үскән яшь кешенең шәхес буларак формалашуы, зур тормышка керү мәсьәләләре драматургның игътибар үзәгенә алына. Әлеге проблемаларны яшьлек, дуслык, мәхәббәт, хезмәткә мөнәсәбәт һ.б. сораулар белән тыгыз бәйләнештә тасвирлаган бу әсәрләрдә, үз хыялыңа ирешү өчен, вөҗдан һәм намусның нык, ихтыяр көченең таза булуы өстенә, җәмгыятьнең дә кешеләр турында кайгыртуы кирәк дигән фикер уздырыла.

«Җимерелгән хыяллар» драмасында әдип «Кызлар күңеле – тирән сер» пьесасының геройларын ун елдан соң очраштыра. Шул рәвешле, әлеге сәхнә әсәрләре Туфан Миңнуллинның «Миләүшәнең туган көне», «Дуслар җыелган җирдә», «Хушыгыз» әсәрләрен хәтерләтә. Т.Миңнуллинның киңрәк планда (трилогия кысаларында) сәнгать өлкәсендә эшләүче тулы бер буын язмышын тасвирлавы аша җәмәгатьчелектә зур яңгыраш тапкан әсәрләрендәге кебек, Ф.Яруллин геройлары да берничә ел эчендә танымаслык булып үзгәрә.

Пьесалардагы вакыйгаларның күпчелеген яшьләр образлары сурәтләнеше берләштерә. Аларның яшьлеге, киләчәге ил өчен катлаулы елларга туры килгән. Автор кеше өчен туган җире, туган туфрагы төшенчәсен, гади сүз генә булмыйча, аның кеше буларак формалашкан, дөньяга күзе ачылган җир дип тәкъдим итә. Әсәр геройлары төрле холыклы, төрле уй-хыяллар һәм максатлар белән яши. Ләкин Ф.Яруллин төп бер идея үткәрә: милли кыйммәтләрнең нигезен тәшкил иткән туган йортны, дуслык-туганлык хисләрен һәркем күңелендә сакларга тиеш. Ул язучы өчен әхлакый кыйммәтләрнең чыганагы, җирлеге буларак та кадерле.

Ф.Яруллин драмаларында замана афәтләрен фаш итүе аерым игътибарга лаек. Тормышта үз урынын эзләп, чор каршылыкларында буталып калган, төшенкелеккә бирелгән, эчүчелек сазлыгына баткан яисә һәртөр сынауларга ныклы ихтыяр көчен куеп, үз максатына омтылган, шул ук вакытта һәрберсе үз рухи дөньясы, характеры белән аерылып торган яшь геройлар тәкъдирен сурәтләгән «Язмышларны кабат язып булмый», «Гайрәтле кешеләр», «Бер күрешү – үзе бер гомер» әсәрләре шундыйлардан.

Фәнис Яруллин күпсанлы пьесаларында торгынлык елларының һәм үзгәртеп корулар дәверенең мөһим социаль-иҗтимагый, әхлакый һәм милли мәсьәләләрен шактый кыю, үзенчәлекле вакыйга-күренешләрдә, үз бәхетләрен таба алмый аптыраган, туганлык мөнәсәбәтләрендә булуга карамастан, каршылык-бәрелешләргә кергән геройлар аша чагылдырып, җәмгыятьтәге эчүчелек, бозыклык, икейөзлелек кебек әхлакый түбәнлекләрнең артуы, милли сыйфатларның кимүе өчен тирәнтен борчылуын белдереп яза. Тормыштагы рухи кыйммәтләрне бернинди акчага да сатып алып булмаганын кат-кат дәлилли.

Драматургның балалар өчен язылган пьесаларында әхлак мәсьәләсе чагылышы зур игътибарга лаек. Гомум әдәбият белән бергә, балалар әдәбияты да үзенең

формалашуыннан башлап бүгенге көнгә кадәр катлаулы озын юл уза, кешелек тәҗрибәсендә булган матур традицияләргә таянып, дәвер таләпләренә җавап бирә торган үзгәрешләр кичерә, һәр чорда тәрбия өлкәсендәге әһәмиятле мәсьәләләрне яктыртып килә.

Соңгы еллар сәхнә әдәбиятында балалар өчен язылган пьесалар фикер ачыклыгы, акцентларның төгәллеге, әхлакый мәсьәләләрнең кыю куелышы белән игътибарга лаек.

Балалар әдәбияты үсешенә өлеш керткән күпсанлы авторлар белән беррәттән, Ф.Яруллин да балаларга багышлап әсәрләр иҗат итте. Алда әйтелгәнчә, әдипнең иҗаты – күпкырлы һәм киң колачлы. Ул – алтмышынчы еллар башында әдәбиятка килгән каләмдәшләре арасында иң зур популярлык казанган һәм әле дә халык мәхәббәтен югалтмаган әдипләребезнең берсе. Нәтиҗәдә, балалар сәхнәсендә дә жанр ягыннан төрле-төрле әсәрләр язды. Аның әкият-пьесалары да бар. Мәсәлән, «Әмәк белән Шәмәк» (1985), «Шүрәлеләр каргышы» (1991-1993), «Каракның бүреге яна» (1992), «Бәхет ачкычы» (1993), «Ак яфрак» (1993), «Хәзинә» (1996) кебекләре балаларны татар халкының әхлак кануннары мисалында тәрбияләү ягыннан зур мәгънәгә ия. Һәр пьесада яхшылык белән яманлыкның бәрелеше, ялкаулык һәм алдау нәтиҗәсендә килеп чыккан күңелсезлекләр балаларны ышандырырлык итеп, эстетик зәвык белән сурәтләнгән. Әсәрләрдә өлкәннәргә хөрмәт, миһербанлык, горурлык, үз шәхесеңне яклый белү, туган җиргә, телгә хөрмәт һ.б. мәсьәләләр уңышлы алым-формаларда чагылдырыла.

Талантлы әдип драма әсәрләрендә, әкияти сюжет файдаланып, бик мөһим әхлак мәсьәләләрен хәл итә, аеруча да әкият-пьесалары нигезендә киләчәк буын хакында борчылу, аларны әхлаклы, кешелекле итеп тәрбияләү, милләтебезнең киләчәген бәхетле итеп күрергә теләү ята.

Әдипнең әкият-пьесаларының түбәндәге үзенчәлекләрен билгеләргә мөмкин:

– теле матур, шигъри, хәтта кайбер әсәрләрен иҗат иткәндә, драматург телнең бар байлыгын күрсәтергә омтылып яза сыман. Әсәрләрдә кулланылган төрле сурәтләү чаралары баланың фикерләү сәләтен үстерергә, тел байлыгының тирәнлегенә төшенергә ярдәм итә;

– алгы планга физик көч түгел, бәлки әхлаклылык, намуслылык, вөҗданлы булу кебек сыйфатлар куела;

– пьесаларында мәрхәмәт, шәфкать төшенчәләре дә зур урын алып тора. Ә кансызлык, бәгырьсезлек, куркаклык, алдау юлы белән максатка ирешү катгый рәвештә тәнкыйтьләнә;

– әкият-пьесалары чынбарлыкка якын булуы белән аерылып тора. Тузга язмаган куркыныч фантастика зәңгәр экраннарны яулаган чорда драматургның тормышчан әсәрләр язуы – бала күңеленә явызлык, кансызлык үтеп кермәсен дип тырышуы, явызлыкка яхшылыкны каршы куеп көрәшүе күңелдә якты хисләр уята;

– әсәрләрендә авторның катлаулы һәм гыйбрәтле язмышы да чагыла. Бу – лирик чигенешләрдә, геройларның кыен хәлдә калган вакыттагы кичерешләрендә ачык күренә.

Алда аталган пьесаларда билгеләнгәнчә, бары тик гомер буе намуслы, гадел яшәгән кешеләр генә теләкләренә ирешә һәм бәхетле була. Фәнис Яруллинның бөтен әкият-пьесалары да мәктәп программасына кертелеп укытылырга лаек. Алар анализлау өчен дә бик җиңел. Эчтәлекләре дә кызыклы, теле дә балаларга тиз аңлашыла һәм истә кала, дәрестән тыш чараларда да әлеге әсәрләрне яшь буын белән сәхнәләштерергә мөмкин. Балалар өчен язылган әсәрләре – бик кыйммәтле тәрбия дәресләре.

Алтмышынчы еллар башында иҗат юлына басып, сүз сәнгатенә үзенчәлекле, кабатланмас шигырьләре, проза әсәрләре белән килеп, укучылар игътибарын казанган әдип Фәнис Яруллин әдәби мирасын драматургия жанрлары кысаларында өйрәнеп, аерым нәтиҗәләргә килдек.

Драма төренең комедия, драма, трагедия жанрларында каләмен сынап караган драматург, беренче чиратта, комедияләр остасы буларак танылды. Югары эстетик зәвыкка сизгер күпкырлы талант иясе Ф.Яруллин, нинди генә жанрда язмасын, үз әсәрләрендә матурлыкны, камиллеккә омтылышны һәм рухи байлыкны иң зур

кыйммәтләрдән саный. Драма төренең төп таләпләренә буйсынып, автор замана өчен актуаль, тамашачыны кызыксындырырлык конфликт-каршылыкларны оста тотып ала, проблемаларны халкыбызның рухи-әхлакый кыйммәтләре яссылыгыннан хәл итә.

Драматург үз әсәрләренә вакыт һәм чиксезлек төшенчәләрен бик табигый рәвештә кертеп җибәрә. Бу аның пьесаларына киңлек, биеклек кенә өстәп калмый, персонажлар кабыгына төренгән фәлсәфи фикерләрне ачарга, аларны җирдән биеккәрәк күтәрергә ярдәм итә. Ф.Яруллин заманның характерлы проблемасы – әхлаксызлык, халкыбызга хас матур традицияләрнең – кешелеклелек, ата-ананы зурлау, үз гаебеңне тану кебек сыйфатларның югала баруы өчен борчыла.

Ф.Яруллин каләме белән тудырылган геройлар арасында рухи-әхлакый кануннарны бозучы, аларны исәпкә алмаучы, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәүче, милләтебезнең яшәү рәвешенә салынган рухи кыйммәтләрне санламыйча, матди байлыкларга табынып яшәүчеләр кискен тәнкыйть ителә, әхлакый кануннарны саклаучылар авторда симпатия уята. Драматург идеалы буларак, күпчелек әсәрләрдә олы буын кешеләре – зур тәҗрибә туплаган, катлаулы тормыш юлы узып та, гомумкешелек кыйммәтләрен югалтмаган геройлар бирелә.

Әдипнең балаларга багышланган әкият-пьесаларында милләтебезнең киләчәген дөрес юнәлешләрдә, гомумкешелек, милли кыйммәтләр үрнәгендә тәрбияләү максаты куела.

Балаларны аңлау, аларның психологиясен белеп эш итү Ф.Яруллин иҗатында көчле чагылыш таба. Аның нәниләр өчен язган әсәрләре укучыны балачагына кайтара, уйландыра, сагыш рәшәләренә алып кереп китә, күктәге салават күперләре буйлап йөгертә, серле-тылсымлы дөньяга алып керә, рәхәтләндереп көлдерә, дөньяның гыйбрәтле хәлләрен йөрәк аша уздырырга ярдәм итә. Шул ук вакытта җитди проблемалар да читтә калмый. Өлкәннәргә хас барлык сыйфатлар балаларда да бар. Автор тормышта килеп чыккан яки мөмкин булачак проблемаларны, балалар җаны аша уздырып, үз әсәрләрендә оста чагылдыра. Шаянлык, көлдерү аның өчен үзмаксат түгел. Драматург көлү аша берәр кимчелекне ача (физик түгел), начар гадәтнең аяныч хәлдә калдырачагын искәртә.

Балаларга атап язылган әкият-пьесалары башка авторларныкыннан иң элек шигъри телле, образлы сөйләмгә бай булуы белән аерылып тора.

Гомумән, Фәнис Яруллинның һәр драма әсәренең теле, поэзиясе һәм прозасы кебек үк, юморга, сурәтләү чараларына бай, эмоциональ, йөгерек. Әдип иҗатында табигать сурәте еш кулланыла һәм ул фон өчен генә түгел, ә матурлыкны кеше белән табигатьнең гармониясе аша сурәтләү өчен алына. Кеше һәм табигать бөтенлеге саега башлаган күңел байлыгын тулыландыра, аңа бизәкләр өсти.

Драматург Фәнис Яруллин, әхлаклылык сыйфатларын алгы планга чыгарып, тәнкыйди эчтәлекле әсәрләре белән укучылар күңелен яулады. Тормыштагы рухи кыйммәтләрне матди байлыклардан өстен күргән, милләтебезнең яшәеш каннуннарын саклап яшәүче геройлар аның эстетик идеалын тәшкил итә.

Ф.Яруллинның драма әсәрләренә нигезләнеп куелган спектакльләр Татарстан һәм Башкортстанның төрле театрларында уңыш казанды.

**Динара МИННЕКАЕВА**

# ЯШӘҮГӘ МӘДХИЯ ТУДЫРГАН ШӘХЕС

Миңа кайвакыт бик авыр хәлгә тарыган танышлар, дуслар килеп, эчләрен бушата. Тыңлап утырам да шунда ук күз алдыма танылган халык шагыйре, прозаик, драматург Фәнис Яруллин килеп баса. Без аның белән озак еллар очрашу-аралашу дәверендә шактый ук якын кешеләргә әверелгән идек. Сөйләшкән-көрәшкән саен, мин аның чын мәгънәсендә көчле рухлы, нык ихтыярлы, үз-үзен аямыйча, иҗат ялкынында янып яшәгән шәхес булуына инана идем. Без аның белән якташлар бит, Баулы районыннан. Үземнең районның хакимияте башлыгы вазифаларын башкарган чорда Фәнис абый белән аеруча тыгыз элемтәдә тордык. Иртәнге эш сәгатемне телефоннан яисә өенә кереп, аның белән сөйләшеп, хәлләрен белешеп, бүгенгә нинди планнар коруын, нинди ярдәм кирәклеген сорашып алудан башламасам, көнем хәерле булмас кебек тоела иде, дисәм дә ялгышмамдыр. Алай гына да түгел, ул миңа көндәлек хезмәтемдә өстәмә энергия, эшкә дәрт өсти сыман иде. Уйлап яки күз алдына китереп карасаң, искитмәле язмышка дучар ителгән кеше бит ул. Яшьли хезмәт, спорт белән шөгыльләнеп, баһадирдай буй җиткергән егетнең егерме яше тулып кына киткән чагында имгәнеп, бер кулын тотмыйча икенчесен күтәреп куярлык та егәре булмаган, гомерлеккә яткан урыныннан тора алмаслык хәлдә дә бер генә көнен дә бушка уздырмыйча иҗат итүе белән шаккатыра иде ул. Аяк-кулларыбыз исән-сау килеш, сәламәтлегебез ташып торган чакта да кайвакыт үземнең яисә якыннарымның, хезмәттәшләремнең өметсезлеккә бирелеп, башларыбызны кая куярга белмичә йөргән чакларыбыз юкмы әллә? Аның халәтендәгеләрнең йә эчүчелеккә бирелеп, йә үз-үзенә кул салып, якты дөньядан китеп бару очраклары да бар бит. Ә ул, районнарга, авылларга гына түгел, хәтта ерак чит илләргә чыгып, күргәннәрен китап итеп тасвирлардай әсәрләр иҗат итте. 73 яшенә кадәр яшәп, 50дән артык китапка тупланган роман, повесть, шигырьләр һәм башка жанрдагы әсәрләре белән татар милли дөньясын баеткан танылган шәхескә әверелде. Юкса, хезмәт юлын гап-гади электрик вазифасыннан башлаган, Кызылъяр авылының алты балалы, әтисе сугышта үлеп калган гади колхозчы улы иде.

...Беренче шигырьләр китабы дөнья күргәндә, аңа нибары 26 яшь булган. Өйдән чыкмыйча, кеше ярдәменнән башка бер генә эшен дә башкара алмаган егетнең урта мәктәпне, аннары Казан дәүләт университетын тәмамлый алырлык ихтыяр көчен югалтмавына республиканың мәктәп балалары да сокланып туймый. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр аның өеннән укытучылары белән берлектә килеп торган укучылар төркеме өзелмәде. Әсәрләренә, иҗатына мөкиббән китүчеләр булмаса, аны кызганып кына килергә атлыгып торучылар табылыр иде микән? Яки, мәсәлән, «Татнефть» кебек зур предприятиенең элекке генераль директоры Ринат Галиев, Әлмәт районы башлыгы булып эшләгән Ришат Әбүбәкеров кебек шәхесләр, дөнья мәшәкатьләре, тормыш хәлләре турында сөйләшү өчен генә әледән-әле аның өенә килеп йөрергә вакыт бүлә алыр идеме? Мондый олпат, бай предприятие яки нефтьчеләр башкаласы саналган Әлмәт районының бер язучының тормышын тәэмин итеп торырлык мөмкинлекләре юкмы? Кирәкле йомышын үтәп, савап җыярга булса, кешеләрен җибәреп тә эшли алалар бит алар! Юк, Фәнис Яруллин шикелле, көндәлек тормышны гына түгел, сәясәтен дә, район, ил яңалыкларын да, иҗат даирәсендәгеләрнең көнел халәтләрен дә тирәнтен тоемлап, юнәлеш бирә белгән халык шагыйре янына йөрәк кушуы, җан тартуы буенча килә андыйлар.



*Фәнис Яруллин яшь вакытта балык тотарга яраткан Ык буенда. Уңнан сулга: «Татнефть» АҖ генераль директоры Ринат Галиев, Баулы районы һәм шәһәре башлыгы Нурислам Хәбипов, Баулы районы һәм шәһәре судьясы Марсель Фәхриев, Баулы районы һәм шәһәре башлыгының беренче урынбасары Фоат Хасиятуллин, шагыйрь, прозаик һәм драматург Фәнис Яруллин. 1997 ел.*

Миңа да тәүлекнең теләсә кайсы вакытында телефоннан шалтыратырга мөмкин иде ул. Гаҗәпләнми идем, чөнки күп очракта аның үзенә йә хатыны Нурсөя апага медицина ярдәме кирәк була. Шундый хәлдәге кешене үзенең хәләл җефете дип кабул итеп, сыкранмыйча-зарланмыйча, 46 ел буена карап-тәрбия кылган бу ханымга да кергән саен сокланып чыга идем. «Нурсөя ул үзен күрсәтергә яратмый. Телевидениедән килсәләр дә, юк-бар сәбәп табып, күләгәдә калырга тырыша», – ди торган иде. Нурсөя ханым – үзе Марий Эл Республикасыннан. Абыйсы вафат булгач, кайтып килергә машина сорап мөрәҗәгать итте бервакыт. Илтеп куеп, икенче көнне барып алдык апаны, чөнки Фәнис абый аннан башка берни дә эшли алмый. «Ничә ел район башлыгы булып эшләп тә, кешелеклегеңне югалтмагансың, энем, рәхмәт инде сиңа», – дип, каршы алды ул, һәм алдагы көндә генә булып узган бер вакыйганы сөйләде: – «Ничек итеп үләргә микән? – дигән сорау белән бер кыз өйгә килде. – Агу эчеп үләсе килми, йоклаган җирдән уянмаслык итеп, тыныч кына китеп барырга иде», – ди. «Андый ансат үлемгә мин дә каршы килмәс идем. Алай гына үлеп булмый, көрәшергә кирәк, яшәү өчен көрәшергә кирәк», – дидем, ди. Әнә шулай, ул яткан килеш сиңа әллә нинди тормыш гыйбрәтләре, иртәгәсе көннең нинди булачагы турындагы кыйммәтле фикерләре белән уртаклаша, яшәүгә, тормышка өмет уятып, терелтеп җибәрә белә иде.

Республика җитәкчелеге турында да, район башлыклары турында да, кемнең кем булуына карамастан, үзенең гадел сүзен әйтеп язган көндәлекләре үзе үлгәч, хатыны Нурсөя апа ярдәме белән дөнья күрде. Исән чагында туган авылында музей ачу нияте белән яшәгән Фәнис Яруллинның теләген дә шушы ханым тормышка ашырды. Хәзер ул яшәгән йортка элмә такта куйдыру мәсьәләсен хәл итү уе белән йөри апабыз. Якташыбызның гаиләсен ярдәмнән ташламаска, һәрчак игътибар үзәгендә тотарга тырышабыз.

Бу урында тукталып, Фәнис абый белән Нурсөя апаның гаилә тормышы (дип әйтүе дә кыен!) турында яшь буын колагына нәрсә җиткерер идемме? Яратышып-сөешеп,

гомерлеккә бергә дип, йөзләгән сумнарга төшереп туйлар уздырган парларның берничә айдан гына түгел, хәтта берничә атнадан аерылышу очракларын ишеткән-күргән бар. Хәзерге заман яшьләрен бер калыптан сөреп, хурлап әйтәсем килми, алар арасында да төрлесе бар, әмма егетнең яки кызның машинасы, фатиры, гомумән, социаль тормышының хәлле булуы беренче урында торганын яшерергә мөмкинмени? Ә менә Нурсөя апа бит – Фәнис абыйга сәламәт чагында түгел, авыру хәлгә калгач, ризалык биреп кияүгә чыккан кеше. Аның байлыгына, дәрәҗәсенә, абруена кызыгып та түгел – ул чагында данга-танылуга ирешкән Фәнис Яруллин әле «тумаган» да булган. Тора-бара яулаган дәрәҗәле исемнәре, халык мәхәббәте барлыкка килгәч, нинди генә гайбәтләр, нинди генә кимсетелүләр, көнчелек кичереп тә сабырлыгын, ир хакын хаклый белү хисен югалтмаган ханымның эчке халәтен Фәнис абыйдан башка аңлаучы зат булмагандыр. Хәер, шагыйрьнең каләменә, нечкә кичерешләрне тоемлап язган әсәрләренә дә көнләшеп караучылар юк идеме әллә? Бу хакта ул шундый шигырь иҗат итте.

*Мин үземне бик бәхетле санайм,*
*Көнләшсен, әйдә, көнчелләр.*
*Тормышымда очрап торды минем*
*Киң күңелле, әйбәт кешеләр.*
*Кайвакытта очрап торсалар да,*
*Аяк чалулар, көнчелләр.*
*Өстен бул, дип, барлык вакыйгалардан*
*Кул суздылар әйбәт кешеләр.*
*Рәхмәт сезгә – яхшы кешеләр!*

Фәнис абыйны, Баулыга кайткан саен, китап укучылар, мәктәп балалары белән очрашуларга йөртә идек. Кайда гына булса да, кем белән генә очрашса да, аның төпле фикере, тирән мәгънәле киңәшләре бар иде. Мин үләм дип яшәмәде, һәрчак күңел күтәренкелеге, тормышка мәхәббәт хисләре белән гомер кичерде ул. Көндәлекләрендә язганнарына караганда, аның бер көнне дә бушка уздырмаганлыгы мәгълүм. Туганнарына гына түгел, бер белмәгән җиде ят кешеләргә дә ярдәм итеп, төрле мәшәкатьләрне чишәргә көч тапкан бу шәхеснең юклыгына әле дә күңел ышанмый. 2004 елда яңа фатирга күченгәннәр иде. «Шатландык, билгеле. Яңа, иркен, биек түшәмле йорттан фатир алырбыз дип уйламаган идек. Әмма шунысы читен: биредә телефон кертү мөмкинлеге юк икән. Сотовый телефон алырмын-алуын, ләкин бармаклар эшләмәгәч, аның номерларын җыю бик кыен миңа», – диде бервакыт очрашкач. Телефон номерын да җыя алмаган бармаклары белән йөзләгән шигырь, пьеса, проза әсәрләре, газета-журналлар өчен мәкаләләр ничек туды микән соң? Бу сорауга җавапны мин гомерем буена да таба алмам кебек.

Сагынабыз, юксынабыз, синең эчкерсезлегеңә, синдәге табигыйлеккә сокланабыз, Фәнис абый!

**Нурислам ХӘБИПОВ,**
*Татарстан Республикасы буенча*
*«Россельхознадзор» идарәсе җитәкчесе*

# АЛТЫ ТИЕНЛЕК ШАТЛЫК

Күренекле мәгърифәтче, мөгаллим Вәли Хаҗиевның 100 еллыгын уздырганда (ул 99 яше тулып узгач бакыйлыкка күчте), аның элеккеге укучысы булган Фәнис абый Яруллиннан да укытучысы турында сакланган истәлекләре белән уртаклашуын үтендек. Ул бик теләп ризалык бирде һәм мине өйләренә чакырды. Вәли Хаҗиевка бәйле мәгълүматларны шактый яздыргач, диктофонымны сүндереп куюны сорады. Шуннан соң без тормыш, яшьлек, яшь буынның дөньяга карашы, әдәби иҗат турында озаклап сөйләштек. Фәнис абый әдәбиятка үзенең ничек килүен, тәүге тәҗрибәләре – хикәя-шигырьләре язылу тарихын бәян итте. «Май төне» дип аталган беренче хикәяләр җыентыгының ни дәрәҗәдә кадерле булуын да искәртте. Бу санда шул хакта сөйләшербез.

«Олы яшьтәге мәктәп балалары өчен» дип тамгаланган, нибары 62 биттән гыйбарәт, бәясе 6 тиен торган әлеге мәҗмуга 1966 елда Татарстан китап нәшриятында 7 мең тираж белән дөнья күрә. Редакторы – Ләбибә Ихсанова. Китапка Фәнис Яруллинның берничә тематик юнәлешкә туплап өйрәнергә мөмкин булган 11 хикәясе кертелгән. Һәммәсенә аерым-аерым тукталыйк.

Җыентыкны ачып җибәргән «Көлү авазы» хикәясе үсмер укучыларның колхозга булышу вакыйгасы – печән өмәсен тасвирлауга багышлана. Зәкәрия белән Галия арасында мәхәббәт бөреләнә. Эскерткә йөк-йөк печән китерүче яшьләр шул рәвешле парлашып, үзара ярышып эшлиләр. Тик төп герой Зәкәрия, артык романтик-хыялыйлыгы аркасында, төннәрен уйланып ятып, иртән уяна алмыйча, һәрвакыт эшкә соңга кала. Атның иң ялкавы гына эләгә аңа, китергән печән йөкләре дә башкаларныкыннан кимрәк була. Ләкин егетне автор ялкаулыкта һич тә гаепләми – боларның һәммәсенә тәүге сөю хисләре сәбәпче икәнлеген сиздерә.

Үзләренең һәрчак артта «сөйрәлүе» хәйләкәр Галияне бик борчый. Әнисе уята алмыйча тилмергән Зәкәриянең беркөнне йокысын көлү авазы бүлә. Бакса – Галиясе, егетне узып, колхозның иң өлгер атын әләктереп, аны җигеп, йокы чүлмәген алырга килгән икән бит!

Шул рәвешле, иртәнге авыл өстендә саф сөюнең көр авазы яңгырый, Зәкәриянең психологик күңел халәтенә тормышка реаль караучы Галия йөгән сала.

Әкияти-фантастик башлангыч – Су анасын күрү вакыйгасына корылган «Су буенда» хикәясе дә мәхәббәт бөреләнүнең бер вариантын ача. Хикәяләүче мин, ягъни Котдус су буенда чәчләрен тарап утыручы су кызына тап була. Бар фантазиясен эшкә җигеп, бу әкият герое белән очраштым дигәндә генә, чәчләрен бер якка сыпырып җибәреп, йөзен ачкан кызый «әле көзен генә Казанга укырга китеп барган» «ябык кына бер нәрсә» – Зифа булып чыга. Котдус аның «баш әйләндергеч гүзәл» кызга әйләнүенә соклана. Ике арада ләззәтле сөю уты кабына.

Әлеге хикәяләрне үсмерлек-яшьлек мәхәббәте берләштерә, хисләр ташкынына бернинди каршылык юк. Ә менә «Ике очрашу» хикәясендә хәл бераз катлаулырак: Әнисә белән Барый арасындагы мөнәсәбәтләрнең якынаеп китүе өчен дүрт ел вакыт кирәк була.

«Тәүге мәхәббәт» хикәясе исә үкенү, үткәнне сагыну, сагыш хисләренә корыла. Бер-берсенә битараф булмаган төп герой – хикәяләүче Камил һәм Гөлшат су буена балык чистартырга төшәләр. Шулвакыт кызның пычагы әле бер атна элек кенә бозы киткән елгага төшеп чума. Егет, аны эзләргә дип, суга сикерә. Бик озак тырышса да, таба алмый. Салкын су үзенекен итә – Камил больницада икенче көнне генә аңына килә. Гөлшат аның хәлен белеп тора, тик Камил, терелеп чыгуга, коточкыч хәбәр ишетә: сөйгәне башка берәүгә кияүгә чыгарга җыенып ята. Ләкин моның сәбәбе аңлашылмый кала.

Ир уртасы булып җитешкән Камил, әнә шулай яшьлек хатирәләрен сагынып, пычак төшеп югалган су буенда йөри.

«Әлфирә» исемле хикәя тагын да аянычрак хәлләрне үз эченә ала. Аяклары йөрми торган, урынга беркетелгән Әлфирәгә Кәрим гашыйк була, уртак сөюләре билгесе дип, кул сәгате бүләк итә. Әлфирә сәгатьне тагарга ашыкмый, карават башына бәйләргә куша, чөнки бергә буласыларына, Кәримнең гарип кызны гомерлеккә хатыны итеп сайлаячагына ышанып бетми. Чыннан да, көннәрдән бер көнне Кәрим Әлфирә янына килүне туктата. Сәгать тә туктап кала. Үзе дә бу хикәяне язганда инде сигез ел урын өстендә яткан Фәнис Яруллин финалны оптимистик рухта тәмамлый: «Ул бит (сәгать. – Р.Х.) Әлфирә белән Кәримнең бары тик бәхетле минутларын гына исәпләргә тиеш. Ә хәзергә... Хәзергә эленеп торуы хәерле».

Юмор хисенә корылган, карт белән карчык арасындагы каршылыкны җиңелчә психологизм аша хәл иткән «Бушлай булгач» хикәясе дә, санаторийга картын озатканда, бер-бер кирәкле кешегә төртерсең, дип, биш сумлыкны кесәсенә салган карчык һәм әлеге акча язмышын ачып биргән «Бишлек» хикәясе дә безне елмайта. Ветеранга бирелергә тиешле бушлай даруларны алып кайтуын таләп итеп теңкәсенә тигән карчыгына Хисмәтулла карт сихәт чарасының иң зәһәр, иң әчесен юнәтә. Аны эчкән Зәйнәпбану үлемнән чак кала. «Врачлар укол ясап киткәч, йөрәк сикерүе басылды Зәйнәпбануның. Хисмәтулла картның да куанычы йөзенә чыкты, бөтерелеп кенә йөри. Шулай булмыйни, йөрәге генә түгел, холкы да ипләнеп китте карчыгының. Тик беләсе иде, күпкә микән?» – дип төгәлли «Бушка булгач» хикәясен Фәнис Яруллин.

«Конфликтсыз гына» хикәясе дә тормыш-көнкүрешнең иң вак мәсьәләләренең берсен үз эченә ала: яңа фатирга күчкән гаилә күршеләрендә тәүлек буе радио акыртучы саңгырау карчык белән каршылыкка керә. Гаилә башлыгы – хәйләкәр ир мәсьәләне бик җиңел хәл итә – «безгә синең музыкаң да җитә» сылтавы белән, үз радиоалгычын сатарга алып китә. «Алай кешенеке белән кештәкле булырга уйламагыз әле, сезнең өчен алган радио юк. ...Тыңламый торыгыз әле моннан соң», – дип озатып калган күрше карчыгы радио тавышын кысып куя. Шуны гына көткән күршеләр, кеше-кара күрмәгәндә, комиссионкадан әле сатылып өлгермәгән радиоалгычларын алып кайталар.

Шул рәвешле, алда телгә алынган өч хикәяне юмористик аһәң берләштерә.

Китапның исеменә чыккан «Май төне», хикәядән бигрәк, нәсер жанрына якын. Автор мәхәббәтнең күп төрләрен саный: кырларына гашыйк агроном, галәмне, йолдызларны үз иткән космонавт, алма чәчәкләрен, сөеп, кыраудан саклаучы карт бакчачы, сабыен өзелеп яраткан ана, ниһаять, үз ярын тапкан гашыйк йөрәк... Болар барысы да бер теләктә: ямьле май төне тыныч узып, илебез тынычлыкта уянсын иде!

Эчкерсез сөю, үкенечле мәхәббәт, яраткан ярың белән бәхетле яшәешкә өмет, тормыш-көнкүреш вак-төяге нигезендә туган юмор, лирик патриотизм кебек тематик юнәлешләрне гыйбрәтле язмышлар – Ана бәхете калыбы йомгаклый.

Моңа кадәр каенаналарына ачык йөз күрсәтмәгән, ирләрен – газиз ананың улларын да үз кубызларына гына биетеп торган ике килен Шәрифә карчык өенә көтмәгәндә кайтып төшә. «Ике килен-килендәш һәм бердәнбер каенана» хикәясе шулай башлана. Әбекәй янында очып кына йөргән, аның һәр теләген үтәргә әзер киленнәрнең чын йөзе соңрак ачыла: каенаналарын кайсысы үзләренә алырга тиеш дигән сорау-бәхәс туа. Китә берсен-берсе мыскыллау, тормыш шартларын хурлау, ә сәбәбе – әбидән бала карату икән бит. Икенче бүлмәдә инде сәфәр төенчеген әзерләгән Шәрифә карчык, оныкларына ясле ачылгач, үзенең ике айдан бер генә килененә дә кирәкмәячәге турындагы диалогны ишетә, төенчек идәнгә төшеп чишелеп китә... Әбинең күңел төене яңадан бер дә чишелмәслек булып төйнәлә.

«Май төне» җыентыгының нәкъ үзәгендә урын алган һәм без тукталачак соңгы – унберенче хикәя – «Ана чәчәкләр китерә». Әйдәгез, укып, бергәләп искә төшерик аны – «Әдипнең тәүге китабыннан...»

**Рамил ХАННАНОВ**



Фәнис
Яруллин

# АНА ЧӘЧӘКЛӘР КИТЕРӘ

хикәя

Кулына букет тотып, сестра килеп керде һәм вазадагы шиңгән чәчәкләрне яңалары белән алыштырды. Дару исләрен басып, палатага чапкан печән исе, каен җиләге исе таралды. Ринат, кызларның чәченнән сыйпагандай, йомшак кына итеп хәлсез бармакларын чәчәкләрнең нәфис таҗларына тидереп алды.

Менә бер ай инде Ринатка чәчәкләр китерәләр. Ә егетнең китерүчене күргәне юк әле. Чәчәкләр биреп назлаучы яхшы күңелле кеше кем соң ул? Егетнең туганнары да, әллә ни якын дуслары да юк әле бу шәһәрдә. Диплом алып эшкә килүенә дә беренче айлары гына иде. Һәм менә бу авыру аны кинәт аяктан екты.

Күпвакыт Ринатның хәле авыр була. Тирән чокырга төшкәндәй өнсез ятканда, ул чәчәкләрнең килүен сизми дә кала. Андый чакларда уттай кызган маңгаеннан кемнеңдер йомшак куллары сакланып кына сыйпавын тойгандай була. Ярым йомык керфекләре арасыннан әнисенең борчулы йөзен күргәндәй, ягымлы сүзләрен ишеткәндәй була. Әмма егет, аңына килеп, күзләрен ачканда, койкасы янындагы тумбочка өстендә әнә шушы чәчәкләр генә була.

Бүген аның хәле бераз яхшырган. Башының чатнавы да кимегән, күз карашлары да күңеллерәк. Чәчәкләр аңа яшел болыннарны, җиләкле аланнарны хәтерләтте. Бу кыйммәтле бүләкне китерүче яхшы күңелле кешене күрәсе килде. Ләкин вакыты тар булганмы, букетның иясе китеп барган иде.

Ә беркөнне Ринат иртәдән үк ниндидер сәер бер хис кичереп ятты. Ни өчендер бүген ул аны – чәчәкләр китерүчене күрер төсле иде. Авырулар белән көрешү сәгатен түземсезлек белән көтә башлады, һәм шул вакыт җиткәч, палатага кергән бер кешене ымсынып каршы ала торган булды. Менә чибәр генә бер кыз килеп керде. Бу кызның әле биредә күренгәне юк иде. Шуның өчендер, бәлки, ишек янында туктап калды да, кая борылырга белмичә, тезелеп торган койкаларга күз йөртеп чыкты.

Шулмы әллә дип уйлады Ринат, улдыр. Алай дисәң, ни өчен чәчкәләре юк? Бәлки, ул бүген чәчәкләр алырга өлгермәгәндер?

Егет шулай уйлап та бетерә алмады, әлеге кыз, эзләгән кешесен тапканга куанып, елмаеп җибәрде һәм тәрәзә янындагы койкага утырып торган күзлекле карт янына ашыкты.

Кинәт кенә Ринатка бик күңелсез булып китте, авыр сулап, мендәренә ауды да күзләрен йомды. Бик озак ятты ул шулай һәм кемдер килеп, одеялын рәтләп япканда да күзен ачмады. Бары тик кыштырдап торган коры куллар чуалган чәчләреннән сыйпап алгач кына, керфекләрен күтәрде. Аның каршында кечерәк буйлы бер карчык басып тора иде. Кинәт әнисен күргәндәй булды Ринат. Яше дә әнисе яшендә, буйга да әнисе сыман кечкенә, күзләре дә аныкы шикелле яратып һәм кызганып карыйлар, йөзенә сарган җыерчыклар бу карчыкка сабыр ягымлылык, шәфкатьлелек өстәп торалар.

Ринат, күз сирпеп, тумбочкасы өстенә карап алды. Анда әле вазага куелырга өлгермәгән кыр чәчәкләре ята иде.

Карчык, урындык алып, егетнең койкасы янына килеп утырды һәм, сумкасын тез өстенә куеп, күчтәнәчләрен бушата башлады. Менә ул чәчәкләр төшереп ясалган капкачлы агач савыт белән хуш исле яңа бал чыгарып куйды, һәм әле ни уйларга да белми тын гына карап яткан Ринат шулвакыт карчыкны танып алды. Барын да менә шушы чәчәкле савыт хәтерләтте аңа. Ул вакытта да аның кулында шушы савыт иде. Шуның белән ул бавырсаклар китергән булган. Ләкин өлгерә алмаган, улын операциягә салганнар. Соңыннан күчтәнәчләрен әби палатадагы авыруларга өләшкән иде. Ә бу савытны бавырсагы-ние белән Ринатның тумбочкасына куйган иде. Егетнең хәле авыр булды, күчтәнәчкә кагыла алмады. Шул көе торды да торды ул тумбочка өстендә.

...Аларның палатасына катлаулы операция ясалган бер егетне салдылар. Күренеп тора, егетнең хәле бик авыр. Иреннәрен сулы марля белән чылатып кына торалар. Ә ул иреннәренә китергән юеш марля кисәген комсызланып суыра. Сестраның: «Сиңа су эчәргә ярамый бит, түз инде, җаным, түз», – дип әйткән сүзләре дә аңа тәэсир итми. Егет су сорый, газаплана. Куллары белән кемнедер чакыра, кайвакыт саташып кычкыра башлый. Әнә шулай озак җәфаланып ятканнан соң онытылып киткәндәй була, ләкин озакка түгел. Ул тагын бәргәләнә, һава җитмәгәндәй, кипкән иреннәрен зур ачып, еш-еш сулый.

Таң алдыннан палата тәмам тынычланып, бар да саташулы авыр йокыга талды. Егетне саклап төн чыгарга килгән ябык гәүдәле карчык та йончыган иде, урындык артына маңгаен терәп, йокымсырап китте.

Ринат кына, берара күз йомып алганнан соң, сызлануга чыдый алмый уянып китте дә, ыңгырашмас өчен тешләрен кысып, коридордан төшкән яктылыкта тонык кына беленеп торган соры түшәмгә карап ята башлады.

Кинәт ул сискәнеп куйды. Чуендай кызган башын күршесендәге койкага таба борды. Әле көндез генә операция ясалган егет урыныннан сикереп торган иде. Егет чатнаган иреннәрен ялап, авыр итеп көрсенде. Үзенең көчсезлегеннән әрнү дә, авыртуны әз генә булса да басарга теләп, эчтәге януын тышка чыгару нияте дә бар иде аның бу хәрәкәтендә. Шулвакыт ул, әллә аңлап, әллә бары тик эчке бер сизенү нәтиҗәсендә, аяк очында яткан грелканы үрелеп алды һәм, иреннәрен ялый-ялый, грелка бөкесен борып

ачарга тотынды. Ринат егетнең ниятен аңлады: ул сусаган иреннәрен, янган эчен грелкадагы суны эчеп басарга, бер селтәнү белән, башына килгән авырлыкны, газапны алып ташларга тели. Бу минутта ул үзенең тормышын никадәр куркыныч астына куюын аңларлык түгел иде, әлбәттә. Ринат, үз-үзен белештермичә, ниндидер ят тавыш белән: «Ташла хәзер үк!» – дип кычкырып җибәрде. Ләкин үз хәле дә әлеге егетнекеннән яхшы түгел иде, тавышы хәлсез бер пышылдау булып кына ишетелде. Бу тавыш авыру егетне айныту түгел, аның йончыган әнисен уятырга да ярамады. Менә бөке борылып чыгачак, башка берәүләргә сусаганда иң тәмле, иң шифалы булган су егет йөрәгенә, аның тамырларына агу булып агылачак. Врачларның төн йокыларын калдырып күрсәткән хезмәтләре дә, кечкенәдән үк баласына багышлаган ана өметләре дә, егетнең таза чакта корган хыяллары да – барысы да юкка чыгачак. Су эчтәге яраның януын гына түгел, бәлки йөрәк ялкынын да, кеше тормышын да мәңгегә сүндерәчәк.

Ринат, үзенең көчсезлегенә, егеткә ярдәм итә алмавына ачуы килеп, бөтен гайрәте белән калкынды да, кровать кырыендагы урындыкны күтәреп алып, егетнең кулындагы грелкага китереп сукты. Грелка идәнгә төшен китте, һәм җылымса тәмсез су идән ярыклары буйлап акты.

Ничәнче ай инде урын өстендә яткан авыруга урындык күтәрерлек көч кайдан килгән? Моны Ринатның үзеннән сорасаң да әйтә алмас иде. Ә ул әнә аңын югалтып, урынына чалкан төшкән. Кешедә бит әллә нинди яшерен көч була. Ләкин ул көч кеше гомерендә бер генә кабатлана. Кеше мондый чакта әллә нинди эшләр эшләп ташлый. Куркыныч килгән вакытны башка китерергә дә мөмкин булмаган эшләр эшләнә...

Ә бүген шушы чәчәкле савытны танып алды Ринат. Аннары кечкенә генә гәүдәле, моңаеп карый торган соры күзле бу карчыкны да хәтерләде ул. Әллә ни күп сөйләшергә хәле юк иде, шулай да авыру күршесе турында кызыксынмый булдыра алмады. «Армиягә китте инде, – диде карчык, – хатлары килеп тора, исән-имин генә хезмәт итәм, дип әйткән».

...Һәр якшәмбе көн бу әби больницага чәчәкләр китерә. Аны инде сестралар да таный һәм күргән саен йөрәкләре әрнеп, ни әйтергә дә белми калалар. Ул китергән чәчәкләргә карап, Ринат шатлана алмый шул хәзер – инде мәңгегә күзен йомды. Чөнки ул чактагы төнге вакыйгадан соң, аның хәле авырайган иде. Аңа кабат операция ясарга туры килде, ләкин егет монысын күтәрә алмады. Ә карт ана һаман да чәчәкләр китерә, аңарга Ринатның инде күптән юк икәнлеген әйтергә кирәк тә бит. Мондый авыр хәбәр белән, ана кеше каршына чыгарга берәүнең дә әлегә йөрәге җитми шул.




*Татар милли хәрәкәте җитәкчеләреннән: Гаяз Исхакый, Садри Максуди, Фоат Туктаров. Үткән гасырның 20нче еллары.*

*Башкортстанның халык шагыйре Сәйфи Кудаш (1894-1993). Татар һәм башкорт телләрендә иҗат итеп, иң озын гомер кичергән әдип.*







*Журналист Венера Ихсанова һәм язучы Кояш Тимбикова «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә») журналы редакциясендә. Үткән гасырның 70нче еллары.*



*Бөек шәхесләр – Нәҗип Җиһанов, Мостай Кәрим, Әмирхан Еники Габдулла Тукайның Яңа Кырлайдагы музеенда. 1986 ел.*



*1937 елны Кави Нәҗмине Татарстан Язучылар берлеге рәисе вазифасыннан азат итәләр һәм кулга алалар. Шул елны төшерелгән рәсем.*



*Язучылар җыелышында. Сулдан уңга: Рафаэль Мостафин, Ил Саттаров, философ-галим (җәлилче Рәхим Саттарның улы), Нәби Дәүли, Мария Елизарова (Казанның Горький музее директоры). 1980 ел.*

*Сәхифәне* **Равил ФӘЙЗУЛЛИН** *әзерләде.*

# МИЛЛӘТ ГАЗИЗӘСЕ



Әгәр укучысы булмаса, шагыйрьләр дә онытыла. Җисеме исән булып, исеме хәтердән җуелган каләм әһелләре күпме! Милли мәгарифе юкка чыгып, халкы телдән язса, шагыйрьне шулай ук билгесезлектә гаип булу көтә. Ярый ла борынгы юнан, рум шагыйрьләрен бүген тәрҗемәдә укып рәхәтлек кичерәбез. Ләкин аларның да безгә килеп җитмәгәннәре бихисап.

Татар халкы, башка төркиләр кебек үк, борын-борыннан шагыйрьләргә бай булган. Безнең гаҗәп мәгънәле халык җырларын нindидер бер төркем, махсус җыелып, чыгармаган лабаса, алар – исемнәре халык хәтереннән җуелган аерым шагыйрьләрнең иҗаты. *«Чын шигырьгә әверелә шагыйрь, / Онытылу дигән үзәндә...»* Ләкин иҗатлары тарих төпкелләрендә югалып, безнең көннәргә бары тик исемнәре килеп җиткән шагыйрьләр дә бар. Мисыр мәмлүкләреннән Ибне Тәңребирденең 1343 елда вафат булган Галәветдин Таңбага турында язып калдырган сүзләре мәгълүм: «Ул – төрки шагыйрьләрнең иң бөекләреннән берсе. Кыпчак ирләреннән ялкынлы шигырьләр иҗат итүдә аның белән чагыштыра алырлык кешене мин белмим». Таңбаганы төрки шагыйрьләрдән иң бәхетсезләрнең берсе, дип тә өстәр идем. Ләкин өмет тә бар: Мисырның искиткеч бай архивларының берсендә, бәлки, аның шигырьләре дә сакланадыр?

М.Булгаковның җиңел кулы белән телгә кергән «Кульязмалар утта янмый» дигән тәгъбир, әлбәттә, чынбарлыкка туры килми. Үз тарихыбызга гына күз салыйк! Янгыннарда янган, илбасарларның табаны астында вәйран булган кульязмаларны, безгә килеп җитмәгән рухи мирасыбызны искә төшерсәң, имәнеп китәсең. Әле бит исән калганнары да XX гасырның имансыз фиргавеннәре кулында һәлак булды, кайсыларын, кяфер кулына эләкмәсен, дип, әби-бабаларыбыз үз каберләренә күмдерде. Меңьеллык татар әдәбияты, дип мактанырга яратабыз да, ләкин, уйлап баксаң, безгә бөртекләр генә килеп ирешкән ләбаса! Аларның да кадерен беләбезме әле? Без бит Хәтер белән бик үк дус халык түгел. Хәтеребез сай булганга, шушы көнгә калдык та инде.

Әстерхан якларында туып-үсеп, шунда гомер кичергән шагыйрәбез Газизә Сәмитованы (1862-1929) бөтенләй үк онытылган шәхес дип әйтеп булмыйдыр. Соңгы тапкыр 1992 елда нәшер ителгән «Татар поэзиясе антологиясе»нә аның әсәрләре дә кергән (үлгән елы гына ялгыш «1894 ел» дип күрсәтелгән). Аның әсәрләрен әдәбият тарихы турындагы хезмәтләрдә дә телгә алалар. Бердәнбер шигырьләр җыентыгы «Сайланма әсәрләр» исеме белән Татарстан китап нәшриятында 1965 елда дөнья күргән икән. Ә инде мең елга якын дәвердә иҗат иткән йөзләрчә шагыйрь-шогараны, язучыны, галим-голамәне бергә туплаган ике томлык «Әдипләребез» (2009) дигән саллы хезмәттә ул юк.

*Идел буе яшел таш;*
*– Ник елыйсың, яшь туташ?*
*– Мин еламый, кем еласын –*
*Үзем ятим, үзем яшь.*

Әлеге юллар татар шигъриятеннән азмы-күпме хәбәрдар кешегә таныштыр. Күзгә бер чалынса, колакка бер керсә, һич тә хәтердән җуелмый торган шигырь ул! Үзе гади, үзендә чыдап булмаслык моң. Андый шигырьләрне бөек шагыйрьләр генә яза ала. Юкка гына ул күп төбәкләрдә халык авыз иҗатына әверелмәгән.

*Идел буе яшел таш;*
*– Син елама, яшь туташ.*
*Еласаң, күзләрең бетәр,*
*Җырлап күңелең күтәр.*

Газизә Сәмитова кулъязмаларының безнең көннәргә килеп җитүе – бәхетле очраклылык, төптәнрәк уйласаң, үзе бер могҗиза ул. Узган гасырның утызынчы елларында СССР Фәннәр академиясенең Ленинградтагы Шәркыять институты хезмәткәрләре Әстерхан якларына экспедициягә чыга. Хәзерге Чернояр районына кергән Ташлыяр (урысча – Каменный Яр) авылында Газизә Сәмитованың туганнары аларга гарәп хәрефләре белән язылган егермедән артык (800 бит тирәсе) дәфтәр тапшыра. Шагыйрә гомере дәвамында көндәлекләр яза, юл хатирәләрен терки, төрле риваятьләр, мәкальләр, халык җырлары да читтә калмый. Ләкин иң кыйммәтлесе – аның шигырьләре. Әгәр дә Шәркыять институты хезмәткәрләренең юлы бу тарафларга төшмәсә, иске язуны контрреволюциягә тиңләгән иң әшәке репрессия елларында, җан асрау белән мәшгуль сугыш чорларында әлеге дәфтәрләр исән калыр идеме икән?! Меңләгән татар кулъязмаларының язмышын искә алсак, моңа төгәл җавап бирүе артык кыен булмас. Газизәнең туганнарына сокланмый мөмкин түгел, зирәклек күрсәтеп, дәфтәрләрне галимнәр кулына тапшырганнар бит!

Милли мирасыбыз өчен искиткеч байлык булса да, әлеге кулъязмалар озак еллар дәвамында беркем тарафыннан да җентекләп өйрәнелмәгән, һәмишә хәзерге хәрефләргә күчерелеп, бүгенге укучыларга тапшырылмаган. Заманында аны шагыйрәнең җияне (энесенең улы) Шамил Сәмитов укып чыккан, шигырьләрне, сайлап, җыентыкка туплаган. «Сайланма әсәрләр»нең дөнья күрүенә, Газизә шигырьләренең әдәби мирасыбызга әверелүенә без әнә шул туган җанлы, фидакяр Шамил кардәшкә бурычлыбыз.

Казан Газизә Сәмитовага шактый битараф булса да, якташлары аны һич тә онытмый. Аларның тырышлыгы белән кулъязмаларның күчерелмәсе Әстерханга кайтарылган, кирилл хәрефләренә күчерергә исә алар Казан галимнәреннән ярдәм көтә.

1992 елда, шагыйрәнең тууына 130 ел тулган вакытка тәңгәл китереп, Әстерхан өлкәсендә Татар мәдәнияте көннәре үткәрелә. Бәйрәм Ташлыярда да гөрләп уза, шагыйрәнең туып-үскән, яшәгән йортына истәлек тактасы кагыла, бераздан әлеге бинада музей оештыру эше дә башлана. Хәзер ул – Әстерхан дәүләт музей-тыюлыгының филиалы.

Шигырьләрен укып, Газизәнең тормышын азмы-күпме чамалап була. Аның гомер юлын тулырак ачыклар өчен, якташлары, туган-тумачалары да шактый эш башкарган.

Газизә 2нче гильдия сәүдәгәр Баһаветдин Сәмитов белән Шәһимә гаиләсендә бишенче бала булып дөньяга килә. Баһаветдин мануфактура белән сәүдә итә: тауар әйләнеше ун мең сум, саф табышы мең сум булган. Әйткәнемчә, аның кызыл кирпечтән салынган ике катлы йорты әле дә исән. Кибете, ул вакыттагы татар байларының гадәтенчә, беренче катта урнашкан. Архив документларыннан күренгәнчә, Баһаветдин анда үзе сәүдә иткән. Тора-бара, әлбәттә, балалары да булышкандыр, алар аның сигезәү: Шәһидә, Шәрифә, Гөлзифа, Асылбикә, Газизә, Сираҗетдин, Камалетдин, Насыйретдин.

Газизә, ул вакыттагы татар балаларының күпчелеге кебек, кече яшьтән укырга-язарга өйрәнә. Башлангыч белемне авылдагы кызлар мәдрәсәсендә ала, аннары гомере дәвамында үзлегеннән укый. Көндәлек дәфтәрләреннән күренгәнчә, ул гарәп, фарсы, урыс, калмык телләрен белгән. Урыс телен яхшы белүе табигый, Ташлыяр, нигезе салынганда ук, катнаш халыклы авыл була. XVIII гасыр ахырында бирегә урнашырга дип татарлар, урыслар, мукшылар, чувашлар төрле төбәкләрдән күчеп килә. Татарлар, асылда, Казан тирәсеннән күчәнә. Газизәнең дә нәсел җепләре Тәтеш якларына тоташа, дип фараз итәләр. Музей хезмәткәре Е.Герасимиди мәкаләсеннән күренгәнчә, XIX гасыр тикшеренүчесе Н.Ровинский болай язып калдырган: «Әлеге дүрт милләт (чуваш, мордва, урыс һәм татарлар) килешеп яши, иҗтимагый эшләрдә үзара урыс сүзләре белән аңлаша, ә гаиләләрендә һәр милләт милли телендә аралаша». Ул татарларның

үз милли киемнәрендә йөрүен, ә чувашлар белән мордваларның урысча киенүен дә теркәп калдырган. «Җир эшкәртүдә, мал асрауда бернинди аерма юк, ләкин татарлар атка мәхәббәтләре белән аерылып тора», – дип яза ул.

Газизә балачактан ук җырга-моңга һәвәслеге белән башкалардан үзгә була. Аның кече яшьтән үк гармун уйнавы турында да истәлекләр калган. Бераздан ул башына килгән шигъри юлларны дәфтәргә теркәп куя башлый. Иҗаты турыдан-туры халык җырларыннан, бәетләрдән, әкиятләрдән үсеп чыга. Алар саф татар телендә, гарәп-фарсы алынмалары гаять аз. Ул әлеге өслүпне үз заманындагы әдәбияттан хәбәрсез булганга түгел, ә махсус рәвештә, ана теленә ихлас мәхәббәттән, иҗатында мәсләк иткән. Без бүген Тукайны яңа татар әдәби теленә нигез салучы буларак хөрмәтлибез. Бу, бер яктан, дөрес, нәкъ менә Тукай шигърияттәге халыкчанлыкны (тәүге шигырьләрен госманлыча язганын да онытмыйк!) газета-журналлар, мәҗмугалар аша бөтен татар дөньясында байрак итеп күтәргән. Ләкин көндәлек матбугат оештырырга мөмкинлек юк заманнарда Идел-Уралда яшәгән халкыбызның саф ана телендә иҗат иткән Габделҗаббарларны, Газизәләрне дә онытмыйк. Әлеге ике шагыйребез арасындагы аваздашлыкны да күрми мөмкин түгел. *«Якутны күпме сарф итсәң, / Табып булмас бу вакытны»*, – дип теркәп куйган Газизә дә.

Аның көндәлек дәфтәрендә үз телебезгә кагылышлы мондый юллар бар: «И кардәшләр, и дуслар, сезләргә мәгълүм булсын, бу сүзләрдер сәхихе әхбар, ягъни бик дөрес сүз. Аларны бән сезгә язам. Борын заманда бер фәлән кеше ничә заманнар мәдрәсәдә укып йөргән һәм гыйлем булган, әмма әйткән:

*Укыдым фарсы, –*
*Фарсы бәңа торды каршы.*
*Янә укыдым гарәп,*
*Гарәп китте тарап,*
*Калдым артыннан карап.*
*Укыдым төрке, –*
*Җанымның күрке.*
*Һәм төркем барга,*
*Һәм күркем барга.*

Үз телеңдә укуның чын татар өчен җан күрке икәнлеген Газизә күптән әйтеп калдырган! Ләкин аның заманында, патша изүе никадәр көчле булмасын, безнең җан күркен, җан иркен бүгенгедәй бумаган. Газизәләр кебек, халык күңеленең иң нечкә кылларын тибрәтүчеләр табылырмы киләчәктә? Халыкның күңелендә тибрәнергә торган иң нечкә милли кыллар сакланырмы? Кистереп җавап бирүе кыен.

Күңел дөньясы бай булган кешегә үзенә тиң яр табу авыр. Бигрәк тә хыял дәрьясында җилкән күтәргән кыз балага. Аннары ул заманда ата-ана ихтыяры дигән нәрсә дә бар бит әле. «Татар поэзиясе антологиясе»ндә «1882 елны Газизәне көчләп диярлек кияүгә бирәләр», дип язсалар да, әлеге мәгълүмат хакыйкатькә бик үк туры килми, мөгаен. Кияүгә чыкканда, кызга инде егерме яшь була. Әлеге заманда кызларны бик иртә ярәшкәннәрен искә алсак, Газизә – тәмам өлгергән кыз. Аны туган авылыннан читкә кияүгә бирәләр. Күрәсең, булачак кияү Баһаветдин сәүдәгәр тауар-ишенең улы булгандыр. Документларда аның турында анык кына мәгълүмат юк. Исемен Гимдит дип бик үк төгәл язмаганнар ахрысы. Газизә хәләле белән унике ел яшәп, биш бала таба. Ләкин үзара мөнәсәбәтләр һич тә җайланмый. Иренең рухи яктан аңа иш булмавы шигырьләрендә чагылыш тапкан: *«Үсә-үсә кызлар зур була, / Үз тиңенә бармый хур була. / Сач бауларын кабып үкреп елый, / Буй кыз баралмаган тиңенә»*.

Газизә, әтисенә хат язып, туган йортына кайтаруны үтенә. Сәбәп җитди булгандыр, әтисе аңа балалары белән аерылып кайтырга рөхсәт бирә. Шагыйрәнең калган гомере туган авылы Ташлыярда үтә. Аның Казанга килеп китүе дә көндәлекләреннән билгеле. Биредә матбугат эше гамәлгә куелгач, татар башкаласы белән рухи бәйләнешләр тагын да ныгый, өйләренә Казан газета-журналлары даими килеп тора. Газизә кулы аша үткән, аның күз нурлары түгелгән «Аң» һәм «Сөембикә» журналлары бүген дә Ташлыярдагы музейны бизи.

Шагыйрәнең Истанбулга сәфәре дә безгә билгеле. Андагы мәһабәт мәчетләрнең берсендә намаз укуын ул, горурланып, көндәлегенә теркәп куйган. Әлеге сәфәр тәэсирендә язылган шигырьләре булуы да ихтимал. Чөнки совет заманында аның ише язмалар берничек тә «сайланма әсәрләр» арасына керә алмый иде. Кульязмалары дөньяга чыкса, безнең өчен Газизә Сәмитованың иҗаты кителмәгән яклары белән дә ачылырга мөмкин.

Күпме югалтуларны кичереп тә, могҗиза белән сакланып калган мирасыбызга без җитәрлек игътибар итмибез, барларга, бергә тупларга әллә ялкаулыгыбыз, әллә мәнсезлегебез комачаулый. Шуңа да чит-ятлар безнең күренекле әдәбият-сәнгать әһелләрен инде үзләренеке дип игълан итә, ә гасырлар дәвамында кыйммәтен җуймаган әсәрләрне һич кыенсынмыйча үзләштерәләр. XIX гасырда, колониаль шартларда, ягъни бернинди көндәлек матбугатка хөкүмәт рөхсәт бирмәгән заманда, шигырь мәҗмугасын нәшер итү хыялга да кермәгән дәвердә! – мөселман дөньясының бер кыйсеме – татарлар арасында шундый шигъри куәткә ия хатын-кызның пәйда булуы үзе үк искитмәле күренеш бит югыйсә. Дөрес, күңеленә тулышкан хисләрне шигъри күңелле кеше кәгазьгә түкмичә булдыра алмыйдыр. Ләкин бит Газизә кайбер шигырьләрендә укучысына турыдан-туры эндәшә! Хәтта вакыт-вакыт вәгазь укудан да тайчанып тормый. Димәк, ул сүзенең халыкка барып җитәсен тәгаен белгән! Мондый ышаныч булсын өчен, милләтеңнең мәгариф системасы мөкәммәл булу зарур. Мәктәп-мәдрәсәләр үзара даими бәйләнештә торган. Газизәнең дә шигырьләре, шәкерт дәфтәрләренә күчерелеп, кулдан-кулга, телдән-телгә бар татар дөньясына таралгандыр, мөгаен. *«Каләм үгрән! – каләм изгегә тартыр, / Каләм белгән кешенең бәхете артыр»,* – дип, ул юкка гына язмаган. Мондый бәхет аңа тормыш авырлыкларын җиңәргә, хөр күңелле, ирек сөючән кеше булып калырга ярдәм иткәндер дә...

Ә бит кайгы, сагышлар аны гомере дәвамында эзәрлекләгән. Ир балаларының яшьли үлеме хакындагы шигъри юлларын тетрәнмичә укып булмый. Югалтулар, фаҗигаләр генә шагыйрьне шигърияттнең буй җитмәс биеклегенә күтәрә, күрәсең. Ә иң зур фаҗига – гомернең заялыгы, тормышның фанилыгы. Шагыйрә барлык шигырендә дип әйтерлек яшәешнең мәгънәсезлеге хакында уйлап бәргәләнә.

Былтыр Әстерханда Газизә Сәмитованың татар һәм урыс телләрендә шигырьләрен туплаган «Ташлыярский соловей» дигән җыентык дөнья күрде. Урыс теленә шигырьләрне Ирина Левитан тәрҗемә иткән. Һәм иң гаҗәбе шул: әлеге игелекле эшнең башында Ахтуба һәм Енотай епископы Антоний торган икән. Китаптагы кереш сүзләр арасында аның исеменнән дә язма бар. Ун ел элгәре Газизә яшәгән йорт каршына чиркәү салып куйганнар, епископның «күрше» белән кызыксынуы табигый. Бу очракта андый кызыксыну менә шундый уңай нәтиҗә биргән.

Татар милли-мәдәни мохтарияте рәисе Әнвәр Алмаев тырышлыгы белән, Әстерханда Газизә Сәмитованың тууына 155 ел тулу мәрасимен дә билгеләп уздылар. Элек татарлар гына яшәгән Тияктә урнашкан Габдулла Тукай исемендәге мәктәптә фәнни-гамәли конференция үтте. Шагыйрә турында нотыклар сөйләнде, яңа тәрҗемәләр яңгырады, хәтта Газизә сүзләренә урыс телендә җырлар да ишеттек. Шагыйрәнең исеме онытылмый, чит телдә булса да, яңа укучыларын таба.

Әлеге җыенга өлкәнең төрле төбәкләреннән татар теле һәм әдәбияты укытучылары да килгән иде. Алар Татарстандагы вазгыять белән кызыксына, бездәге татар теленә каршы барган һөҗүм турында да хәбәрдар. «Сездәге җил исүе дә безгә давыл булып килеп ирешә», – диде Дәрыйга ханым Мамлеева. Мин аңа Газизә сүзләре белән җавап бирдем:

*Иртә була, кич тә була –*
*Гомер шулай үтәдер.*
*Дөнья ничек әйләнә дип,*
*Бәнем исем китәдер.*

Башкача мин ни дип әйтә ала идем соң?

**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА**

# ИСХАКЫЙНЫҢ ГЕРОЙЛАР ЭВОЛЮЦИЯСЕ

## (МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК ЧОРЫ )



Татар халкының бөек әдибе Гаяз Исхакыйның 1917 елгы Октябрь инкыйлабына кадәрге иҗатын язучының «дөньяга карашы, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә мөнәсәбәте, әдәби-эстетик зәвыгы, сәнгатьчә фикерләве, әсәрләренең идея юнәлеше, язу стиле» ягыннан фәндә өч чорга бүлеп тикшерү гадәткә кергән:

– Мәгърифәтчелек дәвере (1897-1904);

– «Таңчы»лык дәвере (1905-1911);

– Милләтчелек дәвере (1912-1918) *[14: 319]*.

Аңлашыла ки, һәр чор иҗатының үзәгендә язучының шушы дәвердәге иҗтимагый, әдәби-эстетик карашларын гәүдәләндергән үзенчәлекле герой тора. Мәсәлән, Гаяз Исхакыйның беренче проза әсәрләре авторның мәгърифәтчелек идеалын чагылдырган герой һәм аны борчыган мәсьәләләр тирәсендә формалаша. Шуны әйтергә кирәк: бу герой статик фигура түгел. Әдипнең карашлары үскән саен, ул да сыйфат үзгәрешләре кичерә, аның фикер офыклары киңәя, чынбарлыкка мөнәсәбәте катлаулана. Гаяз Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» (1897), «Кәләпүшче кыз» (1897), «Бай углы» (1899), «Өч хатын берлән тормыш» (1900), «Ике йөз елдан соң инкыйраз» (1904) кебек әсәрләре уртак иҗат ысулы – мәгърифәтчелек реализмы кысаларында язылсалар да, алардагы төп каһарманнар үзләренең дөньяга карашлары, күтәргән мәсьәләләренең киңлеге, җәмгыятьне камилләштерү юллары турындагы фикерләре, хәтта ки эстетик идеаллары нисбәтеннән бер-берсеннән шактый аерылалар.

Әдәбият галиме Д.Заһидуллина билгеләвенчә, «татар әдәбиятында мәгърифәтчелек реализмы агымы укыту ысуллары хакында бәхәсләшеп мәйданга чыкты» *[1: 155]*. Филология фәннәре докторы Ф.Хатипов исә укыту мәсьәләләрен әдәбиятта сурәтләүнең ике юнәлештә баруын ассызыклый: «беренчесе – искечә сабак бирүне, ысулы кадимне тәнкыйтьләү; икенчесе – яңача белем бирүнең, ысулы җәдитнең кирәклеген, зарурлыгын раслау» *[15: 273]*. Әлеге фикерләрне Гаяз Исхакыйның беренче әсәре – «Тәгаллемдә сәгадәт яки гыйлем үгрәнүдә рәхәт гомер» (1897) хикәясенә карата да тулаем кабатларга мөмкин.

Академик М.Хәсәнов күрсәтүенчә, «үзенең темасы белән дә, эчтәлеге ягыннан да бу әсәр әле алда торган сәяси тетрәнүләргә ишарә ясамый, татар тормышында булачак җитди үзгәрешләргә нигез бирми шикелле. <…>. Әсәрдә иҗтимагый тәртипләргә кизәнү дә, социаль проблемалар да, сәяси нәтиҗәләр дә юк. Башлап язучы бары тик аң-белем, тәрбия мәсьәләләрен генә күтәреп чыга» *[8: 15]*.

Хикәянең сюжеты катлаулы түгел. Хәлим, туган авылында мәдрәсә тәмамлагач, укуын Казанда дәвам итәргә тели. Әнисе Фатыйма һәм укымышлы затлар – Кәрим абзый белән Әсма абыстай ярдәмендә, ул әтисе Габдерахманның каршылыгын җиңеп чыгып, аңардан гыйлем эстәргә китәргә рөхсәт ала, хәтта ки әтисе улына ун сум акчасын да кызганмый.

Казан мәдрәсәсендә Хәлим яхшы укуы, тәрбиялелеге белән мөгаллимнәре арасында ихтирам казана. Беренче елны ул акча түләп белем алса, икенчесендә түләүдән азат ителә һәм тиздән үзе үк Казанның бер мәктәбенә мөгаллим булып урнаша. Мәдрәсә җитәкчесе Рәшит бай хәйләсе белән аның кызы Маһирәгә өйләнүдән баш тартып, Габдерәхим мөгаллим кызы Галия белән никахка керә һәм бәхетле гаилә кора *[8: 31-49]*.

Шулай итеп, «әсәрнең төп мәгънәсе – кешенең гаиләдә, тормышта бәхетле булуы өчен зарури шарт – уку, белемле, тәрбияле булу» *[8: 15]* дигәнгә туры килә. Д.Заһидуллина билгеләвенчә, биредә «кешенең әхлагы турыдан-туры аның белеменә бәйләп карала» *[1: 155]*.

Хикәядә Гаяз Исхакый «бәхет» төшенчәсен шактый тар – шәхси тормыш һәм гаилә кысаларында гына карый, әлегә гомум милләт, җәмгыять дәрәҗәсенә күтәрелә алмый. Ләкин үзәк герой Хәлимнең, (ә димәк, авторның да), уй-фикерләре шул юнәлештә үсә баруын егетнең Казанга китәр алдыннан әтисе белән килеп чыккан бәхәсеннән күрергә мөмкин.

«Дөньяда килүдән мәкъсуд *(теләк, омтылыш. – И.Ф.)* – дөньяда гына ничек житте шулай көн уздыру түгел, бәлки үземез рәхәт яшәп вә башка мөселман карендәшләремезнең дә рәхәт гомер кичерүләренә тырышып вә гайрәт кылып, ахирәт көнендә әбәди мәсгудиятләр *(мәңгелек бәхет. – И.Ф.)* ирешмәктер, болар өчен тәхсиле гыйлемнән башка бернәрсә берлә хасил була торган түгел, шуның өчен дә мәдрәсәләргә барып гыйлем өйрәнергә кирәк *[8: 32]*», – ди ул. Димәк, Хәлимнең максаты шәхси бәхеткә ирешү белән генә чикләнми, ул гыйлем-мәгърифәт аша барлык «мөселман карендәшләремезне» дә бәхетле итәргә тели. Ләкин, кызганычка каршы, геройның әлеге максаты аның эш-гамәлләрендә берничек тә ачылмый, коры вәгазь сату булып кына кала.

Шул ук вакытта, автор Рәхимә абыстай авызыннан барлык мәдрәсәләрнең дә, барлык укыту алымнарының да бер түгеллеге, аларда дөньяви белем бирү һәм тәрбия эше бергә алып барылырга тиешлеге хакындагы фикерләре белән дә уртаклаша. «Менә монда Сәгъди хәзрәт шәкертләре бар, – ди ул. – Алар да шул ук мәчеткә баралар, күрерсең, әллә ни кыланып бетәләр, берсе берсе берлә көлешкән булып, ялтыр-йолтыр күзләрен тәрәзәгә әйләндерәләр, әйтерсең, аларны монда көтеп торалар. Ул, шәкерт булгач та, бары да әдәпле булмый, әдәп өйрәтсәләр генә әдәпле була» *[8: 41]*. Хәлим биредә белем һәм әхлак камиллеге аша рухи гармониягә, ә димәк, шәхси бәхеткә ирешкән идеаль герой дәрәҗәсенә күтәрелә.

Әдәбият галиме Мәсгуд Гайнетдин фикеренчә, «җәдитчелек шавы әдәбияты Муса Акъегет, Заһир Бигиевлардан башланса, әдәбиятта ысулы җәдит Г.Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт» хикәясеннән башлана» *[2: 211]*. Галим шушы хикәядән соң язылган «Бай углы», «Кәләпүшче кыз», «Өч хатын берлән тормыш» әсәрләрен идея-тематика, стиль уртаклыклары ягыннан Исхакый иҗатындагы аерым этап итеп бәяли һәм аның мәшһүр «Ике йөз елдан соң инкыйраз» повестена кадәр дәвам итүен күрсәтә *[2: 211]*. Санап үтелгән әсәрләрдә үзәк герой җәһәтеннән язучы иҗатына гына түгел, ә бөтен татар мәгърифәтчелек әдәбияты өчен мөһим булган сыйфат үзгәрешләрен күрергә мөмкин. Мәсгуд Гайнетдин билгеләвенчә, «яңа реалистик проза, мәгърифәтчелек реализмына хас идеал гәүдәләнеше, заманының матур максатларына ирешү юлын күрсәтүче, әдәпле, эшчән, сөйкемле үрнәк мулла абзыйлар, сәүдәгәрләр, әдәпле егетләр, гүзәл кызлар образларын үзәккә куеп, бу «алдакчы дөньяда» аларның ничек <…> әүлиядәй саф яшәүләрен күрсәтергә дә өлгерми, Г.Исхакый тормышның интегүле язмышлы Камәрләрен («Кәләпүшче кыз») әдәбият түренә китереп кертә» *[2: 212]*.

Чынлап та, Гаяз Исхакыйның «Тәгаллемдә сәгадәт» (1897) хикәясеннән соң язылган әсәрләрендәге үзәк геройлар башка мәгърифәтче язучыларның хикәя-повесть каһарманнарыннан шактый үзгә. Муса Акъегетнең «Хисаметдин менла» повестендагы Хисаметдин менла, Закир Һадинең «Җиһанша хәзрәт» повестендагы Хәсән мулла, Риза Фәхретдиновның «Сәлимә яки гыйффәт», «Әсма яки гамәл вә җәза» әсәрләрендәге Сәлимә, Әсма кебек идеаллаштырылган образлардан аермалы буларак, Гаяз Исхакыйның геройлары реалистик планда сурәтләнә. Кеше язмышына белем, тәрбиянең генә түгел, ә җәмгыятьтәге социаль-иҗтимагый факторларның да хәлиткеч йогынтысы язучы тарафыннан татар әдәбиятында беренчеләрдән булып тасвирлана башлый. Бу сыйфат аның һәр героеның язмышына да хас диярлек.

Мәсәлән, «Кәләпүшче кыз» (1897) повестенда Кәримә, ире үлеп, улы Габделәхәтне мәдрәсә интернатына урнаштыргач, теккән кәләпүшләрен Сәлимовлар кибетенә илтеп тапшыру эшен яшүсмер кызы – Камәргә йөкләтеп, аны берьялгызын ирләр янына чыгарырга мәҗбүр була. «Чыгармый хәле юк! Чыгармаса, акча юк, башка чыгарга кеше юк. Ай, фәкыйрьлек ниләр күрсәтә?! *[8: 55]*» – дип яза автор. Димәк, үзәк геройны һәлакәткә илтүче сәбәпләрнең берсе – социаль эчтәлекле, ягъни фәкыйрьлек. Нәтиҗәдә, физик яктан да, мораль-әхлак сыйфатлары да ныгып җитмәгән кыз, Вафа исемле бозык приказчикның татлы сүзләренә алданып, сафлыгын югалта; Зөһрә карчык «ярдәмендә» кулдан-кулга китеп, фәхешханәгә килеп эләгә, яман чир эләктерә; дәваланып чыкса да, җәмгыятьтә үз урынын таба алмыйча, элекке шөгыленә кайта һәм ахырда кабат-кабат

женси авырулар белән чирләп, бала тапканда вафат була. Безнең фикеребезчә, Камәрнең трагедиясен, мәгърифәтчеләргә хас булганча, бары тик ана тәрбиясе һәм белем җитмәүгә генә кайтарып калдыру хакыйкатькә туры килми. Юкса автор: «Камәрнең фатирга акчасы, расхутка акчасы юк иде, һәммәсе кирәк! Фатирга акча сорыйлар! Кибеттә кенәгә тулган! Анда акча кирәк иде. Ни эшләсен?.. Кемгә киңәш итсен?.. Кемнән гакыл сорасын – һичкем юк» *[8: 68]* яисә: «Шулай итеп, Камәр больнистан аерылды. Ләкин ничек тамак туйдырсын? Кайда торсын? Ни берлә дөньясын кичерсен? <…>. Ике тәүлек буе ашаган юк *[8: 74-75]*», – дип, героеның авыр матди хәленә кабат-кабат басым ясамас иде. Димәк, әлеге шәхес фаҗигасен рухи сәбәпләр белән бергә, фәкыйрьлек, акчасызлык кебек социаль факторларга таянып та аңлатып була. Кешенең бәхет-бәхетсезлеген аның социаль хәле, әйләнә-тирәлек, иҗтимагый тәртипләр белән бәйләү мәгърифәтчелек әдәбияты өчен, чын мәгънәсендә, яңалык иде.

«Теләнче кыз» романының 1901-1907 елларда язылган беренче өлешендә дә үзәк геройның язмышы мәгърифәтчелек реализмына хас традицион схемага сыешмый, вакыйгаларга янә социаль мотивлар килеп керә. Әсәрнең төп каһарманы Сәгадәт *(бәхет. – И.Ф.)* исемле. Димәк, ул дөньяга бәхетле яшәр өчен килгән. Ата-анасы ярлы гына булсалар да, кызларына тиешле тәрбия һәм белем бирәләр. Ул мулла кызы белән ахирәт була, күркәм гадәтләргә өйрәнә. Шулай итеп, мәгърифәтчелек реализмы калыплары буенча, Сәгадәтнең тормышы имин һәм бәхетле булырга тиеш кебек. Ләкин алай килеп чыкмый. 1897 елны иген уңмый һәм кызның алтмыш яшьлек әтисе Шәрип карт, ачлыктан куркып, гаиләсе белән шәһәргә күчәргә карар кыла. Тик калада аларны беркем дә көтеп тормый. Шәрип карт та, Хөсниҗамал карчык та яшәрләренә урын, тамак туйдырырга эш таба алмыйча, ачлыктан һәм авырулардан үлеп китәләр, ә уналты яшьлек Сәгадәт хәер сорашып көн күрергә мәҗбүр була. Бай углы, «потомственный почётный гражданин» Габдулла Әмирханович Сәгадәтне, капкадан капкага йөргән чагында хәерчеләр төркеменнән аерып, аулакка алып керә һәм мәсхәрәли. Нәтиҗәдә, кыз фәхешханәгә килеп эләгә.

Сәгадәтнең фаҗигасен бары тик рухи сәбәпләр белән генә аңлатып булмый. Ул тиешле тәрбия алган, укыган. Ләкин заманның аяусыз чынбарлыгы, кешегә үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен җәмгыятьтә шартлар тудырылмавы аркасында, кыз бәхетсезлеккә дучар була. Фәхешханәгә дә аны җан саклап калу ихтыяҗы өстерәп китерә, ул анда ачтан үлмәс өчен бара. Күренүенчә, биредә шәхес трагедиясен социаль-иҗтимагый сәбәпләр белән аңлату инде, гомумән, өстенлек ала һәм бу сыйфат язучының, мәгърифәтчелек реализмы кысаларын җимереп чыгып, тәнкыйди реализм позицияләренә басуын билгеләп тора. М.Сәхапов күрсәтүенчә, әлеге әсәрләрдә хатын-кыз язмышы милләт язмышы белән тәңгәл куела һәм женси тигезсезлек киләчәктә халыкның юкка чыгуының бер сәбәбе булу мөмкинлеге турында кисәтелә. «Хатын-кызны ихтирам итмәгән, аны гаилә учагын саклаучы, балаларга тәрбия бирүче шәхес итеп күрмәгән, рухи үсеше һәм камилләшүе өчен тиешле шартлар тудырмаган милләтнең киләчәге томанлы *[8: 74-75]*», – ди галим.

Димәк, «Тәгаллемдә сәгадәт» хикәясеннән аермалы буларак, автор биредә үзәк геройларының язмышын милләт язмышы белән тәңгәлләштерә, аларның рухи сәламәтлеге гомум милләт киләчәген билгели. Шулай итеп, «бәхет» төшенчәсе, «Тәгаллемдә сәгадәт» хикәясендәге шәхси бәхет кысаларына гына сыймыйча, гомум милләт дәрәҗәсенә күтәрелә. Язучы бары тик гомум милли бәхеткә ирешкәндә генә, ягъни халыкның һәр вәкиленә җәмгыятьтә үз урынын табарга мөмкинлекләр тудырылганда гына, аерым шәхес үзен бәхетле исәпли ала дигән карашка күчә.

Гаяз Исхакыйның мәгърифәтчелек чоры иҗатындагы герой эволюциясен югарыда анализланган әсәрләрне 1904 елда дөнья күргән атаклы «Ике йөз елдан соң инкыйраз» хыялый-публицистик повесте белән чагыштырма планда тикшергәндә, аеруча ачык күрергә мөмкин. Әсәр үзәгендәге каһарман язмышын милләт язмышы белән тәңгәлләштерү биредә ярылып ята.

Әдәбият галиме Фоат Галимуллин «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ны «геройсыз әсәр» дип атый *[3: 161]*. Чынлап та, «XXI гасырның соңгы унъеллыгын тасвирлый башлаганчы, автор сүзне, гомуми рәвештә, ягъни тулаем милләт хакында алып бара. Бары тик болгарлар тәмам юкка чыгарга берничә ел калгач кына, әсәргә Җәгъфәр исемле аерым бер шәхес – тарихчы,

язучы образы килеп керә» *[3: 162]*. Фоат Галимуллин фикеренчә, «әлеге әсәрдә Җәгъфәр чын мәгънәсендә үзәк образ түгел, бәлки ул – автор күтәргән мәсьәләләрнең олылыгын һәм әһәмиятен тагын да көчәйтү өчен хезмәт итә торган сәнгать чарасы» *[3: 162]*.

Җәгъфәр образы повестьта милләт символы булып хезмәт итә. Ул – гомумиләштерелгән образ. «Соңгы болгар»ның Болгар хәрабәләрендә манара астында калып һәлак булуы да очраклы түгел. Дәүләтсез халыкның киләчәге юк – бу үлемнән килеп чыккан төп нәтиҗә шул. Әсәрдә тасвирланган вакыйгалар язучының иҗтимагый һәм фәлсәфи карашларына иллюстрация вазифасын үти. «Ике йөз елдан соң инкыйраз»ның өчтән ике өлеше патша цензурасы тарафыннан киселеп, бары тик 1990 елларда гына олуг галимебез Миркасыйм Госманов тарафыннан табылып, яңадан гыйльми әйләнешкә кертелүе дә *[5: 200-240]* повестьның заман чынбарлыгына, милләт сагында торырга тиешле дин әһелләренә, акчаларын халык файдасына тотар урынга, «курчак туйлары» үткәреп, җилгә очырган татар байларына, Русиянең колониаль сәясәтенә гаепләү акты булып яңгыравын күрсәтә. Язучы милли инкыйразга каршы көрәшкә бар гомерен багышлады.


Шулай итеп, Гаяз Исхакый иҗатындагы мәгърифәтчелек чоры озакка сузылмаса да, андагы үзәк герой катлаулы үсеш, эволюция юлы үтә дигән нәтиҗәгә килергә мөмкин. Башта ул, «саф» мәгърифәтчеләргә хас булганча, «белем, тәрбия һәм тән камиллеге»нә ия идеаль шәхес сыйфатында тасвирланса, соңрак дөньяви, реалистик төс ала һәм әйләнә-тирәлек, социаль-иҗтимагый күренешләр белән бәйләнештә сурәтләнә башлый, кешенең бәхет-бәхетсезлегенең сәбәпләре итеп, аның белем һәм тәрбия дәрәҗәсе генә түгел, ә җәмгыять тәртипләре дә күрсәтелә; соңга таба исә үзәк герой, гомумән, милләт символына әверелә. Болар һәммәсе дә Гаяз Исхакыйның фикер үсешен, рухи эволюциясен билгеләп тора. Чөнки әсәр – язучының күңел көзгесе ул...

**Әдәбият**

1. Әдәбият белеме: терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / Төзүче-авторлар Д.Ф.Заһидуллина, В.Р.Әминева, М.И.Ибраһимов, Н.М.Йосыпова, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйләҗев, Г.Р.Гайнуллина; фәнни редакторлар Т.Н.Галиуллин, Д.Ф.Заһидуллина. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.
2. Гайнетдин М. Гасырлар мирасы. – Казан: Татарстан китап нәшрияты, 2004. – 319 б.
3. Галимуллин Ф. Эзләнү вакыты: укытучылар, педагогия колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2005. – 247 б.
4. Гаяз Исхакый һәм татар дөньясы: әдипнең 120 еллыгына багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары / Җыентыкны төзүче, җаваплы редакторы Н.Г.Ханзафаров; баш редактор М.Х.Хәсәнов; ТР ФА Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, сәнгать институты. – Казан: Фикер, 2000. – 296 б.
5. Госманов М. Гасырдан – гасырга; төзүчесе Җәүдәт Миңнуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2004. – 488 б.
6. Гыйлаҗев Т.Ш. Әдәби мирас: тарих һәм заман; кереш сүз авторы Д.Заһидуллина; фәнни мөхәррире А.Әхмәдуллин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2005. – 206 б.
7. Заһидуллина Д. Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр: монография. – Казан: Мәгариф, 2006. – 191 б.
8. Исхакый Г. Әсәрләр: унбиш томда; беренче томны төзүче, текст, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче Л.Гайнанова; фәнни редакторлар М.Хәсәнов, Р.Исламов; ТР ФА Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, сәнгать институты. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1998. – 1 т: Повестьлар һәм хикәяләр (1899-1908). – 399 б.
9. Исхакый Г. Зиндан: сайланма проза һәм сәхнә әсәрләре; җыентыкны төзүче, текст һәм искәрмәләрне әзерләүче Л.Гайнанова; кереш һәм ахыр сүз авторлары И.Нуруллин, Һ.Мәхмүтов, Л.Гайнанова; фәнни җитәкчесе Ф.Мусин. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1991. – 671 б.
10. Миңнегулов Х. Гаяз Исхакыйның мөһаҗирлектәге иҗаты. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2004. – 367 б.
11. Миңнегулов Х. Гасырлар өнен тыңлап: укытучылар, педагогия колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен методик кулланма. – Казан: Мәгариф, 2003. – 335 б.
12. Сафуанов С. Рухи күперләр. – Уфа: Китап, 2006. – 376 б.
13. Сахапов М. Золотая эпоха татарского ренессанса: монография; предисловие академика М.Хасанова; научный редактор Э.Тагиров. – Казань: Татар.кн.изд-во, 2004. – 319 с.
14. Татар әдәбияты: теория, тарих / Төзүчеләре Д.Заһидуллина, Ә.Закирҗанов, Т.Гыйләҗев, Н.Юсыпова. – Тулыландырылган икенче басма. – Казан: Мәгариф, 2006. – 319 б.
15. Хатипов Ф. Әдәбият теориясе: югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2000. – 351 б.

**Илдус ФАЗЛЕТДИНОВ,**
*филология фәннәре кандидаты,*
*Башкорт дәүләт университетының*
*татар филологиясе һәм мәдәнияте кафедрасы доценты*

# БЕР КҮРЕШҮ



Узган гасырның җитмешенче елларында, Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаганда, диплом яклау мәҗбүрияте килеп тугач, укытучыбыз Флёра Әкрам кызы Ганиева тәкъдим иткән темаларның «Фатих Хөсни – хикәяче» дигәнен сайлап алдым. Балачактан бирле укылмаган әсәре калмады, иң яраткан язучыларымның берсе... Шулай булгач, хикмәти хәйран бай иҗатын шәп беләм – җылы юмор һәм нечкә лирика белән сугарылган әсәрләре дәрьясында рәхәтләнеп йөзәргә була янәсе. Әмма фәкать күпсанлы хикәяләрен җентекләп өйрәнә торгач, шуны аңладым: кече күләмле прозада беренче карашка шук күңелле, шаян, гади күренгән Фатих Хөсни үзе бер – ифрат катлаулы, фәлсәфи, романтик, сихри, тылсымлы дөнья икән ләбаса! Аһәңе, моңлы көйдәй җырлап торган җор теле белән, тормышның үзеннән чумырып алган теләсә кайсы вакыйганы, хәлне яисә гадәти кеше холкын, сурәтен хикәя дигән кысан мәйданда ачык, җете күрсәтеп бирергә сәләтле, олуг талантлы каләм иясе... Образларны тасвирламый, коеп кына куя инде менә! Чагыштырмача әлләни киң булмаган күренешләрне, табигать манзарасын йомшак, сихри ут яктысында бирә белүе белән ул Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Равил Фәйзуллин кебек зур шагыйрьләрне хәтерләтә, димме. Хикәядә «Фатих Хөсни феномены» дигән кабатланмас асыл сыйфатны диплом эшемдә ничекләр генә күрсәтә алырмын дип гаҗизләнеп калган, ут йоткан чакларым бу... Диплом эшен яклар көн дә якынлаша.

Фәнни җитәкчем Флёра Әкрәмовна, гадәтенчә сөйкемле генә елмаеп, әлеге мөһим вакыйгага язучының үзен дә чакырырга киңәш итте. Иң әүвәле, кечерәк гәүдәле, чибәр мөгаллимәмнең мондый батырлыгына сокланып карап каттым. Ниндидер диплом кәмәшен тыңлауга Фатих Хөсни хәтле Фатих Хөсни үзе киләме?! Аның алдында хурлыкка калсам?

Урам телефоныннан курка-курка гына Фатих аганың фатирына шалтыратам. Ул төребкәне алуга, исәнләшкәннән соң, дулкынлануымны басар өчен, бертуктаусыз тамак кырам:

– Фатих ага, ...Сезне Казан университеты... студенты борчый иде, – дип өнемне кысып чыгарам, ниһаять.

Ярый әле, үзем белән таныштырганда, бик тә каушавымнан дөньяларымны онытып, ...Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы... В.И.Ленин-Ульянов исемендәге... дәүләт университеты ... дип, әлеге вуз титулын тулысынча вәземләп тезеп чыкмаганмын...

Язучының:

– Ул Казан университеты студентына нәрсә кирәк булды икән соң? – дип гади генә, көлемсерәгәндәй сорап куюы тынычландырды булса кирәк мине – Ходай тел ачкычлары биреп, йомышымны юньле-башлы аңлата алдым. Кыюланып та киттем хәтта:

– Теләсәгез, алдан ук автореферaты белән дә таныша аласыз, – дип тә ычкындырдым бугай. Һәм, гозеремә җавап итеп... ни ишетәм? Үз колагыма үзем ышанмыйм… Фатих ага: «Сезне бүген кич өйдә көтәм», – дип әйтте дә куйды!

...Маяковский урамындагы күпкатлы йорттагы фатирның ишеген кыяр-кыймас кына шакуга, каршыма хуҗасы үзе килеп чыкты... Фоторәсемнәрдән таныш зур түгәрәк йөз, игътибарлы үткен караш, дулкынланып торган, чалара башлаган чәч. Ихластан ачык чырай белән каршылады, яшь кенә егетнең аягына чүәк табып бирмичә тынычланмады. Ул арада үзе аяк астында чуалган дүрт-биш яшьлек сабый белән әвәрә килә, урысчалатып үгетли, җаен көйли тегенең. Минем бу хәлгә бераз сәерсенүемне күреп алды булса кирәк.

– Сез инде, Илдус, язучы башына оныгы белән урысча гына сиптерә икән бу, дип гаҗәпкә калгансыздыр. Нишлисең бит, заманалар шундыйга китте... Үземнең балаларны чын татар итеп үстердем, ә боларына хәлемнән килми... Картаелды, күрәсең, – дип уңайсызлануыннан уфтанып куйды.

Өстәл артына әңгәмәгә утыргач та, берәр чынаяк чәй эчерми торып, гозеремне үтәргә ашыкмады. Җайлап кына хәл-әхвәлемне белеште башта, кайда туып-үсүемә тиклем сорашты. Норлат-Октябрь[1] районы исемен ишеткәч, аеруча җанланып китте. Алтмышынчы елларда китап укучылар белән очрашуларын тәэсирләнеп, сагынып искә төшерде.

Шулкадәр гади, эчкерсез сөйләшә, гәпләшә, кешене тыңлый белүе белән үземнең бабама охшаттым мин аны. Әйтерсең лә, янәшәмдә күп нужа күргән, олыгая төшкән авыл карты, якын кешем – дәү әтием утыра. Чыннан да, ачысын-төчесен байтак татыган әңгәмәдәшем. Соңгы елларында тәкъдир дигәнең аеруча мәрхәмәтсез кыланган: бер-бер артлы коточкыч бәла-каза, хәвеф-хәтәр кичергән ул. Машинада авариягә очрап вафат булган киявен гүргә иңдереп өлгермиләр, ул да булмый, газиз улы фаҗигале төстә үлеп китә. Аннары хатыны Мәрфуга апа... Ни кызганыч, бу очрашудан соң шактый еллар узгач, әнә шул кайгы-хәсрәт касәфәте гомере азагында хәтерен чуалтып, саташуга китерә дә инде...

Әнә шулай кайгылары белән уртаклашып күңелен юаткач, инде миңа сүз биргәндәй, тынып калды. Авторефератымны бер сулышта укып чыктым.

... – Да-а-а, – дип кенә сузды Фатих ага, тыңлап бетергәч. Ни яхшы, димәде, ни начар, димәде. Соңыннан белдем, ифрат четерекле, мөһим мәсьәләне хәл иткәндә, шулайрак урысчалатып «да»лап куя торган гадәте бар икән аның. Аннары, үзалдына гына сөйләнгәндәй, уйчан рәвештә:

– Хикәя белән новелла арасында Кытай стенасы юк инде ул үзе... Язучы кеше алар арасындагы сизелер-сизелмәс аерманы, чикне үзе төгәл тоемларга тиеш. Бары шул гына... – диде.

Тәнкыйть сүзләрен диплом яклаган көнгә калдырган булып чыкты хәйләкәр абзый. Фатих ага килгәнне ишетеп, байтак кеше кереп тулды аудиториягә. Оппонентым да теләсә кем түгел – яңа гына, «Хәзерге татар поэтикасы» китабы өчен, галимнәр арасында беренче булып Тукай бүләге алган Нил Юзиев. Дәүләт комиссиясе рәисе дә Мөхәммәт ага Мәһдиев үзе! Нык борчылам, тәшвишләнәм, билгеле. Түбән Кама төзелеше чорыннан ук дус иткән шагыйрь Фәннур Сафин, «нык бул!» итенгәләп, иңемә кагылып үтә.

...Менә диплом эше белән таныштыру тәмам. Аннан соң чыгыш ясаган Нил абый хезмәтне уңай бәяләде. Инде эчке калтырану белән четерекле, астыртын сораулар гына көтәсе калды. Мөхәммәт ага, әлеге дә баягы, хикәя белән новелла арасындагы принципиаль аерма турында төпченде дә, җавабымнан разый булды. Гомумән, диплом яклау, майлагандай, ипле генә бара әле минем, тыңлаучылар канәгать күренә. Шулвакыт арткы рәттә утырган Фатих ага торды да:

– Психологик хикәяләрне анализлау бүлегенә «Ана хикәясе»н дә кертергә кирәк иде, минемчә. Авыл карчыгының ничәмә елдан соң күрешү өчен генә төнлә кайтып кергән кызылармеец улының күлмәк төймәләрен ай яктысында ныгытып тагу күренеше, мәсәлән?.. Образларның эчке кичерешләре динамикасы мул итеп бирелгән анда, – дип, катгый төстә сорау куйды.

– Дөрес анысы, рухи халәтне куе буяулар белән сурәтләгән һәйбәт хикәя ул. Әмма без бит Сезнең бөтен хикәяләрне дә анализлап чыгу максатын куймадык, – дидем.

[1] Шәһәрнең элеккеге атамасы.

Фатих ага үзе дә, бу җавабыма күңеле булып, «Молодец, үз сүзеңдә тора беләсең икән. Бик кирәкле сыйфат», дип мактап та җибәрде хәтта. Ни генә булмасын, үзенең иҗатын диплом рәвешендә яктырткан өчен генә дә бик рәхмәтле икәнен яшермәде гаҗәеп әдәпле, итагатьле классик язучы.

Диплом эше «бишле»гә бәяләнгәч, бу уңышны «юу» гадәте бар икән ич. Флёра апа белән Нил абый, вакытлары тыгыз булганга, кече «мәҗлес»тән баш тарттылар. Фатих ага исә каршы килмәде. Нindidер бер ресторанда чамасын белеп кенә пирәшләп утыргач та, очрашу түгәрәкләнеп бетмәгән икән әле, Эрмитаж бакчасында дәвам иттердек аны. Искиткеч кызыклы әңгәмәдәш, мәзәк кеше икән ул. Фәлсәфи уй-фикерләрен дә фонтандай аттырып кына тора... Сүзебез һаман да иҗат эше, китаплар тирәсендә әйләнә. Янә, хикәя жанрына кагылгач, бу хакта да әйтер сүзе калган булып чыкты Фатих аганың:

– Әмирхан Еники салмак-сабыр агышлы, моңсу-уйчан психология белән сугарылган хикәяләр төрен үстерә... Фатих Хөсни исә, башлыча, елмаюлы, җырлап торган әсәрләре, нечкә лиризм, үткен юморы белән көчле, диләр... Бөтенләй үк дөрес дип булмый ич моны. Ике язучыны шулай маңгайга-маңгай китереп чәкәштерергә маташу ярыймыни?!. Дөрес, безнең икебезгә дә төрле индивидуаль стиль хас. Әмма арада аның кадәр үк тирән, киң упкын ыржаеп тормый ич... Уртак якларыбыз да җитәрлек... Миндә, мәсәлән, психологик дөреслек азракмы? – дип сөйләп китте. Күңеленә юшкын булып утырган үпкә-сапкасын да тышка чыгармыйча түзмәде:

– Тотабыз да һәрбер хикәядән иң элек, каш җыерып, проблема эзли башлыйбыз. Ә бит аны шәм яндырып эзлисе юк, ныграк игътибар иткәндә, төбеннән әһәмиятле икенче мәсьәләләр дә калкып чыга. Булганны күрә белергә генә кирәк...

Монысы инде минем бакчага атылган таш дип кабул иттем. Чөнки әлеге дә баягы диплом эшендә аның «Шәмәхә тавыклар», «Сабан туе», «Үземне югалттым» кебек хикәяләренә – юморга, лирикага манчылган булсалар да, асылда шуклыкка, сүз уйнатуга гына корылган, вак темаларга язылган әсәрләр дигән тамга суккан идем.

Йөзем кызарып чыгуны сизмәгән атлы булып, игътибарлы Фатих ага һични булмагандай, тиз генә бүтән «сукмакка» кереп китте... Көндәлек тормыш турында, каләмдәшләре хакында яратып, үз итеп, юксынып, уенын-чынын кушып тасвирлый ул. Тыңлап туймассың. Үзләренең йортында Гомәр ага Бәшировның, тагын кайсыдыр күренекле әдипнең яшәвен горурланып искәртүе дә хәтердә калган. Сәясәт турында кызып-кызып сөйләшкәндә, кинәт сүзеннән бүленеп, ни өчендер:

– Син, энем, фиркадә тормыйсыңдыр бит? – дип, һич көтмәгәндә сорап куйды ул. Тискәре җавап ишеткәч:

– Бик ашкынма анда... Сизәм, үзең дә язгалыйсың бугай. Шуның белән ныграк шөгыльлән, каләмеңне чарла, – дип тә өстәде. Партиянең кызганыч киләчәген шул чакта ук чамалады микәнни тирән гакыллы әдип?


Саубуллашканда:

– Син минем фатирны беләсең хәзер, килеп йөр, оялма!.. Менә бу бакчаны көзен килеп күрсәң икән син! Яфраклар коелганда, искиткеч матур була монда, – диде Фатих ага, беравык әсәрләнеп, хискә бирелеп... Аның елмаюлы, сөйкемле йөзе, мәзәк сүз ишеткәч, киң маңгае өстендә бер тотам ак чугы шәйләнеп торган куе чәчләрен артка таба сыпыра-сыпыра, чын күңелдән шаркылдап көлүләре, әңгәмә барышында тиктомалга сүздән туктап, тирән уйга талып, авыр көрсенүләре хәзер дә күз алдымда. Бүтән очрашу насыйп итмәде. Күрәсең, ул чакта чиктән тыш тыйнак булганмындыр инде...

**Илдус ДИНДАРОВ**

# СҮЗЕ ХАКНЫҢ – ЙӨЗЕ АК

## ХУҖИӘХМӘТ МӘХМҮТОВКА 85 ЯШЬ



Хуҗиәхмәт аганың исемен беренче кат ишетүем мәктәптә укыган елларымда радио аша булды. Туган телебезнең бетмәс-төкәнмәс хәзинә икәнлеген төшендерә торган «Тел күрке – сүз» тапшыруын гаять кызыксынып тыңлыйм. Ягымлы тавышлы диктор тапшыруны әзерләүченең галим Хуҗи Мәхмүтов булуын хәбәр итә. Әтием миңа бу кешенең безнең авылныкы икәнен әйтә. «Хәзер ул Казанда зур галим. Китаплар яза», – ди. Мин әлеге фактны искиткеч бер хәл буларак кабул итәм, Хуҗи Мәхмүтов дигәннәре минем өчен шундый якын да, уй җитмәслек ерак та зат булып тоела.

Әйе, якын. Исеме бөтен татарлар да тыңлый торган радиодан еш яңгыраган бу шәхес син белем алган мәктәптә укыган, син узган сукмаклардан атлап йөргән, сиңа таныш булган кебек, авыл аша үтә торган, әле Әби патша заманында ук салынган ап-ак тарихи таш юл аңа да таныш, син су кергән Ушмы елгасында кайчандыр ул да коенган, Сабан, Шәрбән чишмәләренең суын эчкән, Уйгын әрәмәлекләрендә йөргән, син менгән Мадъяр тавына менгән, Янык, Туры юл, Каратөп урманнары, Айбулат аланы, Кадермәт чокыры, Балантау басуы хакында ишетеп түгел, боларның барысын да үз күзләре белән күреп белә! Туган авыл бер генә була бит ул, димәк, Түбән Ушмы күренекле якташым өчен дә, әлбәттә, газиз! Әлеге шәхес белән үзем арасында шушының кадәр уртаклыклар булуны аңлаудан миңа бу кеше туганым кебек якын тоела башлый.

Шул ук вакытта аның зур галим булуы, мәркәзебез Казанда яшәп, китап кадәр китап белән эш итүе миндә горурлану катыш соклану тудыра, аңа карата зур хөрмәт хисләре уята һәм гади авыл баласы өчен әдипне югарыдагы Ай биеклегенә меңгереп куя. Нинди була икән ул фәнни китаплар авторы, исеме мәгълүм авылдаш-шәхес? Күңелдә һәрчак тартып тора, аның белән кызыксынырга мәҗбүр итә, хәтта үзенә чакыра торган ниндидер бер якты тойгы бөреләнә.

Хуҗи Мәхмүтов атлы фольклорчы галимгә карата балачакта ук туган игътибар һәм ихтирам хисе, шул рәвешле, күңелемнең бер почмагына оялады да еллар узган саен кимемәде. Университетта укыган елларымда күренекле авылдашымның исемен күп ишеттем һәм, әлбәттә, аның хезмәтләрен укыдым, әмма галимнең шәхсән үзе белән Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына (ул вакыттагы исеме – Тел, әдәбият һәм тарих институты) аспирантурага укырга керү теләге тартып китергәч кенә таныштым. Халкыбызны теле, әдәбияты, фольклоры, тарихы, сәнгате җәһәтеннән башка халыкларга таныта торган, милләтебезнең йөзек кашы булган Институтта фән белән шөгыльләнү теләге тарткандырмы мине бирегә, әллә затлыдан-затлы авылдашыма мөнәсәбәттә балачактан күңелдә бөреләнгән тойгының өлеше зур булгандырмы – кыюлыкны җыеп, Институтның Хуҗиәхмәт ага эшли торган бүлегенә барып кергәнем хәтердә. Әлегәчә шушы өлкәдә ямь һәм тәм табып эшләвемнең сәбәбе – зирәк аксакалның яшь кешегә үз вакытында дөрес юнәлеш бирә алуында. Гомер юлымның иң башында ук бу кеше белән танышып, аның янәшәсендә фән белән шөгыльләнүем Аллаһы тарафыннан бирелгән хәерле бүләк булган.

Хуҗиәхмәт агага быелның 15 февралендә сиксән биш яшь тула. Үзенең яше белән дә, башкарган эше белән дә олуг ихтирамга лаек гаҗәеп бер шәхес ул. Гомеренең

алты дистә елдан артыграгы – фәнни эшчәнлектән гыйбарәт фидакарь хезмәт юлы. Аллаһы биргән чагыштырмача озын гомереҢ мул җимешле дә булса, күпкырлы һәм күләмле эшеҢ аша исемеҢне күпләр белеп, сиҢа хөрмәт белән карап, яшәвеҢ бушка китмәгән, узган юлыҢда җуелмас эзеҢ бар, димәк. Олпат ирләрчә бәхет-сәгадәткә ирешү юлы – нәкъ менә шулдыр ул.

Филология фәннәре докторы, Халыкара Төрки академиясенеҢ хакыйкый әгъзасы, РеспубликабызныҢ Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге лауреаты, ТатарстанныҢ һәм РоссиянеҢ атказанган мәдәният хезмәткәре Хуҗиәхмәт аганы татар милләтенә халкыбызныҢ телен, моҢын саклаган, гореф-гадәтләргә бай, гүзәл табигатьле Мамадыш төбәге биргән. Хуҗиәхмәт Мәхмүтов 1933 елда Түбән Ушмы авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килгән, шушында – җидееллык, ә район үзәге Мамадыш шәһәрендә урта мәктәпне тәмамлаган. Булачак галим үзенеҢ хезмәт юлын да туган җирендә башлаган – Казан дәүләт университетына укырга кергәнче, ике ел Көек Ерыкса җидееллык мәктәбендә математика һәм физика укыткан.

Хезмәт сөючәнлеге, белемгә омтылучанлыгы 1953 елда аны Казанга, университетныҢ тарих-филология факультетына алып килә. Татар телен, әдәбиятын, тарихын максатчан өйрәнеп, яштән үк төп игътибарын халыкныҢ рухи хәзинәләренә юнәлткән җитди холыклы акыллы егет 1958 елда университетны кызыл дипломга тәмамлый.

Озын хезмәт юлыныҢ 50 елга якыны гел бер урын – Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән бәйләнгән. Ул әле университетта укыган елларында ук Институт оештырган фольклор экспедицияләрендә катнаша, абруйлы галимнәр белән берлектә халык җәүһәрләрен җыю, туплау белән шөгыльләнә.

Университетны тәмамлаганнан соҢ, берничә ел үзе белем алган уку йортыныҢ татар теле һәм әдәбияты кафедрасында өлкән лаборант, соҢрак Буа районыныҢ «ЯҢа юл» газетасында әдәби хезмәткәр, җаваплы сәркатип, бүлек мөдире булып эшләп, иҗат тәҗрибәсе туплагач, әле студент сыйфатында ук юл сапкан Тел, әдәбият һәм тарих институтына 1966 елда Х.Мәхмүтов янә әйләнеп кайта. Халык иҗатына мәхәббәте, хикмәтле фольклор дөньясындагы бетмәс-төкәнмәс рухи байлык белән кызыксынуы аны XX йөзнеҢ алтмышынчы елларыннан ИнститутныҢ халык иҗаты бүлегенә бәйли. Биредә ул аспиранттан алып баш фәнни хезмәткәргә кадәр үсү юлы үтә, «Татар халык табышмаклары» дигән темага кандидатлык, халкыбызныҢ афористик иҗатына багышланган докторлык диссертациясе яклый. 1970 елдан – ИнститутныҢ Гыйльми советы, 1981 елдан – диссертацияләр яклау советы әгъзасы. Байтак еллар биредә профсоюз һәм партия оешмаларын җитәкләгән, Мәгариф, югары мәктәп һәм фәнни учреждениеләр хезмәткәрләре профсоюзыныҢ VII съездына делегат итеп сайланган. Ярты гасырга якын Институтта эшләве дәверендә галим татарлар яшәгән төрле төбәкләргә оештырылган күпсанлы фольклор экспедицияләрендә катнашкан, үзе яшәгән чор халык авыз иҗатын бөртекләп җыйган, аларны тәртипкә китереп, академик җыентыкларга керткән. Х.Мәхмүтов үз гомерендә өч дистә китап, сигез йөзләп мәкалә язган. 1989 елда Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек булган 12 томлык «Татар халык иҗаты» җыелмасын әзерләп бастыру эшендә Х.МәхмүтовныҢ өлеше зур. Бу фундаменталь басманыҢ редколлегия әгъзасы, биш томыныҢ фәнни мөхәррире, «Табышмаклар», «Мәзәкләр», «Мәкальләр һәм әйтемнәр» томнарын төзүче, аларга кереш мәкалә һәм фәнни искәрмәләр язучы да – Х.Мәхмүтов.

Хуҗиәхмәт аганыҢ фәнни иҗат юлы киҢ, якты, дәвамлы. Ул – фәнНеҢ халыкка аеруча якын өлкәсе фольклористикада уникаль шәхес, гомере буе фольклорныҢ туган телебез өчен хәзинә тулы тирән кое булуы хакында армый-талмый сөйләгән Каюм Насыйри, Нәкый Исәнбәт, Хәмит Ярми, Гомәр Бәшировлар кебек үк, сирәк, олуг зат. Халык иҗат иткән әсәрләрнеҢ үзе кебек гади дә, шул ук вакытта гали дә ул. Хуҗиәхмәт аганыҢ тормыш юлы башка берәүне дә кабатламавы белән матур.

СоҢгы утыз-кырык ел эчендә күпгасырлык язма мирасыбызныҢ төрле катламнары ачылды, алардагы хәзинә-байлыкны өйрәнеп, халыкка кире кайтару юнәлешендә биниһая зур эшләр башкарылды. Бу җәһәттән, Х.Мәхмүтов – борынгы фольклорыбыз мәсьәләләрен өйрәнүгә бик күп көч куйган галим. Борынгы ядкарьләребездә теркәлеп калган рухи кыйммәтләрне барлап, фәнни монографияләр әзерләп чыгару – галим

эшчәнлегенең иң әһәмиятле биеклеге. Галим бик борынгы чорларга караган язма ядкарьләрдәге халык акылын – мәкаль-әйтемнәрне һәм башка төр гыйбарәләрне җентекле өйрәнеп, аларның бүгенге көнгәчә үсеш-үзгәрешен күзәтеп, тирән анализлый, бу төр әсәрләрнең тирән хикмәтен, нәзберек шигърияттен нечкә тоемлап яза. Аның «Мәңгелек ядкарь» (2002), «Борынгылар әйткән сүзләр» (2002) кебек монографияләре – шушы өлкәне колачлый торган зур хезмәтләр. Болардан тыш татар халкының борынгы фольклорын ачуга галимнең дистәләгән саллы мәкаләсе багышланган, шушындый характердагы тикшеренүләре төрле хрестоматия һәм фәнни, фәнни-популяр җыентыкларга кертелгән.

Х.Мәхмүтовның табышмакларның жанр үзенчәлеген өйрәнүгә багышланган «Кечкенә дә төш кенә» (1980), халык календаре серләренә төшендерә торган «Ел тәүлеге – 12 ай» (1991), фольклорда әдәп-әхлак мәсьәләләренә багышланган «Язылмаган кануннар» (1995), халык сөйләмендә очрый торган сүз-гыйбарәләрнең хикмәтен, тарихын, нинди уңай белән әйтелүен тәфсилле аңлатып-төшендереп, сүз эченә яшерелгән энҗе бөртеген күрсәтеп бирә торган «Канатлы сүз – хикмәтле сүз» (1999), «Гыйбарәләр тарихыннан сәхифәләр» (2008), «Изге китаплар кайтавазы» (2012) кебек саллы монографияләре фәнни-теоретик яктан да, киң катлам укучыларның гамәли ихтыяҗын кайгыртып язылган булуы белән дә гаять әһәмиятле.

Х.Мәхмүтовның монографик хезмәтләре арасында югарыда телгә алынмый калганнары да шактый. Бер кеше гомеренә шулкадәр күп хезмәт башкарылган! Монографияләрдән тыш, Х.Мәхмүтов – «Татар фольклоры жанрлары» (1978), «Татар фольклорында социаль мотивлар» (1986), «Поэтика татарского фольклора» (1991), «XX гасырның күренекле тюркологы Рәшит Рәхмәти Арат» (2001), «Хәмит Ярми: галим һәм шәхес» (2004) һ.б. җыентыкларның да җитәкчесе, төзүчесе, төп авторларыннан берсе. «Энҗе чәчтем – энҗе җыям» дип аталган, мәктәп-гимназияләр өчен татар халык иҗатыннан уку ярдәмлеге буларак чыгарылган китапларның дүртесе шулай ук аның тарафыннан әзерләнгән. Галим үзенең язган хезмәтләре, татар матбугатында даими ясаган чыгышлары белән татар дөньясына үтә таныш. Аның исеме һәрбер милләттәшкә «Тел күрке – сүз» дип аталган, ике атнага бер чыгып килгән гаҗәеп кызыклы радиотапшыру аша да озак еллар дәвамында барып ирешә торды. 2003 елдан Х.Мәхмүтов – Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Галим буларак, Х.Мәхмүтов эшчәнлеге, әлбәттә, фәнни конференцияләрдә югары дәрәҗәдәге чыгышлар ясау һәм яшь галимнәргә юнәлеш бирү белән еллар дәвамында тыгыз аралашып барган. Казан, Түбән Новгород, Тбилиси, Алматы, Бишкәк, Анкара һ.б. шәһәрләрдә уздырылган халыкара конференцияләрдә ул укыган докладлар фикерле, төпле, җитди булулары белән игътибарны җәлеп итә. Галим җитәкчелегендә 2 докторлык, 6 кандидатлык диссертациясе якланган. Ул – озак еллар дәвамында Казанның филология профильле югары уку йортларында Дәүләт аттестация комиссиясе рәисе булып эшләде. 2004 елда, гыйльми хезмәтләре белән бергә педагоглык эшчәнлеген дә исәпкә алган Югары аттестация комиссиясе карары нигезендә, галимгә «профессор» исеме бирелә.

Хуҗиәхмәт аганың иҗаты, фәнни хезмәтләре, кылган гамәлләре, тапкыр сүзе, хәтта кайбер очракларда дәшми калуының тирән мәгънәгә ия булуы хакында гына да озак сөйләргә мөмкин. Ә менә осталыкны кыскалыкта күргәндә, аның хакында халкыбызның талантлы улларыннан берсе, фольклорчы галим, шагыйрь Рәшит Ягъфәровтан да төгәлрәк һәм кыскарак әйтеп булмастыр, шуңа күрә язмамны нәкъ менә шул юллар белән тәмамлыйм:

*Насретдиндәй тапкыр, зирәк зат ул,*
*Тагын ни дим аңа багышлап? –*
*Язганы хак аның, гамәле – сак,*
*Сүзе – мәкаль, үзе – табышмак.*

**Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,**
*филология фәннәре докторы,*
*Г.Ибраһимов исемендәге*
*Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*әйдәп баручы фәнни хезмәткәре*

# РӘХМӘТЛЕ КАЛӘМДӘШЕМ

## ШАҺИНУР МОСТАФИНГА 70 ЯШЬ

Үзен күргәнчегә кадәр Шаһинур Мостафин исеме белән матбугат битләре аша таныштым мин. Балык Бистәсенең район газетасы редакциясендә эшләп йөргән вакыт. Гаҗәеп матур йола чәчәк аткан икән: егермедән артык район газеталарын үзара алышабыз. Нindидер тема чәлдерү, сюжет күчерү шикелле яман чир булмаса да, күрше район газеталарын да почта килеп җитүгә үк кулга эләктерәбез. Ерак районмы, терсәккә терәлеп торамы, барыбер дә кызык: алар нинди тормыш белән яши, күршеләрдә кайсы сәхифәләр отышлырак? Бер үк хикәя-шигырьләрен фәлән төбәккә юллап, каләм хакы сугып ятучы әрсезләр юкмы икән?

Кукмара районының «Хезмәт даны» газетасы аеруча саллы. Шаһинур Мостафин атлы егет сугыш ветераннары, аеруча сирәк батырлыклар күрсәткән каһарманнар турында бик тәфсилле яза. Егетнең матросовчы якташларыбыз турындагы мәкаләләренә, рәхәтләнеп, бер дә «тунамыйча», республика матбугатында да урын биргәлиләр. Совет чире, ватанпәрвәрлек белән сугарып үстергән буын вәкиле бит. Шаһинурның язмаларын икешәр-өчәр газета битләрендә эзләп тапкан саен, амбразура каплаучылар белән горурлану хисе арта бара. Тагын бер «чир»не дә яшерүдән тирән мәгънә күрмим. Байтак газета кочак ачып торган өчен, Шаһинурның каләме дә шактый көнләштерә. Ләкин яңа язма күргән саен, сорау арты сорау калкып чыга: һәр мәкаләне шаккатырлык итеп язарлык ничек кенә чимал таба соң ул?..

Яшь чак, йөгәнсез чак бит. Гаиләм юк. Үзем Балык Бистәсендә эшлим, ә ял көннәре саен Казан тарафына чыгып чабам. Шунда мине серле автор белән яшьтәш дустым Нияз Акмал таныштырды:

– Шаһинур шалтыратты. Чемодан тутырырлык китап җыйган икән. Кичке алтыга Кукмара поездына билет алдым, син, дускаем, давай, мине озатып куй әле, ди. Ул Хөсәен Ямашев премиясенә дә лаек булды, әйдә, киттек, берочтан аны котлап та кайтырбыз, – ди.

Ялгышмасам, Болак тирәсеннән тимер юл вокзалына чаклы Шаһинурны озата киттек. Әллә хәйләкәр, әллә ачык күңелле булып чыкты инде, Шаһинур да: «Сине укып барам, матур язасың?» – дип, салпы якка салам кыстыргалый. Каләмне әле чарлап кына маташкан чак, үземнән өлкәнрәк булган каләмдәш бәясе башны әйләндерә. Поезд вагоны янына килеп җиткәч кенә, инде түшенә элгән Ямаш медаленә дә күз төшереп алырга рөхсәт итте ул. Утыз яшьлек чагында ук республика журналистлары арасында әйдаманга әверелсен әле, көнләшмичә түз, ди!..

Шуннан ары Шаһинур дустым белән гел кочаклашып кына күрешә торганга әвереелдек. Танышуыбызга 40 еллап вакыт үткән икән, кайларга гына бергә бармадык та нинди генә хисләр кичермәдек!

Шаһинурдагы олы җанлылык, киң күңеллелек һаман сокландыра. Анысын аеруча Казаннан шактый еракта, Киров өлкәсенең Түбән Шөн авылында яшәп ятучы әдип Рафаэль Сибат янына барып йөргән чакларда күрдем. Рафаэль үзенең яшьлегендә, күзе төшкән бер кыз янына дип, безнең авылга гына түгел, хәтта урамыбызга килеп йөргән булган. Беләкләре дага сындыра алырлык куәткә тиң, әмма, ни галәмәт, яз җитүгә, аяклары хәрәкәтләнүдән туктап, берничә атна буена газап чигә икән. Компьютер яки язу машинкасы дигән «җәфалар»ны белми, аның каравы, сәйлән тезгән төсле, каләм белән үтә матур яза. Чаллыдагы «Мәйдан» журналын нәшер итүче булгач, Рафаэльнең роман-повестьларын алып та киткәләдем. Әүвәл берәм-берәм итеп, аннары инде махсус санга туплап та дөньяга чыгардык; фәкыйрегез тырышлыгы илә ике-өч китабы да пәйда булды. Рафаэль белән кулга-кул тотынышып яшәгән «Яңа тормыш» колхозы рәисе Рәфыйк абый Рәүпов, тагын бер-ике Шөнле – дуслар булып киттек. Рафаэль янына юл ешайды, шушында йөри-йөри, Гариф абый Ахунов, Илдар абый Юзеев,



*Кукмара районының «Яңа тормыш» арендачылар берлегенә Казан, Чаллы әдипләре, журналистлар, еш кына кунакка килеп, әдәбият һәм матбугат көннәре үткәрә торганнар иде. Беренче рәттә сулдан уңга: Татарстан Язучылар берлегенең шул чордагы рәисе Фоат Галимуллин, каләм әһелләре Рифә Рахман, Рәшит Бәшәр, Мәгъсум Насыйбуллин, Рәфыйк Рәүпов (хуҗалык рәисе), Мәдинә Авзалова, Габделбәр Ризванов, Заһид Мәхмүди; икенче рәттә – район газетасы редакторы Мирзахмәт Идрисов, хуҗалыкның шефы – тегү фабрикасының директоры Анатолий Голов, язучылар Рашат Низами, Вахит Имамов, Шәмсия Хәлимова, Факил Сафин, Рафаэль Сибат, Шаһинур Мостафин, Газинур Морат. 1999 елның 13 ноябре. Татар Толлысы авылы. Мидхәт Шакирҗанов фотосы.*

Шәүкәт абый Галиев белән әшнәгә әвереледек. Өлкән каләмдәшләр белән мәктәптә очрашулар, сәхнәдә чыгыш ясауларны тасвирлаган сурәтләр генә түгел, ат арбасында, салам эскертендә аунап төшкәннәре дә гаилә альбомында кадерләп саклана...

Шаһинур тумышы белән Мамадыш каһарманы. Ел саен 15 гыйнвар көнне уздырыла торган Шәйхи ага Маннурны искә алу чараларына да иң әүвәл ул дәште. Туган-үскән җирендә шагыйрьгә мәхәббәтне, әдип ядкәре авылны саклап калуын һәм төптән яңартуын тәү мәртәбә менә шунда күрдем. Шуннан ары Шәйхи аганың Тулбаен гына түгел, райондагы иллегә якын авылын урап чыктым, газиз Татарстанымның гүзәллегенә шулар аша тәмам гашыйк булдым.

Кече Кирмән авылындагы мәктәп ихатасында әлеге төбәктә туып үскән сугыш һәм хезмәт батырларына һәйкәлләр калкып чыккан икән, монда, директор-каләмдәшебез Рафаил Газизов тырышлыгы белән бергә, аны шушы эшкә рухландырган университет буенча сабакташы Шаһинур дустыбыз тәэсире дә бар бит. Ә Мамадыш үзәгендә 8 баласын (!) сугыш кырларында югалткан Герой-Ана, тыл каһарманы Фатыйха апа Әхмәдиева һәйкәле калкуда, иң беренче чиратта, һичшиксез, Шаһинур Мостафинның өлеше зур. Аның «котыртуы» һәм йөгереп йөрүе нәтиҗәсендә район үзәгендә «Батырлар аллеясы» пәйда булды (һәйкәл-сыннарның скульпторы – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Әлфәрит Әбдрәшитов); туган төбәк тарихына багышланган музейлар ачылды; ел саен аның җитәкчелегендә Шәйхи ага Маннур бәйрәме шаулап үтә. Гомумән, Мамадыш җирендә Шаһинур ымыннан башка «җил дә исми, яңгыр да яумый» сыман. Ул Мамадышның сөекле баласы, мактаулы гражданины. Аның өчен мин дә горурланам. Әйткәч-әйтим: үз төбәгенең җитәкчеләре белән кулга-кул тотынып, үзара аңлашып һәм аларны яңадан-яңа идеяләре, башлангычлары аша рухландырып яши торган башка бер әдипне дә белмим...

Сүз дә юк, матур итеп нотык тоту белән генә үрнәк биреп булмый. Шаһинур бик сирәк каләм ияләре генә сайларга җөрьәт иткән эзтабарлар сукмагыннан китте. Илдәге Кораллы Көчләрнең Подольск каласында урнашкан төп архивына барып, Шаһинурдан да артыграк казынган татар журналисты булмагандыр да әле. Иртәнге тугызда ук өстәлләр артына кереп утырган каләмдәшемнең кичке тугызда бик теләмичә

генә архив документларын тапшырырга мәҗбүр булуы, үзем дә унике ел буе архивта чокынган кеше буларак, шактый анык рәвештә күз алдыма килә. Эзләнә башлаган җеп очын инде таптым, дип өметләнгәндә генә, газиз шөгыленнән мәхрүм итүләре нарасыйны ана күкрәгеннән аеруга тиңдер. Ләкин өлкән агайлар урнаштырган тәртип әнә шундый: иртәгә янә таң сәгате белән өр-яңадан «казый башлау» өчен гайрәт туплап килә белү кирәк. Нәкъ шундый үҗәтлек нәтиҗәсендә, Шаһинур архив материаллары арасыннан Шакирҗан Мөхәммәтҗанов – Александр Матросов батырлыгын кабатлаган 20 татар каһарманының исемен эзләп тапты. Татарстан матросовчылары арасында тагын дүрт урыс, бер чуваш герое бар. Ә инде Советлар ватаны буенча санасаң, андыйларның гомумсаны 478гә җитә икән. Дзотка күкрәге белән капланганнан соң, Ходай миһербанылыр, фидакарь шәхесләрнең фәкать тугызы гына исән-сау калган... Шул ук чигенү белмәс холкы ярдәмендә, остазы Рафаэль ага Мостафин кебек, Шаһинур Муса Җәлил, Гайнан Кормаш белән бер үк легионда, бер үк яшерен оешмада фашистларга каршы көрәшкән татар каһарманнарының исемнәрен, кылган гамәлләрен бөтен Советлар илен гизеп ачыклады. Тынгысыз җанлы Шаһинур янә Бөек Ватан сугышы чорында яки Беренче Бөтендөнья һәм Гражданнар сугышы елларында батырлык кылган бихисап якташларыбызның данлыклы исемнәрен туганнарына һәм халкыбызга кайтарды...

Югыйсә ул үзе дә якты җиһанга зур могҗиза белән генә туган егет ләбаса! Аның әтисе Әхмәтсафа да 18 яшендә дошман дзоты амбразурасына капланган һәм, җиде ай буе госпиталь өстәлләрендә теккәләгәч һәм ямагач кына, исән кала алган. Ярымгарип, дөм сукыр булып туган авылы Арташка (Мамадыш районы) әйләнеп кайткан егет Гөлзәйнәп исемле кызга өйләнгән. Ирле-хатынлы Мостафиннар гаиләләрен, бер-бер артлы, унбер сабый белән баетканнар!

1948 елның 12 февралендә туган Шаһинур шулар арасында иң өлкәне. Холкына хас булганча, аларның һәркайсын кулларыннан җитәкләп баручы, үрнәк бирүче, җаннарына туганлык хисе һәм армас көч өстәүче, җыйнап кына әйткәндә, гаилә ткасы ул! Мин аның туганнары өчен янып-көеп йөрүен күреп гаҗәпләнәм, әти-әнисенә карата гомер буена сакланган хөрмәт һәм мәхәббәте дә нык сокландыра. «Менә шундый итеп яши белсәң иде!» дигән таң калу сүзләре дә, иң беренче чиратта, эчкерсез һәм сабый җанлы Шаһинур дускаема карата әйтелгәндер. Аның белән Чаллы, Мамадыш, Кукмара, Алабуга, Минзәлә җирлегендә, күршедәге Ижау каласында дистәләгән кичәләрдә катнаштык. Каләмдәшемә карата укучылар мәхәббәтен күреп, аңа ихтирамым тагын да арта төште...

...Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре, ике мәртәбә «Бәллүр каләм» иясе, РФның М.Ломоносов исемендәге алтын медаленә һәм Кол Гали исемендәге Халыкара премиягә лаек булган Шаһинур Мостафинның иҗатташлар теленә менгән матур гадәте бар. Ул очрашкан, сәламләшкән һәрбер танышына бер үк гыйбарәне әйтми китә белмәс:

– Рәхмәт сиңа, дустым, рәхмәт, рәхмәт!

Үзен «акылга утыртмакчы» булып, кайбер очрашулардан соң юри төрттергәнем бар:

– Иренмичә санап утырдым, «чын күңелдән» тәкъбирен – 39 мәртәбә, «рәхмәт»еңне 57 тапкыр кабатладың!

Җавап урынына дустым авызыннан һаман шул ук сүз:

– Ялгышмыйча санаганың өчен рәхмәт сиңа, дустым, рәхмәт!..

Казан – Мамадыш юлындагы Рәхмәт(улла) Аланын да Шаһинурныкы, дип атауга чаклы барып җиттек. Ә дустымның йөзендә гел елмаю. Әнә шундый якты учак, һәрбер милләттәшеңне үз янына тартып торучы җылы учак булып яши белүең өчен рәхмәт сиңа, дустым, олы рәхмәт!

**Вахит ИМАМОВ,**
*Татарстан Республикасының*
*Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты*

# ШИГЫРЬЛӘРЕ – ГОМЕР МИЗГЕЛЛӘРЕ

*Еламыйм, дим – елата,*
*Уйламыйм, дим – уйлата.*
Гөлзадә Бәйрәмова

Гап-гади ике-өч сүзне берничә шигъри юлга салып, күңел мизгеленнән сөйләп бетермәслек кичерешләрен үтемле итеп сурәтли белү – шигърияттнең төп вазифасыдыр. Ә инде үз холкыңның тынгысыз үҗәтлеген бер кискен юл белән ачып салу – осталык, талант билгеседер. Гөлзадә Бәйрәмованы язмышыннан зарланып, елап кына йөри икән дип уйламасыннар тагын. Көлә дә белә, сөя дә белә, эшли дә белә, яше илледән узса да, һаман белем дә эсти белә ул. Шигырьләр – гомер мизгелләре. Тәүлек буена, гомер буена барысы да үзгәрергә мөмкин. Шушы мең төрле үзгәрешләр нигезендә, шәхеснең төпле, какшамас холкы, тормышка карашы, яшәү рәвеше формалаша.

*Шомландырып күңелләрне,*
*«Их, дөньясы!» – димә әле.*
*Туар көннәр бүгенгедән*
*Мең мәртәбә булыр ямьле.*

Өмет яшәтә кешене. Бүгенге көндә кара козгын телебезне умырганда да, милләтебез таянычсыз калганда да, өмет булганда, әле тырышабыз, елый-елый, булган тарихыбызга, нигезебезгә ябышабыз. Киләчәк, балалар, оныклар өчен борчылабыз. Читтән бернинди ярдәм булмаячак. Таянычыбыз – бары үзебез, халкыбыз.

*Дөнья шулай, татлысыннан бигрәк,*
*Ачыларын күбрәк ашата.*
*Падишаһ та ясый, мәхбүс-кол да,*
*Зинданнарга салып таптата,*

– дип яза Гөлзадә, фин сугышыннан бер кулын югалтып кайткан, ялган әләк буенча төрмәгә эләккән әтисенә багышланган «Ил кадерен белер илсез калган» исемле шигырендә. «Нигә малай булып тумадың икән син, кызым?..» – дип әйткәләгән әтисе үзе дә, кул арасына бик иртә кереп, үзенә булыша башлаган кызына.

*– Сызгыр әле, кызым, яңгыратып бер,*
*Их, малай булып калган туасың! –*

*Дия идең миңа һәрчак шулай,*
*Урманнарда печән чапканда;*
*Йөк өстенә йөгереп менеп китеп,*
*Бастырыкка аркан такканда.*

*Сыңар куллы әти, мин үсмер кыз,*
*Сабыйлыгым чыгып бетмәгән.*
*Сәнәк-тырмаларым онытыла,*
*Җир җиләге күренеп киткәндә,*

Башка мисаллар буенча да яхшы беләм – андый гаиләләргә авылларда кырын карап, исәнләшмичә үтүчеләр дә, хәтта «халык дошманы», дип ысылдаучылар да булган. Мондый мәгънәсез дошманлык Бәйрәмовлар гаиләсендә тирән яра калдырган, күрәсең. Күптән белгән авылдашлар арасында мондый «тамга» белән йөрү җиңел булмагандыр, ләкин, шул ук вакытта, чыныккан, каешланган талантлы шәхесләр тәрбияләүгә зур өлеш керткән, ә тормыш моны исбатлап кына тора. Авыл ул үзе бер зур гаилә һәм бу зур гаиләдәге кимсетелүләр гомер буена онытылмый. Әлеге яраларны вакыт та, күпкә соңга калып килгән үзгәрешләр дә төзәтә алмый. *«Тигезләде дөнья һәммәсен дә, / Синең исем күптән акланды»*.

Аянычлы, үкенечле аклаулар...

Бүгенге көндә хатын-кыз язучыларыбыз, шагыйрәләребез татар әдәбияты арбасына җигелеп, аның Олы йөген ир-атлар белән бер дәрәҗәдә диярлек тарта. Җентекләбрәк карасаң, кызларча яза торган егетләр дә, егетләрчә яза торган кызлар да бар икән. Кызларча язу әллә ни кыен түгелдер. Кызларга егетләрчә язу өчен, егетләр холкы кирәк.

Гөлзадә Бәйрәмова нечкә күңелле, хисле хатын-кыз затыннан булса да, аның холкында егетлек, шигырьләрендә һәм язмаларында кырыслык, кискен турылык, кыска сүзлелек, тайпылышсыз дөреслек бар. Тик холкың нинди генә булса да, мәхәббәт үзенекен итә, эретә, йомшарта: *«Иелерлек башлар идемени, / «Сөям», дигәч, мин дә иелдем»*.

Әйе, егетләр мәхәббәте күңелләрне эретә ала, ләкин хатын-кызлардагы егетлекне, тайпылышсыз көчле холыкны яратмый шул. Көчле гүзәл затлар арасында ялгызлар күп.

Бу дөньяда тагын да аянычлырак ялгызлык бар әле. Монысы инде үлеп барган авыллар ялгызлыгы. Милләтнең саулыгын, гореф-гадәтләрен саклап килгән авыл бүген, күп очракта, йә бетеп килә, яисә, берән-сәрән генә булса да, үзенең йөзен, үзенчәлеген, чисталыгын югалтып үзгәрә, заманга яраклаша. Бөтен илгә шаулаган, 4-5 мәчетле, хәмер сатылмый торган, динле-иманлы берничә авылны да беләбез һәм аптырыйбыз – башкаларга нәрсә комачаулый соң? Милләтне һаман кысрыклап килгән, бөтенләй башка менталитетлы зур ил уртасында яшәү дә комачаулыйдыр. Татарның макталган тырышлыгы, эш сөючәнлеге аңа зыян гына китерде кебек. Халкыбыз үз илендәге гаделсезлектән, ясалма хәерчелектән бөтен дөньяга таралды һәм беркайда да югалмады, фәкыйрьлеккә батмады. Димәк, безгә монда, бу илдә үләргә «булышалар». Хәерчелеккә батып үлеп барган авылларыбызны күргәндә, шундый фикер генә туа. Соңгы айларда телебезгә каршы барган һөҗүм, бу «үтерү»нең бер өлеше кебек кабул ителә. Әле һаман да ялган әләк язучылар безнең белән идарә итә...

*Керү сукмакларын әрем баскан,*
*Аралыймын аны як-якка.*
*Тигәнәге сарыла бәгыремә,*
*Әрем исе әрни йөрәктә.*

Үземнең дә, чүп үлән баскан туган йортым нигезендә шундый ук хисләр кичереп, сызланып торганым бар. Бала чагым узган нигездәге үләнне чүп дип әйтәсе дә килми. Алабута, кычыткан, әрем, тигәнәк... Анда хәзер нигез дә юк инде. Йөрәк никадәр әрнесә дә, «әрем исе әрни йөрәктә», дип, шагыйрьләрчә әйтеп бирә алмадым.

Шигырь өчен хисләр киеренкелеге, кичерешләр көчәнеше, тынгысыз йөрәк кирәк. Шуларга тагын талантыңны, тырышлыгыңны өстәсәң, йөрәктән йөрәккә үтеп керерлек әсәрләр иҗат итәргә була. Талант белән тырышлык – мәҗбүри шартлар. Туң йөрәкле, битараф күңелле адәмнәр дә аз түгел бит. Тик болары вакытлы күренештер. Бу аяусыз тормыш барыбер үзенекен итә, сикәлтәле юлларда сикертеп, тетрәтеп ала. Чыныкмаган, гамьсезлектән мәрткә китеп барган ваемсызлар өчен кечкенә генә сынаулар да кайвакыт бәхетсезлеккә, һәлакәткә әйләнә, таза-таза тәкәббер генә күкрәк кагып йөргән тәти егетләр дә елак имгәккә әверелә. Мин боларны үзем күреп, тормыш тәҗрибәсеннән чыгып беләм. Ә минем язмыш гади генә булмады...

Шагыйрь өчен гамьсез тормыш үлем белән бер. Ул хәтта яшен утына да кулын сузарга әзер: *«Шул яшеннең бер чаткысы / Төшсен, димме, күңелгә. / Кара күмер кебек күңел – / Сүнми дә, дөрләми дә»*.

Дөрләмәгән тормышның яктылыгы булмый инде. Ялкынсыз пыскыган күңелгә җан өрергә кирәк, бу җан өрү чытырдатып суккан яшеннән булса да, ахыры куркытмый.

Тормыш кырыслыгында әвәләнеп үскән, күрәчәген күреп чыныккан Гөлзадә Бәйрәмова кайвакыт күп уйлап тормый – рәвеш-стиль, ритм-рифма кебек шигъри кануннарга артык игътибар итмичә, туры сүзен әйтә дә сала һәм, эчтәлеге белән, килеп чыккан кытыршылыкларны шомарта да куя, үзенең гадилеге белән әсәрләренә шигъри очкын сала. Аның гадилегендә катлаулы тормыш юлының кыен-кискен борылышлары ята. Ул сүзләр белән дә, хисләр белән дә уйнамый, күңелендә ничек бар – шулай яза. Шәхсән үзем, рәвешнең эчтәлеккә йогынтысы (рәвеш эчтәлекнең тәэсирен бермә-бер көчәйтә ала) зур дип саныйм. Ләкин, ахыр чиктә, фикер яңалыгы яисә шигъри ачыш, камил рәвеш калыбына салынмаган булса да, яңалык һәм ачыш булып кала. Кайвакыт ялт итеп торган кимчелексез әсәрнең эчке бушлыгы гаҗәпләндерә.

Шигырь шундый нәрсә ул – инде исемле, тәҗрибәле шагыйрьләрнең шигырьләрендә дә теге яки бу яктан ниндидер «кимчелек» булмый калмаска да, кемгәдер нәрсәдер ошап бетмәскә дә мөмкин. Гөлзаданең шигырьләре дә «кимчелексез» генә дип әйтеп булмый, ә эчтәлексез дип әйтергә тел әйләнми.

Әлеге уйлануларым минем Г.Бәйрәмованың «Дөнья шигырь яздыра» дип исемләнгән шигырьләр китабын укыганнан соң туды. Аның чәчмә әсәрләре дә (повесть-хикәяләр, публицистик язмалар, әңгәмәләр...) аерым игътибарга лаек. Ул әлеге язмаларны «Син һаман шул сандугач» дигән исем астында аерым бер китап итеп чыгарган. Шул ук исемле повестен укучылар яратканнар иде. Әсәр геройларның хис-кичерешләрен сурәтләүгә нигезләнгән. Әйе, Гөлзадә Бәйрәмова вакыйгаларны ясалма сузып, озаклап сурәтләп, күз яшьләре сыгарга яратмый. Кыска, кырыс сүзләр белән дә тетрәндерерлек әдәби сурәтләр ясый.

Бу китапта шулай ук күренекле, олы шәхесләребез турындагы мәкаләләр, алар белән әңгәмәләр тупланган. Алар турында язу, бер яктан, җиңел дә, икенче яктан, бик кыен да. Ничек кенә булса да, Гөлзадә мондый зур эшне башкарып чыга алган. Әлеге әсәрләр арасында мине тетрәткәне авторның «Дисбемнең өч төймәсе» дип аталган автобиографик язмасы булды. Өч бүлеккә («Әби», «Әни», «Апа») кыйссаларга җитәрлек эчтәлек сыйган. Ул монда да озын-озак итеп, тартып-сузып язмаган. Саллы-саллы фикерләрне, аяусыз фактларны җыйнак һәм үтемле итеп, буяулы пумала тоткан рәссам кебек кәгазьгә төшергән.

Авыл җирендәге бала кечкенәдән үк авыр эшкә өйрәнеп үсә. Үзем үскән балалар йортында да кечкенәләр ярылган утынны кырмыскалар кебек зур сарайга ташыйлар иде. Ә без, уналты яшьлек егетләр, шул ике-өч метрлы юан-юан агачларны Арча станциясендә йөк машинасына төяп ташый, бушата идек. Күз алдына китерегез, машинага сыйган кадәр утын төялгән, шуның өстендә без, чокырлы-чакырлы авыл юллары буйлап 20 чакрым кайтабыз. (Хәзерге ЮХИДИ хезмәткәрләре дә, балалар хокукын яклаучылар да әлеге күренештән акылдан язарлар иде...) Әле бу «почётлы» эшкә теләсә кемне алмыйлар да иде. Күз атып йөргән кызларга өстән генә карап узу – үзе бер дәрәҗә бит! Утынны бушаткач, бик эшлекле кыяфәт белән, салмак атлап, ашханәбезгә керәбез. Башкалар режим буенча ашый, ә без – «особый»лар. Инде үсеп җиттек, беребездә дә мондый авыр хезмәт өчен үпкә хисе калмады. Бар яктан дип әйтерлек, үзебезне үзебез карый идек. Алдагы мөстәкыйль тормышта да шулай булды.

Әйткәнемчә, ишле гаиләдә үскән Гөлзадә Бәйрәмова да туганнары белән бергәләп тир түгеп көн күрүне татып үскән.

«Җәйге чиллә. Чөгендер кыры башында «уфалла» арбасы өстерәгән берничә бала мәш килә. Кайсы арба тарта, кайсы эт эчәгесе, чүп үләне китереп сала. Эш белән мавыгып, яннарына колхоз рәисе машинасы килеп туктаганны сизмиләр дә. Колхоз кырын «таптаганнары» өчен, рәис арбаның тәгәрмәчен салдырып китә. Чөнки белә, бер куллы этиләре тәгәрмәчне рәтли алмаячак...»

Колхоз кырларында без дә печән җыя идек. Печән җыю дигәне – шул чүп үләне утау бит инде. Ләкин, бригадирлардан бик курка идек, куалар иде. Яшелчә бакчасыннан кыяр урлаган өчен кусалар да аңлашыла. Ә чүп үләне өчен... Хәзер Совет чорын сагынучылар да күбәйде. Бәхәсләшәсем килми, яхшы яклары да бар иде. Шул ук

вакытта шәфкатьсезлек тә, мәгънәсезлек тә артыгы белән булды. Үз гаиләсенә кагылмагач, моны кайберәүләр аңлап та бетерми. Хәер, чоры гаепләме монда, әллә аерым-аерым денсез, котырган вак-төяк түрәләрме – аңлап бетермәссең. Уйлаган саен гаҗәпләнәм, нинди коточкыч коллыкны халык дәшми генә, карышмый гына, шулай булырга тиеш дип кабул иткән. Шулай тилмерү аның ДНК молекулаларында генетик эз калдырган кебек. Без бит хәтта сайлауларда да үз-үзебезне иректе тота белмибез, кемгә кушалар, шуңа тавыш бирәбез. Шундый юл белән сайланган икән, андый шәхестә өмет юк инде. Угры, денсез чиновниклар турында тикшерелгән, нигезләнгән күпме язмалар укыдым, күпме видео күрдем. Ә җәнҗал «геройлары»на җил дә, яңгыр да тими, күбесе депутат булып өлгергән. Ә аларга кагылырга ярамый. Тавыш бирүне дә нәкъ шундыйлар «көйли», үз ишләренең иминлеген тәэмин итә. Беләбез, тик дәшмибез. Якын арада кискен үзгәрешләр көтеп булмый.

Соңгы елларда бер ханым үзенең берсе артыннан берсе язылган чәчмә әсәрләре белән бик танылган язучыга әйләнде. Укучылары, нигездә, хатын-кызлар, «елый-елый укыдык, укыйбыз...» диләр. Мин дә укып карадым, беренче битен, һәм үземне «туң йөрәкле кешедер мин», дип уйладым. Максатым – ул китапларны хурлап, авторының дәрәҗәсен төшерү түгел. Әдәбият белән кызыксыну шактый кимегән чорда күпме милләттәшебезне китап укыта алуы да аерым мактауга лаектыр. Булдырган. Шуны гына көтәм: сан исәбе кайчан сыйфатка әверелер икән? Минемчә, беркайчан да. Елый-елый уку – сыйфат, тетрәнү билгесе түгел. Югары сәнгати дәрәҗәдә язылган әсәрләрне укырга һәркемнең дә көче, әзерлеге, рухи нигезе җитешмәскә дә мөмкин. Андый авторларның үз укучылары, үз катламы, алар күпчелек түгел. Интернетта, буыннан-буынга күчеп, инде таушалып беткән, шигырь итеп куелган декларатив сүз тезмәләренең дә үз укучысы бар. Һәркем үзенекен сайлый.

Кечкенәдән күп укыдым. Җанымны тетрәткән әсәрләр дә аз булмады. Хәтерлим, Воронеж язучысы Гавриил Троепольскийның «Ак Бим Кара Колак» исемле роман-газетаны бер танышымның үсмер кызына бирдем. Бер атнадан кызның әнкәсе: «Балконга чыгып елый-елый укыды», – диде. Ышанам, бу күз яшьләре тетрәнү-чистарыну, ягъни катарсис булгандыр. Хәзер инде ул кызның үз оныклары бар. Шулай да балконда укылган әсәрне ул әле дә онытмый. Әйтерләр, тапкансың мисал, тапкансың чагыштыру... Ләкин эш монда башкада. Менә Гөлзадә Бәйрәмова әсәреннән бер мисал (сүз 1921 елда Идел буендагы ачлык турында):

«Аерым-аерым кабер казып тора алмадылар, казырга кешесе дә юк, үлүчесе дә күп иде. Зур бер чокыр казыйлар да барчасын берьюлы күмәләр. Мин дә алты баламны бергә салдым. Чокырны күмәргә ашыгалар. Әле кечкенәмнең, җан биреп бетереп, җылысы да суынырга өлгермәгән, бишеге белән төшереп куйдым». Боларны, ачынып, Гөлзадәнең әбисе сөйли торган була. Менә кайда ул чын, аяусыз тетрәнү!


Шушы арада миңа Кукмара районының Балыклы авылы тарихы турында басылып чыгарга тиешле китапны тикшерергә бирделәр. Озакка сузылган искиткеч зур эшне җентекләп эшләгәннәр. Татар күргән, әле без белмәгән күпме газап, михнәт тулып ята икән тарихыбызда! Инде күпне беләм кебек иде, бу китап мине тетрәтте. Китапны әзерләүче Фирдания Нугаева: «Мин әле күп кенә хәлләрне монда кертмәдем», – диде һәм сөйләп тә күрсәтте. Ул сөйләгәннәрне китапта чыгарырга ярамый. Укучыны да бераз җәлләргә кирәк... Әйтәсе килгәнем шул: күпчелек, елый-елый, егыла-егыла, шикле язмаларны укыганда, чын әдәбият, тарих, хакыйкать, тетрәнү-чистарыну, камиллеккә хәрәкәт читтә кала түгелме? Ягъни битараф наданлыкка юл тотабыз түгелме?

Танылган шәхесләребез турындагы мәкаләләрдә, алар белән әңгәмәләрдә дә Гөлзадә Бәйрәмова, иң мөһимен эләктереп алып, кыска, төгәл итеп, шәхеснең холкын, иҗатын, аларның тормыш юлын күрсәтә, ача белә, буш сүзле лирика белән мавыкмый. Кыскасы, фикерле шигърият, шәхесне зурлый торган әдәби портретлар язу – аның иҗатының төп асылы. Әле гомер уртасына гына якынлашып килүче Гөлзадә Бәйрәмовага яңадан-яңа иҗади уңышлар телик.

**Рәниф ШӘРИПОВ**

# ТАПКЫРЛЫКТА – МАТУРЛЫК

## РИНАТ МӘННАН «КЫТЫКЛАРЫНА» БЕР КАРАШ




Тапкыр сүзгә һәм очкын фикергә маһирлык халыкның характерына һәм рухи дөньясының байлыгына бәйле. Сүз сәнгатенең сатира һәм юмор төрендә туган тәҗрибәләр татар кешесенең иң яратып тыңлаган, укыган әсәрләре рәтендә йөри. Телебезнең сыгылмалы байлыгына ишарә итеп торган шаян җырларны, такмакларны, йомшак җәеп, катыга утырта белгән мәкаль-әйтемнәрне, асылташ кебек, телдән-телгә күчеп, гасырлар акылын сыйдырган хикмәтле сүзләрне, Тукай «Халык әдәбияты»нда үрнәк итеп китергән «Касимский Ибырай», «Җизнәкәй», «Башмак көе»н генә алыгыз! Аларда шаярту артына яшерелгән, таң кебек кыска гомернең кадерен белергә өйрәткән акыллы киңәшләр! Авыр, четерекле тарихи юлында көлү татар кавеме өчен хаклыкны ялганнан аеруда арадашчы, яшәешнең җилдавылларында исән калуга өйрәтүче, кайгыда юаныч, шатлыкта якын сердәш, үз бәхете, халык хокукы өчен көрәштә киңәшче булды. Тормыш-көнитешкә якынлыгы, халыкның төрле катлаулары арасында киң абруйда йөрүе, таралуы ягыннан бәяләгәндә, һөҗү белән җыр жанры гына ярыша ала.

Аерым сыйфатлары көлү вә усал «чеметү» булган сатира һәм юморның (соңгы атама татарның «йомры» сүзеннән алынмадымы икән?) мондый популярлыгы аларга таләпне бермә-бер арттыра, әдәбиятыбызның бу тармагы нindирәк юнәлештә үсә икән, дигән сораулар уята.

Ошбу нәзари вә гамәли сөальләр балаларга атап язылган «Табиб әлифбасы», «Исхакый әлифбасы» тупланмалары, күбесе төрле чорда «Чаян» журналында басылган кыска, шаян парчалар, пародияләр, багышлаулар, эпиграммалар, Һ.Такташ образын тудырган поэма авторы Ринат Мәннанның юбилее уңаеннан Татарстан китап нәшрияты бастырып чыгарган «Минем яратканнарым» *(2016. – Б.141)* исемле китабы белән танышу барышында туды. Җыентыкның тышлыгында язылганча (юморист булса да, алдашмый торгандыр инде), Ринат Мәннан (Архипов Ринат Николаевич), 1946 елның 6 февралендә (кышның иң буранлы вакытында) Чистай шәһәрендә туып, Казан дәүләт медицина институтын тәмамлагач, гомере буе табиб булып эшләгән. Гелән урысча гына укыган егетне телебезнең нечкәлекләренә (юморның нигезе – сүз уйнату) әнисе – татар хатыны өйрәткәндер, «Микулай дәдәй» каршы килмәгәндер, дип чамалыйм.

Россия һәм Татарстан Язучылар берлекләре әгъзасы Р.Мәннан К.Насыйри исемендәге һәм тагын әллә ничә конкурслар бүләге лауреаты да икән. «Минем яратканнарым» җыентыгында, шигъри сатира белән юморның поэма, әкият, скетч, памфлет кебек төрләреннән башка, барчасы үз жанрлык мөмкинлекләрен ачып салырга «тырышканнар». Юмористик шигырьләр, пародияләр, эпиграммалар, багышлаулар Р.Мәннанның иҗади алгарышын, үсеш юнәлешләрен шактый тулы күзалларга мөмкинлек бирә.

Р.Мәннанның «кытыклары» белән кызыксынучы мин беренче түгел икән. Тәнкыйтьне юмористның эзләнүләренә илтифатсызлыкта гаепләргә сәбәп юк имди.

Анның күләме ягыннан тыйнак җыентыклары Ленар Шәехне «Ялкау өстәл»дә ниләр бар?», Мансур Вәлине «Үзе табиб, үзе шагыйрь» мәкаләләрен язуга рухландырган. Барлас Камалов «Мәдәни җомга»да басылган мәкаләсендә *(1999, 22 окт.)* мәсьәләне «кабыргасы» белән «үзеңне чеметү авырмы?» дип куя. Шагыйрьнең әсәрләренә иң төгәл бәяне күренекле сүз осталары Зөлфәт белән М.Әгъләм биреп калдыра. «Үтә дә төгәллек һәм җыйнаклык таләп итә торган бер жанр бар: эпиграммалар һәм пародияләр, – дип яза Зөлфәт. – Әдәбиятның бу өлкәсенә мөрәҗәгать итүче шагыйрьләребез күп түгел... Ниһаять, шушындый нәзберек эшкә тәвәккәлләгән кеше табылды. Безнең «Чаян»да канат ярган Ринат Мәннан юмор шикелле затлы жанрның серләренә төшенеп бара». Иманым камил, киң күңелле шагыйрь Р.Мәннанның әлеге җыентыгына тупланган, соңгы елларда иҗат ителгән шаян шигырьләрен, пародия белән эпиграммаларын да хуплар, дусларча җылы сүзен дә әйтер иде.

Тукай шикелле, мәдхияне тешен кысып, чыраен сытып кына чыгарган М.Әгъләм сүзен классиканы, бу очракта Ш.Бабичның «Исемнәр бакчасы»н искә төшереп, аны «Таң калырлык эпиграммалар, пародияләр», дип бәяләп, Р.Мәннанның «Төртмә телле юллары игътибарга лаек», дип үсендереп ала да, катгый таләбен калкытып куя: «Андыйларны читкә тибәрмәскә кирәк. Алардан усал әйберләр таләп итәргә кирәк». Сүз сөрешеннән, күплек саны куллануыннан аңлашылганча, М.Әгъләм бер Р.Мәннанны гына истә тотмый, бу жанрга мөнәсәбәте булган барча каләм ияләрен «эпиграммалар короле» Бабичтан үрнәк алырга, халык мәнфәгатьләрен яклап, җитешсезлекләрне кояш яктысына чыгарып, каләмнәрен кыюрак уйнатырга чакыра. Дөрес, әдәбият тарихы җәмәгатьчелекне, зыялыларны тулысынча канәгатьләндергән бер үсеш чорын да хәтерләми. Хәтта XX гасыр башы сүз сәнгатебез дөнья классикасы дәрәҗәсенә күтәрелгән «алтын чоры» да «ура»га бәяләнмәгән. Тукайның «Тәнкыйть – кирәкле шәйдер», дип чәчрәп чыгуы шул хакта сөйли.

Тукайның комсыз дин әһелләреннән, ялган милләтчеләрдән каһкаһә белән көлгән сатирасы, памфлетлары шул елларда языла. Ш.Бабичның «Газазил», «Кандала» поэмалары, «Күренекле шәхесләр турындагы» эпиграммалар мәҗмугасы ритмик төгәллекләре, тел-сурәтләү чараларының байлыгы аша хәзергәчә һөҗү сәнгатенең казанышы булып кала.

Бөекләребездән соң да, совет хакимияте, социалистик реализм чорында да, шигъриятебезнең бу юнәлеше яулаган үрләрдән чигенмәскә тырыша. Ә.Фәйзи, С.Баттал, Ә.Исхак, Ш.Мөдәррис юмор-сатира утын сүндермәделәр. Сугыштан соңгы унъеллыкларда көлү сәнгате үзенә яңа буын шагыйрьләрне җәлеп итте. Зыя Мансур, Г.Афзал, Ш.Галиев, Ф.Шәфигуллин, безнең көннәрдә дә юмор – «кирәкле шәйдер», дип, гади тормыш чагылышында, кеше холкында кызыклы борылышлар, әкәмәтләр, сүз-фикер уйнату әмәлен тапкан Р.Миңнуллин «авыр йөкне» тартып бара.

Җитешсезлекләрне, кояш төшми торган почмакларны күреп борчылган яисә артык җитди яшәүдән гарык булган очракларда юмор һәм сатира ярдәмгә килә. Теләсә кайсы кырыс шагыйрь иҗатында һөҗү гонсырларын күреп алу өчен бинокль кирәк түгел!

Арабыздан киткән Ф.Яруллинның – мөлаем юморы, А.Вергазов – мәсәлләре, Р.Харис, Р.Вәлиев, Г.Морат, Л.Шәех, Р.Мөхәммәтшин, Р.Сәлах, соңгы чорда прозада да, шигырьдә дә «азынып» киткән А.Хәмзин эзләнүләре шул хакта сөйли. Һәркайсының иҗатына юмор, ямь бөркеп, елмаеп, күз сирпеп тора.

Кадерле укучым, гафу, читкәрәк киттем бугай, сүзебез бит Р.Мәннанның яңа китабы тирәсендә «куерырга» тиеш иде.

Икенче яктан, юмористның нинди традицияләргә таянып күтәрелүен искәртмәсәк, сөйләшүебез берьяклырак булыр дип уйлап, Г.Исхакый әйтмешли, «сүземезне» «зәңгәр офыктанрак» башлыйк.

Мәгълүм ки, Р.Мәннан безгә элегрәк «Анатомик театр» (2003), «Микроб» (2006) кебек тупланмаларында тыйб фәненең үзенчәлекләрен ачарга тырышкан иде. Ошбу китабында ул элеккеге һөнәрдәшләреннән яратып, «учына» көлүен дәвам итә. «Дәва», «Коткаручы» шигырьләрендә каһарманның хатыны белән уртак тел таба алмавыннан сүз уйнату, сурәтнең күпмәгънәлелеге аша ирештереп көлә. «Зур рәхмәт»тә авыруны берсе сукырайтса, икенчесе саңгыраулата. Өченче табибка сырхау рәхмәтле, чөнки

анысы – «Теш диеп, ул телемне ярый әле суырмады. Менә нинди белемле!» Шигырьдә, гипербола алымыннан башка, әллә ни шаккатырырлык яңалык та юк шикелле. Тик элеккеге күренекле врачның үзләренә тәнкыйть күзлеге аша карый алуы – үзе зур егетлек.

«Табиб фатирында», «Профилактика», «Сәерлек» кебек шаян юморескаларында иҗатчы социаль мәсьәләләрне калкытып куя.

*Өй буры сүзләре әле дә*
*Үзәкләремне өзә –*
*Алырга әйбер булмагач,*
*Өстәлдә язу калдырган:*
*«Дорогой, так жить нельзя!»*
(«Табиб фатирында»)

«Тел», «Тузан» кебек юморескаларында, табиблар белән бәйле комик борылышларны үзәккә алып, көлә дә, көлдерә дә.

Табиблардан көлгән шигырьләрнең барысын да хуплый алмадым. «Оча сөяге»нең фабула канвасын тәшкил иткән, хатын-кыз мәетен ирләрнеке белән бутаган булачак табиб турындагы мәзәк үткән гасырның 50-60нчы елларында ук ирләр мәҗлесенең үзәгендә «йөри» иде.

Түрәләрне тәнкыйтьләмәгән, төрле дәрәҗәдәге депутатлардан көлмәгән сатирик юктыр. Барча «үксезләрне» бер ояга җыйган «бренд» тема.

Түрәләрне көнләшү катыш кабул итмәвен Р.Мәннан дүрт сүздән торган юморескасына сыйдыра.

*Бәйрәмнәр –*
*Мөбарәк.*
*Түрәләр –*
*Түгәрәк!*
(«Менә шул»)

«Хурлыйлар» шигырендә, үткәнне каһәрләп, үзләренә миллионлап, миллиардлап табыш биргән «бу тормышны» мактаучыларны, үзенең гаделлек хыялыннан чыгып камчылый. «Сарайлар чоры»нда *«Алда-артта, уңда-сулда / Сарай сала түрәләр»*, дип, юри мактаган булып, матди тигезсезлеккә ишарә ясый.

Өстән күрсәткән адәмне үзебез үк сайлап куйгач, депутатларның, халык белән очрашуларда биргән вәгъдә-антларын онытып, шәхси мәнфәгатьләре белән генә шөгыльләнүләреннән көлгән сатирик әсәрләр буа буарлык. Тик, рус мәкалендә әйтелгәнчә: «А Васька слушает, да ест». Депутатларның чын йөзләрен ачуга Р.Мәннан да үз өлешен кертә.

«Сайлау» пародиясе, заманында совет хакимиятен, коммунистлар фиркасен күкләргә чөеп, бик күп панегириклар язган М.Садриның *«Сайлау йортларына киләбез, / Туйга килгән кебек киенеп»*, дигән купшы сүзләренә «ышанып», безнең көннәр кешесенең депутатка тавышын бүләк иткәнгә сөенүен үзәккә ала. Ни өчен тырыша икән сайлаучы? Юк, ул депутаттан үзенә берәр файда тияр, дип уйламый. Шулай хөкем итсәгез, бик нык хаталанасыз. Ул, сабый бала кебек, хөсетсез, риясыз, кеше бәхете өчен «шатлана» белә.

*Тавышымны мин биргәч тә,*
*И сөендем бит, малай.*
*Ник сөенмим? Депутатым*
*Көн итәр менә болай!*

Иртәгесе көннән сайлаучы минем «яклаучым», «саклаучым» «йөзә башлар ул майда!», «ичмасам, бер яшәп калыр», дип шатлана. Игътибар үзәгенә алынган

типны мактаган, үзен аның теләктәше итеп, шуңа күңеле белән ышанган беркатлы кеше кыяфәтенә керү – комизмның сыналган алымы. «Жәлләү» дүртьюллыгында да сайлаучы депутатына гел «изгелек», бәхетле, тук тормыш тели.

*Елына ничә тапкыр*
*Йөримен мин сайлауга –*
*Ярлылар депутат булып*
*Әверелсен дип байга!*

(«Жәлләү»)

Парчаның асылында яткан, һәр юлыннан бөркелеп торган ироииядә шагыйрьнең телдәге тапкырлыгы, фикерләүдәге үткенлеге күренә. Әйтәсе килгән уйның мантыйкый агышын расламаган нәтиҗә чыгару, төрле төшенчәләрне (хәерче сайлаучы – бай депутат) янәшә урнаштыру халыкның телдән иҗат иткән һөҗү культурасында күптәннән яши. Шуның кечкенә, әмма үтемле үрнәге: *«Пычрак эшне ташладык – дегет сата башладык»*.

Түрәләрне, депутатларны сурәтләгәндә, астыртын көлү алымын, ирониянe иркен кулланса, халыкның елдан-ел авыррак яшәвен, хезмәт хакының, шул исәптән язучыларга түләүнең мыскыл итү генә икәнен искә төшергәндә, ул кырыс, катгый, шаяртуың бер якта торсын!

*Китап язучы кайгыра:*
*– Кая бара бу тормыш?*
*Бер китап өчен гонорар –*
*Ике кесә көнбагыш!*

(«Бәя»)

Гаиләләрдә туган низагларның күбесе шул ук хезмәт хакының аз булуыннан килеп туа:

*Хатын, ачуланма мине,*
*Вәт хезмәт хакы айлык:*
*Эшемә барып җитәрлек*
*Һәм өемә кайтырлык.*

(«Хезмәт хакы»)

Миңа, тәнкыйтьче, татар шигъриятен өйрәнүгә гомерен багышлаган кеше буларак, аеруча пародияләр бүлеге ошады. Беренчедән, һөнәре буенча табиб кешенең поэзиябезне яхшы аңлавы, нәкъ пародия тудыруга «ризык» сыйфатындагы мисалларны нәзберек зәвык белән сайлап ала белүе бер гамәл булса, икенчедән, китерелгән шигъри өзектән өр-яңа фабула канвасын тудырып, көнүзәк мәсьәләләрне калкытып куюы күңелгә хуш килде.

*Мин елмаеп кына дөнья үзгәрерме?*
*Шундый сорау бәргәләнә җанда.*

Р.Низамиев каләменнән төшкән ошбу юллар хәзерге яшәешебезнең үзенчәлекләрен чагылдырган, төгәлләнгән сюжетның нигезенә ята. Бур кесәсенә керсә дә, фатирының ишегенә ачкыч тыкса да, тәмәкесен көйрәтеп, бакчасын яндырса да, тиле бәрән орлыгы ашаган кешедәй, ул һаман елмая. Ә иң соңыннан, күрәсен күргәч, дөньяны үзгәртергә кирәк, дигән нәтиҗәгә килә.

*Елмаеп булмаса, елап*
*Бер үзгәртәм мин аны.*

(«Елмаю»)

Киң күңеллелек, мәрхәмәтлелеккә чакырган шигырьне автор Ф.Әһлия иҗатыннан да табып ала.

*Каты куллы була күрмә,*
*Йомшаклыкта синең көчең!*

Илһамын «котыртып» җибәргән, битарафлыкка, түземлелеккә, баш иеп яшәргә өндәгән («барысына да түзәрбез, сугыш кына булмасын», дигән кебек) бу юллар каһарманны «чыгырыннан» чыгара. Ул үзе белгән мисалларны терки: күршесе хатынының ун кабыргасын сындырган, икенчесе бөерен алдырган, өченчесе сөеклесенең бер күзен чыгарган... Әлбәттә, тормышта барысы да бар. Р.Мәннанның күпертү, гипербола алымы белән һөҗүнең тәэсир көчен, эффектын арттыруга омтылуын, шулай кирәклеген аңлаган хәлдә дә, Ф.Әһлия «йомшаклыкны» яклавы белән хаклы кебек.

Шигырьләрне тулаем укыганда игътибар итмәгән, мәгәр контексттан «суырып» алгач, өзеккә бөтенләй башка мәгънә салып була икән. Сатирикның көче дә нәкъ шунда. Шагыйрь Н.Акмалның «Туктатыгыз әле трамвайны, төшеп калсын әле бер бәндә!» дигән сүзләрен үзенчә юрый, акчасыз шагыйрьнең халык белән тулы трамвайда яратмаган бәндәсе кондуктор буларак күзаллана.

«Булышу» пародиясендә автор, шигырьләр укып, тәрәзә төбендә гөрләтеп гөлләр үстергән Р.Миңнуллинга, ул чорда әле депутат кешегә, шыпырт кына «юк белән шөгыльләнеп йөрмә, көчкә очын-очка ялгап яшәгән халыкка ярдәм итү җәһәтеннән, бәрәңге үстерергә булыш», дигән киңәшен бирә. Һәм һөҗү сәнгате «ярдәмендә» каләмдәше аның фикеренә «колак сала»:

*Бераздан тагын килермен,*
*Шигырь укып китәрмен,*
*Алла боерса, мулдан сезне*
*Бәрәңгеле итәрмен.*

(«Булышу»)

Халыкның ярдәмгә мохтаҗлыгын Р.Мәннан үзе шикелле табиб-язучы А.П.Чеховның «Лечиться после шестидесяти лет безнравственно», дигән сүзләрен хупларга мәҗбүр.

*Әптикләргә йөргәнем юк –*
*Бик кыйммәт дарулары,*
*Куркыта бит анда барып*
*Тәмам ач калулары.*
*Пинсәм арта бара, әйе,*
*Елына ике тапкыр,*
*Бәяләре исә арта*
*Атна саен – хет акыр!*

(«Кризиска»)

Мәхәббәт мәүзугы, Такташ әйткәнчә, үзе иске нәрсә булса да, һәр буын аны яңарта, һәр кеше аны үз башыннан кичерә. Бик күп сүз осталары, шул хисне җырлап, әдәбият тарихында калдылар. Бу яктан хәзерге татар шигърияте дә тел-теш тидерерлек түгел икән. Ошбу хакыйкатьне мәхәббәт «антологиясен» төзегән Р.Мәннан ачып бирде. *«О, шәраб исертте, дисәм – / Синең иреннәрең икән»*, – дип язган Таңчулпан. Үбешү кебек бала-чага шөгыле белән мавыгуны өнәмәгән Ә.Гаффар бөеклекне табигатьтә таба: *«Пешкән җиләк белән үбешеп тора / Болын падишаһы кырмыска»*. С.Гәрәеваның кырмысканы күзәтеп торырга вакыты юк, ул табигать кочагында үзенең ләззәтләнүен артыграк күрә.

*Үләннәргә ятып үбешмәгәч,*
*Ни тәме бар җирдә яшәүнең?*

Башка мәүзугларга багышланган шигырьләрендә сүлпән шагыйрь Р.Корбан да, үбешүгә «чират» җиткәч, тәмам «туарылып», ачылып, Р.Харистан да («Өч үбешү») уздырып җибәрә:

*Онытылыйк әле, онытыйк,*
*Үбешик ироннәр канаганчы,*
*Үпкәләрне читкә ыргытыйк.*

Югарыда китерелгән шигъри өзекләр, Р.Мәннанның хыялын уятып, һөҗү таләпләре буенча, кире яклары белән ачыла, абсурдка чаклы үстерелә. Мәсәлән, пародист, Р.Корбанның иреннәрне канатканчы үбешүе белән канәгатьләнмичә, мондый «тәкъдим» кертә:

*Үбешү шушы булдымы?*
*Их, пешмәгән бәрәңге!*
*Үбешергә кирәк, иркәм,*
*Йотканчы бер-береңне!*

И.Иксанова: *«Шундый кайнар әле минем кочак – / Җәйге чиллә... Утта өтәрлек»*, – дип кенә калмый, алдагы юлларда, (пародист ярдәме белән) өч минутта бәлеш пешерергә, борчак ашы ашатырга һәм, камин-мичләрне алыштырырлык җегәре барлыгын хәбәр итеп, «Күпме була эканум...», «Менә дигән мин ханым» кебек катгый нәтиҗәсен дә ясап куя, ягъни ироник көлү гиперболага, үтә шартлы арттыруга юл бирә.

Р.Мәннан «Үбешү», «Кайнар кочак», «Төнге кул», «Очу» һ.б. юмористик әсәрләрендә дә астыртын көлә, «төрттерү», көткәннең киресен әйтеп, аңлы рәвештә фикерне тискәре ягы белән әйләндереп кую, мактаган булып мыскыллау алымнарына таяна.

Әлбәттә, барлык тәҗрибәләрендә дә Р.Мәннан теләгән максатына ирешми. Аның иҗатында, әйтик, «Зар», «Трамвайда», «Бәхетлеләр», «Йокысызлык», «Эчкече тормышы» кебек «кытыклары»на образлы киная, тематик яңалык, хыял уены, тел-сурәт төрлелеге җитенкерәми.

Аннан килеп, эпиграммалар белән багышлау – мәдехләрне аерым бүлекчәләргә урнаштыру соралып тора. Ниһаять, бу адәмгә дә «эләккән», дип укый башлыйсың, ә язма тоташтан мактау, соклану булып чыга («Вил Усмановка», «Хөсәен Вәлиәхмәтовка», «Зөфәр Хәйретдиновка» һ.б.)

Мәгълүм булганча, Тукай, тормышның төрле кыйтгаларын үзәккә алып, киң гомумиләштерү көченә ия сатирик поэма үрнәкләрен биреп калдырган иде. Аның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» әсәре Ш.Мөдәррисне «Печән базары, яхуд яңадан-яңа Кисекбаш», Ә.Исхакны «Мещан базары, яхуд киселгән тел» кебек сатирик поэмаларын язуга рухландырды. Тукайга тәкълид итеп язылган әсәрләрне Ш.Галиевнең «Сөзгәк үгез маҗаралары», Г.Афзал, Ф.Шәфигуллин, Р.Миңнуллиннарның һөҗү сәнгатебезне баеткан эзләнүләре тулыландырып килә. Ринат Мәннанның «Минем яратканнарым» җыентыгы юмор-сатира өлкәсендәге олы традицияләрнең йөзенә «кызыллык» китерерлек түгел, дип саныйм. Авторны, уңышлары белән котлап, халыкның көлү һәм көлдерү алымнарыннан, тирән акыл салынган мәкаль-әйтемнәреннән, үткен гыйбарәләреннән, тапкырлыгыннан, кыскасы, олы тарихында иң авыр чорын кичергән, сыгылмалы телебез байлыгыннан иркенрәк файдаланып, комик типлар һәм сатирик поэмалар, сәяси әсәрләр тудырсын, дигән ышанычта калам. Кем әйтмешли, киңәш бирү – авыр капчык ташуда, бүрәнә күтәрүдә түгел. Бигайбә!

**Тәлгат ГАЛИУЛЛИН**

# АТЛАРНЫҢ ДА ТУГРЫ ҖАНЫ БАР

Гасырлар дәвамында ат кешенең тугрылыклы дусты, ярдәмчесе, хуҗалык тормышын алып баруда төп таянычы булган. Алар турында китаплар нәшер ителгән, фильмнар төшерелгән, җырлар җырланган. Дөньяда барган үзгәрешләр, техник прогресс ат һәм кеше арасындагы мөнәсәбәтнең беркадәр суынуына китерсә дә, соңгы елларда бу акыллы хайванга карашның уңай якка борылуы сизелә. Республика күләмендә аерым программалар игълан ителде. 7-8 сәгать эчендә ялсыз 70-80 чакрым юл узарга сәләтле Татар аты турында да күп кенә материаллар вакытлы матбугатта үз урынын алды, төрле районнарда ат чабышлары уздырыла башлады.

Һәр авылның атлар белән бәйле кызыклы, гыйбрәтле вакыйгалары күптер дип уйлыйм. Үзебезнең төбәккә бәйле берничә вакыйганы сезгә дә җиткерергә телим. Аларның һәрберсе, чынбарлыкка нигезләнеп, документаль җирлектә язылган.

Рәис Әсәдуллиннар гаиләсен Олы Шыңарда «ат җене» кагылган гаиләләрнең берсе дип санарга була. Рәиснең бөтен эше, үткән гомере атлар белән бәйле булды. Малларга утыз елдан артык азык ташыды, асларын җыештырды, көтү көтте. Янәшәсендә һәрвакыт тугры юлдашы – аты булды. Аеруча күңеленә кереп калган җирән бия – Дишканы ул бүген дә оныта алмый әле...

Озак еллар бергә эшләү дәверендә ат һәм кеше бер-берсен күз карашыннан аңларга өйрәнгән иде шул. «Әйдә», дисәң, кузгала, «трр», дисәң, туктап калган малкай, хуҗасы артыннан ияреп йөри торганга әйләнде. Печән ташыган вакытта чүмәлә янына үзе килеп баса, эш булгач, икенчесе янына күченә дә тагын туктап кала. Әйтәсе, дәшәсе дә юк. Кеше акыллары булган, шундый аңлы малкай иде ул.

Бервакыт хуҗалыкта азык ягы сыегая. Атны тикмәгә генә «борыч тегермәне» белән чагыштырмыйлар бит. Аңа һәрвакыт чемченеп торырга кирәк. Тамак ягын кыссаң, малкай авыр эшкә яраксызлана.

Көнен эштә үткәргән Рәис, караңгы төшеп килгәндә, арбасына чалгысын салып, авылдан читтәрәк урнашкан люцерна басуына юнәлә. Исәбе – бераз печән юнәтү. Ясәвиев Радикның яңарак кына председатель булып килгән вакытлары. Нindирәк кеше икәнен дә белеп бетермиләр, «хуҗадан» яңа шәпкә курмы сорап йөрү дә уңайлы түгел.

Гөнаһлы юлга чыгуын чамалаган юлчы атын тынычрак, ераграк якка, Түлешкә буена куалый. Бераз чапкалап, арбага төягәнче, караңгы төшә, берничә дистә адымнан берни күренми башлый. Вакытлы булды әле бу, кузгалырга кирәк, дип уйлап кына бетергәндә, авыл ягыннан, якты утларын кушып, «УАЗ» машинасының килгәне күренә. Фара яктысы бөтен басуларны айкап ала да бераз туктап тора, тагын кузгалып китә. «Әйткәннәр иде аны, яңа пред көн саен соңлатып басуларны әйләнә, дип. Хак икән... Болай төнгә калып башка берәү дә йөрмәс, пред инде бу», дип уйлый ул.

«Беттек!» дигән уй сызылып китә егетнең башыннан, һаман үзенә якынлашкан машинаны күреп. «Их, Дишка, Дишка, килеп каптык бугай, уңмас юлга чыгасымны сизеп, җан карышкан иде аны», дип уфтана ул. Шулай, җан дусты белән сөйләшә-сөйләшә, җавап тотарга әзерләнә ат хуҗасы. Биянең ялын тарый-тарый: «Борчылма, борчылма, хурлыгы сиңа түгел, миңа инде моның», – дип пышылдап, әллә үзен, әллә атны тынычландырырга тели ул.

Әллә Рәиснең уйларын бия дә тоемлап аламы, Алланың рәхмәте, арбага җигелгән ат башта алгы аякларына тезләнә, аннан, арткы санын авыр гына җыеп, тәртә арасында килеш җиргә сузыла да ята. Бия дә, аның юеш танавына битен куйган хуҗа да тынып кала. «УАЗ», аны-моны шәйләмичә, утларын балкыта-балкыта, якыннан гына узып китә...

Еллар үтә тора. Дишка да картая. Малкайны, эштән бушатып, фермага кайтаралар. Иткә җибәрү турында сүзләр ишетелә. «Хайванны үзем карыйм, риза булмасагыз, ит бәясен үзем күтәрәм, малкайны әрәм итмик инде», – дип, җитәкче янына барыбер керергә туры килә

аңа. Хуҗалыкта һәр тиен исәптә заман, шулай да Дишкага кагылучы булмый. Рәис үзе йә малайлары бияне арканда тота. Торакта чакта да печәннән, солыдан өзмәскә тырышалар.

Ферма мөдире Айтуган да, бер-берсен алыштырган председательләр Радик белән Илшат Мисбахыч та бу мәсьәләне бөтән күтәрми, бәйләнеп йөрми.

Сигез ел буена җирән бия лаеклы «пенсионер әби» булып абзарда яши. Кешеләрчә мөнәсәбәтне хайваннар да аңлый икән. Бу очракта кешеләр дә яхшылыкка яхшылык белән җавап бирә. Әйтәсе килгән фикерем шул: замана авыр, дип, хайваннардан да түбәнрәк дәрәҗәгә төшмәсәк иде.

***

Раиф Ибраһимов 1970-1980 елларда Олы Шыңар авылында ат караучы вазифасында эшли. Утыз дүрт ат, дистәгә якын тай һәм кырыкмыш аның карамагында була. Үз эшен тырышып, яратып башкара. Малайлары Миңнәхмәт, Гаделхан да, аталарыннан калмыйча, көн дә фермага йөри. Берсе тагаракны чистартса, икенчесе Мишә елгасыннан су алып кайта, печән кертә, малларга башак бирә.

Миңнәхмәт атларны бигрәк тә үз итә. Кече яшьтән үк җәйләрен ат көтүе ала. Аларны көн дә диярлек Саркыяк астына Мишәгә коендырырга, су эчерергә алып төшә, ялларын тарап, тәртипләп тота. Үсә төшкәч, атланып йөри торган Сынок кушаматлы җирән кашка белән сабан туйларындагы ярышларда катнаша башлый. Ат, хуҗасының үзенә булган яхшы мөнәсәбәтен тоеп, аңа да яхшылык белән җавап бирергә омтыла. Башта – авылда, аннан районда беренче урынны яулый. Колхоз эшеннән бушый алмаган җирән кашканың, айлар буе әзерләнеп, ярышта катнашкан атларны артта калдыруы гаҗәп хәл була, билгеле.

Миңнәхмәт белән Сынок бер-берсен ярты сүздән аңлыйлар. Язга чыккач, малай бахбаена солысын да күбрәк сала, өйдән икмәген, шикәрен дә алып килә, авыр эшләргә җибәрмичә, фермада калдырырга тырыша. Чаптар да сабантуйлар җитүен, ярышка чыгасын алдан сизенә. Көтүдә вакытта да, ялларын туздырып, кешни-кешни чабып, шул рәвешле үзенең бәйгегә әзерлеген белдерә. Сынок ике ел рәттән районда беренче урынга чыга. Тальян гармун, талдан үрелгән өстәл-урындыклар белән бүләкләнә. Күп тапкырлар челтәрләп чигелгән сөлге-яулыкларга, тастымалларга ия була. 1973 елның җәй башында, район Сабан туена өч көн кала, ат колынлый. Ярышларга чыгасы булмаганга, гаилә авыл бәйрәмен тыныч кына үткәреп җибәрә. Икенче көнне исә әти кеше, гадәттәгечә иртүк торып, атлар янына юнәлә. Арада җирән бия белән колыны күренмәгәч тә аптырап калмый, малае атны кичтән арканлап куйгандыр дип уйлый. Үз атына хатынын, күршеләрен утыртып, районга бәйрәм карарга чыгып китә. Сабантуй күңелле генә бара. Менә атлар килгәнен хәбәр итәләр. Мәйданга беренче булып Сынок белән Миңнәхмәтнең керүен күргәч, ата кеше сүз әйтә алмас дәрәҗәгә килә. Өч көн элек кенә колынлаган ат беренче урынны алсын әле!

Эш болай була. Малай, беркемгә дә әйтмичә, иртән сәгать икедә тора. Атлар аранынннан бияне һәм колынны алып чыга да Сабага таба китеп бара. Колын арымасынга, акрын гына, ял итә-итә баралар. Таң атканда, урман аша турыга чыгалар. Иртәнге сигезләргә районның бәйрәм үтә торган төньяк өлешенә килеп җитеп, туганнарында малай колынны калдыра. Ни гаҗәп, баласы өчен җан атып торган җирән кашка да артык киреләнми, каршылык күрсәтми. Шулай итеп, ял иткәннән соң, ярыш атларына килеп кушыла һәм өченче мәртәбә беренче урынны яулый!

Моннан соң да әле ул күп ярышларда катнаша. Соңгы елларда, совхоздан чын юртак атлар килә башлагач кына, крестьян хезмәтенең бөтен авырлыкларын тартып барган малкай бәйгедән төшеп кала башлый.

Озак та үтми, Миңнәхмәтне армиягә алалар. Җәй айларын кешнәп, ярыш дәрте белән каршы алса да, Миңнәхмәт кебек «ат җене» кагылган кешеләр кашка биянең тормыш юлында бүтән очрамый инде...

***

Олы Шыңарда янгын сүндерүчеләр бинасын «пожарный» дип йөртәләр. Ул бүгенге Ришат Ахунҗановлар бакча башы тирәсендә урнашкан була. Каршыда каланча тора. Өстә сигнал бирү өчен чаң эленә. Пожарник каланча башыннан, бәла-каза булмасын,

дип, авылны күзәтә. Тыныч вакытта, сәгать саен чаңга сугып, басуда эшләүчеләргә вакытны белергә ярдәм итә.

Янәшәдә янгын аты өчен абзар корыла. Өсте ябулы әвеслек эчендә ике йөз литрлы агач мичкә һәм су сиптерү өчен насос көйләнгән арба тора. Җәй эссе килгән елларда атны җигүле килеш тоталар. Башка вакытта да арба тәртәләре күтәртелгән хәлдә, камыт та, ат башына шуып кына керерлек дәрәҗәдә, өрлектәге юкә бавына асылынган килеш саклана.

Озак еллар «пожарный»да Бирка исемле алаша эшли. Аның, хуҗалыкларны колхозга берләштергән вакытта, Шаһи карттан (Шаһиев Котдус абыйның бабасы) алынганлыгы билгеле. Бирка үз эшен төгәл үти. Уттан курыкмый, кирәк вакытта ялкын эченә дә керә. Янгын вакытында ялларына һәм койрыкларына ут капкан очраклар да була хәтта.

Егерме еллап хезмәт иткәннән соң, Бирканы иткә озатылучы маллар янына күчерәләр һәм дәүләткә тапшыру өчен өстәмә тукландыра башлыйлар.

Илленче елларның икенче яртысында Сафиулла абзыйларның ике катлы йортларына ут каба (Ирек Муллахмәтевләр урыны). Авылда янгын барлыгын белдереп, ачы чаң тавышы яңгырый. Пожарник Хәйретдин, яңа атны алып чыкканчы, Бирка ике метр биеклектәге киртәне җимереп чыга һәм насос куелган арбаның тәртә арасына кереп баса. Кеше дә булдыра алмаган осталык белән, эленеп торган камытны башына да киеп куя. Иялек-түшлекне эләктереп, һәлакәт булган урынга чыгып чабасы гына кала. Гомер буе халыкка хезмәт иткән хайван картайган көннәрендә дә үз эшенә тугрылыгын саклый һәм инде, бәлкем, меңенче мәртәбәдер, кешенең чын дусты булуын раслый.

***

50нче еллар ахыры. Нәҗип Шәймәрданов белән Габделхак Кәримов, 7нче классны тәмамлагач, ат көтүе алалар. Көтүдә алтмышлап мал була. Утызы эш аты булса, калганы – картайган яки авыру атлар. Бригадир, яшүсмерләрнең күңелендә нәрсә ятканын тойганга күрә, кырыкмышлар үзегезгә була, дип, аларны гел үсендереп тора. Дөрестән дә, аларга, гадәттә, үзләре өйрәткән тайлар беркетелә. Көндезләрен икәү көтсәләр, төнгә дүрт кеше чыга. Түлешкә астындагы Тар болын алар карамагына тапшырылган. «Бракка» чыгарылган малларны дәүләткә ит өчен әзерлиләр. Атларга өстәмә азык бирелә.

Көтүдә Ярко кушаматлы туры бия генә егетләрнең җелеген суыра. Ул әз генә кычкырганнарын да яратмый. Чыбыркы күрсә, гомумән, җене кузгала: йә көтүне тарата, йә ажгырып өскә килә башлый. Берничә тапкыр, шул чыбыркы аркасында, ат өстендәге көтүчеләрне дә болгап төшерә. Нәҗип абыйның аягында Ярконың тояк тамгасы бүгенгә кадәр саклана әле. Бахбай бары таяктан гына курка, шулай ук таш атып куучыларга да бик шөлләп карый. Холкы шундый кырыс, сәер булса да, көч-куәте, тырыш булуы белән ихтирам казана ул.

1975-1988 елларда Нәҗип абыйга урманчы булып та эшләргә туры килә. Аның карамагында – Оет авылы янындагы урманнар. Гадәттә, хуҗа, атын тугарып, ашарына салып, арбасына бәйләп куя. Үзе исә бетмәс-төкәнмәс урман эшләренә чума. Бервакыт, эшләрен бетереп, аты янына килсә, кызыклы хәлгә тап була. Арбаның бер ягында биясе белән колыны печән ашый, икенче ягында поши үлән чемченеп йөри. Тора-бара бу гадәти хәлгә әйләнә. Кешенең зыян салмавына ышанган кыргый хайван көн саен, аксаклап (аягы күзгә күренерлек дәрәҗәдә шешкән була), ат янына килә. Берничә тапкыр урманчының сумкасындагы икмәген, капкалап алу өчен алган ризыкларын да ялмап куя. Еш кына якында ләм исе чыгарып ятучы сазлыклы урында сәгатьләр буе басып тора, сызлавын, авыртуын баса, күрәсең, аннан кабат бия белән колын янына килеп ята. Кешеләргә, шул рәвешле, урманның шифалы һәм серле урынын калдырып китә ул.

Бер-береңә ышаныч һәм шәфкатьлелекнең безгә генә түгел, хайваннарга да кирәклеген күрсәтүче мисал бу.

**Айдар ГАРИПОВ,**
*Саба районы Олы Шыңар урта мәктәбенең тарих укытучысы*

# ЛОКМАН ЗАКИРГА 90 ЯШЬ



Бу елның 19 феврале көнне танылган сатирик язучы Локман ага Закирга 90 тула. Тиктормас Локман ага һаман да каләмен ташламый, гел язып тора. Локман Закиров – фикер иясе. Аның каләме тарихи теманы да, авыл хуҗалыгы мәсьәләләрен дә, хәрби техника, космос, тәрбия мәшәкатьләрен дә читләтеп узмый. Каләменнән атылган ук һәрвакытта мәргән угыдай төгәл һәм мәрәгә тия.

Локман ага авиатехника буенча шәп узаман-специалист иде, лаеклы ялга чыккач, ул каләмгә тотынды һәм, курку белмәс авиатор кебек, язучы буларак та курку белмәде, шуңа күрә дә шактый кыен күрде, матбугатта турысындөресен сөйли килде.

– Локман абый, пенсияң дә шактый бит инде, нигә син, кыен күрә-күрә, әдәбият белән мавыгасың? – дип сорадым мин аннан.

Ул ихластан елмайды һәм әйтте:

– Полковниклар, генераллар һәм кайбер олы директорлар пенсиягә чыгуга ук ишелеп төшәләр, авырый башлыйлар. Алар кайчандыр игътибар үзәгендә булып та, пенсиягә чыккач, ялгыз карт булып кала, үзләренең бичара бер кеше икәнлекләрен аңлый. Ә мин ике кулыма бер эш таптым һәм актив тормыш алып барам. Темалар эзлим, язам, язганнарымны укыйлар, димәк, мин кемгәдер кирәк. Тормыш чанасыннан төшеп калмас өчен, пенсиягә чыккан кешегә башка бер һөнәр үзләштерү мөһим. Мин каләмгә тотындым.

Локман ага Закирның озак яшәү сере менә шунда: ул тырыша, эшли, аның язганнары мәкальгә әверелә бара:

*Әлкче ул – термоядтан да хәтәррәк.*

*Милиция мине сакламый, милиция номенклатураны саклый.*

*Кем ныграк кыйнаса, без шуны яратырга өйрәтелгән.*

*Гитлер СССРга ябырылмаган булса, Сталин 6 июль көнне Германиягә ябырылган булыр иде.*

Сүз иярә сүз чыккач әйтим, Локман Закиров һәр елны үзенең пенсия акчасына миниатюралар китабы чыгара килә, китап чыгымнарын каплар өчен, ул дачасын, машинасын сатты. Шул түгелме фидаилек.

Иҗатын хөрмәт итүчеләр исеменнән Локман ага Закирны 90 яше тулу уңаеннан ихлас күңелдән котлыйм һәм аның 100 яшен дә бергәләшеп каршыларга насыйп булсын.

**Рабит БАТУЛЛА**

Габдулла
Галиев

# КЫРЫНДЫ АВЫЛЫ ТАРИХЫННАН СӘХИФӘЛӘР

### Үзәккә үткән 1942 ел

Басудан ат белән ташып эскерт көлтәләрен сугу 1942нең март башында гына тәмамланды. Сугылган икмәкне заготзернога тапшырып бетерделәр, колхозчыларга бөртеге дә эләкмәде. «Фронтка! Граммына кадәр фронтка!» – диделәр. Шөкер, бакчаларыбызда бәрәңге уңган иде, шул гына коткарды. Авыл халкының үзәгенә үткән икенче нәрсә – салкын иде. Өйләрне җылытырга утын кирәк, ләкин каян алырга ул утынны? Көн туды исә, шул турыда уйладык. Ярый әле безнең авылга урман якын. Мин еш кына урман ерак авыллар утынга нишлиләр икән дип уйлый идем. Кырык бернең салкынында карама агачлары авырып корыдылар. «Уфалла» чаналарыбызны сөйрәп, тирән карны ера-ера, шул карамалар янына килеп туктар идек. Өлкәннәр төптә калыр, без, малайлар, балталарыбызны билләребезгә бәйләгән каешка кыстырып, ботактан-ботакка басып, караманың очына менеп китәр идек тә корыган ботакларын кисеп-чабып аска, кар өстенә ташлар идек. Аннан чаналарыбызга төяп, бөгелә-сыгыла тартып, үзебезне бахбайлар итеп күз алдыбызга китереп, «на! – на!» диеп шаярышып авылга таба атлар идек.

Корыган карамалар безне берничә ел өшеп үлүдән коткарды, тагын икенче уңай ягы – урманчылар бәйләнмәделәр. Якшәмбе көннәрне безнең белән утынга укытучыларыбыз – иреннән өч айлык сабые белән тол калган Рәйсә апа һәм татар теле укытучысы Ләбибә апа Заитова да йөрделәр.

Язмам барышында язып киткән идем, кыска гына итеп дәвам итим әле. 41нче елны чакырылган әтием Гали башта Бөгелмәдә хезмәт итте, еш кына хатлар яза иде. Бөгелмәдә күбрәге татар солдатларыннан хәрби часть төзелгән, аны Кырымны фашистлардан азат итү өчен төп көч итеп файдаланырга булалар. Ләкин «Кырым операциясе» уңышсызлыкка дучар була, безнең армия чолганышта кала. Бу хакта соңрак искә алырмын әле.

Кырык икенең җәе дә, кышы да бик авыр үтте. Кыр эшләрен башкарырга атлар җитмәде. Колхоз идарәсендә, бу мәсьәләне үгезләр белән хәл итеп булмасмы, диептер инде (колхоз рәисе үгезләр җиккән бер колхозда булып кайткан иде), бер-ике үгезне җигәргә өйрәтеп карарга булалар.

Бу кызык бер яңалык иде. «Бүген үгезләрне җигәргә өйрәтәләр икән», – дигән хәбәрне ишетеп, мәктәптән кайту белән, колхоз идарәсе алдындагы мәйданчыкка йөгердек. Иртәдән бирле яңгыр сибәләп тора, басуларда эш туктаган, без килеп җиткәндә авылның яше-карты шунда иде инде. Беренче Бөтендөнья сугышында Украинада хезмәт иткән Әкәмә абзый (дөрес исеме – Әкмәлетдин) колхоз рәисенә: «Үгез җигүләрне күргән егетләр без. Укринда (Украина) үзебезнең дә җигеп йөргән чаклар күп булды», – дип әйтеп аткан. Менә бүген шул һөнәрен авыл халкына да

*Ахыры. Башы узган санда.*

күрсәтергә булган. Фермадан иң юашы, иң тәртиплесе дигән үгезне алып килделәр. Әкәмә абзыйның үгезне ничек җиккәнен карап торабыз. Үгезгә атныкы кебек киез камыт кигермиләр икән, дугасы да юк. Бар булганы: муены өстенә куелган бөятле калын агач. Маташа торгач, Әкәмә абзый үгезне җигеп бетереп, арбасына менеп утырды. Кулында озын таяк. Шул таягы белән, үгезгә юл күрсәтеп, «цоб – цоббаа, цоб – цоббааа!» – дип тамак төбе белән кычкыргач, үгезебез кузгалып китте бит! «Кара! Кара! Була бит!» – дип сөйләнә-сөйләнә, халык арттан иярде. Бераз баргач, үгезебез кинәт кенә борылды да тар сукмактан инешкә дөбер-шатыр төшеп тә китте. Әкәмә абзыебыз яр башында кендеге ычкынган арба төбендә утырып калды. Үгезебез инештә рәхәтләнеп су эчеп туйгач, «бүгенгә шул җитеп торыр» дигән кебек, инеш ярының икенче ягына чыгып, фермасына кайтып китте. Үгез җигүнең беренче көне әнә шулай тәмамланды.

Заманы шундый иде: үгезләрне генә түгел, хәтта сыерларны да җигәргә өйрәттеләр. Ул бичара терлекләр сугыш елларында, сугыштан соң берничә ел да халыкка чиксез күп хезмәт иттеләр. Үз хуҗалыкларындагы сыерларын җигеп эшләп йөргән «Йолдыз» исемендәге колхоздан Латыйфа, Камал, Маһинур апаларның батырлыкларына сокланмыйча мөмкин түгел иде.

1942 елның җәй ахырларында илебездә тагын киеренке хәл туды. Немец-фашист гаскәрләре Сталинградка килеп җитте. Авыл халкы андагы хәлләрне ирләреннән, улларыннан алган өчпочмаклы хатлардан укып беләләр иде. Төкерек җиргә төшкәнче боз булып ката торган салкында урман кисеп кайткан әниләребез, сукыр лампа яндырып, төннәр буе йон оекбаш, бияләйләр бәйлиләр иде. Гаилә авызыннан өзеп булса да, фронттагы ирләребезгә, дип бәрәнге киптерерләр иде. Газиз әниләребез дошманны җиңү өчен барсын да эшләделәр, тырыштылар. Халкыбызның тырышлыгы бушка китмәде, Сталинград өчен сугышта немец-фашист гаскәрләре, камалышта калып, хурлыклы рәвештә җиңелде. Бу хәбәр авыл халкы өчен зур куаныч булды.

## Авыл җитәкчелегендә үзгәрешләр

Сугыш елы, үз таләбен куеп, авыл советында да үзгәрешләр булып алды. Авыл советы рәисе Вәли абый Әхмәдиев армиягә чакырылу сәбәпле, аның урынына – Миңнегулова Сәмига, секретаре итеп Минһаҗева Мәрхәбә апалар куелды. Авыл халкына сугыш елларының катгый законнары кертелде. Салымнар һәм түләүләрнең хаклары артты: колхозчылар өч йөз литр сөт, кырык килограмм ит, сарык йоны сыман нәрсәләрне һич каршылыксыз түләп барырга мәҗбүр ителделәр. Шуның өстенә һәр елны үткәрелә торган заёмга яздыру болай да, авызын ачса, үпкәсе күренеп торган, көч-хәл белән генә яшәгән халыкның тормышын бик нык какшатты.

Үзәккә үткән кышкы салкыннарда, иртән мәктәпкә килүебезгә, парта өстендәге караларыбыз бозланып каткан булыр иде. Дәресләр тәмамланганчы 5-6 сәгать, тышкы өс киемебез белән утырырга туры килде, калтырана башласак, җылыну физкультурасы ясап алыр идек. Инде язганымча, директорыбыз Гата абый Ибәтов урынына Көчек авылыннан Зөфәр абый Мөхтәсипов килде. Килеш-килбәте белән үк зыялы нәселдән икәнлеге күренеп торган, төскә-биткә чибәр бу абыйны баштарак нигәдер яратып китә алмадык. Директор булуы өстенә, ул безне химиядән укытты, дәресен хәзерләп килмәүчеләрне яратмады. Мин үзем дә химиядән җавап биргәндә калтырап төшәр, тотлыгыр идем. Күп еллар үткәч, бер очрашканда, моны үзенә дә әйттем. Ул : «Бер дә хәтерләмим, ничек алай булды икән соң?» – диде, көлешеп алдык.

1942 елда Төрдәле авылында көтмәгәндә колхоз рәисен алыштырып куйдылар. Будённый исемендәге колхоз рәисе Афанасий Сериковны Әгерҗе кирпеч заводына директор итеп алып, аның урынына күрше «Йолдыз» колхозында озак еллар рәис булган Галиәскәр абый Садыйковны сайлап куйдылар. Белеме булмаса да, хуҗалык итүдә тәҗрибәсе бар иде аның. Галиәскәр абзый халык белән аралашып яшәде: ничә карама, йә ат абзарында, йә фермада, йә кырда булыр иде. Борын астындагы ике якка салынып төшкән мыегын сыпыргалап, үзенең мәзәкчән, мисалларга бай тапкыр теле белән һәркемнең кәефен күтәрергә тырышып йөрде мәрхүм.

Авыл тормышы елдан-ел авырая барды. 1943 елга чыктык. Мин инде 7нче сыйныфта укыйм, быел Ходай насыйп итеп исән-имин булсам, мәктәпне тәмамлаячакмын. Армиягә директорыбыз Зөфәр абый Мөхтәсиповны да алдылар. Директор булып фронттан сул аягы яраланып кайткан Рәзак абый Яһүдинне китерделәр. Килгәннең икенче көнендә үк ул, таягына таянып, аксый-аксый дәрескә керде. Яңа килгән укытучы һәрвакыт кызыксыну уята бит. Аны да без бераз шүрләп, сагаеп каршы алдык. Яралы фронтовик кеше нинди булмас, сак булырга кирәк, янәсе. Керде. Аягөсте баскан хәлдә аңа текәлдек. Ул да, матур итеп елмаеп, һәрберебезгә күз йөртеп чыккач, утырырга кушты. Җыйнак, арык кына гәүдәле бер кеше икән, искитәрлеге юк.

Шулай да аның «искитәрлек» икәнлеге дәрес башлангач ачылды. Рәзак абый безгә, мишәр акценты белән «с» хәрефен җиңелчә генә «ч«га күчереп, башын бераз гына артка ташлап, СССР Конституциясеннән искиткеч мавыктыргыч дәрес бирде. Хәтта дәрес тыңларга яратмый торган кайбер шаян сыйныфташларым да май кебек эреп утырдылар. Шуның өстенә, ул оста тальянчы да һәм гаҗәеп артистлык талантына ия икән. Шактый күп еллар узгач кына, без аның Татарстанның атказанган артисты, тел остасы Әзәл Яһүдиннең бертуган абыйсы икәнлеген белдек. 1943,1944 елларның язлары аеруча авыр булды. Бәрәңгеләрен утыртканнан соң, бик күпләрнең ашарларына да калмады. Хатын-кызлар, балаларын ияртеп, урманга йөрделәр. Урманнан язгы гөмбәләр, бәбчек юа суганы ташыдылар. Иң коточкычы кырык дүртнең язында булды. Кайсысыдыр, исемен хәтерләмим, кар астыннан көзен сугылып бетмәгән учмалардан коелган бөртекләрне табып, җыеп алып кайткан да боткасын пешереп ашаган, искиткеч тәмле булып чыккан. Китте шуннан басудан бөртек җыеп ташу. Кайберләре кул тегермәннәре ясап җибәрделәр, бөртекләрне он итеп тарттылар, күмәч, көлчә кебек ашамлыклар пешерделәр. Куанычларның иге-чиге булмады. Ләкин тиздән бу куанычлар кара кайгыга әйләнде. Авыл халкы, бигрәк тә балалар, агуланып аяктан егылдылар. Температура күтәрелү, тамак бизләренең кинәт ялкынсынуы, йота алмау, хәлсезлек – авыруның беренче билгеләре иде. Ашыгыч рәвештә районнан чакырылган табиблар бу авыруны «септическая ангина» дип билгеләделәр. Ашыгыч төстә сөт ризыклары белән туклану оештырылды. Авыл фельдшеры Данилова, йорттан-йортка йөреп, авыруларны дәваларга тырышты, авыр хәлдәгеләре янында үзенең көчсез булуын бик авыр кичерә торган иде. Хәер, медпунктта хәтта марганцовка да юк иде шул ул елларда. Үлүчеләр булды, сыйныфташыбыз Рафиканы, күз яшьләре белән, җир куенына илтеп салдык. (Ул вакыйганы мин үземнең «Үкенеч» исемле китабымда тулырак чагылдырырга тырыштым.) Тагын бер күңелсез хәбәр шул: кырык өчнең маенда авылыбыздан өч чакрым ераклыктагы Красный Яр авылыннан хәер сорашып кайтып килгәндә, юлда үлеп калган Мөхәммәтзакир бабайны табып алып кайттылар. Чабатачы карт иде мәрхүм, гомере буе чабата үреп, шуны саткан акчага гаиләсен туендырды. Егет булып килгән бердәнбер улын – Касыйм абыйны беренче көнендә үк сугышка озатты. Ул елны картның башына берьюлы ике кайгы килде: ярлы булсалар да, гомерләре буе Ходай биргәнгә разый хәлдә чөкердәшеп яшәгән карчыгын җирләде, шул хәсрәткә батып, ямансулап йөргән көннәрдә улы Касыймның һәлак булуы турында хәбәр килеп төште. Бу хәлләрдән соң Мөхәммәтзакир бабай бөтенләй бетәште. Чабата үрергә юкә кирәк, урманга юкә төшерергә барырга хәл дә, җегәр дә юк. Туган-тумачалардан ярдәм көтәрлек түгел, үзләре көч-хәл белән җан асрыйлар. Нишләргә? Озак уйлагандыр карт, ниһаять, оятын яшереп булса да, хәер сорашырга чыгарга була. Күршеләреннән: «Красный Яр – икмәкле авыл ул, халкы да юмарт, сорашып кергәннәрне борып чыгармыйлар икән», – дигәнне дә ишеткәч, җеп өзәр хәле булмаса да, тәвәккәлли. Әмма авыл башын чыгу белән, ерак китә алмый, чайкалып тора да авып төшә. Картны йортына алып кайттык. Күрше-күлән, хатын-кыз кабер казучылар эзләп урамга сибелделәр. Авылда ир-ат юк диярлек, булганнары да – сугышта яраланып кайткан гарипләр һәм безнеңише 13-14 яшьлек малайлар, шуның өстенә мәет күмүнең тәртибен дә белмибез. Ул арада йортка килеп кергән бригадир Сания апа: «Баһавига әйттем, хәзер килеп җитә, барсын да башкарып чыгар», – диде.

Баһаветдин Шәрәфетдинов турында язмыйча үтеп китсәм, гөнаһ булыр. Сугышта яраланып кайткан Баһави абый күрше Көчек авылыннан иде. Аны безнең колхозга

ветсанитар итеп эшкә җибәргәннәр, шуның өстенә безнең авыл кияве дә булгангамы, халыкка бик ярдәмле, бар эшне дә булдыра торган кеше булып чыкты. Терлекләре авырып китсә, койма-фәлән ауса, хатын-кыз, бала-чага аңа йөгерде. Баһави абый, эш коралын кыстырып, шунда ук килеп җитәр иде. Мөхәммәтзакир картны да берүзе юып, кәфенләп, ләхетен алып, бөтен тәртибе белән ул озатты. Безнең хәтердә Баһави абый әнә шундый легендар кеше булып калды, ярдәмнәре изге гамәлләрдән булып, Алланың ризалыгына ирешеп, зур саваплардан ирешсен аңа.

## Чыгарылыш кичәсе

1943 елның май ае ахырында без, 22 укучы, җиденче сыйныфны тәмамладык. Кич кырдан эштән кайтуыбызга, безне мәктәпкә чакырып алдылар. Мәктәпкә чакыручы апабыз әйтеп йөргән: «Эштән кайту белән, юынып, киенеп-ясанып, мәктәпкә килсеннәр, җидене бетергәнгә таныклык тапшырачаклар», – дигән. Тиз арада барыбыз да җыелып җиттек. Мәктәп коридорында тыйнак кына басып торабыз. Басуда арылган, шаярышу да, көлешү дә юк, ниятебез таныклыкны тизрәк эләктерергә дә өйгә ычкынырга, чөнки иртә таңнан тагын эшкә барасыбыз бар. Шулай уйланып торганда, Рәзак абый кабинетыннан чыкты да, яныбызга килеп, һәрвакыттагыча ягымлы елмаеп, барыбызны да сыйныф бүлмәсенә чакырды. Кердек. Анда – күзләребез күрсә дә, күңелләребез ышанып җитми торган хәл. Өстәлләр өстенә һәрберебез алдына кунак сые әзерләп куелган: беленнәр салынган тәлинкә, пары чыгып тора торган кайнар чәй, тагын иң гаҗәпләндергәне (без инде аның дөньяда барлыгын да оныткан идек) – баш бармак зурлыгындагы шакмак конфетлар! Могҗиза! Ул чор өчен чынлап та могҗиза иде бу. Инде күп еллар үткәч, хәзер дә уйлап куям. Белен пешерергә сыйфатлы ак он, конфет кебек тәм-томнарны каян тапты икән ул? Ансат булмагандыр, югарыдагыларның кабинет ишекләрен күп тапкырлар шакып керергә туры килгәндер аңа, чаялыгы, кыюлыгы, шуның өстенә яралы фронтовик булуы да ярдәм иткәндер инде.

Табын башына баскан Рәзак абый, исем-фамилияләребез буенча чакырып алып, шаян, тапкыр сүзләр кыстырып, изге теләкләр теләп, таныклыкларыбызны тапшырды. Аннан мәктәп белән саубуллашу җырлары җырлап утырдык, хыялларыбызны уртаклаштык. Рәхәт иде соңгы тапкыр бергәләп утыру. Күңелләр бераз гына моңсу булса да, бәхетле идек без ул минутларда, чөнки беразга гына булса да сугыш елы икәнлеген онытып тордык.

## Кызлар да фронтка китә

1942 елдан военкомат авылыбызның кызларын чакыра башлады. Беренчеләрдән булып Габделхәй хәзрәт кызы Мөхлисә Җәмилова, Сәүдә Шәрифуллина, бераз соңрак Надя Иютина, Катя Буторина, Валя Краснопёровалар чакырылып, военкоматтан туры фронтка озатылдылар. Сугыш тәмамланганчы армия сафларында булдылар. Тылда да сугыш елларының иң авыр йөге кызларыбыз җилкәсендә иде. Кырык бернең салкыннарында Канаш җирендә окоп казудан башлап, алар Успьян, Лубьян урманнарында агач кисеп чыгаруда, торф базларында газап чиктеләр. Ә болары: сөйгән егетләре белән матур тормыш корып, сөйкемле балалар тәрбияләп үстерәсе кызларыбыз Гыйльфанова Мөнәвәрә, Гыйззәтуллина Заһирә, Сөләйманова Әминә, Нәфыйкова Мөгаллимәләр, сугышка киткән ир-егетләрне алыштырып, тракторга утырдылар.

Сугыш еллары сузылган саен, тормышны алып барулар тагын да кыенлашты. Сугышның беренче елларында ук ирләре авыр бәрелешләрдә һәлак булган күп балалы аналар – Хөршидә, Майсафа, Гатифә, Мәчтүрә, Галимә апаларның тормышлары аеруча авыр иде. Кышларын зәмһәрир суыкларда чи утын, салам ягып кына җылы төшми торган өйләрдә өшеп, бер кабым ризыкка тилмереп яшәүләрне сугыш чоры кешеләре ничек оныта алсын инде. Ятим калганнарның хәлләре бигрәкләр дә авыр иде. Шәмсетдинов Муллаянның сугыш башланыр алдыннан гына әтиләре белән әниләре үлеп китте, гаиләдә дүрт бала ятим калдылар. Өлкән абыйлары Муллагаскәр абыйны

сугышның беренче атнасында ук фронтка озаттылар. Биш яшьлек Муллаян үзеннән 5-6 яшькә генә өлкәнрәк апалары белән буш йортта яшәп калды. Әти-әнисез, инде абыйларсыз да бу ятимнәр баштарак күрше-күлән кертештергән ризыклар белән тамак ялгап үлмәскә тырышсалар да, ачлык үзенекен итте. Өчесенең дә кул-аяклары шешенеп чыкты. Кулына киндер биштәр тотып, хәер сорашырга чыгып йөргән көннәрен исенә төшергәндә, Муллаянның күзләре әле дә яшьләнә. Сугышның беренче атнасында ук Сталинның рәхимсез сугыш елы законнары хөкем сөрде. Ире сугыш кырында туган илен яклап һәлак булган тол хатын Шәргия апаны, табага салып мичтә куырып булса да балаларыма ашатырмын, дип алган бер кесә бодай өчен хөкем итеп, өч елга төрмәгә утырттылар. Шулай ук ире сугышта башын салган Мөхәссәнә апаны бер рәхимсез бәндә, ярты чиләк бәрәңге белән тотып, бәрәңгеле чиләген колхоз идарәсенә илтеп тапшыра. Мәрхүмә бу оятны күтәрә алмагандыр инде, ике баласын калдырып, төнлә асылынып үлгән.

Әлбәттә, гел яман хәлләр генә булып тормады, күңеллерәкләре дә бар иде. Кырык өчнең кышында кич авыл халкын кинәт клубка чакырып йөрделәр. Налоглар мәсьәләсе буенча «пешекләргә» җыялардыр инде, дип халык сүлпән генә җыелды. Халык алдына хәрби киемдәге бер кеше чыгып басты, исәнлек-саулык сорашкач, фронт хәлләре белән таныштырды. Аннан сумкасыннан газета тартып чыгарды да: «Менә бу «За отвагу» исемле фронт газетасында сезнең авылдашыгыз рядовой Гәрәев Харис турында, аның батырлыгы турында язылган, мин махсус рәвештә хәрби частьтан сезне шул язма белән таныштырырга килдем. Игътибар белән тыңлагыз», – дип кычкырып укырга кереште. Язма рус телендә язылганлыктан, аны укытучы Саҗидә апа тәрҗемә итеп барды. Ул язма болайрак иде: немецларны чигендереп, шактый алга киткән Харис абыйларның частен дошман камап ала башлый. Төп көчләр шактый артта була, чолганышта калу куркынычы яный. Часть командиры пулемётчы Харис абыйга безнекеләрдән ярдәм килеп җиткәнче тоткарлап торырга куша. Харис абый командир боерыгын намус белән үти, безнекеләр килеп җиткәнче, кул пулемёты белән, дошманга баш күтәрергә ирек бирмичә, ут яудырып тора. Берничә тапкыр яраланса да, позициясеннән чигенми, әнә шулай авылдашыгыз сугышчыларны чолганышта калудан коткара... Язманың авторы өлкән политрук шундый батыр солдат тәрбияләп үстергән Харис абыйның әти-әнисенә, авылыбыз халкына тирән рәхмәтен белдерде. Клубта барыбыз да кул чабып, Харис абый өчен горурланып утырдык.

...1945 елның 9 маенда халкыбыз зарыгып көткән Җиңү көне килде. Тик аның шатлыгы белән рәттән аянычы да зур булды. 248 авылдашыбыз чит җир туфрагында мәңгегә ятып калды. 50дән артык авылдашыбыз, төрле яралар алып, гомерлек гарип булып, сызланып, кимсенеп яшәде. Дөньяга килеп тә, бер мәртәбә дә «әти» сүзен әйтә алмаган сабыйлар, сөю-сөелү назыннан мәхрүм толлар торып калды...

## Сугыштан соңгы тормыш

Бөек Ватан сугышы дошманны җиңү белән тәмамланса да, халыкка яшәү шартлары җиңеләймәде. 1946 елның җәе яз башыннан ук коры килде, игеннәр дымга сусап киптеләр. Киресенчә, урып-җыюга төшкәч, яңгырлар башланды. Көнаралаш диярлек чиләкләп коеп кына торды. Андый елларда кышы да иртәрәк килүчән була бит. Һәм шулай булды да. Октябрь урталарында җир туңып, кар ятты. Колхоз басуларында: җыелеп бетмәгән учмада бөртекләр, казылмаган бәрәңгеләр, яшелчәләр кар астында калды. Әнә шулай ачлык дигән нәрсә үзенең ач авызын күрсәтте.

Кырык җиденең язында, карлар эри башлау белән, авыл халкының яше-карты (өлкәннәр таякка таянып булса да), җилкәләренә чиләк асып, көздән казылмыйча калган бәрәңге басуына агылды. Аягы йөргән һәркем, кояш җылысында туңган, суы таралып, крахмалы гына калган бәрәңгеләрне чиләкләренә тутырып өйләренә ташыдылар. Шул бәрәңге крахмалын уч төбендә тәп-тәпләп, зур гына коймак формасына китереп, калайга йә тимер мич өстенә салып пешерерләр иде, һәм ул телне йотарлык тәмле булыр иде. Кайбер авылларда аны – бәрәңге кәлҗемәсе, икенчеләрендә крахмал коймагы дип атаган бу легендар ризыкка безнең авылда «таптап» дигән атама

бирделәр. Әнә шул «телне йотарлык тәмле таптап» бик күпләрне ач үлемнән саклап калды.

1953 елның март башында И.В.Сталин вафат булды. Аның кинәт үлеп китүен авыл халкы авыр кичерде. «И Ходаем, ничек булыр инде? Иптәш Сталинсыз ничек яшәрбез?.. Кулыбыздан тотып кем җитәкләр хәзер безне?» – дип такмаклап елаучылар күп булды. Бер караганда, гаҗәп хәл иде бу! Иксез-чиксез кулга алулар, сөргеннәргә сөрүләр, расланмаган гаепләр тагып, төрмәдә черетүләр, сугыштан болай да йончып калган ач халыкны заём кампанияләре белән газаплаулар – болар барысы да Сталин аркасында иде бит. Шул кешене кызганып, нигә күз яшьләребезне түктек икән? Аңлавы авыр инде моны. Моңа җавап шул инде: без «атабыз Сталинга», аның идарә итүенә күнеккән идек һәм бары ул кушканча гына яшәргә өйрәнгән идек.

1958 елны СССР Министрлар Советы башлыгы булып КПССның беренче секретаре Н.С.Хрущёв сайланды. Һәм, һич көтмәгәндә, авыл хуҗалыгында яңа, уңай үзгәрешләр башланды. Колхозлар өчен хезмәтләре бик кыйммәткә төшүче МТСлар бетерелеп, тракторлар һәм башка авыл хуҗалыгы техникасы тулысы белән колхозларга тапшырылды.

Бераз гына тарихи чигенеш ясап алыйм әле. 1950 елның җәендә Кырынды авыл советына караган 8 колхозны берләштереп, аңа Чапаев исемендәге колхоз исеме бирделәр. Авыл советы рәисе Вәли абый Әхмәдиевне ул эшеннән азат итеп, колхоз рәисе итеп куйдылар. Төрдәленең Будённый исемендәге колхоз бинасында яңа оешкан колхоз идарәсе урнашты. Эшләр уңай якка үзгәрергә тиеш дип, зур өметләр белән берләштерелгән колхоз нигәдер һаман да үзен аклый алмады. Идарә итү өчен белем дә, саулык та җитмәде кебек, Вәли абый бик еш авырый башлады. Күп вакытын хастаханәләрдә дәваланып үткәрде. Башта әйбәт кенә эшләп киткән хуҗалык соңгы елларда шактый нык какшады. Мондый хәл, әлбәттә, безнең колхозда гына түгел иде. Авыл хуҗалыгын тәртипкә салу өчен, нәрсәдер эшләргә кирәклеген югарыдагылар да аңладылар, ахрысы. Ашыгыч рәвештә колхозларны яңа кадрлар белән ныгыту максатыннан, партия Үзәк Комитеты карары белән, авылларга утызмеңчеләр җибәрелде.

## Утызмеңче

1955 елның август башында авылыбызга «утызмеңче» дигән берәү килеп төште. Аны озата килүчеләр арасында район башкарма комитеты рәисе М.Репеев, КПССның район комитеты вәкиле Кузьмин һәм тагын берничә кеше бар иде. Мәктәп каршына җыелган халык алдына басып, М.Репеев, кыска гына кереш сүздән соң, утызмеңченең үзе белән таныштырды: Запускалов Александр Семёнович безгә Казаннан җибәрелгән. Казан авыл хуҗалыгы институтында укытучы-галим икән. Хатыны, ике кызы бар, дигәч, хатыннар бер-берсенә карашып куйдылар. «Иптәш Запускалов Александр Семёнович сезнең колхозыгызга рәис итеп тәкъдим ителә», – диюгә, халык тынып калды. Бераздан арттарак басып торучы берәү: «Нигә кирәк ул безгә? Шөкер, безнең үз рәисебез бар, исән-имин генә әле. Вакыты белән сырхаулап алса да, нигә, сөйри бит әле колхозыбызны», – диде. «Әйе шул, үзебезнең кеше ул – эшләсен», – диде бер җыелышта да тавышсыз гына утыра алмый торган Гатифә апа. Китте бәхәс, китте тартыш. Халыкны тынычландыра алмагач, Вәли абый Әхмәдиев үзе чыгып басты. «Иптәшләр! – диде ул. – Мине хөрмәт итеп яклавыгыз өчен зур рәхмәт. Әмма соңгы елларда саулыгым бик нык какшады минем, алдагы көндә мондый җаваплы, тынгысыз авыр эшне тартырга көчем җитмәс. Партиябез безгә теләсә кемне җибәрмәс. Иптәш Запускалов – көче ташып торган яшь кеше, шуның өстенә укымышлы агроном. Әйдәгез, бәхәс-тартышсыз гына сайлап куйыйк үзен«. Кабат тавышка кую Запускалов файдасына булды.

Җыелыш таралышканда, хатын-кызлар арасында: «Гәүдәсе дә ташка үлчәем генә бит моның, ай-һай, халыкны тыңлата алырмы икән?» – дип шикләнүчеләр дә җитәрлек иде. Бу шик аның эшли башлавының беренче елында ук томан кебек таралып юкка чыкты. Александр Семёнович ничек эшләргә кирәклеген күрсәтә дә, оештыра да

белде. Тормышта тырышлык белән рәттән җай килү дигән нәрсә дә кирәк бит әле. Ул рәис булып эшли башлаган көннәрдә Әгерҗенең үзендә оешкан «III Интернационал» колхозы таралды. Республика күләмендә иң алдынгы колхозларның берсе иде. Бу хуҗалыкның рәисе белгечлеге буенча югары белемле зоотехник Рәхмәтуллин, нәселле сыерлар үрчетү белән шөгыльләнеп, зур уңышларга иреште. 4-5 мең литр сөт бирә торган сыерлар илленче елларда районда бары «III Интернационал«да гына иде. Александр Семёнович форсаттан бик шәп файдалана: кредитка сатыла торган 91 баш сыерны үз колхозына алуга ирешә. Сөтне күп бирә торган элита токымлы әлеге сыерларны, яшь савымчыларга бүлеп бирә. Тиз арада яшь савымчылардан комсомол-яшьләр бригадалары барлыкка килде. Колхозның Кырынды, Карамалы, Чишмә савымчылары, ярышып эшләп, сөт җитештерүдә гаҗәеп нәтиҗәләргә ирештеләр. Яшь савымчылар Гүзәлия Маникова, Кафия Батырова, Рәисә Вәлиәхмәтова, Разия Сәетова районда гына түгел, республика күләмендә дә алдынгылар рәтенә чыктылар.

1955-1960 елларда авылыбызда яңа йортлар төзү киң колач алды. Александр Семёнович колхозчылар җыелышында җитен чәчү мәйданын киңәйтү мәсьәләсен күтәрде. Җитен чәчү, аны йолку күп көч сорый, дип, бик күпләр моңа каршы чыктылар, ләкин ул ниятеннән кире кайтмады, җитен мәйданын тагын да киңәйтте. Колхозчыларны кул көче белән җитен йолкудан коткарыр өчен, махсус машиналар кайтартты. Әнә шулай итеп көз-кыш айларында күп кенә җитен сүсе әзерләнде. Ул елларда авылларда агач йортлар күп салына иде, сүскә ихтыяҗ зур булды, аны сатудан колхоз кассасына акча яңа бәреп чыккан чишмә кебек агып торды. Яңа рәиснең алдан күрә белүенә, тапкырлыгына колхозчылар таң калдылар, аңа ышаныч та бермә-бер артты.

Күзәтеп барган кешегә авылда киң колачлы үзгәрешләр башланганы күз алдында иде. Яңа рәис эшкә керешкәннең атна азагында ук авылга Казан электр техникумыннан студентлар килеп төштеләр, урамнарда баганалар утырту, электр чыбыклары сузу башланды. Бер үк вакытта тракторлар су торбалары салу өчен канаулар казырга керештеләр. Авыл тракторлар тавышыннан гөрләп торды. Авылга су кертелә икән! Яңа килгән рәисебез әйткән, янәсе: «Авылның һәр йортын электрлы, радиолы, сулы итәм», дигән, тагын халыкка җиңеллек ясаячакмын, дип нәрсәләрдер әйткән. Ул көннәрдә авыл халкы телендә бары шул сүзләр генә булды.

Дәүләт күләмендә дә зур үзгәрешләр башланды. МТСлардан авыл хуҗалыгы техникасы колхозларга күчте. Колхозыбызда, машина-трактор паркы белән рәттән, ремонт мастерское төзеп ачып җибәрделәр. Токарь, слесарь, эретеп ябыштыручы кебек яңа һөнәрләр барлыкка килде.

Авылга яңалык китерәсе ул көннең мәшәкате бик иртә башланды. Монтёр егетләр электр чыбыкларын тагын бер тапкыр күздән үткәреп чыктылар. Трактор паркының кирпеч бинасына урнаштырылган «С-100» тракторы моторының карыйсы урыннарын карап бетереп, багына ягулык салдылар, аннары, «бисмиллаһ» әйтеп, генераторга тоташтырдылар. Утызмеңче дә түзмәде, паркка берничә тапкыр килеп, егетләрнең хәлләрен белеп китте.

Офыктан сүлпән генә караңгылык иңеп килгәндә, кинәт могҗиза булды: йортларда, фермаларда, җәмәгать урыннарында, урамдагы баганаларда гөлт итеп утлар кабынды. Лампочкалардан сибелгән нурларга карап, хәтта бик сирәк елмая торган кешеләр дә елмаеп куйдылар. Шул ук атнаны колхозның үз радиоузелы эшли башлады. Һәр атнаның шимбәсендә авылыбыз үзешчәннәренең чыгышларын яше-карты түземсезлек белән көтеп алды.

## Мәдәни тормыш

Авыл халкының рухи яшәешендә дә уңай үзгәрешләр башланды. 1955 елның җәендә үзенең гаиләсе белән Кырынды мәктәбенә укытучы булып Әнвәр Закиров килде. Бу үзешчән рәссам, оста баянчы, һәрьяклы талант иясе авылның мәдәни тормышында күктә балкучы йолдыз кебек булды. Аның тырышлыгы белән, Мәдәният йорты каршында үзешчәннәрдән торган хор коллективы оешты. Ул табып алган

үзешчән җырчыларыбыз Касыйм Шакиров, Кәшфи Бадыйков, Фәүзә Әхмәтовалар республика бәйгеләрендә катнашу бәхетенә иреште, аларның җырлаулары Татарстан радиосыннан да яңгырады. Ул елларда кешеләргә шәхес буларак зур әһәмият бирелде. Мәдәният йортында, мәсәлән, яңа өйләнешкән парларны тәбрикләү, бүләкләр тапшыру, дөньяга килгән сабыйларны тантаналы төстә яздырып, таныклыклар тапшыру, чәйле табыннар оештыру – барысы да тәрбияви чаралар иде.

Илле алтынчы елның Октябрь бәйрәме аеруча тантаналы шартларда үтте. Сугыштан соң колхозыбыз тарихында беренче тапкыр хезмәт алдынгыларына тегү машиналары, радиоалгычлар, кыйммәтле келәмнәр бүләк иттеләр. Гадәттә, шулай бит ул, колхоз алдынгы булса, авыл советы да алдынгы була. Кырынды авыл советы (рәисе – Хаҗиәхмәт абый Нуриев) берничә тапкыр республика күләмендә 2нче, 3нче урыннарны яулады. Татарстан Министрлар Советының күчмә Кызыл байрагын, акчалата бүләкне Министрлыкта эшләүче якташыбыз Шәрифуллин (тумышы белән Олы Барҗы авылыннан) алып килеп тапшырды, (мин ул елларда авыл советы депутаты идем, болар барсы да күз алдымда эшләнде).

1959 елның мартында авыл халкы яратып өлгергән утызмеңчебезне кабат Казанга, Авыл хуҗалагы министрлыгына министр урынбасары итеп алдылар. Колхозның гомуми җыелышы бик киеренке үтте. «Юк, рәисебезне бирмибез. Ул килгәч кенә авызыбызны тутырып ипи ашый башладык, утлы, сулы булдык. Кәнфит кәгазенә генә төреп йөртерлек кеше бит ул. Бирмибез булгач, бирмибез», – дип, халык бик әтәчләнеп караса да, Казаннан килгән вәкил: «Иптәш Запускаловны обком карары белән күчерәбез», – дип, кашын җимереп, катгый итеп әйткәч, тындылар тагын.

Авыл халкы Александр Семёновичны бик җылы итеп озатты, чөнки ул моңа лаек иде. Таякка таянган хуҗалыгыбызны өч ел эчендә миллионер дәрәҗәсенә күтәрде ул. Байлыкка, дәрәҗәгә кызыкмаучы бу кеше Казаннан күтәреп килгән ике чемоданын кире күтәреп китеп барды. Хуҗалык дилбегәсен үзе белән урынбасар булып эшләгән, үзе кебек үк югары белемле агроном Илтөзәр Сәлимгәрәевка тапшырып китте.

Яңа сайланган колхоз рәисе хуҗалык белән таныш, утызмеңчедән шактый тәҗрибә алган һәм үз башы белән уйлый торган җитәкче иде. Ул беренче көннән үк җиң сызганып эшкә кereште. Сәлимгәрәев, иртән идарәгә килгәнче, таңнан торып фермаларда, трактор-машина паркында булырга өлгерә торган иде.

1960 елда Чапаев исемендәге колхозда, районда беренчеләрдән булып, үрнәк күрсәтмә хуҗалык (опытно-показательное хозяйство) оештырылды. Колхозга өстәмә тракторлар, тагылма техника, яңа сорт чәчү орлыклары, фермаларга саву аппаратлары кайтартылды. Терлекчелектә безнең шартларга чыдам, сөт күп бирә торган «холмогор» токымлы сыерлар үрчетүгә өстенлек бирелде. Хуҗалыкта, районда беренче буларак, «түгәрәк ферма бинасы» төзелеп куллануга тапшырылды. Әнә шулай итеп, биредә башкаларга өйрәнү, тәҗрибә алу өчен күп нәрсәләр барлыкка килде. Шуңа күрә бирегә колхоз рәисләре, агрономнар, зоотехниклар, ферма мөдирләре, бригадирлар бик еш килә, район оештырган семинарлар, киңәшмәләр һәм башка чаралар биредә үтә иде. Ягъни бу хуҗалык район колхозлары өчен өйрәнү базасы булды. Биредә, беренче чиратта, бөртекле культураларның яңа сортларын сынап карау тәҗрибәләре үткәрелде. Бигрәк тә бодайның «Саратов», арышның «Казанский-38», «Вятка» сортларын чәчеп югары уңыш алуга ирешелде. Хуҗалык агрономнары Сәет Әминов, Мансур Низамов, практикага кайткан Фаил Гаскәров, соңрак Сәгыйр Ситдыйковлар биредә зур тәҗрибә мәктәбе үттеләр. Хуҗалыкның уңышлары дәүләтебез тарафыннан югары бәяләнде. Тракторчы-механизаторлар Хәмзә Сөләйманов, Галинур Галиев, Анатолий Гребенщиков, ашлама-торф чыгару отряды бригадиры Мәхтүрҗан Гыйльфанов I, II дәрәҗә Дан ордены һәм медальләр белән, үзбушаткыч машина шофёры Минсәет Мөхәммәтшин – Ленин ордены, колхоз рәисе И.Сәлимгәрәев Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнделәр. Терлекчелектә дә яшь савымчылар үсеп чыкты: С.Сәляева, Ф.Шәйдуллина, Ф.Галләмова,Ф.Закирова,

С.Мөхәммәтшиналар һәр сыердан елына 3-4 мең килограмм сөт сауды.

Чапаев исемендәге колхоз әнә шулай алга, яңарышка омтылуын дәвам итте. Энергиясе ташып торган яшь колхоз рәисенең ялгышып куйган вакытлары да

булмый калмагандыр, әлбәттә. Андый чакта төзәтеп җибәрүче, төпле киңәшләре белән ярдәм итүче Гөлсем апа Мусина – колхозның партоешма секретаре һәрвакыт янында иде...

## Бала табу йорты

Авылыбызда сугыштан соңгы буын үсеп җитте. Егетләр өйләнделәр, кызлар кияүгә чыкты. Урамнарга ямь биреп, йөкле хатыннар күбәйде. Минем медпункт мөдире булып эшләгән вакытым. Акушеркалар Кафия Сөләйманова белән Розалия Фәрвазова юлдан кайтып керә алмыйлар, бәбәйгә узган хатыннарны Вольный Труд участок хастаханәсенә йә тимер юл хастаханәсенең бала табу бүлегенә озата баралар.

Колхозда бер кешене бишкә бүлә торган урып-җыю вакыты. Без машиналарны, атларны идарә планёркасында билгеләнгән эшләреннән өзәбез. Бригадирлар безгә транспортны йөзләрен чытып, ыңгырашып кына бирәләр. Миңа күп вакытта колхоз рәисенең үзенә мөрәҗәгать итәргә туры килә иде. Бер барганда шулай, Сәлимгәрәев мине каршысына утыртты да, бераз уйланып торгач: «Кара әле, Габдулла, әллә ул бала табу йортын үзебездә ачып карыйбызмы?» – диде. «Белмим шул, – дидем мин. – Бу бик җаваплы нәрсә, аннан әле югарыдан рөхсәт тә кирәк булачак...» «Анысын миңа калдыр», – диде рәис.

Һәм ул сүзендә торды, районга барып, югарыдагылар белән дә, баш табиб белән дә сөйләшеп кайтты. Икенче көнне үк баш табиб Михаил Фёдорович Спиридонов белән санэпидемстанция башлыгы Риф Гыйматович Абитов килеп төштеләр. Сәлимгәрәев үзе дә килеп җитте. Медпункт урнашкан алты почмаклы йортның буш ягын бергәләп карап чыгып, фикер алышканнан соң, аны бала табу йорты итәргә яраклы дип таптылар. Вак-төяк ремонт, чистарту эшләре үткәргәннән соң, ике атна эчендә ике койкалы колхоз бала табу йортын ачып та җибәрдек. Акушеркаларга хезмәт хакы түләүдән тыш, колхоз бөтен чыгымнарны үз өстенә алды. Медпункт акушеркасы янына тагын ике акушерка җибәрделәр. Дежур тору графигы төзелде. Вольный Труд участок хастаханәсе йортны стериль материаллар белән тәэмин итеп торды. Әнә шулай бала табу йортыбыз матур гына эшләп китте. Ике койка бервакытта да буш тормады, бирегә хәтта күрше Шаршады авылыннан да килеп бәбәйләүчеләр булды. Акушерларыбыз Розалия Фәрвазова, Рәйсә Муллахмәтова, Минзифа Вахитовалар, зур җаваплылык тоеп, тырышып эшләделәр. Бу игелекле йорт авыл халкы тарафыннан гел яхшы яктан гына искә алынды.

Соңгы елларда телевизордан күреп торабыз, илебезнең иң дәрәҗәле, иң яхшылардан саналган бала табу йортларында да коточкыч «ЧП»лар була. Шушы юлларны язып утырганда, шатланып уйлап куям: Аллаһы Тәгалә саклагандыр безне, ике елдан артык эшләгән, шул фәкыйрь генә җиһазлы бала табу йортыбызда бер ананың һәм бер генә сабыйның да үлү очрагы булмады.

## Төзелештән – төзелешкә

Илтөзәр Сәлимгәрәев һәрвакыт авылыбызны төзекләндерү турында хыялланып яшәде. Ә моның өчен, әлбәттә, төзү материаллары, бигрәк тә кирпеч кирәк. Ул елларда аны ерактан кайтару шактый кыйммәткә төшә торган иде һәм ул, уйланып йөри торгач, кирпечне үзебездә сугарга кирәк, дигән карарга килә. Ниятен озакка сузмый, авылыбызның «дипломсыз инженеры» Гаяз Әхмәтовны машинасына утырта да Исәнбай авылына китә. Биредә инде берничә ел кирпеч заводы эшли һәм сыйфатлы кирпеч чыгаралар икән. Болар завод белән танышып кайталар. Гаяз, куен дәфтәренә сызгалап, кирпеч сугу схемасына кайбер яңалыклар да кертә. Барсын да уйлап-тикшереп өйрәнгәннән соң, авыл башыннан кирпечкә яраклы кызыл балчыклы урын сайлап, завод төзергә керешәләр. Гаяз төзелешкә тагын да күп кенә җайланмалар кертә, завод бер ай эчендә сафка басып, кирпеч чыгара да башлый. Бу – колхоз өчен зур хәзинә иде, хуҗалыкта төзелеш алып бару бик күпкә җиңеләйде. Монда чыккан кирпечләрне күбрәк ферма, склад, трактор паркы төзелешенә кулландылар. Шәхси хуҗалыкларга да өлеш чыкты, шулай итеп, авылда төзелеш гөрләде. Вакыт үткән саен, кирпечнең сыйфаты камилләшә барды, авыл хуҗалыгы белгечләренә аерым бүлмәләр, утырыш

заллары белән тау буенда бик күркәм идарә бинасы калкып чыкты. Ә авыл халкын иң куандырганы авыл уртасында икмәк пешерү бинасы барлыкка килү булды. Игелекле эш рәхмәтсез булмый, бигрәк тә икмәк пешерү кебек мәшәкатьле эштән коткарганы өчен, хатын-кызлар колхоз рәисенә кат-кат рәхмәтләрен җиткерделәр.

## Мусиннар

Мин инде колхозның партком секретаре Гөлсем апа Мусинаны искә алып үттем. Хәзер Гөлсем апаның аерылгысыз дусты, тормыш юлдашы Йосыф ага Мусин турында язам.

Йосыф ага Мусин сугыштан соң Кырынды мәктәбенең беренче директоры, заманында шөһрәтле мәгърифәт үзәге булган Иж-Бубый авылыннан иде. Ходай бүләк иткән төз гәүдә, буй-сын, күпләрдән аерылып торган сөйләм культурасы аның тумыштан ук зыялы нәселдән икәнлеген күрсәтеп тора иде. Йосыф ага сугышның беренче көннәреннән үк Бөек Ватан сугышында катнаша. Ленинград өчен барган авыр бәрелешләрнең берсендә, кулы яраланып, госпитальдә дәваланганнан соң, хәрби хезмәткә яраксыз дип табылып, тылга җибәрелә һәм ул Көчек җидееллык мәктәбендә укытучы булып эшли башлый. Шунда үзе кебек яшь укытучы Гөлсем белән таныша, алар гаилә корып җибәрәләр. Ләкин бу бәхетле гаиләгә Көчек авылында озак яшәргә туры килми. 1943 елның көзендә Йосыф абыйны Кырынды җидееллык мәктәбенә директор итеп күчергәч, алар шушында килеп төпләнә.

Йосыф ага авылның иҗтимагый-сәяси тормышында да актив катнашты, илленче елларда Будённый исемен йөрткән Төрдәле колхозында партоешма секретаре буларак та, авыл халкы белән якыннан аралашты һәм үзен акыллы, сабыр җитәкче итеп күрсәтте.

Йосыф ага һәм Гөлсем апа авыл халкының иң хөрмәтле кешеләре булды, аларны авылның яше дә, карты да онытмый, чөнки бик күпләргә тәрбия-белем биргән, тормышка аяк бастырган хөрмәтле мөгаллимнәр иде алар. Кимчелек-хаталарын Ходай гафу итеп, урыннарын җәннәттә кылса иде!

## Фоат Садыйков

Фоат ага 1918 елда – дәһшәтле Гражданнар сугышы барган чорда дөньяга килә. 1926 елда авылдагы башлангыч сыйныфны тәмамлагач, аны Татар Шаршадысындагы мәктәпкә илтәләр. Ул шунда бик теләп матур гына укый башлый, әмма бишенче сыйныфны тәмамлагач, малайны мәктәптән чыгаралар. «Чөнки, – дип яза Фоат абый истәлекләрендә, – 1931 елда әтиемне, кулга алып, төрмәгә яптылар. Ярый әле авыл советы каршында оештырылган драмколлектив бик актив иде. Үзебездә генә түгел, күрше авылларда да атна саен спектакльләр куеп тордылар, мине дә үзләренә суфлёр итеп алдылар. Һәр спектакльдән әнә шулай бер сум акча эшләдем».

Улы өчен борчуга калган Минҗыян апа 1932 елның август аенда Фоатны Тирсәгә алып бара. Ул елларда Тирсә мәктәбендә директор булып Советлар Союзы Герое Асаф Абрахмановның әтисе Котдус ага эшли. Ул Фоатны 6нчы сыйныфка укырга кабул итә. «Мин рәсемнән кала бөтен фәннәрдән дә гел «бишле»гә укыдым» – дип искә ала Фоат ага.

1934 елны ул, авиация техникумына укырга керү нияте белән, Казанга китә. Имтиханнарны уңышлы гына тапшырса да, конкурстан үтә алмый, документларын кире кулына тоттырып кайтарып җибәрәләр. «Елый-елый урамга чыктым. Инде нишләргә? Кая барырга? Кесәмдә сукыр бер тиен акчам да юк. Вокзалга киттем. Перронда елап утырам. Яныма яхшы гына киенгән бер кеше килде дә: «Егет кешегә елап утыру килешми, йә, сөйлә әле миңа, нәрсә булды?» – дип сорады. Мин аңа башымнан кичкәннәрне сөйләп бирдем. «Кайгырма, була торган хәл. Әйдә, киттек», – диде. Ул мине үзенә ияртеп педтехникумга алып килде. Директорына минем турыда сөйләде. Документларымны карап чыккач, директор: «Безгә тиешле имтиханнарны тапшыра алсаң, студент итеп алырбыз үзеңне», – диде. Имтиханнарны «бик яхшы» билгеләренә генә тапшырдым. Шулай итеп, мин Болак буендагы педтехникумның студенты булдым», – дип яза ул.

Бередә Фоат Садыйков өчен яңа тормыш башлана. Монда яңалыкка омтылучы зирәк егетне бик тиз күреп алалар, шигърияткә тартылганын белгәч, әдәби түгәрәккә чакыралар. Җитәкчеләре Гали Хуҗи түгәрәк утырышларына Хәсән Туфан, Шамил Усмановларны чакыра. Башка студентлар белән бергә Фоат та үзенең шигырьләрен укый, уңай бәя алганнарын «Яшь ленинчы» газетасына илтә. 1937 елны Фоат А.С.Пушкинның юбилеена багышланган бәйгедә катнашып, шагыйрьнең әсәрләрен сәнгатьле уку буенча беренче урын яулый һәм аның җыелма әсәрләре белән бүләкләнә.

1937 елны кулына диплом алган педагог Азнакай районының Әсәй авылы мәктәбенә укытучы итеп эшкә җибәрелә һәм ул биредә рус теле укыта, мәктәп тормышында актив кайный, әдәби түгәрәкләр җитәкли. 1938 елның көзендә Фоат Садыйковны Тирсә мәктәбенә татар теле һәм әдәбияты укытучысы итеп күчерәләр. Балалар да, ата-аналар да бик яраталар, хөрмәт итәләр аны. Укучылары сәнгатьле сөйләү буенча бәйгеләрдә җиңүләр яулый.

1942 елда Фоат аганы укытучы булып эшләгән җиреннән армиягә алалар. Казанда берникадәр вакыт хәрби хәзерлек узганнан соң, аны Көнбатыш фронтка озаталар. Ул Мәскәү астындагы Калуга шәһәрен азат итүдә катнаша, ләкин кинәт фронттан тылга чакырып, кырык икенең декабрь аенда Минзәләдәге политработниклар курсына укырга җибәрәләр. Ул кырык өченең мартында курсларны тәмамлый, лейтенант дәрәҗәсе биреп, аны яңадан Карелия фронтына җибәрәләр. Ул анда батальон командиры урынбасары буларак сугыш операцияләрендә катнаша, фронтның татар сугышчылары өчен чыга торган «Ватаным өчен – сугышка!» газетасына мәкаләләр җибәреп тора.

1944 елда аны тылдагы партия-совет эшендә катнашу өчен туган ягына кайтаралар. Ул елларда Фоат абый Әгерҗе райкомында парткабинет мөдире, райкомның пропаганда бүлегендә эшләп ала. 1950 елда Кырынды мәктәбенә кайтып, тарих укытканда, эзтабар тарихчылар түгәрәге оештырып җибәреп, Удмуртия буйлап сәяхәт итә. Анда тапкан материалларны «Совет мәктәбе» журналында зур мәкалә итеп бастыра. Игелекле эшләр дәвам итә, яшь тарихчылар демократ шагыйрь Даут Гобәйди әсәрләрен эзләп табып, бастырып чыгару бәхетенә ирешәләр. Фоат аганың «Туган якны өйрәнү практикасыннан» дигән фәнни хезмәте РСФСР Мәгариф Министрлыгы тарафыннан югары бәяләнә һәм аңа «Россиянең халык мәгарифе отличнигы» дигән мактаулы исем бирелә. Шунысын да әйтим: Фоат абый Садыйков гаҗәеп трибун иде. Октябрь, Май бәйрәмнәрендә һәм башка әһәмиятле даталарда, халыкны җәлеп итеп, эчтәлекле докладлар белән чыгыш ясар иде. Тагын шунысы бар: хәтта радио-телевидение дикторлары көнләшерлек сөйләм культурасына, аһәңле тавышка ия иде ул.

Фоат абый озак еллар дәвамында районыбызның «Ленин юлы» газетасының алыштыргысыз хәбәрчесе булды, аның язмаларын районыбызның яше-карты бик яратып укыды. Ул Хәсән Туфан, Гариф Ахунов, Рәшит Әхмәтҗанов кебек язучылар белән дус иде. Сиксәненче елларда язучылар төркеме авылыбызга килгәч, Хәсән ага Туфанның, Фоат абыйны сорап, аларда кунып калуы да шул турыда сөйли. Шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов белән Фоат абый Даут Гобәйдинең шигырьләрен китап итеп чыгарганнар икән.

Фоат абый белемле, ярдәмчел кеше иде. Бик еш киңәш сорап, нәрсәдер язарга кирәк булса, аңа киләләр иде. Ул беркемне дә кире бормады. Тол хатыннарга сугышта вафат булган ирләре өчен пенсия, балаларына пособиеләр алуга Фоат абый язган гаризалар һәрвакыт ярдәм итте. Фоат абыйның тормышында фаҗигаләр аз булмады. Матур гына гаилә корып яшәп ятканда, берничә көн генә авырып, хатыны Наилә апа үлеп китә. Аннан уртанчы улы Рубин, Варзи-Ятчә аэродромыннан эштән кайтканда, төнге буранда адашып туңып үлә. Тагын берничә елдан кече улы Рөстәмнең фаҗигагә юлыгып вафат булуы турында коточкыч хәбәр килеп ирешә. Ничек түзде икән аның йөрәге? Хәер, кайгылы көннәрендә аны ялгыз калдырмадылар, янында һәрвакыт хезмәттәш дуслары, яраткан укучылары булды. Фоат абый соңгы сәфәренә җирле җитәкчеләргә үпкәләп китеп барды. Берничә ел, зур кыенлыклар белән оештырган мәктәп музееn, мәктәптә болай да бүлмәләр җитми, дигән сылтау белән юкка чыгаруларына рәнҗеп яшәде һәм аны саклап кала алмавына бик үкенде ул.

Фоат абыйның үзеннән бердәнбер улы Зөфир Садыйков калды. Садыйковлар

нәселен дәвам итүче Зөфирнең улы барлыкка бик шатлана иде ул. Зөфир, Уфа медицина институтын тәмамлап, Ижауга кайтты һәм балалар хастаханәсендә җитлекмичә туган бәбиләр бүлеген җитәкләде. Табиб-педиатор Зөфир Садыйковның исеме күпләргә таныш: әнисе Наилә апа кебек мөлаем, йомшак күңелле, үтә дә игелекле доктор. Зөфир туган авылындагы инде сәламәтләнүе өметсез дип диагноз куелган сабыйларны да үз бүлегенә алып дәвалап аякка бастырды. Авыл халкы аңа бик рәхмәтле.

## Авылның йөрәге – авыл советы

Октябрь революциясенә кадәр старосталар авылларда башлыклар булып торганнар. Кырынды белән Төрдәле үзләреннән унике чакрым ераклыктагы Мүшәк (Мушаково) волосте карамагында булганнар (бу авыл хәзер Удмуртия җирлегенә керә). Авылыбыз старосталарын башта халык сайлаган, әлбәттә, бу халык җыеннарында волость башлыгы белән урядник катнашкан (Әсәдулла абый белән Дәхидулла абзый сөйләгәннәрдән). Халыкка караганда үзләренә кулайрак, нык тормышлы кешене сайлатканнар. Староста, һәр атнаны волостька барып, авыл хәлләре, налоглар түләү мәсьәләләре буенча отчёт биреп кайткан. Авылыбызның соңгы старостасы Ситдыйк бабай булган. 1918 елда авыл советы оеша, аның беренче рәисе итеп Мөхәмматҗанов Хуҗа бабай сайланып куела. Мин үзем белгәннәре – Әхмәдиев Вәли, Минегулова Сәмига апа, сугыштан исән-имин кайткан Нуриев Хаҗиәхмәт абый башта авыл советы секретаре, илленче елны Вәли абый Әхмәдиев колхоз рәисе булып күчкәч, авыл советы рәисе булып сайланды. Үзем дә, ул елларда авыл советы депутаты буларак, яхшы хәтерлим: Хаҗиәхмәт абый сессияләрне бик төгәл итеп вакытында үткәрә, авыл төзелеше, укыту-тәрбия, халыкка медицина хезмәте күрсәтү, депутатларның башкарган эшләрен тыңлап үтү кебек көн тәртипләре кертеп, бик эшлекле уздыра торган иде. Ул елларда (60-70-80нче еллар) авылда халыкны тәртиптә тотуда зур әһәмияткә ия иптәшләр суды, урамнарда төнге дежурлык, халык дружиналары авыл советының күзәтүендә булды. «Иптәшләр суды» (суд рәисе – халык үзе сайлап куйган Фәхри Шәйхетдинов) җәмгыять урыннарында хулиганлык кылучыларга, колхоз милкенә кул сузучыларга карата катгый гына тәрбия эшләре алып барды. Халык алдында кызарып басып торган гаепләнүчеләр, өлкән яшьтәгеләр, туганнары, дуслары акыллы сүзләр, эшлекле киңәшләре белән чыгышлар ясагач, гаепләрен таныргa, киләчәктә мондый хурлыклы ялгышлар ясамаска халык алдында сүз бирерләр иде.

Хәрби кеше булгангамы (ул сугыштан лейтенант булып кайтты), Хаҗиәхмәт абыйның холкы бераз кырысрак иде. Кайвакытта ул халык белән эшләүдә хаталар да җибәргәләде. Шундыйлардан: колхоз идарәсе җитәкчеләренең күрсәтмәсе белән, эшкә чыкмаучыларның, сәбәбен дә тикшереп тормыйча, сыерларын көтүгә чыгартмау, бәрәңге бакчаларын кисүләр; шуларның берсе, мәсәлән: Бөек Ватан сугышында бер аягын калдырып кайткан сугыш инвалиды Хәмидуллин Шәрифулла абзыйның малае шәһәргә китеп барган өчен, бәрәңге бакчасын кискәч, инвалид картның күз яшьләрен агызып рәнҗеп елавын күрү минем йөрәгемне сыкратып, хәзер дә күз алдымда тора. Бу очракта авыл советы кайда иде соң? Якламады ул Бөек Ватан сугышы инвалидын, колхоз идарәсе күрсәтмәсенә буйсынды, битарафлык күрсәтте. Әнә шундый хаталары булуга карамастан, авыл советын тотрыклы җитәкләде ул. Нәкъ менә Хаҗиәхмәт Нуриев авыл советы рәисе булып эшләгән елларда, авыл советы Татарстан Министрлар Советының күчмә Кызыл байрагына лаек булды.

## Авылның медицина пункты эшчәнлеге турында

Урамга ян белән салынган алты почмаклы Матвей кулак йортына урнашкан медицина амбулаториясенә 1932 елда фельдшер булып Захар Константинович Коробейников килә.

Мин аны якыннан беренче тапкыр икенче сыйныфта укыганда күрдем. Мәктәптә дәрес вакытында кинәт колагым сызлый башлады, сулкылдап сызлаганга түзә алмыйча елап җибәрдем. Укытучыбыз Әмитов абый кайтарып җибәрмәде, медпунктка барырга

кушты. Өстенә ак халат кигән, озын буйлы, Чапаевныкына (кинода күргән Чапаев) охшаган мыеклы кеше минем белән йомшак кына сөйләште, колак тишегемнениндидер әйбер белән карагач, дару тамызды да көтү бүлмәсендәге эскәмиядә бераз утырып торырга кушты. Тиздән яныма чыгып: «Ну как?» – дип сорады. Колагымның авыртуы басылган иде, мин, рәхмәт әйтергә дә онытып, чыгып йөгердем.

Фельдшер Коробейников зыялы кеше иде, бик матур киенеп, галстуктан йөрде, кулында күренекле табиблар тотып йөри торган кәкре таяк иде. Халык арасында гына түгел, сәламәтлек саклау даирәсендә дә абруе зур булгандыр. Чөнки Коробейников авыргач, Казаннан ике канатлы самолётта профессорлар килделәр. Авыл башына төшкән самолётны күрергә авылыбызның бөтен яше-карты җыелды. Фельдшерыбызның авыруы җитди булгадыр, күрәсең, ул хатыны Анна Васильевнаны ялгызын калдырып китеп барды. Хөрмәтле фельдшерыбыз Коробейниковны озатырга бөтен авыл халкы җыелды, аның белән хушлашырга, сафларга тезелеп, без, мәктәп балалары да килдек.

Коробейниковтан соң авылыбызга фельдшер булып Казан медтехникумын тәмамлаган Кыдырлы авылы егете Димөхәммәт Якупов килде. Яшь, энергиясе ташып торган егетне авыл халкы бик тиз яратып өлгерде. Ул авырулар күңеленә ачкыч таба белә һәм ышандыру көченә ия иде. Аның дәвалау осталыгы тирә-якка таралды. Аңа хәтта Удмуртиянең ерак районнарыннан килерләр, күпләре: «Дими Якуповка йөри башлагач кына терелдем», – дип сөйләрләр иде.

Икенчесе, Якупов белән Казанда медтехникумда укыган акушерка Зәетова Кафия апа, тумышы белән Кыдырлыдан булса да, ата-аналары Әгерҗегә күчкән гаиләдән иде. Шактый күп еллар үткәч, без аның игелек кылып, авырлыкка төшкән кешеләргә ярдәм итеп яшәүче абруйлы сәүдәгәр Зәетовлар нәселеннән икәнен белдек. Акушерка Кафия апа Кырындыдан өч чакрымдагы Йолдыз авылында яшәде. Кайтып кына керер иде, «Кафия апа, хатыным бәбәйгә авырды», – дип килеп тә җитәрләр иде. Ул акушерка булып эшләгән 1955-1960 елларда Кырынды авыл советы буенча 35-40 бала туар иде. Хатыннарның яртысын өйдә бәбәйләтергә туры килде, район хастаханәләрендә, бала табу бүлекләрендә урын җитми, шуның өстенә анда илтергә транспорт табуы иң авыр мәсьәләләрнең берсе булды. Кафия апа, соңрак яшь акушерка Розалия, бик кыен шартларда эшләделәр. Мин аларның батырлыкларына хәзер дә сокланып туя алмыйм.

Кырынды медпункты мөдирләре булып төрле елларда эшләгән фельдшерлар: Шадрин, Щелконогов, Бахреевалар авыл халкына медицина ярдәме күрсәттеләр.

1955 елның августында Алабуга медучилищесын тәмамлап кайткач, медпункт мөдире булып мин билгеләндем.

Авылның санитария торышы начар иде. Төрдәледә Садыйков Галимәрдән абзыйларның бәрәңге бакчалары артында бөтен авылга бер чишмә, суга килгән һәркем үз чиләген батырып су ала, су белән тулган тәпәннең өсте ябылмый кала иде. Авыл халкының сәламәтлек торышы да уйланырга мәҗбүр итә торган хәлдә, унике гаиләдә трахома (йогышлы күз авыруы), корчаңгы (йогышлы тире авыруы), педикулёз (бетләү), таракан иде.

Трахома белән көрәштә, беренче чиратта, шәхси гигиена кагыйдәләрен үтәүгә әһәмият бирелде. Һәр йортта умывальник булдыру, гаиләдә һәркемгә аерым сөлге тоту тәртибе кертергә тырыштык. Трахома белән авыручылар һәркөнне медпунктка дәваланырга йөрделәр. Трахомадан күрүләре начарланганнарны хастаханәгә озаттык.

Тырышуларыбызның нәтиҗәсе булды, бер ел эчендә трахоманы җиңдек. Безгә медицина хезмәткәрләре җыелышында Райкомның беренче секретаре Гәрәев «Халыкка медицина хезмәте күрсәтүдәге уңышлары өчен» дигән мактау грамотасы тапшырды.

1957 елның көзендә авылыбызда бик күңелсез хәл булып алды. Армиягә китәргә чакыру алган Сабирҗанов Мансур исемле егетебез машинага тапталып һәлак булды. Сәгатендә үк фаҗига урынына чакырып алдылар. Егет аңын югалткан, йөзе акшарланган кебек агарган, пульсы юк дәрәҗәдә, мондый билгеләр күп вакытта эчке кан киткәндә була. Егетне район хастаханәсенә илтергә кирәк. Иң аянычы шул: ул елларда район хастаханәсендә ашыгыч ярдәм күрсәтү пунктлары юк иде әле. Хастаханә белән элемтәгә кердем. Җавап кыска булды: «Машинабыз юк, дежур табиб бар, монда

китерегез«. Авыруның хәле бик җитди икәнен кабат аңлатырга тырышканда, элемтә өзелде, кабат элемтәгә керергә маташтым, җавап бирүче булмады.

Авыл буйлап машина эзләп йөрергә мөмкинлегем юк, авыруым янынннан китә алмыйм. Паркка җибәргән кешеләрем: «Колхоз машиналары барсы да юлда, паркта ремонтка сүтелгән машиналардан кала, кычкырып еласаң да, берни дә юк», – диделәр. Кырыема җыелган хатыннар: «Көндез үк исерек иде инде ул, исереккә шайтан булсынмы, менә йокысы туйгач сикереп торыр әле», – диештеләр дә үз юлларына китеп бардылар.

Мансур төн уртасында аңына килә алмыйча китеп барды. Вольный Труд участок хастаханәсендә Мансурны ярып тикшереп карадылар. Нәтиҗә: бавыры ярылган, нык бәрелүдән баш миенә кан сауган, эчке кан китүдән үлгән булып чыкты. Бу вакыйга миңа бик нык тәэсир итте, шуның артыннан берничә көн үзем дә авырып алдым.

Күп тә үтмәде, Ситдиковлар гаиләсендә коточкыч вакыйга булды. Кичен ау мылтыгын корып утырган җиреннән әтиләре «С»нең кинәт мылтыгы атылып китә. Каршында утырган бер яшьлек баласы белән анасы идәнгә авып төшәләр. Ядрәләр икесенең дә күкрәкләрен тишеп үтә. Ашыгыч ярдәм сумкамны күтәреп, мин барып кергәндә, йортта коточкыч күренеш иде. Әбекәй белән сабый (оныгы) идәндә кан эчендә тәгәрәп яталар. Әти кеше мылтыгын ташлап чыгып качкан. Киленнәре Миннур үксеп елый. Шул арада бөтен авыл җыелып җитте. Авыл советы рәисе шалтыратырга җитешкән икән инде, ашыгудан сулышы кабынып, участковый килеп керде. «С»не эзләргә чыгып киттеләр. Җиргә караңгылык иңәргә җитешкән иде инде, таба алмыйча кайттылар. Кешеләрдән качып булса да, үзеңнән качып булмый бит. Ул анасы белән баласын җирләргә кайтты. Кулындагы мылтык ялгыш атылган булса да, «С» ялгышын авыр кичерде. Гаиләсе белән Кизел якларына да китеп карады, читтә дә тирән борчылуына тынычлану таба алмады ахры, гел авырды һәм район хастаханәсендә дөнья куйды.

Авыл халкы белән аралашып, матур гына яшәп киттем. 1957 елның ноябрендә Казанда үткән медработниклар корылтаена делегат итеп сайладылар. Минем Кырынды медпункты Республика күләмендәге ярышта үзенең эш күрсәткечләре белән икенче урынны яулады. Амбулаториягә медицина җиһазлы зур шкаф һәм кече хирургия инструментлары белән бүләкләделәр. Көзен медкомиссия алдында имтихан биреп, I категорияле фельдшер исеме алдым.

Шатлыкларым артында алда күрәчәк хәсрәт-кайгыларым яшеренеп яткан икән. Авыруларны дәвалап йөри торгач, үз баламны онытып җибәргәнмен. Өченче сыйныфта укучы улым Сирин кинәт авырый башлады. Һәркөн мәктәптән хәлсезләнеп кайта, аппетиты югалды, күренеп тора – Сирин җитди авыру белән авырый. Анализларын алып, балалар поликлиникасында тикшерү узарга кирәк иде. Сиринем берничә көн поликлиникага барудан баш тартты. Әнисе белән каршыбызга утыртып бик озак үгетләгәч кенә ризалашты. Ул елларда педиатр булып Роза Таһировна эшли иде. Анализларны карап, Сиринне җентекләп тикшергәч, мине бик нык кына тиргәп алды. Сирин ревматизм белән авырый, нишләп безгә мөрәҗәгать итми тордыгыз. Ревматизм йөрәгенә күчә башлаган, бүген үк стационарга салабыз, дигәч, Сирин еларга кереште. Роза Таһировна үзе йомшак кына барсын да аңлатып биргәч, күнде. Малаемны калдырып кайтканымны ишеткәч, әнисе, әбисе еларга тотынды. Әлеге көннән алып күңелләребезнең эчке сиземләвен тойсак та, Сиринебез белән бик авыр сынаулар үтәчәгебезне аңлап җитмәгәнбез икән шул.

## Авылда яңа үзгәреш

Чапаев колхозында шактый озак еллар рәислек иткән Илтөзәр Сәлимгәрәевне кинәт эшеннән алдылар. Кинәт дип язуым шартлы. Сәлимгәрәевне эшеннән алып ташларга тырышучылар бары күптән ишетелә иде инде.

Илтөзәр үзенчәлекле кеше иде. Районның башка колхоз рәисләре арасында аның дуслары юк дәрәҗәдә иде. Райком тирәсендәге кайбер колхоз рәисләре Илтөзәрдән көнләшеп яшәделәр, аның һәр кимчелеген купайтып, райкомның беренче секретаре

Н.Сафинга җиткереп тордылар. Алар өчен Чапаев исемендәге колхоз рәисе Сәлимгәрәев күзләренә кергән чүп иде.

Нургали Сафич (райкомның беренче секретаре), колхозчылар җыелышы ясап, җайлап-майлап кына: «Без Сәлимгәрәевне вакытлыча гына эшеннән алабыз, менә бераз ял итсен, кире үз урынына чакырачакбыз...» – дип, халыкны тынычландырып, рәислектән азат итте. Илтөзәргә районда эшләр тәкъдим итеп карасалар да, кабул итмәде. Удмуртиянең Варзи - Ятчи санаториясенең ярдәмче хуҗалыгына управляющий булып китеп барды.

Сәлимгәрәев урынына Тугызбуй ягыннан китерелгән Н.Мурзинны сайлап куйдылар. Бу кеше авыл хуҗалыгы белән түгел, ә партия-оештыру эшләре белән яхшы таныш иде. Халыкка начар булмады, бик еш авырды, хастаханәләрдә озак кына ятып чыккалады. Ул югында җитәкчелек итеп йөргән хатын-кыз парторгның хезмәтне оештыруда тәҗрибәсе дә, белеме дә җитенкерәмәде, колхоз шактый какшады.

Мурзин намуслы коммунист иде, сәламәтлеге тагын да катлаулангач, гариза язып, эшеннән китеп барды.

1974 елда Кырындыга күптәннән җитәкче булып кайтырга хыялланып йөргән, башка колхозларда рәис, парторг булып эшләп тәҗрибә туплаган Мөхтәр Шабаев кайтты. Үз кешебез дә булгач, колхозчылар аны бертавыштан сайлап куйдылар. Мөхтәр Шабаев рәислек итүнең беренче-икенче елларында яңа дәрт белән матур гына эшләп китте. Терлекләр өчен яңа фермалар, төрле объектлар: яңа медпункт, элемтә бүлеге, киемнәр тегү мастерское, кибет, ашханә төзелеп эшкә тапшырылды. Шулар белән бергә авылда күңелле чаралар: урып-җыюга төшәр алдыннан комбайннар параде (ул елларда районда беренче тапкыр), урып-җыю төгәлләнгәч, комбайннарны идарә алдына кайтарып, җыелган халык алдында комбайнчыларның ярышларда яулаган урыннарын әйтеп, авыл үзешчәннәренең җыр-биюләре белән гөрләтеп бүләкләр тапшырулар, хезмәт кешесен зурлау-данлау – мактауга лаек гамәлләр иде.

Партия райкомының артык үстереп җибәрүеннән башы әйләнеп киттеме, бәлки, халык аңлап җитмәгән башка сәбәпләре дә булгандыр. Мөхтәр Шабаев җитәкчелек итүдә хаталар җибәрә башлады. Бу хаталарның иң беренчесе кадрлар мәсьәләсендә барлыкка килде, дисәм, ялгыш булмас кебек. Колхозның урта звеносы җитәкчелек постларына ул үз нәсел-нәсәбен җыйды, бухгалтериядә дә шундый хәл иде. Үзеңнекеләрне нык таләп шартларына куеп булмый шул. Таләпчәнлек югалу – җитәкчелекнең югалуы белән бер ул. Сиксәненче еллардан башлап колхозның экономик хәле шактый какшый башлады, колхоз рәисе бу хәлне күреп төзәтергә күпме генә тырышып караса да, вакыт ычкынган, соң иде инде. Кайбер аны яратмаган кешеләрнең райкомга жалобалар язып торучылар, районга яңа райком секретаре килү белән, аны эшеннән азат итүне таләп иттеләр.

1986 елның март аенда, Чапаев исемендәге колхозның гомуми җыелышы карары белән (колхозчыларның кул күтәреп тавыш бирүләреннән соң), Мөхтәр Шабаевның эшеннән азат итүне сорап язган гаризасын канәгатьләндерделәр. Аның урынына «Таң» колхозында инженер –механик булып эшләүче Асаф Гарифуллин сайланды. Ул гаиләсе белән Кадыбаштан Кырындыга күчеп килде. Яшь, көче ташып торган Асаф үзен сайлап куйган колхозчылар алдында зур җаваплылык тоеп, аларның ышанычларын аклау өчен, җиң сызганып эшкә кереште. Ләкин кемнәрдер аның бирегә рәис булып килүен ошатмады. Колхозның терлекчелек фермасында йә кочегаркасында янгыннар чыга башлады. Асафлар гаиләсе белән без ике-өч йорт аша гына күршеләр булып яши идек. Асафның тормыш иптәше Зөлфирә: «Без инде өйдә йокларга курка башладык, Тәскирә апа», – дип, хатыныма зарланганын ишетә идем.

Шактый вакыттан соң янгыннар тынды. Колхозчылар рәиснең чын күңелдән эшләп йөргәнен күреп, аңа ышанычлары көннән-көн арта барды. Асаф Гарифуллин керткән яңалыкларның беренчесе механизаторлар арасында таралган эчүчелеккә каршы көрәш чаралары куллану булды. Авылның медпункт хезмәткәрләре һәр иртәне эшкә баручы механизаторларның, юлга чыгучы шофёрларның, профилактик осмотр үткәч кенә, путёвкаларына кул куйдылар. Бу чара механизаторлар арасында ризасызлык тудырса

да, әкренләп күнектеләр, медосмотр куллану үзен аклады. Эчүчелек күзгә күренеп кимеде, хезмәттә җаваплылык артты.

Нигезе Сәлимгәрәев Илтөзәр рәислек иткәндә үк салынган «аксакаллы» мәдәният сараен төзетеп бетерәсе, сафка бастырасы бар иде. Төзелеш материаллары артыннан Асафка, парторг Т.Муллахмәтовка, авыл советы рәисе Шәехова Светланага югары оешма җитәкчеләренә шактый күп чабарга туры килсә дә, халык өчен, ниһаять, шатлыклы көн килде. 1988 елда тантаналы шартларда Кырынды мәдәният йорты ачылып, авыл халкын, районнан килгән зур кунакларны кабул итте. Бередәге кичә авыл яшьләренең бәйрәменә әйләнде.

Асаф Гарифуллин рәис булып эшләгән елларда авыл урамнарына асфальт түшәү иң куанычлы вакыйгаларның берсе иде. Авыллар тарихында гомергә күрелмәгән хәл бит бу! Район авыллары арасында иң беренче булып Кырынды урамнарында асфальт түшәлде. Асаф өчен иң тынгысыз көннәр булды ул, чөнки шул асфальт мәсьәләсендә йә Чаллыга, йә Алабугага, Удмуртия районнарының берсе – Алнашка чабарга, берсен җайларга, икенчесен майларга туры килгәндер.

Тынгысыз кеше иде ул. Мин, юлга җыенучы шофёрларны медосмотр ясап чыгарырга, машина-трактор паркына иртә таңнан килә идем. Ул инде механизаторлар йортына килеп җиткән булыр иде. Механизаторларның хәл-әхвәлен сорашып, киңәшеп эшкә озатыр иде. Ләкин кемнәргәдер ул да ярамады. Колхоз рәисенең үзенә йорт буратуын сәбәп итеп, аның өстеннән партия райкомына жалоба артыннан жалоба яудыра башладылар.

Үзенең гаризасы белән дип, Асафны рәислектән бушату җыелышы тыныч кына үтте. Шулай да күңелләренә җыелган сүзләрен әйтүчеләр булды. «Асафның безгә эшләп калдырган хезмәтләре барыбызның да күз алдында, – диде, урыныннан торып, алдынгы сыер савучы Рәисә Кәримуллина. – Капкабыздан чыгуга, урам буйлап сузылып киткән асфальтка басабыз. Мондый хәл безнең хыялыбызда гына иде, хыялыбыз аның тырышлыгы белән тормышка ашты. Рәхмәт сиңа, Асаф туган! Без сине һәрвакыт рәхмәт хисләре белән генә искә алырбыз», – дип, колхозчыларның алкышлары астында тәмамлады ул сүзен.

## Авылдашыбыз – колхоз рәисе

Авылыбызга колхоз рәисе булып авылдашыбыз Җәүдәт Кәримов кайтты. 1990 елның яз башында аны рәислеккә сайлау бер тавыштан үтте. Җәүдәт Кәримов армия хезмәтеннән кайткач, Удмуртиянең Әсән авыл хуҗалыгы техникумының механизация бүлеген, берничә елдан Ижау авыл хуҗалыгы институтын читтән торып тәмамлап, инженер-механик белгечлегенә ия булды. Аны Чапаев исемендәге колхозда инженер булып эшләгән җиреннән Әгерҗе районының «Алга» колхозына рәис итеп алдылар. Ул елларда кадрларның язмышын партия райкомнары хәл итте. Инде менә Җәүдәт Кәримов кабат туган авылына рәис итеп кайтарылды. Яңа рәис колхозның экономик хәле белән дә, башкасы белән дә таныш иде.

Терлекчелек фермалары искергән, капиталь ремонт сорый, кайберләрен яңадан төзергә кирәк иде. Ләкин ул, беренче итеп, үзе бередә эшләгәндә үк корыла башлаган, хәзер ни сәбәпледер игътибарсыз калган гаражны төзетергә кереште. Үзәктән җылытылган, электр белән яктыртылган, механизаторлар түземсезлек белән көтеп алган зур гараж кышка өлгереп җитте. Салкыннарда машиналарын, тракторларын кабыза алмый газап чиккән шофёрларга, тракторчыларга чын бәйрәм килде. Якты, җылы гаражда эшләү, ремонт эшләре алып бару да бик күпкә җиңеләйде. Ремонт мастерскоена техник җиһазлар кайтарылды. Кичләрен механизаторларның классностьларын арттыру буенча агрономнар, инженерлар катнашында укулар оештырылды. Механизаторларның туган көннәрен тәбрикләп, билгеләп үтүләр гамәлгә керде. Идарәнең утырыш залын киңәйтеп төзү, колхоз идарәсе белән рәттән төзелеп килә торган балалар бакчасын тизрәк сафка бастыруда колхозның ярдәмен әйтеп китәргә була. Санасаң алар күп, әмма мактауга лаеклысы, халыкны дингә кайтару, авыл уртасында манаралары белән балкып торган мәчет төзү булды.

1990 елларда дингә карата Мәскәү ягыннан җылы җилләр исә башлады. Динне кысрыклау бетә барганын күреп, ишетеп торган авыл картлары Җәүдәткә авылда мәчет төзергә кирәк, дип мөрәҗәгать иттеләр. Рәис, картларның фикере белән килешеп, бу эшне колхоз өстенә алды. Галимов Даһидулла абзыйны ике арада төзелү эшен күзәтеп барырга арадашчы итеп билгеләделәр, идарәгә чакырылган төзүчеләр белән сөйләшкәч, эш башланып китте.

Тау буеннан урын сайлап, авыл картлары бергәләшеп, булачак мәчеткә нигез кордык. Ул елларда авылда имамлык иткән Кәримуллин Хикмәтулла абзый, Коръән сүрәләре укып, бу изге эшебезне исән-иминлек белән башкарып чыгарга Аллаһы Тәгаләдән ярдәм сорап дога кылгач, төзү эше башланды.

1992 елның 7 октябрь көнне мәчетне ачу тантанасы булды. Тантанага район башлыгы Н.Баһрамов һәм учреждение җитәкчеләре, колхоз рәисләре килделәр. Мәчетебезне зурлап, акчалата һәм башка бүләкләр тапшырылды. Мәчетне төзүче осталар: Сабирҗанов Мансур, Яхин Рәис, Шәехов Фирдәвес, Әхмәтов Гаяз иҗат иткән гаҗәеп күркәм манараларга (өч манара) килгән кунаклар сокланып карап торды. Мәчетебезгә имам итеп сайланган Даһидулла абзый Галимов белән бергә «Җәүдәт мәчете» дип язылган таш плитканы мәчет стенасына беркетеп куйдык. «Нишләп ул Җәүдәт мәчете булсын? Җәүдәт аны үз акчасына төземәде бит», – диючеләр булды. «Мин Җәүдәтнең бу изге эшкә күпме көч түккәнен үз күзләрем белән күреп тордым. Күпсенмәгез, бу аңа истәлек бүләге булыр», – дип җавап кайтарды Даһидулла абзый. Төрдәле мәчете артыннан ук Кырынды мәхәлләсендә дә шундый ук күркәм мәчет төзелде. Аны төзүдә, колхоз идарәсе белән беррәттән, Кырынды авылыннан чыккан, хәзерге көндә Ижауда яшәүче эшмәкәрләр: Мөхәммәтшина Рәсимә, Закиров Дамир, мәчет әһелләре Кәримуллин Рифкать, Иж-Бубый авылында яшәп, Әгерҗе шәһәрендә эшләүче «Чистый город» ширкәте директоры Расим Закиров (мәрхүм), «Кичкетаң тыюлыгы» начальнигы Фәйзуллин Әһли техник һәм материаль ярдәм күрсәттеләр.

Әнә шулай, авылыбызда ике мәхәллә – ике мәчет барлыкка килде. Ике манарадан намазга чакырып, моңлы азан тавышлары яңгырарга кереште. Авыл халкы онытыла барган иманын кире кайтарып, әкренләп дингә тартылды.

Мәгълүм булганча, 2000 еллар башында илебез буйлап колхозлар тарала башлады. Бу шаукым Чапаев исемендәге колхозны да читләтеп үтмәде.

Күмәк хуҗалык булып яшәргә күнеккән авыл халкы кинәт буранда адашкан кеше кебек калды. Эш юклыктан аптыраган яшьләр хәмергә тотынды, аяныч хәл туды. Яшьләрнең күбесе, авылда эш булмагач, шәһәргә китте, күп йортлар бушап калды.

## Кырынды урта мәктәбенең аяныч хәле

Үзенең 100 еллык юбилее алдында торган Кырынды урта мәктәбе авыл халкына мәгърифәт нуры чәчүдә алга омтылышлар белән данлы юл үтте. Мәктәп укытучылары авыр сугыш һәм сугыштан соңгы киеренке елларда агитаторлар, лекторлар, авыл советы депутатлары иде, халыкның иҗтимагый-сәяси тормышындагы вакыйгаларның үзәгендә иде алар. Авыл халкының аңы, белем югарылыгы, культурасы анда эшләүче укытучыларга бәйле диючеләр белән мин тулысынча килешәм. Чөнки укытучылар мәгърифәтле җирдә халык та шундый була.

Кырынды җидееллык, соңрак урта белем бирү мәктәбендә Г.Мусина, Й.Мусин, Ф.Садыйков, Н.Садыйкова, Р.Аитова, Т.Галиева, Р.Муллахмәтова, Һ.Шәймөхәммәтова, М.Яхина, Ә.Закиров, А.Вахитова, С.Гребенкина, М.Минекаева, И.Зарипова, Г.Харисова, Р.Садыйкова, Л.Шәйдуллина, А.Фәрвазов, Д.Фәрвазова, Р.Гайнетдинова, Г.Әхмәтова һәм башка күп кенә укытучыларыбыз бик тырышып эшләделәр. Озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен мәктәп директоры Г.И.Асаевага «Татарстанның атказанган укытучысы» дигән мактаулы исем бирелде. Башлангыч сыйныф укытучылары Т.З.Галиева районда беренчеләрдән булып «Өлкән укытучы», Р.Г.Ибраева «Әйдәп баручы укытучы» исемнәренә лаек булдылар. Тагын да куанычлысы: Кырынды урта мәктәбен тәмамлап чыккан укучыларның күбесе, югары, урта уку йортларында белем алып, төрле профессияләргә ия булды. Шулардан: 69 укытучы, 9 югары белемле табиб,

20 урта медицина хезмәткәре, 8 агроном, дистәдән артык зоотехник һәм инженер-механиклар.

Түбәндәгеләр белән мәктәбебез горурланырга хаклы:

1. Сәгыйть Хәбибуллин – Казан консерваториясе профессоры
2. Чулпан Сәлимова – Удмуртия авыл хуҗалыгы академиясендә доцент;
3. Чулпан Закирова – филология фәннәре кандидаты;
4. Гөлшат Хуҗина – биология фәннәре кандидаты;
5. Габдулла Галиев – Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы;
6. Светлана Гаскәрова – Минзәлә пед. көллиятендә укытучы һәм директор булып эшләде, хәзер лаеклы ялда;
7. Ирек Шәрипов – Татарстан халыклары дуслыгы йорты директоры, ТР Дәүләт Советы депутаты;
8. Нур Хәмиди – хәрби очучы;
9. Тельман Хәмиди – очучы;
10. Александр Иютин – подполковник;
11. Александр Кочкин – подполковник;
12. Фәрит Низамов – подполковник;
13. Мирсәет Фәсхетдинов – майор.

Тагын дистәгә якын хәрби офицерлар, төрле югарылыктагы хуҗалык җитәкчеләре.

Ни кызганыч, ул мәктәп юк инде хәзер. Балаларын очырган кош оясы кебек бушап калды ул. Район җитәкчеләребез, хәзергә сезгә шушысы да ярап торыр, дигән кебек, башлангыч сыйныфларны балалар бакчасының бер почмагына, кысан гына бүлмәләргә урнаштырып куйды да, шуның белән эшләре төгәлләнде.

Авылым халкы белем алган мәктәбебез ташландык хәлдә ялгызы моңаеп утыра бирә. Мәктәбебез шундый хәлгә калыр дип кем уйлаган, яныннан күз яшьләрсез генә үтеп булмый, – ди авылдашларым.

Йә, Ходай! «Оптимизация» дигән булып, хәзер бар җирдә дә милли мәктәпләрне кыскарту бара. Һәркемгә билгеле, бу чараның башында шул «каһәр суккан капитал» – акча тора.

Бичара авыл мәктәбе! Күпме күренекле шәхесләрне: Тукайны, Туфаннарны, Исәнбәтне милләтебезгә бүләк иттең син! Ифрат итагатьле, кече күңелле, бик күп авыр хәлләрне дә гаять сабырлык белән үткәреп җибәрергә өйрәнгән авыл халкына карата ашыгыч, җитди эшләнгән зур хата икәнен киләчәк күрсәтер әле.

Шулай да авыл халкы, кайчан да булса, бу белем учагы бер торгызылыр, дигән өмет белән яши. Башкача мөмкин түгел, чөнки мәгърифәт йолдызы сүнгән авылның киләчәге юк бит. Без киләчәгебезгә ышанып яшибез, авылыбыз яшәгәндә, мәктәбебез дә торгызылыр әле, иншә Аллаһ!

Мин язып үткән 1930-2010 еллар арасында үз күзләрем белән күргән һәм ишеткән тарихи вакыйгалар шуннан гыйбарәт. Бу кыска гына язмада барсын да яктырту мөмкин түгел, кайбер иптәшләремнең исемнәре, фамилияләре төшеп калган булса, гафу итүләрен сорыйм.

## ГӨЛЧӘЧӘК ГАЛИЕВА
*(1928-2014)*



Язучы-прозаик, әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм публицистик язмалар авторы Гөлчәчәк Кәрим кызы Галиева (Яхина) 1928 елның 5 февралендә Татарстанның Арча районы Сеже авылында укытучы гаиләсендә туа. Үз авылларында җидееллык һәм Арча педагогия училищесында урта педагогик белем ала. Читтән торып укып, 1954 елда Казан дәүләт педагогия институтының тарих факультетын тәмамлый. 1946-1952 елларда туган авылы мәктәбенең башлангыч сыйныфларында укыта. Шул елларда авыл советы депутаты, җәмәгать тәртибендә үзешчән сәнгать түгәрәге җитәкчесе һәм авыл яшьләренең комсомол оешмасы секретаре вазифаларын да башкара. 1952 елдан Г.Галиева Казанда төпләнеп яши. Әүвәл шәһәрнең 26нчы һәм 89нчы мәктәпләрендә пионервожатый, 22нче эшче яшьләр урта мәктәбендә тарих укытучысы булып эшли, 1963 елдан Идел буе районының 18нче эшче яшьләр урта мәктәбендә унбиш ел директор хезмәтендә була.

Бала чактан әдәбиятка, туган телгә гашыйк Гөлчәчәк Галиева мәктәптә эшләгән елларында ук балаларга үзенең төп белгечлеге булган тарих фәненнән тирән белем бирү вазифасы белән генә канәгатьләнмичә, балалар күңелендә матур әдәбиятка, туган телгә мәхәббәт уяту юнәлешендә дә тырышлык күрсәтә. Тора-бара үзе дә кулына каләм алып, көндәлек матбугатта әдәби язмалары, бигрәк тә аерым әдәби әсәрләрнең идея-эстетик эчтәлегенә, теленә кагылышлы тәнкыйть мәкаләләре, рецензияләре белән катнаша башлый. Аның узган гасырның туксанынчы елларында һәм яңа гасыр башында дөнья күргән «Татар хикәясе ни хәлдә?», «Без белгән Бакый агамы?», «Сөяркә булу гөнаһмы?», «Язучы кем өчен яза?», «Каләм алдым кулыма», «Милләт каһарманы», «Чын сәнгать әсәре булсын», Рәфикъ Юныс иҗатына багышланган «Шагыйрь, публицист...» кебек иҗат портретлары һәм тәнкыйть мәкаләләре, аерым караш-фикерләре, әдәби җәмәгатьчелекнең бер өлешендә кайнар бәхәсләр кузгату белән бергә, авторның каләмдәше Фәнис Яруллин әйткәнчә, «Үткенлеге, төпле дәлилләргә бай булуы, кешенең кемлегенә карап тормыйча, бары тик әдәбиятыбыз үсешен генә кайгыртып язылуы белән кызыклы». Г.Галиева көндәлек матбугатта басылган «Сөенечләр бүлештек», «Күп укыган – күп белгән», «Туган телнең ләззәте», «Буыннарның көмеш чылбыры», «Мәйдан токкан егетләрдә өмет», «Ул былбылы иде милләтнең», «Мае беткән шәм шикелле», «Утларыгыз яктырак балкысын», «Сабада алган тәэсирләр», «Юксындырасың, бик тә юксындырасың, Гариф абый» кебек истәлек һәм публицистик язмалары белән дә укучыларга яхшы таныш.

Бер-берсен яратышып кавышкан парның төрле тормыш сынауларына дучар ителгән мәхәббәт тарихын чын сәнгатьчә матур, бизәкле тел белән һәм психологик тирәнлектә тасвирлаган «Тулгак» повесте Гөлчәчәк Галиевага аеруча популярлык китерә.

2003 елда әдибәнең «Тулгак» әсәрен һәм бүгенге җәмгыятьтәге кешеләр арасында барган астыртын көрәшнең нигезендә акча, байлык, комсызлык ятуын һәм шуңа бәйле булган төрле бозыклык, әхлаксызлык күренешләрен фаш иткән «Өзелгән өмет» исемле яңа повестен, хикәяләрен, мәкаләләрен, истәлек язмаларын үз эченә алган икенче китабы басылып чыга.

Г.Галиева – 2001 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Ул 2014 елның 11 маенда Казан шәһәрендә вафат була, туган авылы зиратында җирләнә.

## ГАКЫЙЛЬ СӘГЫЙРЕВ

*(1938-2009)*



Гакыйль Шәрифулла улы Сәгыйрев 1938 елның 15 февралендә Татарстанның Октябрь районы (1997 елдан Нурлат районы) Әхмәт авылында колхозчы гаиләсендә туа. Ватан сугышы башлануның икенче көнендә үк, аның әтисе Шәрифулла фронтка китә һәм 1941 елның көзендә Смоленск шәһәре тирәсендә барган каты сугышларда хәбәрсез югала. Гакыйль әнисе Хәбибҗамал кулында тәрбияләнеп үсә. Үз авылларында башлангыч мәктәпне тәмамлаганнан соң, ул 5-6нчы сыйныфларда укуын күрше Биккол авылына йөреп дәвам иттерә. Ләкин авырып китүе сәбәпле, алтынчы сыйныфны аңа бу авылда төгәлләргә насыйп булмый. 1951 елда әнисе Хәбибҗамал, ике баласын ияртеп, үзенең туган якларына – Самара өлкәсенең Кошки районы Иске Фәйзулла авылына күченеп кайта. Биредә җидееллык мәктәпне тәмамлагач, рәссам булырга хыялланган Гакыйль Пенза шәһәрендәге сәнгать мәктәбенә китәргә дип җыенганда гына, умыртка сөяген имгәтүдән аяк-куллары хәлсезләнә башлап, сәнгать мәктәбе урынына табиблар юлламасы белән Самара шәһәрендәге хастаханәгә барып эләгә. Дәвалаулар уңай нәтиҗә бирми, 1957 елда операция ясауның да файдасы тими, Гакыйль аяк-кул хәрәкәтләре бик нык чикләнгән урын өсте авыруына әйләнеп кала.

Бөтенләй урын өстендә ята башлагач, Гакыйль күп итеп китаплар укырга, кайчан булса да кирәге чыгар әле дип, күңеленә килгән уй-фикерләрне кәгазьгә теркәп барырга тырыша. Куллары эшләмәсә дә, карандашны яисә ручканы тешләренә кыстырып язарга өйрәнә.

Гакыйль Сәгыйревнең беренче шигырьләре 1960 елда район үзәге – Нурлат шәһәрендә нәшер ителә торган «Дуслык» газетасында дөнья күрә. Озакламый Казандагы газета-журналларда да исеме күренә башлый, «Социалистик Татарстан» (хәзерге «Ватаным Татарстан») газетасында яшь шагыйрь турында зур язма басыла, журналист Луиза Хәйруллина Лениногорск телевидениесеннән аңа багышланган зур тапшыру оештыра, шагыйрьнең бер бәйләм шигырьләре «Беренче карлыгачлар» дигән күмәк җыентыкка (1968) урнаштырыла, ә 1970 елда Татарстан китап нәшриятында «Тормыш җиле» исеме белән беренче мөстәкыйль китабы басылып чыга. «Айбагарлар» дип аталган икенче китабы исә 1983 елда Татарстан Язучылар берлегенең Ш.Маннур исемендәге әдәби премиягә лаек була. 1994 елда Татарстан китап нәшрияты әдипнең сайланма әсәрләр төсендә төзелгән зур гына тупланмасын («Кабатланмас моң») укучыларга тәкъдим итә. Шул җыентыкны тулаем рус теленә тәрҗемә итеп, татарча оригиналлары янәшәсенә русча тәрҗемәләрен урнаштырып һәм авторның үз рәсемнәре белән бизәп, Самара шәһәрендә уникаль китабы дөньяга чыга.

Димитровград (Мәләкәс) шәһәре дә шагыйрь иҗатына битараф калмый: «Ике кояш» дип аталган күләмле җыентыгын укучыларга бүләк итә.

Рәсем сәнгатендәге уңышлары өчен Г.Сәгыйрев 1999 елда Халыкара «Филантроп» оешмасы бүләгенә лаек була. Мөмкинлекләре чикләнгәннәргә ярдәм күрсәтү оешмасы игълан иткән бәйгедә (анда дөньяның 62 төбәгеннән бер мең инвалид катнаша) Г.Сәгыйрев график рәсемнәре белән җиңү яулый. Ул шулай ук Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе дә (2001).

Г.Сәгыйрев – 1993 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Ул 2009 елның 29 июлендә Ульяновск өлкәсе Димитровград (Мәләкәс) шәһәрендә вафат була.

---

* Сәхифә «Әдипләребез: биобиблиографик белешмәлек» (төзүчеләре: Р.Даутов, Р.Рахмани. – Казан: Татар. кит.нәшр., 2009) китабы нигезендә әзерләнде.

# ЫШАНЫЧЛЫ ИЛӘК

***Пароль кебек гади, кыска һәм күп мәгънәле сүз ул – «Исәнмесез!» Казанда гына түгел, җиһанның теләсә кайсы кала-саласында очраткан, эшең төшкән, аралашкан кешеләрнең кайсы милләттән икәнен беләсең килсә, шулай сәлам бир. Гадәттә, каршы тараф елмаеп яки исе китмичә җавап бирә, кемдер, аңламамышка сабышып, битараф кына узып китә...***

***Кешенең табигате шундый инде: җавап кайтармаганнар күбрәк istә кала. Әлеге очракта нечкә билләрне исәпкә алып тормыйк. Чөнки алар таныш түгел ир-егетләрнең сәлам бирүен танышырга, сүз башларга сылтау эзләү дип кенә бәяли. Яшел тышлы китап: очраган һәр кешегә сәлам бир, дип әйтсә дә, бу юлы туташларыбыз хаклыдыр – бәйләнергә теләгән әрсез алабайлар азмыни?! Тукай турындагы хатирәләрдә кечкенә Апушның берәүгә: исереккә сәлам бирмә, биргән сәламен алма, дип белдергәне дә күңелгә уелып калган. Бүген бөтенләй башка очракларны, танылган кешеләр белән очрашу мизгелләрен хәтердә яңартып утырам.***

***

Төркиядә уздырылган бер халыкара җыенда күренекле кыргыз әдибе Чыңгыз Айтматовны күреп алгач, газетабыз өчен интервью алу теләге туган иде. Тик атаклы язучының ялгызын гына туры китерү бик кыен. Янәшәсендә һаман кеше, һаман нәрсәдер хакында гәп куерталар. Бүлдерүе читен. Беркөнне тәки форсат чыкты. Кичке аштан соң, әкрен генә атлап, каршыма килүче Чыңгыз әфәндене күреп алдым. Араларыбыз якынаюга: «Исәнмесез!» – дип сәлам бирергә ашыктым... Әфәндебез берни ишетмәгән-аңламагандай янымнан узып китте. Мин бу хәлне агаебызның анасы Нәгыймә апабыз теленә мөнәсәбәте икән дип, алга таба аралашу теләгеннән ваз кичтем.

Легендар биюче Рудольф Нуриев белән әңгәмә оештырырга җыенганда да, шундыйрак хәл килеп чыкты. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында тантаналы ыгы-зыгы иде ул көннәрдә. Менә тырыша-тырмаша эчкә, сәхнә артына үттем. Ничек тә Нуриевтан интервью алырга, каләмдәшләремне шаккатырырга исәп. Бирим дигән колына, чыгарып куяр юлына дигәндәй, коридорда үзе каршыма килеп чыкты. Тар гына аралыкта икебездән башка кеше шәйләнми. Рудольф әфәнде каядыр ашыкмый да кебек. Мөмкин кадәр шат-бәхетле (очрату шатлыгыннан) күренергә тырышып: «Исәнмесез!» – дип дәштем. Янә шул хәл кабатланды. Берни күрмәгән, ишетмәгән шикелле, бу янымнан узып китте.

«Бәхетле булсын!» – дип, үземчә саубуллашудан башка чара калмады.

***

Соңгы очрак әле бер-ике ай элек кенә башкалабыздагы «Корстон» күңел ачу-тамаша бинасында булды. Меңләп кеше катнашачак зур җыелыш башланырга санаулы гына минутлар калган. Шөкер, җитештем, дип, әкрен генә икенче катка күтәреләм. Өске яктан, баскычтан, зур гына түрә төшеп килә. Ике-өч адым калышып, артыннан ярдәмчеләреме, тән сакчыларымы ияргән. Йөзгә-йөз диярлек очрашу бу. Күзенә туры карап: «Исәнмесез!» – дидем. Ул мине беләдер, таныйдыр дип тә уйламыйм. Һәрхәлдә татар кешесе икәнлегемне, бу җыелышка очраклы гына эләккән зат булмавымны аңлый бит инде. Дәшми. Пыяла күзләрен өстемнән шудыртып үтә дә юлын дәвам итә. Сайланучылар исемлегендә күрсәм, мин беркайчан да бу адәмне яклап тавыш бирмәм, танышларымны да каршы тавыш бирергә үгетләр идем. Беренче Президентыбызны да, икенчесен дә шулай сынаганым – «Исәнмесез!» иләгеннән үткәргәнем бар. Шөкер, Ходай Тәгалә аларның күңелләренә – иман, туган телебезгә мәхәббәт салган. Кызганыч, кайберәүләр шуннан мәхрүм калган. Андыйларны йомшак, затлы кәнәфиләрдән ераграк тотсаң иде, Раббым!

**Рәшит МИНҺАҖ**

*(Дәвамы киләсе санда)*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Сергей МИХАЛКОВтан**

## Гимн авторлары

Советлар Союзы Гимны сүзләрен һәм музыкасын язарга бәйге игълан ителгәч, дистәләрчә шагыйрьләр арасыннан нәкъ менә шушы ике шагыйрь – Сергей Михалков белән Эль-Регистан (Уреклян) бергә язган сүзләр Политбюро әгъзаларының күңеленә хуш килә. Баштагы нөсхәсендә аның «Нас вырастил Сталин – избранник народа», дигән юллар да була. Шагыйрьләрне парлап Кремльгә чакырталар. Менә шул текстның кайбер юлларын үзгәртергә, өстәмә бер куплет язарга тәкъдим итәләр.

Бервакыт Сергей Михалковны фронтта чакта командующийга чакырталар. Бик ашыгыч рәвештә Ворошиловка чылтыратырга кирәк икән. Тоташтыралар. «Иптәш Сталин белергә кушты: икенче куплетның икенче юлында тыныш билгесен алыштырырга мөмкинме?» – ди К.Ворошилов.

Ә инде Гимн кабул ителеп, Зур театрда башкарылганнан соң, партия һәм дәүләт җитәкчеләрен кунак бүлмәсенә чакыралар. Өстәл башында Сталин бер ягына – Михалковны, икенче ягына Эль-Регистанны утырта.

– Нинди милләттән Сез? – дип сорый Сталин Эль-Регистаннан.

– Әрмән.

– Ә нигә Эль-Регистан? Кемгә буйсынасыз, мөфтигәме, католикоскамы?

– Католикоска, иптәш Сталин.

– Ә мин мөфтигә дип уйлаган идем.

Шуннан соң Эль-Регистан, рөхсәт сорап, тост әйтергә баса:

– Мин безнең белән Гимн сүзләрен камилләштерүдә ярдәм иткән кешеләр – иптәш Ворошилов, иптәш Молотов һәм тагын иптәш Сталин хөрмәтенә тост күтәрергә тәкъдим итәм, – ди.

Щербаков кырыс кына әйтеп куя:

– Менә кемнән башларга иде сүзне...

Акланырга тотынган Эль-Регистанны бүлдереп, Сталин шәһадәт бармагын күтәрә:

– Реплика мөмкинме? – ди. – Чеховның бер купец турында хикәясе бар. Храм төзелешенә иң күп акчаны ул бирә, ә газетада аны исемлекнең иң азагына куеп чыгаралар. Купец үпкәли. Мин купец түгел... дәвам итегез, иптәш Регистан.

Тост арты тост әйтелә, бокаллар күтәрелә тора. Сталин тагын, Михалков ягына борылып:

– Һәр тосттан соң төбенә кадәр эчү мәҗбүри түгел, алайса Сезнең белән сөйләшү кызыксыз булачак. Кыенсынмагыз. Без нахалларны яратмыйбыз, кыюсызларны да өнәмибез.

Бераздан Сталин янә, Михалковка борылып:

– Сез тотлыгып сөйләшәсез икән. Молотов та шулай иде, мин әйткәч, тотлыкмый башлады, – ди.

**Аршак ТЕР-МАРКАРЬЯН**

## Тау Мөхәммәд янына килмәсә...

Никита Хрущёв АКШка визиты вакытында үзе белән бер төркем журналистларны һәм язучылардан бердәнбер Михаил Шолоховны ала. Мактанасы килеп, Кеннедига болай ди:

– Без синең белән ике бөек держава башлыклары. Менә безнең арада атаклы

язучы Михаил Шолохов бар. Сезнең Хемингуэй белән безнең Шолоховны якыннан таныштырырга иде бит, – ди.

– Бик шәп булыр иде дә ... гафу итәсез, минем хакимлек иҗат кешеләренә кагылмый шул, – ди Кеннеди. Үз илендә чикләнмәгән хакимлеккә күнеккән Хрущёв аптырап кала, әмма барыбер сүзен-сүз итә:

– Үткен күзле егетләреңнән таптырып китерт үзен, – ди.

Күпмедер вакыттан соң Ак йорттан шундый хәбәр алына: Кубада яшәп яткан Хемингуэй болай дигән, имеш: «АКШ Президентыннан башка да рәхәтләнеп рус язучысы белән виски эчә алам. Тик хәзергә вакытым тыгыз чак, өстәл янында язып утырам...»

Америкадан әйләнеп кайткannan соң, бу сәфәрдә катнашкан ун журналист һәм дә Шолоховка Ленин премиясе бирелә. Шолохов Мәскәү Кремленә бүләк бирү тантанасына: «Мондый футбол командасында катнаша алмыйм», дип бармый кала.

Атаклы Дон казагы яшәгән Вёшенская станицасына Илбашының үзенә барырга туры килә.

**ҮЗЕ**

## Димәк...

Партия өлкә комитетының беренче секретаре Фикрәт Табеев гаҗәеп оста оратор иде. («Оратор» сүзе, Батулла әйтүенчә, «Өрә тор» сүзеннән чыккан). Бигрәк тә ул язучы-әдипләр каршында чыгыш ясаганда, җәелеп китеп,әдәбият теориясенә кереп батып, соңында исә җиңеп чыккан сыман, үз-үзен ышандыра ала иде. Мәһабәт гәүдәсе белән трибуна артыннан калкынып, бармагын түшәмгә пистолет итеп төбәп, «Почему?!» дип, сүзеннән туктап калган чакта... «У» авазы, бармак очыннан атылып чыгып, түшәмгә бәрелә дә... дәһшәтле пауза урнаша. Шул мәлдә кайбер мүкләк язучыларның, Гамил Афзал әйтмешли, «җаны үкчәсенә китә».

Табеев, гадәтенчә, Нурихан Фәттах исемен телгә алмыйча калмый иде. Моның күптәнге сәбәбе бар. Кайчандыр ул Нурихан Фәттахны кабинетына китертергә ниятләп, машинасын җибәрткән. Казан читендәге Чыңгыз посёлогында үз кулы белән төзегән йортта яшәгән Нурихан ага: «Йомышы булса, Табеев үзе килсен!» – дип, «Волга»ны капка төбеннән борып җибәргән. Республиканың хан дәрәҗәсендәге хуҗасы моны бик авыр кичергән күрәсең.

Әдәбият әһелләре белән очрашуда ул тагын: «Нурихан Фәттах залда бармы?» – дип сорады. Җыелышларны җене сөймәгән Нурихан ага, әлбәттә, юк иде.

– Язучылар – сәер халык бит, – дип сүзен башлады Табеев. – Университетта укыган чактан ук якыннан беләм мин Нурихaнны. Тулай торакта без бер бүлмәдә дүрт егет тату гына яшәдек. Арабызда бердәнбер Нурихан, тумбочкасына йозак асып, гел бикта тота иде...

Шул мәлдә, залга бик яңгыратмыйча гына, Батулла әйтеп куйды:

– Димәк, бүлмәдәшләр арасында карак булган...

## Юклыктан туган үтенеч

Язучы Нәби Дәүли, Кремльгә килеп, халык телендә «президент» дип йөртелгән Салих Гыйлемхан улы Батыев (ТАССРның Югары Советы президиумы рәисе) кабинетына керүгә ирешә. Яңа фатир алуын, яңа мебель кирәклеген, аны беркайдан да табып булмавын әйтеп, ярдәм итүен үтенә.

– Мин бит мебель фабрикасының да, мебель магазинының да хуҗасы түгел, – ди Батыев. Нәби Дәүли, үпкәләбрәк, үз дәверендә иптәш Сталинның Шолоховка ничек ярдәм итүе хакында сөйләп ала. Батыев, өстәл артыннан чыгып, янәшәсенә килеп, язучының иңеннән кочып:

– Их, Нәби ага! Әгәр сез – Шолохов булып, мин – Сталин булсам, ярдәм итмәс идеммени Сезгә?! – дигән.

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

## КАЗАНГА В.ПУТИН КИЛДЕ

Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин ике көн республикабызда булды. 24 гыйнварда мөселман дин әһелләре белән очрашты. 25 гыйнварда КФУда студентлар белән аралашты, Горбунов исемендәге авиация заводында берсе-берсе 15 миллиард сумнан артык 10 очкыч җитештереләчәген әйтте, «Татнефть» ТАНЕКО комплексын югары бәяләде.

## КОЛЛЕГИЯ УТЫРЫШЫ

Г.Тукай исемендәге Татарстан дәүләт филармониясе залында ТР Мәдәният министрлыгының 2017 елда башкарган эш-гамәлләренә йомгак ясалды. Анда ТР мәдәният министры Айрат Сибагатуллин хисап тотты. Аннары Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының идарә башлыгы урынбасары Е.Сергеева, ТР Дәүләт Советының Мәдәният, мәгариф, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев, Кукмара муниципаль районы башкарма комитеты рәисенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Р.Галиева, сәнгатьне үстерү буенча «Sforzando» фонды рәисе Д.Соколов һ.бның чыгышлары тыңланды. Гәрчә былтыр бу тармакны үстерү өчен тотылган чыгымнар 2016 елныкы белән чагыштырганда 1,2 миллиард сумга кимрәк булса да, чыгышларда министрлык тарафыннан башкарылган байтак эш-гамәлләргә югары бәя бирелде. Коллегия утырышына ТР Премьер-министры Алексей Песошин йомгак ясады, бер төркем сәнгатькәрләребезгә һәм мәдәният хезмәткәрләренә мактаулы исемнәр бирү турында дипломнар һәм хөкүмәт бүләкләрен тапшырды.

***

Узган ел Татарстанда 96 яңа массакүләм матбугат чарасы теркәлгән. 2018 елның гыйнварында «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең 87 сайтына тәүлегенә 134 мең 400ләп кеше кергән. Бу 2017 ел күрсәткече белән чагыштырганда, 56 процентка артык. 141 редакциянең социаль челтәрләрдә 300ләп аккаунты бар. Республикада 4 миллион 100 мең кеше стационар һәм мобиль интернеттан файдалана. Шул хакта коллегия утырышында «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм республика агентлыгы җитәкчесе Айрат Зарипов хәбәр итте. Утырышта Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе Әсгать Сәфәров матбугат вәкилләре алдында март аенда булачак Россия Президентын сайлауны киң яктырту бурычын куйды. Быел республикада Лев Толстой елы игълан ителүен дә, тарихчы, галим, мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 200 ел тулуын да искәртте. Коллегия утырышында матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Федераль агентлык җитәкчесе Михаил Сеславинский да катнашты һәм чыгыш ясады.

## МӘРҖАНИНЕ ИСКӘ АЛУ

Бер төркем дин әһелләре, районнардан имам-хатыйблар, дини уку йортлары шәкертләре мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин җитәкчелегендә Шиһабетдин Мәрҗанинең Яңа Бистә зиратындагы каберен зиярәт кылды, аның рухына дога багышлады. ТР Милли музеенда «Мәрҗани һәм аның мирасы» дигән күргәзмә ачылды. Анда 90лап экспонат, шул исәптән Мәрҗанинең сандыгын, дивар сәгатен, урындыкларын, диванын, китапларын, документларын күрергә мөмкин. Киләчәктә Казанда Мәрҗанигә һәйкәл кую күздә тотыла.

## ДӘҮЛӘТ БҮЛӘКЛӘРЕНӘ ТӘКЪДИМНӘР КАБУЛ ИТЕЛӘ

Татарстан Президенты карамагындагы Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе буенча комиссиясе 2018 елда премиягә дәгъва итү өчен эшләр һәм әсәрләр күрсәтү турындагы тәкъдимнәр кабул итә башлады. Югары бүләккә дәгъва кылучылар гаризаларын 2018 елның 15 февраленә кадәр тапшырырга тиеш. Татарстан министрлыклары һәм идарә тармаклары, шулай ук мәдәният һәм сәнгать учреждениеләре үзләренең тәкъдимнәрен Татарстан Мәдәният министрлыгы аша, предприятиеләр, фәнни учреждениеләр, югары уку йортлары, җәмгать берләшмәләре – тәкъдим ителгән хезмәтләрнең һәм әсәрләрнең асылына туры килгән юнәлешләр буенча, Татарстан Республикасының иҗат берлекләре аша кертә.

Шушы көннәрдә «Тантана-2018» театраль премиясенә гаризалар кабул ителә башлады. «Тантана» – профессиональ премия, ул театр

сәнгате өлкәсендәге иҗади казанышлар өчен тапшырыла. Премиягә дәүләти, муниципаль һәм шәхси театрлар дәгъва итә ала. Бүләккә тәкъдим ителәсе спектакльләрнең премьералары 2017 елның 1 февраленнән 2018 елның 1 феврале аралыгында булырга тиеш. «Тантана» премиясе лауреатлары 27 мартта Камал театры сәхнәсеннән игълан ителәчәк.

## ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕНДӘ

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы булды. Аны берлек рәисе Данил Салихов алып барды. Рәис урынбасары Рәмис Аймәт ике утырыш арасында башкарылган эшкә хисап тотты. 2018 елга юбилейләр планы расланды.

Язучылар берлеге идарәсе 2018 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә кандидатлар тәкъдим итте. Алты кеше арасыннан Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан «Игезәкләр йолдызлыгы» һәм «Карурманда кара песи» китаплары өчен прозаик Камил Кәримов узды. Утырышта катнашкан 24 кешедән 18е аны яклап тавыш бирде. Идарә әгъзалары шулай ук Рәниф Шәриповны – Гаяз Исхакый, Рифат Җамалны – Һади Такташ, Фирүзә Җамалетдинованы – Фатих Хөсни, Рифә Рахманны Җамал Вәлиди исемендәге әдәби премияләргә тәкъдим итте.

Утырышта Раушан Шәриф белән Ольга Иванова Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителде.

## КИТАП ТӘКЪДИМ ИТҮ

Мәскәүнең ГУЛАГ тарихы музеенда Татарстанның халык язучысы Аяз Гыйләҗевнең рус теленә тәрҗемә ителгән «Ягез, бер дога» («Давайте, помолимся») китабын тәкъдим итү кичәсе булып узды. Наил Ишмөхәммәтов тәрҗемә иткән бу китапны Мәскәү зыялыларына Казаннан килгән кунаклар – язучының уллары Искәндәр һәм Мансур Гыйләҗевләр, КФУ доценты Миләүшә Хәбетдинова тәкъдим итте.

## ШӘЙХИ МАННУР БӘЙРӘМЕ

Мамадыш районында күренекле татар әдибе Шәйхи Маннурның туган көненә багышланган Шигырь бәйрәме үткәрелде, аның исемендәге премиянең яңа лауреатлары игълан ителде.

Бәйрәмгә Казаннан Шәйхи Маннурның мирас комиссиясе рәисе, язучы һәм публицист Шаһинур Мостафин, шагыйрь һәм галим Рифат Җамал; Чаллы Язучылар оешмасы җитәкчесе Факил Сафин, «Мәйдан» журналының баш мөхәррире Фидаил Мәҗитов, язучы Мансур Сафин һ.б. килгән иде. Шигъри сабантуй Шәйхи аганың Мамадыштагы һәйкәле янында әдипне искә алу, чәчәкләр салу белән башланды. Анныры Ш.Маннур исемендәге премиянең быелгы лауреатларын бүләкләү композитор Яруллиннар исемендәге сәнгать мәктәбендә дәвам итте.

Мамадыш районы традицияләренә, гореф-гадәтләренә һәм атамаларына багышланган фәнни хезмәте өчен, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты өлкән фәнни хезмәткәре, филология фәннәре кандидаты Гүзәлия Хаҗиева-Демирбаш; 2015-2016 елларда дөнья күргән «Я вам пишу», «Родина моя», «Счастливое детство», «Карусель» һ.б. китаплары өчен Юлия Аполонова; «Иң зур бәхет – хезмәттә», «Туган авылым Акманым», «Комазан башы – чишмә башы», «Дүсмәтем – гомер бишегем», «Чал тарихлы Комазаным» тарихи-публицистик китаплары өчен Гөлфинур Дувалова; яшь буынга патриотик тәрбия бирүгә керткән хезмәтләре өчен, туган якны өйрәнү музее коллективы (директоры – Светлана Ишпахтина) быелгы лауреатлар булды.

Шагыйрьнең каберен зиярәт кылганнан соң, күңелле очрашулар Тулбай авылында – әдипнең үз акчасына салдырган музей-китапханәдә дәвам итте.

## БӘЙГЕ

Баулыда, Татарстанның халык шагыйре Фәнис Яруллинның тууына 80 ел тулу уңаеннан, шигырь уку бәйгесе булып узды. Анда мәктәпләрдән һәм балалар бакчаларыннан 20ләп бала катнашты. Бәйгедә Фәнис Яруллинның шигырьләре һәм поэмалары яңгырады.

## ХЕЗМӘТКӘ ХӨРМӘТ

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе өчен, язучы, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге (Иҗат берлеге) иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Әхмәдуллин Азат Гыйльмулла улына** ТР Президенты Рәхмәте белдерелде.

***

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм нәтиҗәле иҗади эшчәнлеге өчен, язучы, ТР Язучылар берлеге (Иҗат берлеге) иҗтимагый оешмасы әгъзасы **Харрасова Рифә Фәтхрахман кызына (Рифә Рахман)** «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исем бирелде.

***

ТР Фәннәр академиясенең эксперт комиссиясе карары белән, КФУның Л.Толстой исемендәге филология һәм мәдәниятара бәйләнешләр институты татар әдәбияты кафедрасы профессоры **Хатыйп Йосыф улы Миңнегулов** гуманитар фәннәр өлкәсендә Ш.Мәрҗани премиясенә лаек булды.

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: повести С.ШАМСИ «В этом доме я родился…», А.АХМЕТГАЛИЕВОЙ «Белые ичиги»; стихи Р.ФАЙЗУЛЛИНА, Ш.МУСТАФИНА, Г.БАЙРАМОВОЙ, Л.ГАЗИЗОВОЙ.*
*«Лучший рассказ»: Ф.ЗАМАЛЕТДИНОВА. «Упрямая».*
*«100-я страница»: М.ГАЛИЕВ. «Какая судьба ждёт нас?»*
*«80 лет со дня рождения Ф.Яруллина»: стихи Ф.ЯРУЛЛИНА (с предисловием Р.ГАТАША), статьи С.ХАКИМОВОЙ «О творчестве Фаниса Яруллина», Д.МИННЕКАЕВОЙ «Воспитательная сила драматургии Фаниса Яруллина», Н.ХАБИПОВА «Личность, сотворившая оду жизни».*
*«Из первой книги писателя»: рассказ Ф.ЯРУЛЛИНА «Мать приносит цветы» (с предисловием Р.ХАННАНОВА).*
*Статья Р.ЗАЙДУЛЛЫ, посвящённая 155-летию со дня рождения Г.Самитовой.*
*«140 лет со дня рождения Г.Исхаки»: И.ФАЗЛУТДИНОВ. «Эволюция героев Исхаки».*
*«110 лет со дня рождения Ф.Хусни»: И.ДИНДАРОВ. «Незабываемая встреча».*
*«Наши юбиляры»: статьи Р.БАТУЛЛЫ, посвящённая 90-летию Л.Закира, Л.МУХАМЕТЗЯНОВОЙ, посвящённая 85-летию Х.Махмутова, В.ИМАМОВА, посвящённая 70-летию Ш.Мустафина, Р.ШАРИПОВА, посвящённая творчеству Г.Байрамовой.*
*«Книжное обозрение»: рецензия Т.ГАЛИУЛЛИНА на книгу Р.Маннана «Мои любимые».*
*«Природа и я»: А.ГАРИПОВ. «Преданность лошадей».*
*«Воспоминания»: Г.ГАЛИЕВ. «Странички из жизни села Кырынды».*
*«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.*
*«Из записной книжки»: миниатюры Р.МИНГАЗА.*
*«Наш календарь»; «Из фотоархива журнала»; Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: Памятник Нурсие и Фанису Яруллиным в городе Бавлы (Автор – уроженец деревни Шалты Бавлинского района). Фото Вахита Имамова; Дом-музей Фаниса Яруллина в селе Кзыл-Яр.*

# IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: stories by S.SHAMSI «In this house I was born …», A.AKHMETGALIYEVA «White ichighi»; poems by R.FAYZULLIN, SH.MUSTAFIN, G.BAYRAMOVA, L.GAZIZOVA.*
*«Best story»: F.ZAMALETDINOVA. «Stubborn».*
*«100th page»: M.GALIEV. «What destiny is waiting for us?»*
*«80th anniversary of F.Yarullin»: poems by F.YARULLIN (with preface by R.GATASH), articles by S.KHAKIMOVA «About Fanis Yarullin's works», D.MINNEKAYEVA «The educational force of dramatic art by Fanis Yarullin», N.KHABIPOV «The personality who has created the ode of life».*
*«From the first book by the writer»: story by F.YARULLIN «Mother brings flowers» (with preface by R.KHANNANOV).*
*Article by R.ZAYDULLA devoted to the 155th anniversary G.Samitova.*
*«140th anniversary of G.Iskhaki»: I.FAZLUTDINOV. «Evolution of heroes by Iskhaki».*
*«110th anniversary of F.Khusni»: I.DINDAROV. «An unforgettable meeting».*
*«Our jubilees»: articles by R.BATULLA devoted to the 90th anniversary of L.Zakir, L.MUKHAMETZYANOVA devoted to the 85th anniversary by H.Makhmutov, V.IMAMOV devoted to the 70th anniversary of Sh.Mustafin, R.SHARIPOV devoted to G.Bayramova's works.*
*«Book review»: review by T.GALIULLIN on the book by R.Mannan «My darlings».*
*«Nature and I»: A.GARIPOV. «Devotion of horses».*
*«Memoirs»: G.GALIEV. «Pages of life of the Kyryndy village».*
*«Pages of humour»: heading is conducted by M.GALIEV.*
*«From the notebook»: miniatures by R.MINGAZA.*
*«Our calendar»; «From the magazine photoarchive»; Diary of social and cultural life.*
*On our covers: Monument to Nursiya and Fanis Yarullins in the city of Bavly (The author is the native of the Shalta village of the Bavly district). Photo by Vakhit Imamov; The house-museum of Fanis Yarullin in the village of Kzyl-Yar.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Баулы шәһәрендә Нурсөя һәм Фәнис Яруллиннарга куелган һәйкәл. Авторы – Баулы районы Шалты авылыннан Рәсим Шәрифуллин. *Вахит Имамов фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Баулы районы Кызылъяр авылында Фәнис Яруллинның музей-йорты. *(bavly.tatarstan.ru сайтыннан алынды).*